# КАЗАН УТЛАРЫ

5
МАЙ
1980



ИЛДАР ЮЗЕЕВ

КПСС өлкә комитетында һәм Татарстан АССР Министрлар Советында

# 1980 ЕЛ ӨЧЕН ТАТАРСТАН АССРның Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА



ВАСИЛ МАЛИКОВ

*Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы 1980 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен түбәндәге иптәшләргә бирү турында карар чыгардылар:*

*1. Юзеев Илдар Гафуровичка — шагыйрь, «Таш диварлар авазы», «Өзелмәс кыллар» поэмалары авторы.*

*2. Маликов Васил Маликовичка — скульптор, тарихи-революцион һәм хәрби-патриотик темаларга эшләнгән скульптура әсәрләре циклы («Чекист Н. Голубятников», «Соңгысы», «М. Җәлил») авторы.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

20

**5**

МАЙ
1980


## Бу санда

БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 35 ЕЛЛЫГЫНА


**Ә. МАЛИКОВ.** Юлым синдә туктар. Шигырь . . 3
**Р. ӘХМӘТҖАНОВ.** Ирләр юк. Шигырь . . . . 4
**Р. ГӘРӘЙ.** Туган авылымның туксан батыры. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . 4
**Д. СИРАЙ.** 1418 көн. Шигырь . . . . . . . . . 5
**Р. ГАТАУЛЛИН.** Германия. Шигырь . . . . . . . 5
**Н. ӘХМӘДИЕВ.** Солдат хатлары. Шигырь . . . 6
**С. БАТТАЛ.** Ярдан очып... Шигырьләр . . . . 7
**М. МӘҺДИЕВ.** Ут чәчәге. Повесть . . . . . . 8

**Н. АРСЛАНОВ.** Язгы таңда. Шигырьләр . . . . 61
**Г. АХУНОВ.** Йолдызлар калка. Повесть . . . . 67
**Ф. ЯРУЛЛИН.** Күңел күзем. Шигырьләр . . . . 107
**Ш. РӘКЫЙПОВ.** Комбат истәлеге. Чын хикәя . . 110
**Д. ВӘЛИЕВ.** Портрет. Хикәя . . . . . . . . 125


ТАТАРСТАН КУНАКЛАРЫ ҺӘМ ДУСЛАРЫ


**В. ОСКОЦКИЙ.** Бер сәяхәт турында. Юл язмалары . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
**С. САНБАЕВ.** Йөрәгемә кадерле яклар . . . . 144


ПУБЛИЦИСТИКА


**Х. ЗӘЙНУЛЛИН, З. ШӘФИГУЛЛИН.** Күңелләрдә Тукай моңнары . . . . . . . . . . . . . 149


ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ


**Г. ВОЛКОВ.** Татарстанның үз улы . . . . . . 155


ЯЗУЧЫНЫҢ ӘДӘБИ МИРАСЫННАН


**И. ГАЗИ.** Көндәлектән бер бит . . . . . . . 159

**С. ШАКИР.** Мәрмәргә уелган исем . . . . . 161
**Г. КАМАЛИЕВ.** Тәҗрибәле журналист, танылган шагыйрь иде ул . . . . . . . . . . . . . 164


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


**Ф. САФИУЛЛИНА.** Татар прозасында хикәяләү . 166



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Олы шагыйрь турында җитди хезмәт . . . . . . . . . . . . . . . 175

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Р. МИҢНУЛЛИН.** Йолдызлар. Шигырьләр . . . 178

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Ф. ШӘФИГУЛЛИН.** Кояшлы гөрләвекләр . . . 181
**Р. ВӘЛИЕВА.** Ленин туган көн. Шигырьләр . . . 182
**М. ВӘЛИЕВ.** Моң чишмәләрен эзләгәндә . . . 184

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**И. ӘХМӘТҖАНОВ.** Яшьлек һәм шигърият юлдашы . . . . . . . . . . . . . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова** (җаваплы секретарь), **Нил Юзиев, Сибгат Хәким, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

Производствога бирелде 23/I-1980 ел. Басарга кул куелды 28/IV-1980 ел. ПФ 09013. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 94.000 экз. Заказ У-44. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

Әдип Маликов

# ЮЛЫМ СИНДӘ ТУКТАР

Тормыш гизеп,
Бер җилләнеп кайту —
Үзе бер гомергә торырлык.
Корт шикелле,
Эчтән ашый җанны
Мещаннарча гамьсез торгынлык.

Дәшә мине погранзаставалар,
Уяу тора һаман постларым.
Танырмын да, танымам да сезне,
Яшел фуражкалы дусларым.

Җырларыбыз бара походларда,
Запастагы чинда торсак та.
Ленинчылар — җирдә бер армия,
Безнең урын, димәк, бер сафта.

«Иярчен»нәр — гүя күгәрченнәр,
Сибелгәннәр космос түренә.
Татарстан,
Якты калаларың
Космос аша миңа күренә.

Юл тотсам да кайда,
Озатып йөри
Туган якның шифа-җилләре.
Йомарланып күңел түрләрендә
Чәчәк ата назлы гөлләре.

Аерылганда синнән, туган ягым,
Юксынуым җырда чагылыр.
Урый торгач зәңгәр планетаны,
Юлым синдә туктар барыбер.

## Роберт Әхмәтҗанов

# ИРЛӘР ЮК

Офыкларга карап китте алар,
җырлый-җырлый минде үрләргә.
Яшь киленнәр әйтте: «Бу дөньяның
бөтен авырлыгы ирләргә!»

Атакадан исән-имин чыккач,
сөйләштеләр ирләр, — сабыр, нык:
«Ялгыз башка килсә — берни түгел,
хатыннарга — бөтен авырлык!..»

Авыр хәбәр килде. Шундый авыр...
(Үлчәр өчен андый герләр юк!)
Кырлар кипте. Туфрак орлык көтә.
Сөрелмәгән кырлар — ирләр юк.

Бу яудан да чыктык. Киләсендә
кемнәр бар да тагын, кемнәр — юк...
Кырлар тулып арыш сыгылып тора.
Җилләр коя тагын — ирләр юк...

Айга карап көтә сөйгән яры,
гүзәл ярлар сула — тиңнәр юк.
Сылуларга идиот кул салганда
сугып егар өчен — ирләр юк!

Бирмим дисәң әгәр ятка серне,
өметләрне акка биләрлек.
Сабыйлар да инде егет була,
ата булыр кеше — ирләр юк.

Ирләр булса — канат тигез була,
хәлләр имин була, илләр — нык...
Күпме еллар илләр имин. Әмма
чыгып киткән җирдән
ирләр юк...

## Рәшит Гәрәй

# ТУГАН АВЫЛЫМНЫҢ ТУКСАН БАТЫРЫ

Тугам авылымның туксан батыры
Ятып калган сугыш кырында.
Җирне иңләп, якты истәлекләр
Йөри бүген алар турында.

Кук йөзендә кояш янган чакта
Исемнәре калмас онытылып:
Һәйкәл булып авыл уртасына
Баскан алар иңгә-иң торып.

Соры шинель киеп өсләренә
Сафта бара алар һаман да.
Гомерләре — якты маяк сыман,
Нурын сибә килер заманга.

Туган авылымның туксан батыры
Исәннәрнең күңел түрендә.
— Уяу булыгыз,— дип, ил улларын
Кисәтәләр алар бүген дә.

## Дифгат Сирай

# 1418 КӨН

Бер мең дүрт йөз унсигез көн,
Бер мең дүрт йөз унсигез төн
Тетрәп торды җирләр көн-төн,
Күкрәп торды күкләр көн-төн,
Коеп торды өстебезгә
Бер өзлексез ут яңгыры:
Янды шәһәр,
Авыл белән
Янды бергә иген кыры.
Янды йөрәк!
Күкрәкләрдә
Үч ялкыны күтәрелде.
Өермәдәй соңыннан Берлин
Урамына бәреп керде.
Һәм ул ялкын байрак булып
Балкып рейхстагка менде.
... Бер мең дүрт йөз унсигез көн,
Бер мең дүрт йөз унсигез төн
Көттек бары бер көнне без—
Җиңү көнен!
Килде ул Көн!

## Рәшит Гатауллин

# ГЕРМАНИЯ

Бик ерактан килгән уйларыммы,
Нәрсә тартты мине бирегә?
Юлларыннан үтеп Европаның
Килеп җиттем менә Берлинга.

Трептов-парк. Ак каеннар үсә.
Каеннарның башы иелгән.
Алар елый... Алсу гөлләр елый...
Күпме солдат монда күмелгән.
Ак ташларда алтын язулар бар,
Таш җәелгән юллар тап-такыр.
Һәйкәл булып гүя җир астыннан
Бала тотып чыккан яшь батыр
Карап тора Берлин иртәсенә.
Карашында ныклык, тынычлык.
Бала йоклый солдат күкрәгендә,
Ә бер кулда һаман кылычы.

Германия!
Дары мичкәсеме,
Маркс җире, Гейне илеме?
Яуда үлгән солдат улын сиңа,
Мине — сиңа юллар китерде.
Европаның уртасында торам,
Ноктасында торам сугышның.
Туфрагыңа каен яше тама,
Колагымда дөнья сулышы.
Гаҗәпсенеп карыйм...
Озак еллар
Үзәкләрне микән өзгәнгә.
Германия...
Беләм, кешелек тә
Яхшы якка таба үзгәрә.

## Нур Әхмәдиев

# СОЛДАТ ХАТЛАРЫ

Саубуллаштылар...
Исендә һаман:
— Җиңеп кайтырбыз! — дигән антлары.
Җиңү дә килде, тик үзе генә,
Тик үзе генә кире кайтмады.

Юксыналар да туган яклары,
Таңнар барыбер алдан атмады.
Ядкаре булып бер улы калды
Һәм калды тагын язган хатлары.

Шушы хатларны укыды кат-кат,
Һәрбер сүзенә кадәр ятлады.
Йокысыз күпме төннең шаһиты —
Күз яше сеңгән солдат хатлары.

Ничә ел буе борчып йөрделәр
Ишеккә килеп әрсез ятлары.
Тугры калырга көч бирде аңа
Мәхәббәт тулы солдат хатлары.

Булды аның да бу тол язмыштан
Боегып башын игән чаклары...
— Горур бул, җаным! — дип дәшә һәрчак
Саргаеп беткән солдат хатлары.

## Салих Баттал

•

Ярдан очып менеп китәм
Владивосток күгенә;
офык тәрилкәсе тулы
Тын океан күренә.

Шул кадәр таныш күренеш...
Калдырмый бар сырларын,
күзне йомып сыза алам
мин бу океан ярын.

Турысын әйтим, туйдырдың
Бөек Петр заливы!
Тагын күпме өсләреңдә
очар Баттал Салихы!

Әнә, якын чик артында
дошман күтәргән кылыч.
Ә мин синең калканыңмын, —
калкан астында тыныч.

Кизәнгән дошман иреклe:
сугу минутын сайлый.
Калкан ирексез, өзлексез
сугудан сине саклый...

... Бу интектергеч бурычны
тик алмашчыма биреп
кайтканда очу — ял миңа,
тәмам аламын ирек.

Тагын җиргә иркәләнеп,
сыйпанып очыйм әле;
канат — колачларны җәеп,
офыкны кочыйм әле!

Ни кадәрле куркынычлы
булса борылышларым,
шулкадәрле иркенәеп
китәдер сулышларым!

•

Мин киттем, хуш, Владивосток,
онытылмаслык кала!
Йолдызларың мине озатып
рельсәгә егылып кала.

Керсәм, — туңган тәрәзәле
вагоным дөп-дөп атлап
адаштырырга илтә күк
мине, күземне каплап.

Рельсәләрнең дөпелдәвен
туктаусыз тыңлап барам;
тыңлап йоклыйм, тыңлап торам,
кушылып җырлап алам.

Көн саен аның тавышы
тагын моңлырак чыга;
көн саен ярты сәгатькә
кояш соңрак чыга...

Владивосток! Синдә калды
дүрт еллык уяу төнем,
илгә тәэмин итәр өчен
бер Бөек Җиңү көнен.

*1945*

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# УТ ЧӘЧӘГЕ

ПОВЕСТЬ

## XVII

Су буенда дымлы үлән, бакча киртәләре исе иде. Өч яктан өч чишмәнең тавышы ишетелә. Монысы, тыкрык астындагысы — гомер буе суын эчкән чишмә нәкъ элеккечә.

— Чур-р-р...

Әнә тегендә, түбән очтарак көчле чишмә: анысы ярның биек җиреннән улакка бәреп чыга да, шаулап, богырдап төшә, вак ташларны зыркылдатып, болгатып тәгәрәтә. Менә бик кечкенәсе — Гали чишмәсе — анысы самавар борыныннан аккан кебек кенә, аның тавышын тегеләре баса. Әмма су буендагы хорда аның да тавышы бар. Чишмәләр тавышына җылы сулы буадан бака сайраганы кушыла. Бакалар бүген нигәдер кычкырмыйлар, сайрыйлар гына. Ата бака шулай кыланамы? Әллә ана бака мутланамы? Тамак төбен генә дөрелдәтеп, берничә урыннан дүрт-биш бака трель чәчәләр:

— Ра-а-а-а... Ра-а-а-а

Бу тавыш, бу моң бары тик Симетбашта гына. Мондый тавышлы, мондый трельле бакалар Германиядә юк, Австриядә юк. Сайрагыз, авылдашлар, сайрагыз.

Менә Һадилар бакчасы. Асафлар кечкенә вакытта тау киртләченә урнашкан бу бакчада багана умарталар, тагын әллә ниләр бар иде. Бакча башында зирекләр томылып утыра, бакчаның киртә баганалары урынына да үсеп утырган тал-зирек иде, бер төп кара чыршы бар, ул чыршының башына ел саен карга оялый, малайлар менеп аның йомыркаларын урлыйлар. Һади карт малайларны куа, «кош каргышы төшсә, башыгыз бетәр» дип өркетә иде. Асафның яшьтәшләреннән бу авылда җиде малай иде, шуларның алтысын бу сугышта «кош каргышы» алып китте... Карга йомыркасын ул да ала иде, югыйсә.

Хәзер инде теге чыршы юк икән, күрәсең, сугыш вакытында утынга кискәннәр. Ә балан калган...

Һадилар, гомумән, кызык кешеләр иде. Аларда гына, бары тик аларда гына, корт чаккач «бүре уы» була торган кешеләрне имләр

[1] Ахыры. Башы дүртенче санда.

өчен бүре койрыгы бар иде. Бары тик аларның келәт астында гына сасы көзән яши, авылдан бары тик Һади абзый гына урманга комган белән кура җиләгенә бара һәм шуны тутырып алып кайта иде. Һади абзый хатынының сеңлесе Ташкичүдә кияүдә, һәм бу ике туган көн аралаш бер-берсенең хәлен белеп торалар иде. Кышмы, буранмы, янгырмы, алар чана, арба тартып бер-берсенә ни дә булса алып киләләр иде. Бер карыйсың, Ташкичүдән кул чанасы белән ярты кочак печән тартып, сеңлесе килә; икенче карыйсың — Симетбаштан кул арбасына бер чиләк утырту бәрәңгесе, мунча миллеге салган апасы Ташкичүгә төшеп бара. Ни гаҗәп — Һади абзыйларның тау башындагы йортларында төннең теләсә кайсы вакытында ут сүнми һәм кышкы буранлы төннәрдә Симетбашка кайткан кешеләр авылдан беренче итеп әнә шул утны күрәләр һәм адашып йөргән кешеләр иртәгесен сөйлиләр иде:

— Шуннан соң... Йөри торгач... Бервакыт эчкә җылы керде: Һади тәрәзәсен чослап алдым...

Бу — гадәти хәл иде.

Һади абзыйның житкән кызы Гөлбикә бар иде, Гөлбикә мунчага кереп киткәч яшүсмерләр караңгы төндә су буендагы мунчаның тәрәзәсе янына җыелып, бер-берсенең башларын этешеп, кечкенә тәрәзә янында юеш җирдә яталар иде. Гөлбикә җәйге кичләрен фермадан кайткач, тау астындагы чишмәгә төшеп битен, кулларын юа да, алсу эчке күлмәктән генә калып тау өстендәге койма буенда эскәмиядә гәүдәсен кочаклап ял итеп утыра иде. Аның яныннан узганда ул оялган сыман итеп тартыла, әмма матур ак беләкләрен, тырпаеп торган мул күкрәген, аксыл-алсу тиреле юан ботларын эчке күлмәк барыбер каплап бетерә алмый иде һәм эштән кайтышлый чишмә яныннан узучы егетләр, ирләр аңа карап сөртенәләр, әллә нинди ялгыш сүзләр әйтеп бетерәләр, тотлыгалар иде.

Һади абзый сугыш вакытында үлгән, Гөлбикә язылып читкә китеп барган икән...

Асаф аларның су буендагы бакчаларына таба атлады.

Якын килсә — балан чәчәк аткан икән. Юк, мондый гади матурлыкны Асаф бер җирдә дә күрмәде. Германиянең бомба төшмичә исән калган купшы бакчаларында, Австриянең көяз паркларында, тынынны буарлык хуш ис бәреп торган каштан аллеяларында йөрде, әмма Һадилар бакчасы башындагы таралып үскән балан оясындагы кадәр матурлыкны беркайчан да күрә алмады.

Балан куагы үзенең чынаяк тәлинкәсе зурлыгындагы түгәрәк ак зонтларын кичке караңгылыкка җәйгән дә, чишмәләр, бакалар белән сөйләшә иде. Караңгы төшкән булса да, түгәрәк куак өстенә таралып сибелгән бу чынаяклар яктылык биреп торалар иде. Нечкә хуш ис борынны кытыклады, бу ис үпкә юлларын ярып, канга тарала иде. Су буе чишмәләр, бакалар моңын тыңлый-тыңлый кичке дымга бүрткән, күперенгән, бөтен тәнгә ислемай сөрткән сыман иде.

Бераздан тыкрыклардан кызлар чыркылдаганы ишетелде. Андасанда аксыл киемле төркемнәр күренде, кайдадыр гармун тарттылар, су буена төштеләр. Асаф кешеләр янына килде. Яшьтәш кызлар, олыраклар кыю гына килеп күрештеләр, ул югында калкып чыкканнары бер читтә әдәп саклап тордылар. Ирләр затыннан бер әү дә юк дип әйтерсең, сугыш барган арада егерме сигезенче, егерме тугызынчы елгылар калкып чыккан икән. Шәп кенә егетләр булып үсеп киләләр, кыю сөйләшәләр.

— Нихәл, Асаф абый, әйбәт кенә йөреп кайттыңмы? — дип килеп, тәмәке кабызалар. Арадан берсе, кепкасын басыбрак кигәне, килеп җәһәт кенә кулын бирде:

— Яшьти, нихәл, ару гына кайттыңмы?

Асаф кичке караңгылыкка елмайды. «Яшьти»не танып алды. Бу — Бибижамал түтинең егерме тугызынчы елгы улы, көтүче Гафур иде. Әйдә, яшьти икән яшьти...

Аннан түгәрәк уены башланды. Асаф игътибар итте: сугышка кадәр бу чирәмлеккә түгәрәк уен барганда илле-алтмыш егет-кыз була һәм түгәрәк зурга киткәч, ике катлыйлар һәм кызык булсын өчен, ике якка әйләнәләр иде. Уенга барысы да керә, читтә бала-чага гына йөгерешеп йөри иде. Ә бүген! Ник бер генә егет булсын! Бөтенесе егерме сигезенче, егерме тугызынчы, утызынчы елгы малай-шалай, Кызлар белән уйнауның, кызларның кайнар кулын тотып, сөйләшмичә генә аңлашуның рәтен алар каян белсен! Хәер, Асафка да авылда әллә ни эләкмәде, шулай да Ташлытауда укыганда болынга төшеп, кызлар белән түгәрәк уены аз уйнамадылар. Бүген уенда кызлар — ябык, тузган-таушалган киемнән, сугыш авырлыгын кичкән, инде олаеп бара торган кызлар һәм Асаф исемнәрен белмәгән быел калыккан яшүсмерләр... Таныш тавыш җыр башлады. Васиlә икән. Егерме өченче елгы. Әйе, Галимҗан — карга оясын туздырганда һәрчак атаман булган Галимҗан — сугышта ятып калды. Инде Василә тонык, карлыккан тавыш белән җырлый.

> Су буйларына төшмәдем.
> Сулар сачерәтмәдем.
> Гомеремә китәр инде,
> Бәгърем, хәсерәтләрең.

Бу ятим уенны карап тору авыр иде. Менә ике кыз килеп Асафны уенга чакырдылар. Керергәме, юкмы? Авылдагы бөтен яшьтәшләрең кырылып беткәннән соң чирәмле су буенда кызлар белән бергә җырлап йөрергәме? Кермәсәң, кызлар үпкәләмәсме? Синең бу түгәрәккә керүеңнән кемгә кызык? Син бу авылда бер кызны да озата кайтмадың, бер кызның да, капка төбендә кочагыңа алып, кайнар сулышың катыш сүзләр белән күңелен җилкендермәдең... Син үз гомереңдә нибары бер кызны белдең, ә ул монда юк инде... Уртага кергән бер кызга җырлап бирделәр:

> Озын-озын, озын итеп
> Үстергәнсең буеңны.
> Утызынчы елгыларга
> Салып йөрмә уеңны.

— Эх, была — не была! — диде Асаф һәм чакыра килгән кызларның кулларын тотып, түгәрәккә басты да, җайга атлап китте.

Ул кайтканда әнисе ятмаган иде әле. Өстәл өстендә календарь битләре белән капланган ике стакан сөт тора, әнисе почмак якта нәрсәдер тугылый, иртәгесенгә коймак-фәлән изә булса кирәк.

Өйалдында ут яндырылган, кечкенә урындык янында ләгән белән су һәм сөлге куелган иде.

— Юк, әни, ишегалдына чыгып юам,— дип Асаф хром итекләрен салып ишегалдына чыгып китте. Чыкса — чикерткәле, чыклы, тавык үләне исле бер гаҗәеп төн иде. Асаф җылы суга аякларын тыкты. Я дөнья! Адәм баласы үз гомерендә нинди шартларда гына булмый! Дөньяда менә болай да яшәп була икән. Җылы су, аяк сөлгесе, чыклы тавык үләне... Минме бу? Өнме бу, төшме бу?

Өйалдында чыбылдык белән томаланган бер карават тора иде, Асаф шул карават янына урындык куеп, гимнастеркасын, каешын элде. Өйалдын төнге үлән исе баскан иде.

— Чү, улым, анысы кеше урыны, — диде ана.

— Кем урыны тагын?

— Кем дип, теге балакайныкы.

— Нинди балакай тагын?

— Нинди дип... Әйттем ич, ялга кайтып йөри дип. Аның поезы бик җайсыз. Төнлә генә уза разъездан. Төнге икеләрдә генә килеп җитә инде ул. Аңа да җайсыз. Ял саен кайтып йөрүе, дим. Нәчәльник кызы. Әтиләре сугышка бармаган. Финнекендә чулакланып кайткан. Заготзерно мөдире.

— Соң, мин кайда ятам әле болай булгач?

— Сиңа өйдә җәелгән. Әнә түрдә.

— Ә юк, әни. Мин алайса, корт өенә китим. Өйдә ничек йоклыйсың? Мичең ягылган, мунча кебек.

— Соң, ишекне ачып куярбыз.

— Анысын япма инде син аның. Үзең өчен дә кислород кирәк булыр.

— Корт өендә каз утыра шул, улым. Быел соңга калды. Идәнен дә юмаган, кыштан чыккан көе.

— Я, аңа баш ватмыйбыз, әни. Менә монда алып чыгабыз да җәябез.

— Бик каты булыр бит?

— И-их, әни... Дүрт ел буе мин йоклаган урыннарны күрсәң иде син. Иң йомшак урын, беләсеңме, нәрсә? Җир. Бозлымы, карлымы, черәмлеме — үз җирең. Иң катысы нинди, беләсеңме? Миналы җир. Мина ул шундый шартлаткыч — утызар тонналы танкларны җимереп ташлый. Каты җир — әнә шул миналар яшерелгән җир.

Урынны өйалдының түренә — калайлы зур яшел сандык өстенә җәйделәр дә, аяк очларына урындык куйдылар.

— Мягкая плацкарта булды бу, әни, — диде Асаф, юрган астында рәхәтлек белән киерелеп.

— Ярар, балам, әйбәт йокла. Әтәч кенә иртә уяна инде безнең...

Асаф көлде:

— И-и әни! Бомбежка вакытында да йоклап була бер ияләнгәч. Ә син әтәч, дисең. Сугыш узган кешене бернинди тавыш белән дә уята алмыйсың син. Өйалдына ник трактор белән килеп кермиләр шунда...

Фатыйма апа лампаны өреп сүндерде, бисмиллясын әйтеп өйгә кереп китте. Кире чыгып сөйләп алды.

— Крәчиң мае быел гына иркен кайта. Сугыш елларында жик күрдек. Гел сукыр лампа. Өф итсәң, сүнәргә тора. Бибиҗамал түтиеңнең Гафуры гел шаяра икән. Сукыр лампы янына килә дә: «Өфедәге мөфти абзый вафат булган» ди икән. Сүнми калмый ди.

«Яшьти» дип хәтерләп елмаеп куйды Асаф.

Биш минут үттеме — юкмы, өйалдында җиңелчә ыңгырашкан, гырлаган тавыш ишетелде. Үз нигезенә кайтып башын төрткән солдат, тигез ритм белән сулап, уяткысыз йокыга талган иде. Әйе, ник тракторың белән килеп кермисең монда.

Әмма егет бераз гына ялгышкан булып чыкты. Трактор мәсьәләсендә.

Аны җиңел генә шышдыртаган тавыш уятты. Күзләрен ачты, өйалдына марля чыбылдык артындагы чолан тәрәзәсеннән саран яктылык үтеп керә иде. Беравык аңышмый торды. Кай төш бу? Госпиталь! Алай дисәң, нигә карават пружинасы шыгырдамый? Анда аз гына кыймылдасаң да, карават бөтен системасы белән җавап авазы бирә иде. Кай төш бу? Вагонмы? Туктап торабызмы? Ә теге яктылык кайдан? Фу-у, шайтан, нәрсә соң бу?

Аны әтәч тавышы гына айнытты.

Әтәч нык ышаныч белән, бу ишегалдындагы бөтен тавык халкы өстеннән хакимлек итүенең хаклы икәнлеген раслаган тавыш белән кычкырды. Аннан «у-у-у» килеп куйды.

— Несчастный монарх... Культ,— дип йокы аралаш мыгырданып алды Асаф, йокысы бүленгәнгә ачуы килеп. Әмма егет бу юлы да ялгыша иде. Аны әтәч уятмаган булып чыкты. Ул юрганыннан башын чыгарып чыбылдык ягына текәлебрәк карады. Тәрәзәдән төшкән яктылыкны чыбылдык артында бер күләгә каплый иде. Асаф тәмам айныды: күләгә чишенә иде... Менә ул ялангач кулларын күтәреп чәч артына үрелде, менә ул авызына нәрсәләрдер капты да, кулларын баш артына куеп төйнәлеп җыелган чәч толымын сүтә башлады. Авыр толымнар тавышы ишетелде. Менә авыр толымнар ласылдап аның аркасына төшеп салындылар. Бу — әлеге төн кошы — квартирантка кыз бит! Әнисе бала итеп сөйләгән иде, монда буй җиткән кыз басып тора түгелме соң? Юктыр, баладыр, бала булмаса марля чыбылдыкның бик ышанычсыз икәнен белергә тиеш иде. Алай дисәң... Яшь сын тәрәзәгә яны белән басты. Юк, бала түгел. Гәүдәсенең җыеласы урыннары әчкә җыелган, алга яки артка таба калкасы урыннары матур йомры түгәрәкләр булып, озын, зифа буйны бизәгәннәр иде. Менә, менә, кызый таза тәненнән «шерт-шерт» итеп ниндидер моңарчы киерелеп-тартылып торган сәдәфләрне ычкындырды, култык асларыннан, җилкәләреннән нидер аралап алды да, карават башына элде. Моны карап яту күңел котырткыч караклык, исерткеч бер хыянәт сыман иде, әмма Асаф шундук үзенә аклану өчен нигез тапты: ул бит чыбылдык янына килеп ярыктан карамый. Ул йоклый иде, аны уяттылар. Аның ни гаебе бар? Әтәч уяттымы аны? Юк, аны, мөгаен ефәк әчке күлмәккә салмак салынып төшкән толымнар авазы уятты. Менә, менә... Юк, монысы инде гадәттән тыш иде. Менә... Зифа сын кулларын төшерде һәм акрын гына итәкләрен күтәреп билене меңгерде. Авыр ефәкнең таза, тыгыз гәүдәдән ышкыла-ышкыла өскә таба шуганы ишетелде. Бер генә секундка сын яны белән басты. Саран яктылык фонында ярым ялангач гәүдәсенең бөтен сызыклары беленеп сихри бер шәүлә тудырган һәм шул шәүләдән каплап куйган чынаяк чокыры кебек алга таба ыргылган шома калкулыклар яшәргә, тышка чыгарга омтылып бөтен дөньяга чакыру ташлыйлар сыман иде. Матур сын шундук өстенә тоташ бер нәрсә киеп куйды да, юрган астына чумды. Яшь гәүдәнең татлы киерелеп әйләнеп ятканы аңлашылды: ефәккә чорналган гәүдә юрган белән төренгәндә чыга торган тавыш ишетелде. Бу тавышны дүрт ел буе ут эчендә йөргән, үлемнең каршысына барган, борыны белән җир сөргән, кар астында йоклаган, айлар буе госпитальдә аңсыз яткан, дүрт ел буена бер генә тапкыр да хатын-кыз кулы тотып карамаган яшь ир генә ишетә, кабул итә ала иде.

Әйе, ул тавышны бөтен кеше дә тотып ала алмый иде.

Яктырганчы Асаф ләззәтле газап эчендә ятты. Чыбылдык артыннан җиткән кыз балаларда гына була торган әдәпле сулау — «мес-мес» иткән ритмлы сулау тавышы ишетелеп торды.

Йокы качты. Мактанчык әтәч колгасын селкетеп, канатларын шапылдатты да, тагын шәрран ярды. Аңа кушылып башка әтәчләр аваз салды.

Урамнан берәү таза, гырылдык тавыш белән җырлап узды.

Әйдә киттек Чиләбегә,
Ничу монда чиләнергә;
Чиләбедә кызлар беткәч,
Кайтырбыз өйләнергә.

Бу, әлбәттә, «яшьти» иде.

Хәзер иң яхшысы торып чыгарга да, бакчада йөрергә, чишмә буена төшәргә дип уйлады Асаф.

## XVIII

Беренче төн узуга Асаф военкоматка «явиться» итәргә китте. Бу сүзнең гомер-гомергә татарчасы булмады, ахрысы, авыл халкы бу сүзгә һәрвакыт дәүләткүләм эчке мәгънә салып, курку катыш ихтирам белән, шулай да зур сүз итеп үзенчә «җәвится итү» дип сөйли иде. Соңгы көнне шулай ук учеттан төшеп кайтырга туры килде.

Шунысы кызык, үз өйләрендә торган квартирантка кыз белән Асаф ничә көннәр буе йөзгә-йөз очраша алмады. «Җәвится»дән ул соң кайтты, военкомат коридорында үзенең таныш егетен, теге елларда тулай торакта бергә яшәгән, хәзер инде күкрәгенә өч Дан ордены таккан старшина — Шәрәф Солтановны очратты. Кочаклаштылар, көлештеләр, сөенештеләр. Аннан үз гомерләрендә беренче тапкыр Ташлытау ресторанына керделәр. Хәзер, озак еллар узгач, Асаф һаман әле баш вата: коньякның йөз граммы нәкъ ике йөз илле сигез тәңкә идеме, әллә литрымы?

Старшина бөтенләйгә кайткан икән. Яшь, таза, елдам егет. Кыза калдылар, сабакташларны искә төшерделәр.

— Их, син, лейтенант, — дип башын аска иде старшина. (Бүген алар бер-берсенә исем белән дәшмәделәр.) — Их, син. Беләсеңме, безнең ике класс малайларыннан без ничәү калдык? Юкмы? Синең белән өчәү. Өчәү — понял? Унҗиде малайдан. Кеше күзенә, аларның ата-аналары күзенә күренергә оят.

Асаф та кызган иде, авыр сулады.

— Габделнур да исән, димәк — дүртәү.

— Ә, кстати, сез бергә идегез бит аның белән. Дөресме? Значит, унҗидедән — дүрт.

— Әйе, наступлениегә кучкәнче бергә булдык. Бер переплетка эләккән идек, шунда аерылдык.

— Ул кайда хәзер? Чего-то неладный әйберләр сөйләделәр аның турында...

Асаф сискәнеп китте.

— Кем сөйли? Нигә? Габделнур минем взводта иде, миннән узып, аның турында беркем, берни сөйли алмый.

Шәрәф трофей сигарасы кабызды. Көнбагыш мае, кыздырган трескаңың зәңгәр төтене тулы залга затлы ис чыкты, әмма теге төтенне җиңә алмады.

— Мин подробностьларын белмим, — диде Шәрәф, стаканын кулында әйләндереп, — но инде миңа сөйләгәннәре дөрес булса — позор, честное слово, позор.

Асаф тагын сискәнеп куйды. Габделнурның теге вакытта сугыш кырыннан качуын белүче кеше бу дөньяда ул гына, бары тик ул гына иде.

— Нәрсә булган соң? — диде ул, тынычлык сакларга тырышып.

— Апа сөйләде. Габделнур кыш көне госпитальдән өйләнеп кайткан. Ташлытауга туктап эш эзләгәннәр, икесенә дә. Шунда безнең апага очрап, сөйләшеп, кунарга калганнар. И ты, понимаешь? Кичен хатынын апа янында калдырып, киенеп чыгып киткән бу. Чемоданыннан лейтенантский погоннар алып таккан бу, понял? Лейтенантские! Барган клубка. Кызлар очрамасмы, дескать, сабакташлар. Шунда, кем беләндер сүзгә килгәннәр. Скандал чыккан. Шунда кемдер ычкындырган: офицер түгел бу, самозванец. Арадан берсе чәчрәп чыккан: менә минем документ, мин НКВДдан, күрсәт офицерская книжкаңны дип. Ике кеше белән безнең апаларга кайтканнар. Хәзер утыртабыз, или бер литрлык юнәтәсең дип үзгенә үткәннәр. Хатыны кычкырып елаган. Погоннарын үз кулы белән йолкып алган, тегеләргә ялынган. Чемодан төбеннән ике йөз тәңкә акча алып, тегеләрне чак озаткан.

Апа тегеләрнең берсен таныган: нинди НКВД булсын, сугыш вакытында тегеләй итеп, болай итеп хәйлә белән калды, спекуляция белән шөгыльләнде ди. Милициядә завхоз ди — мин аны беләм, жулик ул.

Шәрәф явыз сүгенде.

— Их-х, автомат очерете белән кырып йөрер идем шул гадларны,— диде. — Ну, инде Габделнур да... Хикмәт званиедә мени? Менә минем кайтканыма ике көн, урамда очраган офицерлар имәнеп китеп, үзләре миңа честь бирәләр. Өч орден, алты медаль бар минем. Хикмәт погонда мени...

Асаф үзен тыйды, әмма тege вакыйганы сөйләмәде. Шәрәф белән алар аерылышканда кич житкән, ресторан каршындагы агач рәшәткәләргә бәйләнгән атның клеверы инде беткән, ат рәшәткә башын кимерә, ак күлмәк жиңнәрен сызганган Гафур кызу-кызу тәмәке суыра иде.

— Әйдә, яшьти, утыр, — диде, ул арбадагы брезентны рәтләп, — Фатыйма апа әйткән иде: очратсаң утыртып алып кайт дип...

Туган якның күгенә карап, брезентка ятып озак кайттылар. Кичке жылы жил йөгерә, ул авыллардан сыер исе, кырдан уҗым исен куалап йөртә иде. Бер урында туктап люцерна чабып алдылар да, арбага түшәделәр.

Гафур гел егетләр-кызлар темасына гына сөйләде. Белмәссең, әллә яшен киметеп йөри, әллә, чыннан да, сугыш вакыты иркенлекләреннән файдалана белгән егет. Сугыш елларында кем ничек булган, аулак өйдә кем янында кем кунган, кайсы хатын кем белән гөнаһка кергән — барысын белә. Асаф әллә тыңлый аны, әллә тыңламый, яңа калкып чыга башлаган йолдызларга текәлеп арбада дырылдап кайта. Аулак өй... Алай икән. Ә мина кырындагы теге гарасат кайда? Фәлән хатын фәлән кеше белән гөнаһка кергән...

Ә алты ай госпитальдә яту кайда? Шуның өч аен аңсыз-телсез-авызсыз яту кайда? Асаф командалык иткән взводның Сухиничи янында шартлаткан танкылары кайда? Эх, Гафур, Гафур, энекәш, миңа «яшьти» булырга, беләсеңме, күпме кирәк әле сиңа.

Соң гына кайтып кергән улының хәлен ана тиз аңлады: өй алдында дагалы итек тавышлары кичәгедән катырак чыкты, гимнастеркадагы орден-медальләр кичәгедән ныграк чылдырады, уфылдаган, аһылдаган тавышлар чыкты.

— Шәрәф дус белән очраштык, берни ашыйсым килми, әни, — дип Асаф тиз-тиз чишенә башлады. Өйгә кереп юынгыч янында озак маташты, авызын чайкады, әнисе әзерләп куйган ләгәндә аякларын юды. Аннан өйалдына чыгып кичәге урынына чумды, әнисе өйдәге утны сүндереп, өйалды белән ике арадагы ишекне ачып куйды, ишеккә эленгән марля пәрдәне тартты. Өйалдына тулган чиклы чирәм исенә солдат итеге, каеш, фуражка, одеколон исе таралды, бу — ирсез йорт өчен кадерле, кыйммәтле ис иде, бу — иминлек, бөтенлек, хуҗалыкның түгәрәклеге билгесе иде.

Өйалдын тиздән буйдак егетләргә хас гырлау авазы алды.

Госпитальдән савыгып чыккан Асафның мәңгелек бер чире калды: авызына аз гына эчемлек керсә дә, төн урталары узгач саташа башлый һәм кычкырып уяна иде. Һәрвакыт бер төш, бер саташу: өскә танклар килә. Һәрвакыт бер хәл: кулда ни граната, ни танкка каршы ата торган мылтык юк. Һәрвакыт үзе генә. Һәр саташуында ул кычкыра. Бүген дә шулай булды.

Фатыйма апа иртүк торып, кояш чыкканчы ук мунча ягарга тиеш иде. Авылда янгынга каршы кагыйдәләр бик каты куелган, коры вакыт, шуңа күрә мунчаны көтү куганчы томалап куялар да, теләгәнчә, көннең теләсә кайсы вакытында керәләр иде. Кичтән үк Фатыйма апа иске будильникны икедә уяутуга көйләп куйды һәм шуның уйнаганын

көтеп йокысы йокы булмады. Сәгатьнең кинәт ычкынып китүенә йөрәк селкенә торган гадәте бар. Менә, менә тиздән. Әмма Фатыйма апа йоклап китте.

— Гранату! Гранату!

Мондый көчле тавышның бу йортта беренче ишетелүе иде, карчык сискәнеп торды. Тавыш өйалдында икән.

— Гады! Сволочи! У-ух...

Карчык өйалдына йөгереп чыкты, улы яткан җиргә килде, улының маңгаена кулын куйды: маңгае тирле иде.

— Чү, чү, улым. Бисмиллаһирахман иррәхим. Чү, улым.

Улы исә дер-дер килә һәм тешен шыгырдата иде. Күпмедер вакыттан уянды, әллә ничек кенә, сәер генә итеп әнисеннән вакытны сорады. Аннан су сорады. Әнисе өйалдындагы кисмәктән су алып килгәндә өйдә сәгать уйнап җибәрде.

Ана шунда гына улы сөйләмәгән нәрсәләрне аңлады: өч ай хәбәрсез ятуының чын сәбәбен әйтеп бетермәгән икән бала. Алай икән. Балакай больницаларда әнә шулайрак яткан булырга тиеш...

Әнисе мунча ягарга чыгып киткәндә яктылык беленә башлаган иде. Асаф аңгы-миңге баш белән торды, кисмәктән су эчте. Кисмәк яныннан узып барганда кинәт исенә төште. Юк, исенә төшмәде, күзенә чалынды: марля чыбылдык эчендә адәм баласы — житкән кыз йоклап ята иде. Я инде, язмыш нигә гел сыныйсың? Күпме кыз баланы җирләргә яки гомерен саклап калырга туры килде сугышта? Берәү бар иде — Ык буеннан килгән санитарка. Күпме солдат, күпме офицер аңа үзенең сугыш вакытындагы хисләргә бай йөрәген тәкъдим итмәде. Асаф та җае килгәндә аңа үзенең җылы хисләрен сиздермәде түгел. Сылуны хәтерләтә иде. Ялгыз очрашып татарча сөйләшкәндә Ык буе халыкларына гына хас көй белән бер-ике сүз әйтми калмый, шул як халкына гына хас бер елмаю чыгармый калмый иде йөзенә. Күпме кеше аңа «заход» ясап карады — санитарка бирешмәде. Кул озайткан кыюларга үзе кул озайтты: кемнең яңагына сукты, кемнең кулына. Солдатлар буш минутларда аһ орып сөйләшәләр иде: ну бу Зина (чын исеме Зәһинә) үзен саклый инде... Һөҗүм вакытында үлеп калса, нинди байлык әрәм була. Ә бит фашист пулясы аралап тормый — кемгә тияргә, кемгә тимәскә. Бу да нәкъ безнең шикелле бер әләгә инде. Напрасно. Зрә үзен кызгана. Ичмаса, бер кешегә йөрәген ачсын иде. Безгә булмаса, әнә лейтенант Рәимовка. Без нәрсә, без — гади, ә лейтенант хатын-кызның көен белә кебек. Хатын-кыз бит ул — песи кебек. Җай ярата, йомшак сүз ярата.

Зина исә бер җайга да килмәде.

Соңгы тапкыр Асаф аның белән Сухиничи янындагы каты артобстрел вакытында очрашты. Безнең танклар прорыв ясар, пехота күтәрелер алдыннан иде бу. Һөҗүмгә күтәрелергә команда көтеп яткан вакыт иде, дошман артиллериясе шахмат тәртибендә снаряд сала башлады. Беркем беркемгә ярдәм итә алмый, ут тукталмыйча башны да күтәрергә мөмкинлек юк, исән калыр өчен дә бер чара да күрерлек түгел, тиз-тиз генә казылган окоп сыман балчык өеменә борын белән сеңеп, җиргә ябышып яткан вакыт иде. Снарядлар гел якынга төште — җир селкенеп торды. Ничәдер секундлык тынлык арасында Асаф авызын балчыктан чыгарып, як-якка карады. Якында җиргә сеңеп, куллары белән үләнгә ябышып яткан солдат — Зәһинә икән. Менә тагын җир селкенде, бик якында гына снаряд шартлап күккә балчык багана күтәрде, аннан тагын... Тынлык арасында шыбырдап күктән балчык яуды. Асаф шунда игътибар итте: җир гөрселдәгән саен Зәһинә чытырдатып үләнгә ябыша, гәүдәсе дер-дер килә иде. Күпмедер вакыт узды, дошман ягыннан ут тынды, шунда баш өстеннән безнең

артдивизонның снарядлары сызгырып уза башлады, безнең танклар кузгалды.

Ике сәгатькә якын барган гарасаттан соң немецлар кечкенә поселокны ташлап чыгып киттеләр, кичкә таба бригада штабы поселок үзәгендәге ике катлы кызыл кирпеч пекарняга килеп урнашты. Яралыларны, үлекләрне җыю башланды. Асаф үзенең взводы белән моннан ике сәгать элек кенә ут сызыгы булган кырга чыкты. Анда-санда носилкалар белән яралыларны ташыйлар, мәетләрне җыялар иде. Мәетләр өстенә инде яшел чебеннәр утырган, кичке тымызык һавада кан, дары, янган ит исе таралган иде. Поселокка керә торган олы юл читендә кулларын җәеп, күккә карап тынсыз яткан солдат гәүдәсен табып алдылар: Зәһинә икән. Снаряд кыйпылчыгы аның бот төбенә эләккән дә, актарып ташлаган. Ул әллә ничек кенә шунда, ике кулын җәйгән дә күк йөзенә күзләрен терәгән, күзләре кара пыяла булып каткан, бер аягы бөтенләй гәүдәсенә перпендикуляр булып каерылып ташланган иде. Күпме солдат, офицер күмәргә туры килде Асафка дүрт ел буена, һәр очракта авыр иде, әмма күңел каты була иде — монда исә аеруча газаплы булды, кызның гәүдәсен носилкага салганда ул әле суынып та бетмәгән иде, җитмәсә ефрейтор Лукин белән күтәргәндә кызның башы носилкадан чыгып читкә авышты да, авызыннан ыңгырашу тавышы чыкты. Бу — таныш иде, үлгән кешенең үпкәсе кысылганда кайвакыт авызыннан тавыш чыгарганын Асаф белә иде, әмма монда авыр булды. Гүя Зәһинә:

— Их, сез, егетләр, мине саклый алмадыгыз, ә үзегез исән, — дип боларга үпкәли иде.

Бүген — беренче июнь иртәсендә, сугыш беткән беренче тыныч җәйдә, үз йортының өйалдында кинәт кенә Асафның хәтеренә әнә шул табигать баласы — үзе теләп фронтка киткән һәм күпме-күпме ир-ат арасында үз намусын туган җирне саклаган кебек үҗәтлек, турылык белән саклаган гүзәл кыз Зәһинә искә төште. Җирне дә, үз намусын да саклап үлде бичара. Аның турында ротада беркем, бернинди гайбәт сүзе әйтә алмады. Әй, сез, дөньядан пакь киткән кызлар! Сезнең исемегезне буыннар онытмасын өчен без ни эшләргә тиеш соң? Әйтегез безгә! Әйт безгә син, сеңел...

Асаф әле дә айнып җитмәгән иде. Урыныннан торып, чалбарын, майкасын киде дә, туп-туры чыбылдык артына үтте.

— Ике көн бер йортта яшибез, безгә танышырга вакыт, — диде ул ясалма батыр тавыш белән. — Яле, сеңелкәш, бу якка борылып битеңне күрсәт әле...

Кызый стенага битен борып яткан иде. Асаф килеп керүгә, аякларын җыйды, битенә юрганын тартты. Әмма арка ягыннан муен, җилкәләр ачык калды.

— Я, сеңел, яшь гомерләр ничек уза? — дип юри кычкырып сорады Асаф. Аннан кинәт кенә мендәргә таралган көнгырт чәч көлтәсен күреп алды. Мондый матурлыкны аның кайчандыр күргәне бар иде: таң, мендәр, чәч көлтәләре. Асаф кулын шул көлтә эченә чумдырды. Һәм шул мизгелдә аның башы әйләнеп китте. Башы әйләнүдән ул чайкалды да кинәт ауды. Әмма идәнгә түгел. Кызыйның караватына. Ауды да, ялангач кайнар җилкәсеннән үбеп алды. Кызый дәшмәде дә, борылмады да. Тик тагын да кечерәйде, җыелды. Үзе бер өзлексез дерелдәде. Битенә юрганны ничек китереп баскан булса, шулай калды.

Асаф исә шуннан артык берни дә әйтмәде, кызның кайнар йомшак җилкәсенә иреннәрен тидереп, күзләрен йомды, юрган өстеннән кызның гәүдәсен кочаклады. Гәүдә дер-дер килә иде. Зәһинә менә ни өчен искә төшкән икән. Ихтимал, кызый син торып йөри башлауга дерелдәргә тотынгандыр...

Асафка рәхәт, бик рәхәт иде. Ишек алдында әнисенең аяк тавышлары ишетелгәнче ул шулай ятты.

Тыныч елның тыныч иртәсе никадәр бай, никадәр киң күңелле...

## XIX



Кызның исеме Зәйтүнә икән. Зур күзле, коңгырт калын толымлы, төз озын аяклы, ап-ак тәнле бер кыз икән. Беренче июнь көнне көндез мәктәптән кайтты да, юл хәстәренә әзерләнә башлады. Җәйге ял биргәннәр, бүген, чемоданнары-китаплары белән бергә төяп алып китү өчен, әтисе «Студебеккер» җибәрәсе икән.

Асаф белән алар төшке чәй вакытында тагын очраштылар. Кыз үпкә катыш мөлаемлылык белән аңа карап алды: я инде, син, сугыш үткән кеше, дөнья күргән кеше, кыз баланың яткан караватына шулай рөхсәтсез килеп аварга ярыймыни? Минем тәнем үземнеке генә бит, аңа минем рөхсәттән башка беркемнең дә кагылырга хакы юк бит. Ә син нишләдең? Минем җилкәмне үптең. Оятсыз. Шулай ярыймыни. Миңа бит беркемнең кагылганы юк.

Бу караштан әнә шуларны аңлады Асаф.

Ләкин бу караштан башкасын да аңлап булыр иде кебек. Мәсәлән, болай: и син, батыр егет! Син нинди гүзәлсең, син атлап йөргәндә күкрәгеңдә чалтыр-чолтыр орден-медальләрең чыңлый. Син кайтып кергәннән бирле минем чытлы йокы күргәнем юк. Җитмәсә, безнең урыннар бер тирәгә туры килгән.

«Отпуск акчасы алдым, шул отпусканы билгеләп үтәргә кирәк», дип, кызый мәктәптән кайтышлый кибеткә кергән һәм кибеттә булган затлы ризыклардан иң югары маркалыларын алган иде. Болар — яшел борчак формасында эшләнгән «Драже» витаминны һәм мичкәдән чүмечләп сата торган кызыл аракы иде. Кайнар бәрәңге, чирәм ашап яшәгән тавыкларның агы ак, сарысы сары йомыркалары һәм стаканнарга салган кызыл эчемлек йортка бәйрәм төсен бирәләр иде. Асаф бер үзе эчеп утырды. Ара-тирә Зәйтүнә белән алар бер-берсенә карашып алалар, әмма кыенсыналар иде. Чөнки әле бер сүз дә сөйләшенмәгән, әйтелмәгән иде. Ул арада капка төбенә доңгыр-даңгыр килеп тимер машина килеп туктады, чыкырдап тимер ишек ачылганы, чыкырдап ябылганы ишетелде. Ачык тәрәзәдән бензин исе килеп керде. Зәйтүнә, сикереп торып, җыена башлады. Шофер — кызу канлы кеше булса кирәк, дөбер-шатыр килеп өйалдына үк узды. Аннан өйгә үк.

Киң монгол битле, шадра йөзле кеше икән. Гимнастеркадан. Өстәл янында утырган Асафны күргәч, каушауданмы, шаярыпмы, ялан башка честь бирде:

— Бывший водитель генерала Черняховского гвардии ефрейтор Саубанов...

Асаф торып, каршына килеп, аңа кулын бирде, Сәүбанов күңеле йомшап китеп, лейтенантның аркасыннан каккалады һәм өстәлгә күз ташлады. Яшькелт зур графинның эчендә марганцевка кебек бер сыеклык бар иде.

— Руль артында эчмим, лейтенант, гаеп итмәгез, — диде Сәүбанов. — Начальникның кызын алып китәргә килдем. Башка случайда мин әле уйлап карар идем. Елки-палки. Кайдан? Прибалтийскийда булдыңмы? Черняховскийның ничек үлгәнен беләсеңме?

Зәйтүнә путалы ак күлмәк, җыйнак кына үкчәсез туфлиләр кигән иде, ашык-пошык юлга әзерләнә башлады. Кирә-чыга йөргәндә аның күзләре берничә мәртәбә Асафның карашы белән очрашты, әмма берберсенә сүз кушарга аларның вакыты да булмады, җае да чыкмады. Ирләр сугыш турында сөйләшәләр иде. Сәүбанов чынаягын каплады, стенадагы сәгатькә карап алды.

— Кая суң, кайда ката, кайда тун дигәндәй, өлгерәсеңме, сеңелкәш? Минем бит әле бүген эш көне.

Зәйтүнә соңгы тапкыр керүендә Фатыйма апа белән саубуллашты. Карчык елап ук алды.

— И бала, беренче сентябрьгә кадәр ничек түзәрмен инде, үз кызым күк күргәнием, ияләнешеп беткән иек,— диде.

«Студебеккер» кузовына чемоданны Асаф урнаштырды. Әнисе капкадан чыгар-чыкмас тора, Сәүбанов кабина тәрәзәсеннән тузан сөртә иде. Машина артыннан әйләнеп узып, Асаф кызның каршына төште.

— Син, Зәйтүнә, минем өчен бик кадерле булган бер кызга ошагансың.

Кыз югалып калганнардан түгел икән.

— Кадерле кешегезгә миннән сәлам әйтегез.

— Юк, ул кеше хәзер юк инде.

— Сугышта үлдемени?

— Юк, мин үлеп ятканда, каядыр күчеп киткән дә, кияүгә чыккан.

— Алайса, менә мин дә күчеп китәм. Тик кияүгә чыгарга ашыкмыйм әле. Мин бит учительскийны гына тәмамладым. Быел читтән торып педагогическийга кердем.

— Ә кая күчәсең?

— РОНОда әйттеләр: өченче курсны бетереп кайтышыңа унъеллыкка күчерәбез диделәр.

— Ә кая?

— Әлегә әйтә алмыйм. Бәлки монда да калырмын әле. Үзебезнең лесхоз мәктәбенә дигәннәр иде.

— Адреслар алмашыйк, җәй өчен.

Асаф малайларча ялынулы караш белән мөлдерәтеп аңа текәлде. Кызның битенә кызгылт таплар йөгерде. Түбән карады. Ул арада чыкырдап кабина ишеге ябылды, Сәүбанов сигнал бирде.

— Минем адрес: яңасы... бер айдан мин шунда. — Асаф тотлыгатотлыга әйтте. — Хәтерләдеңме? Башта үзең яз, яме? Полевая почта.

Шофер газ бирде. Асаф әнисе янына килеп басты. Сәүбанов кабинадан башын чыгарып, бөтен битен тутырып елмайды:

— Гуд бай, лейтенант. Ауфвидерзеен, елки-моталки. Губа не дура, мин әйтәм, ха-ха-ха...

Машина кузгалган тирәдән пырылдап тавыклар сикерешеп очты. Урамда резина, бензин исе таралып калды.

## XX

Асафның «для дальнейшего прохождения службы» дип килгән часте — әле генә оешып килә икән. Асаф Рәимовны укытучы итеп билгеләделәр. Укытучылар барысы да фронттан, арада соры шинельләләр кара шинельледән күбрәк иде. Каралар башта сорылар белән кимсетебрәк, югарыданрак торып сөйләшмәкчеләр иде, офицерларның беренче җыелышыннан соң ук ул нәрсә бетте: «сорылар» кительләренә бөтен орден-медальләрен тагып килгәннәр иде. «Пехота», «Сухопутка» дип сөйләп йөргән «мариман»нар утны-суны кичкән соры шинельләр белән шул көнне дуслаштылар: сугыш гарасатын кем җирдә, кем күктә, кем суда күргән...

Май урталарында частьта чыгарылыш булды. Асаф, йөрәге кысылып, теге елның июнь төнен хәтерләде. Дөрес, монда шартлар башка иде. Плацта — оркестр. Офицерлар составы ак фуражкадан, кортиклар таккан. Матрослар строеның түбәсе ап-ак. Җил исә, ленталар лыпыр-лыпыр килә. Оркестр җир селкетеп марш уйный. Икенче ранг

капитаны Цветков уку тәмамлап бүген корабльләргә китүчеләрне тәбрикли.

Инде плац тирәсенә яшьләрне алырга килгән ямьшәйгән баш киемле, хикмәтле, серле, диңгез кичкән «бүреләр» җыелды. Бераздан перекличка башланды. Шул вакытта Асаф тамагына төер утырганны сизде. Үзе укыткан яшь таза егетләр белән аерылышу кыен, моңсу иде. Китүчеләр арасында укуны бик яхшы тәмамлап чыккан ике татар егете бар иде, җай табып, Асаф белән саубуллаштылар.

— Беренче увольнениедә үк сезнең янга киләбез, Асаф абый, — дип авылча авыз тутырып, үз итеп елмайдылар.

Авыр, моңсу булып калды.

Аннан җәй җитте, каштаннар чәчәк атты. Шәһәр урамнары бөтеркәләп җәелгән кызгылт ташлары, текә чүлмәк түбәле йортлары каштан яфраклары кыштырдавына, затлы яфрак исенә чумды. Кичләрен җылы һава каштан араларыннан чыгып, кисәк-кисәк булып биткә бәрелә, класс җитәкчеләре — сугыш узган диңгезчеләр барысы да ак мәрмәр бассейнлы бакчага җыелалар, увольнениегә чыкмаган көе генә, часть янында озаклап сөйләшеп утыралар иде. Сугыш беткәнгә әле бер генә ел, истәлекләр яңа, күңелләр тиз нечкәрә иде. Арада сугыш узган матрослар, старшиналар байтак, шулай да кичләрен «гражданка» турында түгел, күбрәк сугыш турында сөйлиләр, искә алалар иде. Юк, берәү дә диңгез өстен сагынмый, үлем куркынычы белән үткән елларны берәү дә сагынмый, әмма шул еллар турында сүз киткәндә барысының да күзләре дымлана, уйга калалар иде. Ник? Нигә алай? Беркем бернәрсә белми.

Төн. Инде йокы вакыты җитеп килә. Диңгездән җылы һава килеп, каштаннарга бәрелә, ул мендәр-мендәр булып очып йөри, тәнне рәхәтләндерә. Каштаннар астындагы челтәрле ак мәрмәр эскәмиядә сугыш узган офицерлар, матрослар утыра, тәмәке тарталар.

Өеннән сугышка кадәр үк чыгып киткән беренче статья старшинасы Здесенко гитарада уйный, башын артка чөеп акрын гына җырлый.

Помнишь, друг, военные походы,
Дни боев и ночи под Москвой;
Черноморских штормов непогоды
И свинцовый дождь над головой.

Җырны тагын берничә кеше күтәреп ала, каштаннар арасыннан тын җылы кичке урамга авыр елларның дәһшәтле аһәңе, яшьлек куәте кайткан кебек була, җырның кушымтасына кешеләр кушылгач, старшина Здесенко гитарасының юан кылларына даң-доң чиртә башлый, башын тагы да арткарак җибәрә:

Друг мой неразлучный, друг веселый, звучный,
На привале в поле, даже в бурном море,
В самолете быстром, всюду голосистый,
Друг мой, голубой аккордеон.

Нигәдер барысы да авыр сулыйлар, ул арада КПП ишегеннән дежурный ярдәмчесе килеп чыга, боцман дудкасын авызына каба да, сандугач сайраган авазлар чыгарып, сигнал бирә:

— Приготовиться к отбою!

Акрын гына эчкә узалар, төн әле һаман җылы, якындагы бухтага утларын җемелдәтеп кечерәк кенә бер шәһәрчек кереп бара, бу — крейсер. Йокыга кереп барган матрослар, офицерлар белән саубуллашкан кебек, крейсер үзенең юан торбасыннан аһылдаган аваз биреп куя, йомшак җил борынга мазут, диңгез исе алып килә. Ә крейсер — болай карап торганда, әйтерсең лә, коры җир өстеннән шуып барган олы бер шәһәр.

«Отбой», «подъем»нарга буйсынырга бик үк яратмаган карт матрослар әле кубрикларга таралгач та (корабльдәге гадәт буенча коры җирдә дә йокы, яшәү бүлмәсен «кубрик» дип йөртәләр) әле җырлыйлар, моңаялар. Старшина Здесенко офицерлар янына керә, буйдак офицерлар сугышны узган матрослар янында үзләрен бик гади тоталар, «син» дип, «Микола», «Сашок» дип кенә эндәшәләр, тегеләре дә офицерларга карата шундыйрак мөгамәләдә, ләкин бу мөгамәлә һич тә хәрби дисциплинаны какшату исәбенә түгел иде. Менә Здесенко чишенеп, юынып керде, гитарасын алды. Асаф кичә генә Зәйтүнәдән алган хатын тагын бер кабат укырга дип киерелеп сузылып ятты. Здесенко янына кече лейтенант Костя Рыжко килеп утырды, гитараның башыннан кысып тотты. Здесенко кылларга чиртеп җибәрде Костя гитара муенын дерелдәтә башлады. «Отбой» командасы белән өзелеп калган җыр кабат яңгырады. Тик бу юлы инде ул башкачарак яңгырады, гитараны дерелдәткәннән кыллар башкачарак елады: ерак Мексика, Куба аһәңнәре килеп кушылды. Костя Көньяк Америка портларында, Гаванада булган егет, күрәсең пальмалы портларны, җылы дулкыннарны исенә төшерде, ләкин сугыш турында, тыныч көннәр турында җырлады.

Я вернулся в родные просторы,
И опять по-новому влюблен;
Юный друг, веселый и задорный,
Друг мой, голубой аккордеон,
Друг мой неразлучный...

Гитара тынды. Асаф укып бетермәгән хатын мендәр астына тыкты. Соңгы җөмләләре хәтердә калды: «Кыз балалар егетләргә караганда сизгеррәк булалар. Син кайткач та үзеңә урын таба алмыйча, беренче мәхәббәтеңне эзләдең. Син бөтен авыл буйлап Сылуыңны эзләп йөрдең. Ул юк иде. Син мине күрмәдең. Синең гаебең юк иде, әмма миңа да авыр булды...»

Төн. Берәү дә йокламый. Костя Рыжко сөйли. Акрын гына.

— Ике ел хат алыштык. Ут эченнән яза идем. Сугыш беткәч монда калдырдылар. Корабльдән списать иттеләр, әйтәләр: яшь буынны тәрбияләргә кеше кирәк. Ярда кеше әзерлә. Ну, что ж, мин әйтәм. Килдем. Дөрес, мондагы солдат тәртибеннән бик риза түгел мин. Монда бит болай: тилько ляжешь — пидимайсь! Тилько станешь — пидравнясь! Шулай. Элемтәне яңарттык Рита белән. Мин хезмәт иткән җирдән ерак түгел бер шәһәргә күчеп килде бу, комсомол путевкасы белән. Элемтәне урнаштырдык, яңа адреслар буенча. Малай, йөрәк яна бит, күрешәсе килә. Карточкалар алыштык — ошатыштык. Йөрәк урынында түгел. Отпуск алуым булды — ялт мин тегенең янына. Төнлә эзләп таптым. Әйбәт йортта, мезонины, әллә нәрсәләре бар: бер буржуа йорты инде. Ишекне шакыдым. Чыкты халат киеп бер хатын. Чемоданымны куйдым, чин-чином тегеңә:

— Младший лейтенант Костя Рыжко. Рита исемле кыз шушында яшиме? Швартоваться итәргә рөхсәт бирегез, — дим, Апасы икән. Кердем, туры кухняга уздым. АпасыРитаны уятты да, ире янына кереп китте. Ире офицер икән. Ике-өч минуттан Рита белән дә күрештек. Каушамадык, әлбәттә. Ни эшләргә белмичә тик торабыз. Кыз чибәр, барысы да үз урынында. — Рита, — ди апасы эчке бүлмәдән, — ни карап торасың, кунакны ашат-эчерт.

— Нәрсә әзерлим икән, апа? — ди теге.

— Нигә аптырыйсың, — ди апасы, — йомырка белән колбаса кыздыр.

Рита примуска ут кабызды, ул арада мин кулларны юып алдым. Бераздан карыйм Рита юк. Бүлмәдән пыш-пыш тавыш ишетелә.

— Апа, башта кайсысын саласы, йомырканымы, колбасанымы?
— Юләр. Башта май салып кыздыр.
— Аннары?
— Аннары колбаса турап сал.
— Ә йомырканы ничек ватасы? Тоз сибәсеме?

Менә шулайрак сүз бара. Ярый. Барысы да булды, ашадык-эчтек, тегеӘбу турында сүз юк, коридорга раскладушка җәеп бирделәр дә и мин янгынчы булырга имтихан тапшыра башладым. Шәйтан! Йокларсың бар! Башка төрле уйлар килә. Тукта, Костя дим, син дим, иртәгә иртән бу кызга бик кирәкле бер сүз әйтергә тиешсең. Сабыр ит дим. Йомырка тәбәсе дә пешерә белмәгәч бу кем була соң әле дим. Тукта, Костя дим... Менә шулай хәл ителми калды. Ну, яратышабыз һаман. Ул хатларны безнең күрсәң...

Кемдер гырлап йокыга китә, крейсерның юан торбасыннан тагын ахылдаган тавыш ишетелеп ала, карават пружиналары шыгырдый.

Асафны да йокы баса, саташулы төш чорнап ала: ямь-яшел ай нурыннан яшькелт ефәк эчке күлмәк кигән кыз килеп чыга, ул кыз үзе Сылу икән, үзе Зәйтүнә дә икән. Ул кызның кулында бер бәйләм ут чәчәге икән, үзе елмаеп җырлый икән:

Море катит волны голубые
И сады зеленые шумят...

## XXI

Җәй башында яңа набор килде. Хәрби дәресләр башланды. Старшиналар составы эшкә чумды, офицерлар беренче сентябрьдә ант кабул итәчәк бу наборга дәрес бирергә әзерлек башладылар. Асафка чираттагы ялны кичектереп торырга куштылар, класста укытыр өчен аның әлегә теоретик әзерлеге җитми иде. Көннәр китапханәдә үтте. Янадан шул ук дәресләр, шул ук тәрбия эшләре башланды. Авыл, әнисе турында уйларга вакыт аз кала иде. Ара-тирә яшь офицерлар белән кафеларга кереп утыргалыйлар.

Тагын соры, караңгы көз җитте. Диңгез өстеннән ишелеп-ишелеп кергән болытлар тагын шәһәрнең текә кызыл балчык түбәләренә тиеп актылар, дөньяны дым басты. Кичләрен кафе алдындагы лампалар куе томанны тишә алмыйча, тонык саргылт нурларын тарата алмыйча көчәнеп җемелдиләр, куе томан артындагы диңгез эченнән маякның елап-елап ыңгырашканы ишетелә, юеш урамнардан матрослар строеның дың-дың атлап куәтле тавыш белән җырлаганнары салкын стеналарга тонык булып килеп бәрелә. Көзге занятиеләр башлануга Асаф шәһәргә чыгуын сирәгәйтте, күп вакытын учебный отрядның офицерлар өчен булган уку залында дәрескә әзерләнеп үткәрде. Алдагы уку елына аны Хәрби Академиягә укырга җибәрергә дип кисәтеп куйганнар иде. Хәзер аны авыл тормышы белән бәйли торган җепләр нибары икәү генә иде — тагын ялгыз калган әнисе һәм лесхоз мәктәбенә күчеп киткән Зәйтүнә. Хәзер инде «гражданка» турында уйларга да ярамый иде, личный листоклар тутыртып Флот командующиена җибәрделәр. Димәк — гомергә. Сылу акрынлап томан артына кереп югалды, аның урынын килгән хаты саен Зәйтүнә ала барды, тик төннәрен генә, саташулы төш вакытларында гына һәрвакыт сагышлы елмаю белән ай нуры эченнән Сылу килеп чыга да, моңаеп карап тора, үзенең һәрвакыт тәртипсез-матур булып чәчләре таралган, үзе һәрвакыт Асаф беренче күргәндәгечә ай нуры төсле ефәк күлмәктән булыр. Ләкин бу әкият кызы егеткә беркайчан да, бер тапкыр да бер генә сүз дә әйтмәде. Иртән торуга бу әкият кызын тыйнак,

оялчан Зәйтүнә алыштыра иде. Әллә бөтенләй алыштырып бетерә алмыймы? Егет үзе өчен моны ачыклап бетермәгән иде әле.

Йомшак, ябалак карлы кышкы кичләр, озын төннәр әнә шундый уйлар эчендә үтте. Күп трофей фильм каралды, күп әдәбият укылды. Яшь, буйдак офицерлар, класс җитәкчеләре булган матрослар, старшиналар һәрберсе классик әдәбият буенча университетларның филология бүлеген бетергән кеше белән бәхәсләшерлек, бу бәхәстә җиңәрлек дәрәҗәгә җиттеләр.

Февраль башында берничә офицерга ялга кайтып килергә рөхсәт бирелде.

Мәскәүнең җепшек перронына бер вагон кара шинель таралды. Һәркемнең күңел күтәренке, һәркем кәефле иде. Берничә минуттан аларны метро йотып бетерде һәм төрлесен-төрле якка таратты. Казан вокзалына килеп чыккач кына Асафның йөрәге чәнчеп куйды: еш, тирән сулауданмы, дулкынлануданмы? Туган як якын, бик якын иде инде. Билетлар белән эшен бетереп, Мәскәү—Барнаул поездына кереп урнашуга, Асаф, бернигә карамыйча, өске полкага менеп сузылып ятты да, күзләрен йомды. Тыныч заманда, тыныч күк астында мина куркынычы булмаган юллардан тыпы-тыпы килеп туган йортына таба якыная бару нинди зур бәхет! Поезд кузгалуга ул күзләрен йомды. Инде миләрне ял иттерергә, бушанып калырга мөмкин иде.

Проводница чәй керткәч кенә Асаф аскы полкага төшеп утырды. Барысы да офицерлар, кайсы консерва ача, кайсы колбаса турый, кайсы стакан юнәтеп йөри иде.

Аннан танышу, ашыгыч анекдотлар, көлеш китте. Арада бер герой да бар иде. Танкист-майор. Тагын берсе халык артисты икән. Стаканны башлап үзе күтәрде, бик мәгънәле итеп тамак кырды һәм зур канәгатьлек белән «дога» укыды:

— Не пьем, господи, а лечимся. Не через день, а каждый день, не по чайной ложке, а по чайному стакану. Да разольется сия влага по переферии телесной. Аминь!

Асаф аңа колбаса кисәге сузды. Артист фронт күргән кеше икән. Сугыш, дөнья күргән, солдат хезмәтен күргән кешеләр белән сөйләшүе рәхәт. Алар вак булмый, кара эчле, мәкерле булмый.

— Юньле кешеләр белән ни эчсәң дә ярый,— диде Асаф, чемоданыннан бер савыт «Бальзам» алып. — Чәйгә кушып эчәбезме, әллә болай гынамы?

— Юк, без аны башта ачыйк, — диде танкист. — Аннан карарбыз.

Тәрәзәдән караганда вак станцияләрдәге утлы баганалар артка йөгергән сыман иде.

## XXII

— Юк, парень, мин мондый хәлләргә әзер түгел. Мораль яктан әзер түгел. Оялам да, аңлыйсыңмы?

— Юк инде, булгач-булгач бутка булсын, диләрме? Күрешеп кенә калмыйбыз, алып ук китәбез.

— Мин аңламыйм: без кайсы гасырда яшибез? Унсигезенчедәме, әллә егерменчедәме? Безниләр кичердек? Син кая хәтле барып җиттең? Австриягә? Румыниягә? Ә мин — Дрезденга. Һәм менә шуннан соң нининдидер поселокта теләгән кешең белән күрешә алма. Кызык.

— Юк, күрешеп кенә калмыйбыз, алып китәбез кызны. — Шәрәф алга атлады. Зәйтүнәләр йортының капка төбендә тәмәке утлары, кесә фонарьлары кайнашты.

— Туктале... — Асаф аның җиңеннән тотты. — Тимер юл станциясе булган җирдә кем юктыр дисең син? Синең, минем дәрәҗә белән без нишләрбез?

Шәрәф тәмәкесен чыгарды. Ширпы яктысында аның ачу белән янган күзләре, калын, көчле уч төпләре күренеп алды.

— Болар берәүгә дә юньләп буйсынмыйлар, — диде Шәрәф. — Ничә межрайбаза, леспромхоз, тимер юл оешмалары. Боларның главкалары әллә кайларда. Син торып тор, мин хәзер поссовет председателен алып киләм.

— Ә, туган, юк инде. Кыз белән алай көрешмиләр. Поссовет ярдәме белән — свидание? Ну-ка, мин үзем. — Асаф капкага таба кузгалды.

— Тукта дим, харап буласың. Боларның ачуы синдә түгел, миндә. Минем аркада сине...

Әйе, Шәрәф сөйләгән иде. Бу егетләрнең эти-әниләре — бары да бүрекчеләр. Күн бүрек белән сәүдә итәләр. Күптән түгел генә финагент булып эшкә урнашкан Шәрәф монда килеп аларның буранnарын уйнаткан. Доходларын яшереп маташалар икән. Тегеләй итеп, болай итеп караганнар, Шәрәф сынмаган.

— Мин сугышта бер яртыга сынып үземне кимсетер өчен йөрмәдем,— дигән. Арада мәгънәле итеп янаучылар да булган. Шәрәф бирешмәгән.

Бүген әнә шуның аркасында эш катлауланды. Мәктәп капкасына кичен килеп туктаган район кошевкасы янына егетләр җыелды. Ут яктысында, атка клевер салганда күрделәр: теге явыз финагент бу. Ладно... Ә тегесе? Әһә, анысы офицер. Так, так. Әһә, Заготзерно директорының кызы Зәйтүнәне алырга килмәгәннәрме болар? Әйтәләр иде ич, бер офицер кайтып аласы икән дип?

Бәхетсезлеккә каршы, Зәйтүнә мәктәптән кайтып киткән икән. Димәк, туры өйләренә. Өй — ерак түгел, Шәрәф барысын да белә. Әмма кичке сәгать тугыз булды, ун булды — Зәйтүнәләр капкасы таш крепостька әйләнде дә калды. Керүче дә, чыгучы да булмады, якын да җибәрмәделәр.

— Ну, ярый, мин боевое охранениедә торам, эш хәтәргә китсә, мин — момент!

Асаф капкага таба атлады. Кесә фонаре белән аның битенә якты көлтә бәрделәр. Ул кулын күтәреп күзләрен каплады, егетләр янына килде.

— Исәннәрмесез, егетләр!
— Үзең яхшы булсаң, без ярый. Ни йомыш?
— Арада фронтовиклар бармы?
— Юк, фронтовиклар бу вакытта инде йоклыйлар.

Тәмәкесен еш-еш көйрәтеп торган киң битле адәмгә карап, Асаф кыю гына дәште:

— Син үзең кем соң?
— Кем дигәннең үзе — маңгаенда ике күзе.

Асаф мондый юморга әзер түгел иде. Каушый калды.

— Арагызда солдат хезмәтендә булганнар бармы?
— Син нәрсә, прокурормы, әллә ревизормы?
— Алай. Димәк, бу йортка мине кертмисез?
— Нишләп теге иптәшең качып калды? Килсен — сөйләшәбез.
— Ә бит бу йортка миңа керергә кирәк, аңа түгел.
— Керде ди берәү. — Монысын теге киң битле әйтте. Утызларда булыр. Учында тәмәке. Моңа ни кирәк? Ник монда ул?
— Бездә читкә җибәрердәй кызлар юк. Үзебезнең пачулыктан бер кыз да артмый. — Монысын да шул әйтте. Асаф аның каршына ук килеп басты.

— Карале, син, туганкай! Син — сугышта булдыңмы? Син — фашистны күрдеңме? Мин бит дүрт ел буе ут эчендә йөрдем. Ну-ка, капканы ачыгыз әле.

— Ачты ди, тот капчыгыңны. — Кин битле тагын тирән итеп тәмәкесен суырды. — Хәерчегә якты чырай бирсәң, ямаулык сорый диләр. Син бәлки — может бу йорттан мал төяп чыгып китәргә килгәнсең... Сыерын, сарыгын, итагедали... Чужой манастыр своим уставом...

Нәкъ шул вакытта Асаф күреп алды: җигүле ат янындагы Шәрәфне билле тун кигән ак фетрлы кешеләр чорнап алган. Егетләрме алар, олы кешеләрме? Һәрхәлдә, малай-шалай түгел. Нәрсә турындадыр бәхәсләшәләр, кулларын бутый-бутый кычкырышалар. Шәрәфкә ярдәм итәргә кирәк! Кыз йортына аннан соң да кереп булыр! Ярдәмгә, ярдәмгә...

Ерактан сызгырган тавыш ишетелде. Бу — Шәрәф иде. Шәп булды әле бу! Әйтерсең, иртәгә көндез кешечә килеп, Зәйтүнә белән кешечә сөйләшеп булмый! Әйтерсең, урламасаң, кыз алып китеп булмый! Әйтерсең син офицер түгел. Һи-и-и... Күрәсең, тыныч шартларда егетләрчә бер бәхәсләшеп җиңәсе килгән.

Асаф чана янына килде.

Шәрәфкә тимәгәннәр, тик чорнап алып, Асаф янына җибәрмәгәннәр генә икән.

Атка утырдылар да, лесхоз ашханәсенә киттеләр. Ашханә алдындагы аратага атлар бәйләнгән, барысы да мекерт-мекерт люцерна, вика, солы ашыйлар, капчык, киерткәннәре ара-тирә башларын селкеп, капчык төбендәге солыны күтәрәләр, ә хуҗалары парлы ашханәдә кайры туннарын чишеп кәеф-сафа коралар иде. Электрның бердәнбер лампасы тәмәке төтене, пар, янган көнбагыш маеның зәңгәр төтене аркылы зәгыйфь саргылт нур чәчә, Асаф өстәл янына утырды: шинельгә монда игътибар итмәячәкләр иде.

Кызык булды бит әле бу! Фашистлар белән сугышып йөр-йөр дә, әлләкем булып хәрби диңгез көчләрендә хезмәт итеп кокардалар, алтын погоннар белән кайт та, лесхоз малайлары белән бәхәсләш...

— Сез акны гынамы, әллә кушып китерергәме? — диде майлы битле юантык официантка. Асаф гаҗәпләнеп аңа күтәрелеп карады.— Шукрут биримме закускага? Кыяфәтегезгә караганда «чбк» ашап үскән егетләргә ошагансыз... — Официантка мут елмайды, Асаф шаккатып тыңлап утырды.

— Гаҗәпләнмә, — диде Шәрәф, — поселок жаргоны ул. «Шукрут» дигәне — кәбестә кәлҗемәсе. «Широкое употребление капусты работниками умственного труда». Сугыш вакыты фольклары. «Чбк» дигәне — черек бәрәңге күмәче. Сугыш вакытында станциядә болар шуның белән сәүдә итеп ятканнар. Көздән калган бәрәңгене җыялар да, шуны изеп көнбагыш маенда кыздырып саталар. Бер тәбикмәге — биш сум. Ярый бит?

Асаф дәшмәде.

— Монда акка кызылны кушып ералаш ясап эчәләр, — диде Шәрәф,— арзанга да төшә, бу спекулянтларның сай башына тизрәк бәрә дә. Ненавижу! Шуларга социализмның нәрсә икәнен аңлатмасам, фамилиям Солтанов булмасын! Әйдә, тот, мин алардан куркып утырмыйм. Безнең акча — хәләл, эшебез — хәләл, вообще — безнең җирдә басып йөрүебез хәләл! Мин бу эштән китәм, мине партшколага җибәрәләр, ну мин сугыш вакытында каралты арттырып, байлык туплап яшәгән кайбер кешеләргә гомер буе дошман булып калачакмын! Слушай, нәрсәсе обидно аның: менә бер көн килер, шушы кешеләр — алар, конечно, күп түгел монда, мин аларны беләм — шушы кешеләр, сугыш бетеп ун, егерме, утыз ел узгач, «без дә сугыштык» дип йөри-

ячәкләр. Чөнки сугыш вакытында алар тегеләйме, болаймы, призываться иткәннәр, военкомат юлында йөргәннәр, кайберләре Сюгинск белән Вятские Поляны арасында тимер юлдан йөк озатканнар, почта йөрткәннәр, тылдагы солдатларга сабын биреп торучылар да булган.

Шәрәф бушаган стаканын ачу белән «шак» итеп, май сеңдергән, бүрткән такта өстәлгә куйды. Асаф та инде төтен эчендәге бу агай-эне арасында иркенләп, бушанып утыра иде. Бәхәс, төтен, май исе, тәмәке исе... Арада фронтовиклар да байтак.

Төнге сәгать унбердә ашханә бикләнә икән. Таза ирләр, таза егетләр, теге яки бу мәсьәләне хәл итүчеләр һавага чыктылар. Шәп, кәефле, тук әңгәмә башланды. Асаф уйлап куйды: шәп бит мондый тормыш. Мондый тормыш — күн бүрек сатып акча туплау, йорт салу, бүрәнә юнәтү, бакча ясау, мунча салу кебек әйберләр Асаф белән бергә илне-җирне азат итеп исән калган егетләрне дә йота башласа?

Кайры тунлылар таралды. Чиркәү бинасында — поселокның культура йортында бара торган трофей фильмның икенче сериясе дә бетте.

Төнге күккә моңсу гына сыенып утырган иске чиркәү бинасыннан халык агылды. Асаф белән Шәрәф атлар ашаган урынга елышып, папирос кабыздылар. Рәхәт, болытлар ишеп-ишеп дөньяга йомшак кар сибеп, чиркәү гөмбәзләренә тиеп йөргән кышкы йомшак бер төн иде. Рәхәт, суларга, яшәргә, уйларга, омтылырга рәхәт иде.

Кино бетүгә поселоктагы утны сүндерделәр. Чыркылдаша-чыркылдаша кызлар урамга сибелде. Шәрәф белән Асаф чанадагы хуш исле люцернага утырдылар да, төн караңгылыгы эчендә калдылар. Мекердәтеп ашап торган атны борчыйсы, кузгатасы килми иде. Зәйтүнәләр тәрәзәсеннән төшкән ут яктысын да карап торасы килә иде. Кинода булмадымы икән ул? Юктыр, мәктәптә дип әйттеләр, китап-дәфтәрләрен кочаклап өенә кайтып китте, диделәр. Ә йортлар монда — крепость. Бакча эчендә, зур урыс капкалар, биек коймалар, һәр ишек алдында бозау кадәр эт. Һәр капкада диярлек калай: «Осторожно во дворе злая собака». Шәрәф аңлый алмый: кем сак булырга тиеш? Синең ишегалдыңа йомыш белән килеп керүчеме, әллә явыз эт тотучы кешеме? Ә болайрак язсаң дөрес булмасмы эт хуҗасының баш очына: «Сак бул, этеңне тый, ишегалдына кеше килеп керде?» Бу кисәтү кешене мәсхәрә итә сыман. Нигә әле тыныч заманда, үз илеңдә, үзең яшәгән поселокта син «сак булырга» тиешсең? Син эт өчен яшисеңме, әллә эт синең өчеңме!

Бер төркем яшь кызлар, кайры тун кигән егетләр ашханә каршындагы тапталган мәйданчыкка җыелдылар. Гармунчы двухрядкасын гөрләтеп җибәрде. Барысы да руслар икән. Аларның шунысы җайлы— алар кем җыр башлар икән, кем бии башлар икән дип ялындырып, назландырып тормыйлар — алар шунда ук җырны-биюне берьюлы башлап та җибәрделәр. Кыска жикет өстеннән мамык шәл бөркәнгән зифа буйлы бер кыз гармунчы каршына килеп аягын тыпырдатты да, түгәрәк эченнән бии-бии җырлап узды. Гаҗәп! Дәрте бәреп торуына чыдый алмыйча тыпырдаган бу кызыйның җыры мәхәббәт турында түгел иде.

Гитлер — гад незваным гостем
К нам залез в цветущий сад.
По-немецки — «дранг нах остен»,
А по русски — «дранг назад».

Кызның тавышы гаҗәп ачык иде, мондый ачы тавыш частушка җырлаучы авыл марҗаларында гына була. Ләкин бу ачылыкка тагын

каяндыр, йөрәк түреннән чыккан әрнү, рәнҗү аһәңе дә катышкан иде— Асаф әсәрләнеп тыңлады.

Кайры тунын чишеп җибәргән яшь егет бүреген кыңгырайтып фыртланып алды да, сылу кыз каршына чыгып биеп китте.

Дорогая моя мать,
Знать тебе желательно:
Стану ли героем я?
Стану обязательно.

Асаф шаккатып тыңлый иде. Шәрәф ат башына китте, солы капчыгын салдырды, йөгән сабагын дугага тарттырды, аркалыкны күтәрде. Түгәрәк эчендә бии-бии һаман теге кыз җырлый иде.

— Элеккеге поссовет председателе Савелий Матвеев кызы ул,— диде Шәрәф, чанага килеп урнашкач.— Бичара, кырык өченчедә Сталинград янында беткән. Алты баласы калган, монысы — иң зурысы.

Кызның тыпырдап биюе кырык бишенче елның тугызынчы маен искә төшерде. Ул көнне дә солдатлар Дрезден урамындагы купшы бөтеркәләр ясап тезелгән урам ташында шулай тыпырдаганнар, хисне аякка күчергәннәр иде.

Күз ияләште, кисәк-кисәк ишелеп йөргән җылы болытлар арасыннан яктылык төшеп кар белән тоташкалап ала, сугыш булган җирләрдән бик еракта, чыршы урманы эчендәге бер поселокта, сугыш бетеп күпме вакытлар узгач та, шул дәһшәтле көннәрнең аһәңе, моңы, нәфрәте яши иде.

Асаф җиңел сулап куйды: төнге саф кар һавасы белән канга рәхәт дәрт, йөрәккә иркенлек кереп тулды. Юк, бу дөньяда адәм балалары— әйбәт затлар. Саф күңелле кешеләр белән, шулай да, яшәве күңелле.

— Әйдә, Шәрәф дускай, кузгат атыңны. Мин иртәгә үзем генә көндез киләм монда. Миңа бик ошап китте бит әле бу поселок, — диде ул, Шәрәфкә таба борылып.

— Бу — бер дә егетлек булмады инде. Ул компанияне оештыручы кеше, беләсеңме, кем? Синең кәләшеңнең абыйсы — Габидулла. Күн белән алыш-биреш итүче. Сугышка бармаган, тегенди-мондый авыру табып йөргән. Шулай да Чиләбегә кадәр нәрсәдер озатып вагонда барган, шуннан аягын имгәтеп кайткан. Сугыш инвалиды димәкче була үзен. Халык көлә: Чиләбедә сугыш булдымыни диләр. Хәер, сугыштан кайтканнар белән контактка керергә бик яратмый ул. Минә нинди кайнага белән кочаклашып эчәсең бар әле, дускай...

Төз чыршылар уртасына чокыр булып сеңгән йомшак юлда юырткан тук атның эче селкенгәне һәм дуга бөҗрасының келт-келт итеп ат аягы көенә дугага бәрелеп барган тавышы гына ишетелә иде. Рәхәт, моңарчы татылмаган рәхәт иде.

— Иртәгә ял көнеме? — дип сорап куйды Асаф.

— Иртәгә ял, брат. Минем ат үземдә куна. Әниеңә әйт: төшке ашы әзер булсын. Көндезгә кыз алып кайтабыз.

— Син кая китмәкче?

— Ничек кая? Үзебезгә — Ташлытауга.

— Юк, бездә кунабыз.

— Анда нишләрбез?

— Эш табарбыз.

Кар белән болытлар тоташкан үзәнлектә каракучкыл авыл күренде. Бу — Симетбаш иде. Алар авылга килеп кергәндә чат йорттагы бер әтәч саташып кычкырды: югыйсә, әле төнге уникe генә иде.

## XXIII

— Балта биреп шөшле алдым — алдаладым татарны, булды инде бу, — диде пәрәмәч битле юантык гәүдәле «поселок хатыны» — Зәйтүнәнең әнисе — булачак кияүгә карап.

Ял көне иде, йортта мич ашы исе чыккан, түшәмдә кояш нурлары уйный, почмак яктан шаулап самавар кайный, җылы мич буенча эскәмиядә башын ташлап, казык тешен аскы алсу иреннә бастырып, таралып мәче йоклый, зур сәгать теле «тең... тең»... килеп мәһабәт, салмак чайкала иде. Бөтенесе — өй почмагы тулы кышкы гөлләр дә, мичтә чыжылдап утырган хуш исле ризык та, адәмчә мыскыллы елмайган сыман башын тәгәрәтеп йоклап ятучы тук мәче дә, сәгать теле дә Асафка:

— Бу йортта бар да имин, тук, әйбәт, — дип миенә тукыган сыман иде. — Син тимә боларга. Бозма бу тормышны. Монда барысы да җайга салынган...

Шәрәф озак торды. Лапас астында һаман ат янында мәшгуль. Өйдә өч кеше — ана, кыз, булачак кияү генә иде.

— Хат буенча без вәгъдәләшкән, апа, — диде Асаф, елмаеп. — Кызыгыз риза икән, нигә аркылы төшәсез?

— Үз сөягебез үзебездән артмас, — диде пәрәмәч битле «поселок хатыны». — Андый еракка, гидайлыкка ничек кыз биреп җибәрәсең. Әле ике ел укыйсы да бар. Синең бит тормышың бүген монда — иртәгә тегендә.

— Соң бит, үз сөягем дип үз яныгызда гына тота алмассыз. — Асаф тагын әдәпле елмайды.

— Тотмасак, әнә Межрайбаза директоры Мингазов малаена сорыйлар кызыбызны. Күкәй кабыгы эчендә булачак, күкәй кабыгы. Ул каралты-кура дисеңме, ак мунча, мотоцикл, хром пәлтә дисеңме. Синең бит каккан казыгың да юк. Кешегә яшәү өчен йорт-җир дә кирәк. Гомер буе алай җилкәләреңне ялтыратып, җөндыз тагып кына йөри алмассың. Тормыш ул — куласа, бер әйләнә, бер баса. Әнә, ичмаса, Мингазов малаеның...

— Ән-ни! — Зәйтүнә кухня ягыннан чыкты. Өстендә ачык муенлы яшькелт йон кофта иде.— Ән-ни! Иске заманча сөйләшәсең бит! Нәкъ Галиәсгар Камал пьесаларындагыча! Нәрсәгә кирәк миңа аларның хром пальтолары! — Зәйтүнә наз белән Асафка карады. Бу караштан егет бер мәгънә тотып алды: чигенмә, егет, әни болай гына каршы килеп маташа, чигенмә.

— Ул Мингазов малае дигәнегез ничә ел йөрде соң армиядә, сугышта? — Асаф кыюланып китте. Юан хатын сүзнең кая барасын аңлап бетермәде.

— Йөрмәде. ОРСта эшләде, бронь бирделәр аңа. Күпме кешегә ярдәме тиде, бик әйбәт егет.

— Ә-ә, алай икән, апа. Йөрмәдемени? Йөрмәдеме? Без, алайса, беткәнче юләрләр икәнбез, ә? Нәрсәгә дип сугышып йөргәнбез соң без? Килсение фашист монда, Мингазовларның малае аларга ак мунча ягып кертсение, ә? Вәт син, без юләрне...

Хатын телсез калды. Аякларыннан кар кага-кага өйалды сайгакларын селкетеп, өйгә Шәрәф килеп керде — киеренке атмосфераны иркенәйтеп җибәрде.

— Нихәлләр, Гөлбәдәр апа? Кышлар ничек уза? Низаметдин абый бик сызланмадымы бураннарда? — Шәрәф, җавап көтеп тормады, Зәйтүнәгә борылды. — Нихәлләр, чибәр туташ? Яшь гомерләр ничек уза? Төенчегеңне төйни башла — без ике сөйләшмибез.

Зәйтүнәнең болай да алсу бит алмалары тагы да кызарып китте, каушады, озын ике толымының берсен алгы якка — күкрәгенә чыгарып салды. Шәрәф аның каршысына ук килде дә, бер дә кыенсынмыйча, толымны аркасына чыгарды, күзләрен мут кысып әйтте:

— Йоласына китерик инде, мә, мич башына куеп тор, җылынсын,— дип бер шешә тоттырды.

Юантык хатын шат чырайлы, каушаган кызына сөеп карады. Аннан булачак кияүгә. Булачак кияү алтын погоннарын ялтыратып өстәл башында гәзит-журналлар актарып утыра иде, Гөлбәдәр апа аның аягына күз төшерде: егетнең аякларында ялтыравыклы кара хром ботинкалар иде.

— Кызым, — диде ана, дымлы тавыш белән, — Зәйтүнә, мич башыннан җылы оекбашлар карап ал әле.

Аннан Шәрәфкә рәнҗүле карап әйтте:

— Әтиләреннән башка эшләнә торган эшмени ул? Мин бер үзем нишлим? Ник бәйләндегез әле миңа?

— Низаметдин абзый риза! — дип кычкырды Шәрәф. — Ихлас күңелдән әйтәм, риза! Без аның белән бу турыда сөйләштек.

— Алайса, ник әтиеңнән сорап калмадың? — ана ачулы тавыш чыгарырга тырышып, кызына таба борылды. — Ник?

—Ән-ни... Гомер буе сезне борчымадым. Инде миңа егерме бер яшь. Асаф белән без вәгъдәләшкән, хат буенча.

Ана йомшады. Әмма бирешмәде.

— Ә укуың нишләр? — дип каршы килеп маташты.

— Теләгән җирендә укыр, — диде Асаф, без бит ком сахрасына китмибез. — Тели икән уку вакытларында кайтып йөрер. Елына ике мәртәбәме ул сезнең?

Соңгысы ананың каршылыгын бөтенләйгә җимерде. Өстәлгә самавар, бәлеш килде. Мич башындагы шешәне Шәрәф үзе алып килде, егетләрчә җитезлек белән төбенә сукты, сургучлы кәгазь бөке ишек бусагасына очты. Гөлбәдәр апа йөзенә кайгылы, сагышлы кыяфәт чыккан хәлдә бәлеш капкачын кисә башлады, өйгә хуш ис тулды.

— Мингазов малае да кеше үтереп йөрмәде, анысы, — диде ул, бәлеш парына өрә-өрә, — менә әтиләреннән уңайсыз. Гел әйтә килде. Язга, май бәйрәменә туй итик, диде. Зыяны тимәсә ярый инде. Безнең Габидулла — башка чыккан улыбыз — шуның кул астында. — Аннан авыр сүз әйтте. Авыр сулап әйтте:

— Шулай инде, — диде, — кызларны үскәндә күк читенә меңгерел куярдай итеп үстерәсең дә... читенә кыстырып куясың.

Бу — тупас, ямьсез, мәсхәрәле хөкем иде, әмма төп мәсьәлә хәл ителгән иде: ана ризалыгын бирде. Асафның шулай да йөрәге чәнчеп алды. Фатыйма апа гел әйтә килде: анасына карап кызын коч, атасына карап — улын коч диде. Зәйтүнә дә шулай ямьсез, тозсыз телле булса, нишләрсең? Ямьсез уйларны Шәрәф бүлде:

— Мингазовларыңның базасына ревизор килде әле өлкәдән, — диде Шәрәф. Анда хәлләр бар. Туй итәрлек булырмы әле, башка нәрсә итәрлекме, карарбыз. Я, ярар, Гөлбәдәр апа, безгә бу килешүгә кул кую уңае белән рөхсәт итегез! Бездән изге теләк! Что син, апа! Сугышта йөреп дошманны җиңеп кайткан шушындый чибәр егет барында Мингазов малае да, Мингазов малае. Я, әйдә, күтәрдек.

Юлда Зәйтүнә Асафка елышып утырды. Шәрәф ат башында иде.

— Кичә ник кермичә киттең? — диде Зәйтүнә наз белән елмаеп.

— Ә кем әйтте әле сиңа мине кичә килгән дип?

— Үзем белдем. — Зәйтүнә шаярып перчатка кигән кулы белән Асафның яңагын сыпырып алды. Борынга затлы ислемай исе бәрелде.

## XXIV

Туй борчусыз, үпкә-сапкысыз булмый диләр. Асаф белән Зәйтүнәнең дә туе борчулы, мәшәкатьле булды. Бу ник алай икән? Күрәсең, тыныч тормышның кадерен белү өчен шулай кирәктер. Борчулар аша ирешкән тынычлык кына, күрәсең, ләззәтле буладыр.

Иң беренчесе — Асаф кайтканны ишетү белән, ял алып, Гаделия кайтып төшкән иде. Бер яктан капкага кәләш белән кияү килеп керде — әчке яктан Гаделия килеп чыкты. Беренче адым...

Гаделия белән Асафның күрешмәгәненә җиде ел тула икән.

— Һай! — дип кычкырып куйды Гаделия капкада очрашу белән.— Үл-ләм!. Үл-ләм... — Аннан үкереп елап җибәрде дә, урам буйлап торып йөгерде. Асаф та, Зәйтүнә дә, каршы алырга чыккан Фатыйма апа да телсез калдылар. Ярый әле Шәрәф хәл кадәренчә ярдәм итте.

— Менә мине күргәч шулай инде халык, — диде ул. — Әтисен подоходныйга облагать иттем өченче көн. — Менә мине күргәч шулай инде: «Һай! Һай!» Менә мин ничек өйләнермен, ә?

Кичке якта Зәйтүнәнең бертуган абыйсы Габидулла килде. Гөлбәдәр апа паласка төреп бер түшкә сарык, бер тәпән сары май, ике каз, өч банка варенье, бер чүлмәк бал җибәргән иде, Габидулла «менә без кем» дигән эре кыяфәт белән боларны даң-доң китереп өйалдына куйды. Асаф Габидулла белән күреште дә, аны өстәл янына утыртты, үзе кителен иңенә генә салып, ишекле түрле йөренде.

Габидулла бер стаканны тондыргач, иркенләп сөйләшә башлады.

— Сыерыгыз да юкмыни инде сезнең, кодагый?

Фатыйма апа гаепле кеше сыман почмак яктан чыкты, Габидулла алдына суган турап әзерләнгән селедка куйды.

— Барые, кода, барые. Көзен суйдык. Әйбәт сыер иде. Кигәвенгә бер дә чыдый алмады, бичара. Эссе көнне гел урманнан качарые. Гел өйгә. Гел басуга — иркенгә. Шуның аркасында харап та булды. Көтүче — Гафур дигән малай бер көнне бик каты кыйнаган сыерымны. Агачка бәйләп. Янбашын төйгән — имансыз нәрсә, аңа барыбер. Чеп-чи надан, үзе дә шул сыердан ары түгел. Кыйнаган. Шуннан... Шуннан килеп-е... Сыер әкренләп-е... Корып-ы... Бичара, сөтсез калып-ы... Шуннан-ы... Суйдык. Ташлытау сталавайына саттык-ы. Акчасын збиркнижкәдә тотам-ы.

— Син, кодагый, упшым яши белмисең, — дип кызды Габидулла, селедканы тәмләп йотып. Асаф һаман кителен иңендә тоткан килеш ишекле-түрле йөренә иде. — Сыерны, аны, сталауайга бирәсе түгел. Ит заданиесенә тапшырырга иде. Әнә Мингазов малае — безнең пачулыкта — авылларга бара, акча җыя, итагедали, ял көнне Ташлытау базарына чыга да, бура тикле сыерны кул сугып ала, анда мәгәрисчтер, тегедер-будыр, ну, шуны ыздавайть итә дә — вәссәлам итагедали. Аннан авылларга кәпитәнсия өләшеп йөри: ит заданиең түләнде, рәхим итеп кызыл утызлыкларыңны төреп бир. Мин — сиңа, син — миңа. Вәт шулай, кодагый, бу селютканы кем шулай әзерләде? Минем сеңелдер. Ә-ә-ә... Безнең нәселнең күзе яшел. Я, син, кияү, әллә мине уважать итмисеңме?

«Плевать,— дип куйды Асаф, кайнагайның кызыл йөзенә карап.— Плевать! Сеңлесе гүзәл. Дөньяның барлык кырыслыгын бер үзе эретерлек гүзәл. Бер үзе бөтен ямьсезлеккә каршы торырлык сылу. Сылу? Дөнья! Газаплама мине! Минем яшәргә хакым бармы? Тыныч яшәргә хакым бармы?» — ул кителен киде, төймәләде, өстәл янына килеп утырды. Габидулланың йөзендә Зәйтүнәгә генә хас чалымнар бар иде, шуңа күрә бу кеше күпме генә лыкылдап утырса да, Зәйтүнә абыйсы иде, аңа карап утыруы, әгәр сүзләрен ишетмәсәң, ахыр чутта, бер

рәхәт иде, «Плевать!» — дип уйлап та, пышылдап та әйтеп куйды Асаф.

— Бу дөньяда яши белергә кирәк,—дип алып китте кайнагай, каршына Асаф килеп утыргач. — Яши белмәсәң — үзеңә үпкәлә. Хәзер яши белгәннәр заманы килде. Алдыңны-артыңны карап йөрмәсәңме? Эшләгәнеңне эт ашый, арканны бет ашый, сылушай...

Габидулла борынын тартып куйды, майлы ияген кызыл башлы сөлге белән сөртеп алды. Кулына стакан тотты. Исәбе — иркенләп сөйләшү иде.

— Сылуша-а-а-й... Менә мин узган җәй бер баш дуңгыз симерттем, трахмальный завуттан алган атхут белән. Өс — нур, тамак — гүр, ди иптәш Мингазов. Ул белеп сөйли.

Асафның башы әйләнде. Аның күз алдыннан зур тизлек белән кинокадрлар узды: танклар килә, арадан берсе — бер як гусеницасы өзелгәне, бер урында бөтерелеп җирне утюглый, ә окопта ефрейтор Лукин. Ул арада танк астына бер дуңгыз торып чаба, артыннан тагарак тоткан Габидулла йөгерә...

Габидулла ашыкмыйча, иркенләп утырды.

— Эти санаторийда, эни ялгыз йөрми, мин — барысы өчен дә, — диде ул кухня ягыннан каз боты тоткан килеш чыгып. — Мин шту хачу, то и делаю. Мин — и башкода, и абый, и эти, и эни. Ә шту? Менә мин үзем Чиләбедә фрунтыга трактор төягәндә...

Дөрес, Зәйтүнә аңа тынгылык бирмәде. Караңгы төшәр алдыннан атын җиктереп лесхозга җибәрде: энисе килә алмыйм дип өзеп әйтте, әмма җиңги килергә тиеш иде.

Кичен суытты. Ялт итеп юылган өйалдының киң сайгаклары кеше баскан саен суыктан шарт-шорт итеп тордылар, ишекне ачкан саен өйалдына итле шулпа исе — пар бәреп торды. Габидулла китү белән чоланны кактылар — Асаф боларның берсенә дә катышмады, ул почмак якта Зәйтүнә янында закуска әзерләште. Әлегә эчемлек запасы юк иде, бу мәсьәләне хәл итүне Шәрәф үз өстенә алды. Асаф аңа санап тормыйча гына бер пачка акча тоттырды.

Чоланны каккан кеше Гаделия икән. Кайткан өенә, әйләнеп-тулганып йөргән дә, монда килгән. Эшләшим, булышыйм, үзегезгә генә авыр булыр, дигән. Фатыйма апа аны бишкуллап кабул иткән. Кичен, кеше килер алдыннан Гаделия юкка чыгып торды, кайдадыр киемен алыштырып бизәнеп алган иде ул.

Гап-гади мәҗлес башланды. Шәрәф вәгъдәсендә торган, Ташлытаудан лимон тәме килә торган «Померанцевая» дип язылган бер ящик эчемлек алып килде. Гаделия өч-дүрт лимон алып килгән. Габидулла хатыны — җиңгәчи — паштет пешереп килгән иде.

Габидулла беренче стаканнан соң ук исерде. Әмма яшьләр бәхетле иде. Асаф бөтен булган орден-медальләрен такты, Зәйтүнә җиңсез ак күлмәк киде, өстәл янына утырганчы күз-керфекләрен олы якта — кеше юк почмакта буяп алды. Зәйтүнәнең бер як кырында өр-яңа йон гимнастеркасына өч данә Дан ордены таккан Шәрәф урнашты. Баштарак Шәрәфнең күкрәге мәҗлестәгеләрнең инициативасын бераз гына буып торды, шулай да Габидулла бирешмәде.

— Менә бит, — диде ул, майлы ияген учы белән сөрткәләп. — Менә бит. Мингазов малае өен алты почмаклы итеп салам дип йөрде дә, авыз күтәреп калды. Мондый эштә шулай бит: иртә торсаң ит пешә, соңга калсаң бит пешә. Итагедали.

Габидулла тагы да шәплән сөйлисе иде, сөяк кимергән җиреннән кинәт туктап хатынына карады: хатыны шуның алдыннан гына аңа «дыңк» итеп төртеп алган иде. Әмма берничә минуттан Габидулла яңадан үз җапкысына керде, җыр башлады.

Татар әйтә «тары ярма»,
Урыс әйтә «пышана».
Кызлар дигән кызыл авыз,
Алам дисәң ышана.

Габидулла мондый шәп мәгънәле җыр җырлавына бик шат һәм бәхетле иде, кайберәүләр уңайсызланса да, сеңлесе Зәйтүнә уңайсызланмады: абыйсының гадәтләрен яхшы белә иде. Аш тәлинкәләрен чистартып тапшырыр алдыннан стаканнар тагын чынлап алды. Тагын Габидулла җырлады. Тагын бер тозсыз җыр яңгырады. Монысын авыз ерып, Асафка карап җырлады.

Алтын микән, көмеш микән
Кулыңдагы балдагың.
Борын чөеп йөргән идең —
Әллә кемне алмадың.

— Ну-у! — диде Шәрәф урыныннан торып. — Ну-у! Что это такое?

Әмма Зәйтүнә аның гимнастерка итәгеннән тартып утыртты. Колагына үрелеп пышылдады:

— Җырласын, Шәрәф абый, тимә. Әлегә әйбәт ул. Аның холыксызлана башлар алдыннан җырлый торган бер җыры бар. Шул җырдан соң аны һавага алып чыгарга кирәк. Бу — сиңа йөкләнә, — дип Шәрәфкә матур итеп карады.

— Менә, кияү, үзең тапкан карта, тарт та йолык инде, — диде Габидулла. — Без силом бирмәдек, үзең эзләп алдың, итагедали.

Шул вакыт хатыны аңа тагын «дыңк» итеп төртте. Габидулла, беренче тапкыр күргәндәй, гаҗәпләнеп аңа карап алды. Мәҗлес кыза төшкән иде. Әлегә һәркем исәп җыя сыман иде. Габидулла хатынына бәйләнде.

— Син алай төртмә, — диде ул каз ботына горчица сөртеп. — Дөрес, кайвакытта үзеңнекеләрне дә кыйнарга ярый, — Ул карашына тирән мәгънә бирергә тырышып, Асаф белән Шәрәф ягына күз ташлады. — Дөрес, кайвакытта, инагыда, и по своим надо бить.

— Юк! Юк! По своим бить нельзя! — дип Асаф сикереп торды.— Ялгышма, кайнагай! По своим бить нельзя!

— Үзеңнекеләргә атаргамы? Не поз-з-з-волю!

Монысы Шәрәф икән. Шәрәфнең стакан тоткан кулы калтырый иде.

— Үзеңнекеләргәме? Не-е-т! Нет! Мин, беләсезме, штрафнойга ни өчен эләгә яздым! — Ул урыныннан торды. Бәлешкә шулпа өстәп маташкан Бибиҗамал түти шикләнеп, аның терсәк астыннан китте. — Үзеңнекеләргә кул күтәрергә ярамый! Ярамый! Үзенекенә кул күтәргән семья, оешма, дәүләт яши алмый. Без Гродноны азат итәр алдыннан теге якка чыктык. Задание үтәдек — хәзер монда сөйләп тормыйм, минем өченче йолдызым шуның өчен. Камышлыктан шуышып кайтабыз, таң алды. И шунда нәрсә булды? Үзебезнекеләр ата башлады— немецлар дип белеп. Прәме безнең өскә. Безне обнаружить иттеләрме, әллә болай гынамы, бервакыт немец сала башлады өскә. Ике ут астында калдык. Немец атты да тынды, ә безнекеләр селкенгән бер камыш төбенә сибәләр генә. Бер иптәшебезнең ботын умырып ташлады— разрывной белән. Үзебезнекеләр... Понятно? Лейтенант сикереп торды — нибары илле метр ара калган иде — кычкырды: «Что же вы делаете, сволочи! По своим бьете!» — дип. Тагын очередь. Тагын егылдык. Инде яралы иптәшне өстерибез. Ун метр калгач лейтенант тагын кычкырды: «Сволочи! Всех перестрелю!» — шуннан соң гына тындылар. Укрытиега шуып төштек — төшсәк, каршыбызда япь-яшь кечè лейтенант. Кичә генә курс бетереп килгән икән. Сикереп тә төштем, бруствер өстеннән, яңагына китереп тә салдым. Малаең дер-дер килә!

Кара, мин әйтәм, кемне харап иттең син! Ике солдаты бочком, бочком шыкайдылар. Аннан мине особый отделга. Ике «Слава» булмаса мин беткәнием. По своим бить — иң кечсез, иң акылсыз кешенең эше, кода! Бу сүзне, знаешь, ничек? Халыкча әйтсәң, болай: авызыңнан җил алсын, әллә кай төшеңнән диләрме, буран уйнасын! По своим — не позволю.

Асаф сокланып аны тыңлады. Акыллы, тәҗрибәле кеше бу Шәрәф. Моңа укырга, тагы да үсәргә иде. Асаф шунда ук Зәйтүнәгә борылып карады. Зәйтүнә сөрмәле күзләрен зур ачып, йотылып Шәрәфне тыңлый иде. Була шундый табигый сафлык, гүзәллек. Ул гади матурлык була. Ул матурлык кыз баланың күзләренә, керфекләренә, бит уртасындагы чокырларга, чәч толымнарына таралган, чәчелгән була. Ул матурлык кычкырып тормый, әмма ул үзенә игътибар, наз, сөю сорый. Ул матурлык «минем кадеремне белегез, югыйсә, мин әрәм булам» дип кисәтеп тора. Игътибар күрсәтсәң, кадерләсәң, андый тыйнак матурлык күзгә күренеп, назга әйләнә. Зәйтүнә шундый тыйнак гүзәл иде. Асаф аның сөрмәле күзләренә, наз өмет иткән юеш иреннәренә, ап-ак беләкләренә карап сокланып утырды. «Җаныкаем! — дип дәште ул аңа эченнән генә. — Әгәр дә син ничә еллар инде мине газаплаган теге сихри төшне туктата алсаң... Әгәр дә син теге газаплы ләззәт биреп югалган Сылуны алыштыра алсаң, мин сиңа мәңгелек кол булыр идем. Сине ничек таптым соң әле мин... Дөньяда яшәү — нинди бәхет...»

Шәрәфнең кулында гармун иде. Җырны келт иткән йомыш чыгуга почмак якка торып йөгерергә әзер икәнлеген белдереп утырган Гаделия башлады. Асаф белмәгән сугыш вакыты көе иде булса кирәк.

Кичә генә бүләк алдым,
Җибәргән гүзәлкәем.
Ул сагынып бүләк салган,
Онытмаган гөлкәем.

Җырның кушымтасын таза, калын күкрәкле җиңгәчи күтәреп алды.

Аһ, җаным, гөлгенәм
Җир йөзендә бергенәм.

Күрәсең, фронтовиклар чыгарган җыр бу.

Җыр ярты сәгатьтләргә дәвам итте. Шәрәф арып, инде гармунын куям гына дигәндә, бөтенләй икенче көйгә ачы тавыш белән Габидулла җыр башлады. Зәйтүнә куркынып Шәрәфкә пышылдады:

— Шәр-рәф абый! Булды! Теге җырны башлады. Хәзер тавыш чыгарачак...

Габидулла авызын зур ачып, үзе генә белгән көйгә сөрән салды.

Китәмен илегездән,
Бик туйдым үзегездән.
Яшел башлы үрдәк булсам,
Су эчмәм күлегездән.

Шәрәф шунда ук сикереп торды. Асафка күз кысты. Егет тә бу алдашны тиз аңлап алды.

— Дуслар, туганнар, — диде Асаф. — Тәнәфес ясап алмыйбызмы? Әйдәгез, һава сулап керик...

Барысы да дәррәү кузгалдылар. Әмма Габидуллага карап баскан җирдән туктап калдылар.

— Нинди һава! — дип сүз чыгарды кода. — Нинди һава? Ник аны турыдан-туры әйтмисең? Син лучше әйт: давай, диген, кайнагай, без

синнән туйдык диген, син диген, давай моннан аттыравәләй. Кара син аны, ә? Һавага, понимаешь. Һава суларга, итагедали. Миңа монда урын юкмыни инде? Ахирәттә Әхмәдигә урын юк дигәндәй...

Шәрәф коданың җиңеннән инде ныклап тоткан иде. Әмма кода нык торды.

— Һавага, понимаешь. Олы абзардан кече абзарга һас дигәндәй. Кара кительләр киеп, алтын нашивкалар тегеп кайткач та. Андый бөгештрәлизацияне беләбез без. Ваенный техникум бетердем дигәч тә. Менә минем үземнең кызым быел бетерә унынчыны. Алтын мидалга тарта. Дөньяда сез генәме әллә? Һавага, понимаешь. Менә шул инде ул: сөйләшә белмәгән авыздан... белгән... яхшы.

Зәйтүнә бернигә карамыйча өстәлдән савыт-саба җыештырып йөри иде. Абыйсын ул тыңламады, ул бәхетле иде. Ыгы-зыгы килеп өй алдына чыктылар, хатын-кыз чәй хәстәренә кереште. Габидулла өй алдында «Прибой» кабызгач та бәйләнеп маташты. Ләкин якын-тирәдә Асаф юк иде. Фатыйма апа аны мунчага җибәрде.

— Бар, улым, күз-колак булып кайт, суынмаганмы, урын-җирләре рәтлеме, чистамы, кодаларны шунда кундырырбыз, — диде.

Асаф ялан баш, ялан өс абзар артына таба караңгылыкка кереп югалды. Карга бата-бата мунчага юнәлде. Ахрысы, сукмагын бутады. Өйалдында халык гөрли иде. Габидулла тавышы барысыныкын да күмә:

— Нинди һава әле ул, утыра башламас борын. Аның тәртибе бар. Алай мәчет саен бер әттәхият белән ярамый ул. Менә мин үзем узган җәй бер дуңгыз баласы алып симерттем. Алай «һавага» дип кенә булмый бит. Трахмальный завуттан атхут алып. Итагедали.

Ак мунчаның өйалды ишеген ачып җибәрүгә Асаф имәнеп китте. Өйалды сәкесенә куелган лампа яктысында күз аерып бетерми иде, шулай да аңа каршы бер кеше гәүдәсе килде дә, кайнар сулышын өрде.

— Асаф! Бәгырем! Ник терелдең син? Син инде бер үлгән идең бит! Ник бу кадәр бәхетсез мин?

Асафның күкрәгенә кайнар, тулы, йомшак бер гәүдә кереп сыланды. Вазелин исе, мамык шәл исе, майлы ризык — бәлеш исе борынга бәрде. Гаделия икән. Егет айнып китте.

— Гаделия, синмени, туганкай? Әллә эчтеңме? Ни булды? — дип дер-дер килде ул.

— Юк, бәгырем, юк, эчмәдем... — Гаделия аның муенына ташланып, бөтен гәүдәсе белән елый башлады. — Син дип кенә яшәдем мин. Син үлгәч үлдем. Син терелгәч тагын бер терелдем. Инде бүген терелмәслек итеп үтердең. Җанашым! Бәгырем! Ah-ah-ah...

Асаф югалып калды.

— Тукта әле, Гаделия, болай ярамый бит.

— Ярый! Яр-рый. Бүген минем соңгы төнем, яр-рый! Әйдә, җаныкаем, курыкма. Син батыр егет бит. Курыкма, монда беркем килми. Әйдә, менә мин ишекне эчтән биклим.— Гаделия пышылдауга күчте, йөгереп барып утны сүндерде, Асафны эчкә өстерәде. — Курыкма, җанашым, ичмасам мин дә... Бүген минем актык төнем, мин шушының өчен генә килдем әнисең янына.

Алар инде мунча эчендә иде. Гаделия авыр кочаклап Асафның муенына асылынды да, аякларын идәннән алды. Асафның башы әйләнеп китте. Гаделия кайнарланып егетнең иреннәренә ябышты.

Асафның баш миеннән яшен тизлегендә бер фикер узды: ике тәүлектән бирле аның белән гел эреплешәләр иде. Монысында нишләргә? Ул телсез калды. Нишләргә?

Тышта кар шыгырдады. Икесе дә сискәнеп киттеләр. Асаф йөгереп мунча чоланына чыкты. Иңенә шәл салып, тар сукмактан килгән кеше Зәйтүнә иде.


'» № 5.

— Кая югалды минем героем? — дип чыркылдап көлдә дә, Асафны кочаклап үпте. Бу — аларның беренче кочаклашулары, беренче назлары иде. — Әйдә, егетем, киттек. Әнкәй җибәрде мине, бар әле, нигә күренми ди.

Асаф аны иңеннән кочаклап тар сукмактан атлап китте. Аркасы белән сизеп торды: мунча өйалдының ачык ишегеннән боларны Гаделия карап калды. Авыр, бик авыр иде. Абзар аркылы узганчы көтеп тордылар: абзар баганасы янында аякларын киң ерып Габидулла баскан, үзе мыгырдый. Әлегә аның янына килергә ярамый иде: «Һавага чыгам, дигәч тә... Итагедали. Имеш, сеңелне укыта. Имеш, диплом алдырта. Укуына мешәйт итми. Торырга фатирың булса яратырсың әле. Эрләмәгән-сукмаган, Шаһи, сиңа ыштанлык дигәндәй. Әнә, Мингазов малае...».

Ләкин Зәйтүнә өчен бу көтеп тору бик бәхетле бер мизгел иде, ул Асафның яңагыннан сыпырды, үзе еш-еш сулый, үзе елый да иде булса кирәк.

Чәйдән соң кунаклар кузгалды. Шәрәф кунарга Бибиҗамал түтиләргә китте, күрше-күлән дә рәхмәт әйтеп таралды. Фатыйма түтине дә кемдер үзе белән алып китте.

Тыныч, көтелгән, законлы төн башланганны белдереп, Асаф унлы лампаны сүндерде.

Февраль иртәсенең кызгылт кояшы чыкканда кияү белән кәләш кунган йортның юылган, чиста баскычында мех тун кигән, мамык шәлгә төренгән бер гәүдә күреп, кешеләр телсез калдылар. Гәүдәнең ялангач кулында бер кәгазь бар иде.

«Минем үлемемә беркемне дә гаепләмәгез, моны дөньяда ике генә кеше белә. Мине ярмагыз, гаеп итмәгез, хушыгыз».

Йортны, авылны кара кайгы басты. Шәрәф килеп җитте. Ялт кына кызның тунын чиште, кофтасын чиште. Ятып тыңлады.

— Атны! Атны җигегез! — дип кычкырды ул. — Әй, кайсыгыз! Атны...

Җыелган халык җан-фәрман чыгып чапкан атлы чанага карап, күз яшен сөртеп калды. Чана тәрәге артына Гаделиянең мамык шәленең бер почмагы чыгып асылынган да, кар буранында җилфер-җилфер килеп бара иде.

## XXV

Гомер... Ни арада үттең әле син? Әле бит яши дә башламаган. Әле бит гел яшәргә әзерләнү генә, гел әзерләнү генә. Карасаң — гомер үтеп бара икән. Ни өчен гомернең кайбер еллары, айлары, көннәре хәтергә уелып кала? Ни өчен кайбер еллар, айлар, көннәр онытыла? Кеше әллә еллар, айлар белән түгел, секундлар, минутлар белән яшиме икән? Гомер агышына маякларны әллә әнә шул мизгелләр куеп, утыртып барамы? Бәлки шулайдыр, шулайдыр. Әмма яшәгән саен йөрәк туза, баш мие туза. Кеше картаймас өчен иртән йөгерә, кышын су керә, аракыны, тәмәкене ташлый, төнгә кефир эчә. Әмма йөрәк туза, баш миендәге ниндидер күзәнәкләр үлә, ми картая.

Хәрби академиядә укыганда гомер тиз узды. Зәйтүнә, әлбәттә, институтны тәмамлады, мәктәптә эшләде. Барысы да көйле, барысы да әйбәт иде кебек. Әмма яңадан учебный отрядка укыту бүлеге мөдире булып кайткач, тормыш көтелмәгән һәм көтелгән кайгы-хәсрәтләрен алга чыгарып куйды. Фатыйма апа улы, килене белән шәһәрдән-шәһәргә, квартирадан-квартирага йөри торгач, кинәт кенә җирсенә башлады, авылга кайтарып куюларын үтенде. Йортны ачып, аны ялгыз яшәргә дип Симетбашка кайтарып куйдылар. Соңгы тапкыр аэропорт ресторанында утырган вакыт хәтердә калган. Асаф ул вакытта инде

мыекларына аксыл көмеш керә башлаган зур гәүдәле офицер — өченче ранг капитаны иде. Ресторанда дүртесенә — ул вакытта Нәзирәгә биш яшь иде — өстәл алдылар, ресторан тулы хәрбиләр иде. Аш китергәнче күпме офицер өстәл янына килеп Асаф белән исәнләште. Кайсы академия, кайсы учебный отряд буенча танышлар иде. Официантка кыз беренче чиратта өлкәннәрне карады: залда бер адмирал, ике полковниктан кала өлкән званиедә Асаф иде. Асаф беркайчан да әнисеннән яшереп эчмәде: бу юлы ике рюмка коньяк башына китте, ашны ашый алмады. Бу — әнисен уләргә озатып кую иде. Кайда сез теге, дәртле еллар? Кайда тегесен тегеләй, бусын болай итәм дип йөргән көннәр? Әнисе кайтачак, Асаф белән Зәйтүнә аңа күп итеп акча җибәреп торачаклар, ә ул күршеләрдән кружка белән сөт сатып алачак, терт-терт атлап авыл кибетенә чәй-шырпыга йөриячәк... Шулай аерым яшәп, аерым үләр өчен гаилә корыламы? Баланы шулай аерым үләр өчен үстерәләрме? Асаф шуның өчен сугышып йөрдеме? Юктыр, бу хәл кемнендер хатасы аркасында гына шулай килеп чыккандыр...

Әнисе чәен эчеп бетерде, бөтен ресторанны гаҗәпкә калдырып, бик һәйбәтләп дога кылды. Алтын галуннар, ялтыравыклы погоннар, хрусталь, «Алтын руно» тәмәкесенең затлы төтеннәре, хикмәтле люстралар, һәр ун минут саен динамиктан ишетелеп торган «Самолет рейсом... вылетающий...» кебек тавышлар фонында бер карчыкның ике кулын битенә күтәреп иренен кыймылдатып утыруы күпләрне сәерсендерде. Асаф та, Зәйтүнә дә, бәләкәй Нәзирә дә моңа гаҗәпләнмәделәр. Карчык кеше, димәк, шулай кирәк тапкан...

Аннан Нәзирәне лесхозда пионерлагерьда калдырдылар. Җәен ул шунда дәү әнисендә (Зәйтүнәнең әтисе Низаметдин абзый, яралары яңарып, сызланып озак яткач, дөнья куйган иде) җәй буе торырга тиеш иде. Аны алырга көзен Зәйтүнә кайтырга тиеш иде. Әйе, Зәйтүнә тиеш иде. Ләкин, бәндә сагышлый, ходай багышлый диләр.

Хәрби академия тәмам. Зәйтүнә диплом алды. Нәзирә әйбәт, акыллы, сәламәт булып үсеп килә. Тик Фатыйма апа гына — аның ялгызлыгы гына борчый. Ләкин тормышта борчу белән борчуның аермасы зур. Шатлык белән шатлык үзара охшашлар, алар кайдадыр, бер урында тоташып, кушылып китәләр. Ә борчулар — һәрберсе үзенчә. Нәзирәне август ахырында алып китәргә туры килмәде. Асаф зур учебный отрядның укыту эшләре бүлеге мөдире буларак эшкә кереп чумган иде. Көн саен җыелыш, көн саен киңәшмә. Яңа набор — сугыш вакытының ачысын-төчесен әти-әниләре сөйләгән буенча гына белә торган яшьләр киләсе көннәр иде — укыту-тәрбия эшләре буенча командованиенең көн саен диярлек бер приказ җибәреп торган көннәре иде. Лесхоз почта бүлегеннән «молния» килеп төште. «Немедленно вылетайте оба. Габидулла». Шул көнне бугай Асафның чигәсендә беренче ак чәчләр күренде.

Алар туры лесхозга кайтып төштеләр. Райком машинасы Симетбаш аркылы узды. Асаф — әле дә ышанып бетә алмый — үз әнисенең капка төбеннән машинада узды. Йөрәге урынында түгел иде.

Гөлбәдәр түти дә, Габидулла да юашланып калганнар — үзгәргән, сагышлы йөз белән аларны капка янында каршы алдылар. Зәйтүнә әнисен кочаклап үкереп елый башлады. Асаф машинадан чыкты, фуражкасын салды, күк йөзенә карады: кояш сары, дөнья сары, дөньяда сулау өчен кислород юк, тын буыла иде. Ул Габидулла янына килде, әллә күреште, әллә күрешмәде. Шушы юньсез, рәтсез мужикның күз карашында, авыз ачып сөйләшүләрендә Зәйтүнә белән уртак нәрсәдер бар иде, Асаф шул рәтсезне гомергә яратты.

— Слушай,— диде Асаф, фуражкасын әйләндергәләп.— Слушай, синең берәр стакан эчемлегең юкмы, калган? Минем хәлем бик начар. Минем күзләрем күрми.

Асафны җитәкләп алып кереп салдылар. Байтак вакыт ул дәшмичә ятты. Аннан сорап куйды:

— Кайчан күмдегез?

Габидулла авыр итеп тамак кырды.

— Кичә төшкә кадәр. Ике көн асрадык, җәй көне, үзең беләсең, итагедали...

— Иң соңгы сүзен ишеткән кеше бармы?

— Бар, әкәк же. Бар. Мингазов малаеның кызы белән бергә коенганнар. Шул ишеткән.

— Нәрсә дигән? — Асаф авыр ыңгырашты.

— Әт-ти! — дип өзгәләнеп өч тапкыр кычкырды ди. Калкып чыга да кычкыра, калкып чыга да кычкыра икән, наный. Яннарында бер кеше дә булмаган. Без килеп җиткәндә Мингазов малае су эченнән күтәреп чыгып килә иде. Бер сәгать кәчәйт иттек — юк, зәп-зәңгәр, иреннәре балавыз*күк...

— Ул бит бик әйбәт йөзә иде. Мин бит аны бассейнга йөрттем. Аннан — диңгездә.

— Монда да шул — күлне аркылы чыкмакчы булган. Әнә теге яктагы каеннар янына чыгып керәм дип киткән, наный. Анда уртада салкын источник бар, шуңа туры килгән. Без — юк, бездән сорап киткән эш түгел. Күрәчәктер инде, туган, күрәчәктер. Инде безне ыстыруйдан чыгарды бу — аңгы-миңге килеп тик йөрибез. Сезнең алда да уңайсыз.

— И, ташла әле шул сүзеңне. «Әти» дигәнме?

— Ие инде, ие. Мингазов малаеның кызы үзе әйтеп тора.

Асаф авыр ыңгырашты.

— Уй-й-й. Никләр генә сугыштан исән кайттым икән мин? Никләр генә госпитальдән туганнар каберлегенә илтеп күммәделәр икән мине. Нигә, ни өчен миңа мондый җәза? Кемгә, нәрсә эшләдем мин? Минем ни гаебем бар бу дөньяда? Кемгә, нинди зыян эшләдем соң мин?

Габидулла аның янында стакан тотып утыра иде.

— Бик авыр хәл, кияү, аңлыйбыз. Инде күрәчәк шулай булгандыр. Упшым, болай: үлгән артыннан үлеп булмый, пока исәнлегегез бар, бала тагын туар ул. Үзегезнең нервларыгызны саклый күрегез инде. Бигрәк тә сиңа — син бит кантузия алган кеше. Итагедали. Үткән эшкә салават.

Кыш уртасында Асаф әнисен җирләп килде. Хәзер аны бу дөньяда бәйләп торучы бер генә кеше — Зәйтүнә генә бар иде. Борчу-хәсрәт тормышны үзгәртте дә куйды. Аның чигәсендә ак чәчләр күренде. Әнисе «ак чәч — үлем хәбәре» дип әйтә иде. Кичләрен эштән кайтканда Зәйтүнә учебный отрядның ишек төбенә килеп тора да, алар бергә култыклашып кайтып китәләр, иртән эшкә киткәндә кем кайчан бушый, сәгать ничәдә кем кая килеп торырга икәнен килешеп, вәгъдәләшеп аерылышалар иде. Йортта уен-көлке бетте, йортның мамыгы калмады. Кайсы гына бүлмәгә керсәләр дә, нәрсә генә актарсалар да, Нәзирәнең берәр уенчыгы, ясаган рәсеме килеп чыга. Квартирага берничә ел буена ремонт ясатмадылар: теш чыккан вакыттамы икән, Нәзирә коридор стенасыннан штукатур ашады. Болай гына түгел, тәмләп ашый иде: авызына шоколад каба да, шуны җебеткәч, буе белән коридор стенасына иреннәрен тиереп чыга, аннан шул урыннарны ялый иде. Коридор стенасы буенча бераздан чия-кызгылт сызык ясалды. Ул сызыкның иданнән биеклеге Нәзирәнең шул елдагы буен күрсәтеп тора иде.

Ике ел буена Асаф саташулы, газаплы йокы белән җәфаланды. Теге, онытылган куркыныч төш кабат әйләнеп кайтты: Асафның өстенә чайкала-чайкала авыр танклар килә, ләкин беркайчан да аның кулында ни граната, ни ПТР булмый иде. Шуның өстенә ин куркыныч мо-

ментта, каяндыр, танк астыннан йөрәк өзгеч тавыш ишетелеп, бәгырьне телгәли иде:

— Әт-ти!

Берничә елдан соң гына Асаф әллә ниткән җан тетрәткүле хис белән Зәйтүнәне култыклап балалар табу йортына илтеп куйды. Нигәдер, шатлык та, билгесез борчу да иде бу. Зәйтүнә анда чама белән әле бер атнадан соң гына барырга тиеш иде, югыйсә. Иртән больницага кертеп куйды, кичен хәлен белергә дип больница ишегендәге кечкенә тәрәзәне чиртте.

— Фамилия? — диде китап укып утырган ак халатлы хатын.

— Рәимова...

Асаф түземсезлек белән Зәйтүнәне көтте. Учебный отрядта дежур торып үткәргән төннәрдән тыш аларның теге вакыйгадан соң бер генә тәүлеккә дә аерылганнары юк иде. Паркетта аяк тавышлары ишетелде. Тәрәзә кабат ачылды һәм аннан ак калфаклы мөлаем хатын күренде.

— Кемне көткән идегез?

Асаф кабатлады. Мөлаем хатын елмайды:

— Кемне көткән идегез?

Асаф тагын кабатлады. Хатын йөзенә ясалма ачу чыгарды.

— Карагыз әле, иптәш икенче ранг капитаны! Ничек хәрби кеше булдыгыз сез? Сездә акрынайтылган реакция икән. Малай көттегезме, кызмы, дип сорыйм мин сездән...

— Ничек? Юк, сез бутамагыз, аның әле...

— Уф-ф... Мин сезгә «сез аңгыра» дип әйтер идем, әгәр сез чибәр ир кеше булмасагыз... Сезнең улыгыз бар, улыгыз! Аңлашыламы?

Асаф фуражкасын салды. Ул әле барыбер аңлап бетермәгән иде. Теленә килде. Менә мондый сорау бирәсе бугай:

— Икесе дә сәламәтләрме?

— Әйе, әйе. Хатыныгыз әле йоклый, аны борчымагыз. Ә улыгыз болай диде: әти диде, бер шешә «Кристалл» алсын да, үзенең иң якын дустын өйгә чакырсын диде. Кызлар янына чапмасын диде. О-о, беләм мин чибәр кешеләрнең гадәтен... Минем шундый ирем булса иде, мин аны нишләтәсен белер идем, — дип мөлаем хатын сагышлы елмайды.

Асаф урамнан әллә кайтты, әллә ул тик торып, урам үзе аның аяк астыннан шуып торды.

— Кара әле, Костя, — диде ул капитан-лейтенант Рыжкога телефоннан дәшеп.— Кара әле: эш болай булып китте бит әле, парень. Малай туган, малай! Әйе, булачак Ватан сакчысы туган. Син безгә кил әле хәзер, службада эшең бетсә. Мин гастрономга йөгерәм.

Костя Рыжко киткәч, Асаф диванга сузылып ятты һәм йокыга талды. Йокысында аны гаҗәп рәхәт тойгылар көтә иде. Әлбәттә, башта танклар килде (кичтән бер генә рюмка эчсә дә, ул саташа иде), ләкин иң куркыныч моментта гадәттәгечә аңа граната яки ПТР сорап кычкырырга туры килмәде. Могҗиза булды: кинәт кенә күршедәге окоптан ике кулына ике граната тоткан яшь-яшь бер солдат килеп чыкты һәм бер-бер артлы гранаталарын танкларның балчыклы, куркыныч тамак асларына тондырды. Танклар туктап калдылар һәм алардан ургылып кара-зәңгәр төтен бәрде. Шул вакыт яшь солдат кинәт борылды да Асаф янына сикерде, аны кочаклап алды да, кызлар тавышы белән «әт-ти» дип кычкырды.

Аннан, әтисен үпте дә:

— Әти, курыкма, танклар бүтән юк. Мин синең улың — Илдус булам, — диде.

Тәнгә дөньяда әле моңарчы татымаган җиңеллек, сафлык таралды. Асаф сабый бала йокысы белән изелеп йоклады.

Иртәгесенгә бу төштән менә нәрсә хәтергә уелып калды: малайның исеме Илдус булачак иде.

Төшкә ни кермәс. Төштә танкны да шартлатуы җиңел. Тик йөгереп кенә булмый төштә...

## XXVI

Ул көннәрдән соң яшәү җиңеләеп китте. Йөрәк җәрәхәтләре күмелеп калган сыман булды. Француз язучысы Гюстав Флоберның әйткән сүзләреннән бер җөмләне Асаф үзенең күптәннән алып барган көндәлек дәфтәренә күчереп язып куйды: «Газаплардан киңәя-киңәя кешенең җаны шундый гаҗәп бер халәткә ирешә — кайчандыр рухыңның кырыеннан ташып чыккан хәсрәт-борчулар бервакыт җаныңның төбен дә каплап бетерә алмыйлар». Шулай, Зәйтүнәне күргән, аркасыннан килеп ятагында беренче тапкыр аны кочаклаган иртәдән соң сихри әкият — Сылу — ут чәчәге Сылу — аска күмелеп калды. Шулай, фаҗигале үлгән, курчактай гүзәл Нәзирә кайгысына, ялгызлыкта үлгән әнисе килеп кушылды да, бу ике кайгы бер-берсен күмештеләр, бетерештеләр. Тик чәчләргә көмеш кенә тизрәк, мулрак ява барды. Аннан инде тормыш тагын билгеле бер көйгә керде — Илдус үсә башлады. Ир бала тапкан хатын тагын да гүзәлләнеп китә дип Асафның ишеткәне бар иде — үз күзләре белән күреп ышанды: Зәйтүнәнең бөтен гәүдәсенә, йөзенә сагышлы сылулык өстәлде.

Тик, сирәк-сирәк кенә, я эштә, я җыелышта нервларны кузгатырлык хәлләр булганда, йөрәк бозгыч сүзләр ишеткән көннәрдә генә Асаф узган тормышына әйләнеп кайта, тормыш юлындагы сөюләр, газаплы аерылышулар, югалтулар, сугыш кырындагы гарасат, яшьли һәлак булган солдатлар, батырлыклар, хыянәтләр дулкын-дулкын булып хәтеренә ишелеп киләләр дә йөрәкне телгәли башлыйлар иде. Әмма боларның барысына берьюлы каршы тора алырлык бер көч өстәлде аңа хәзер: андый көннәрне кич, бала бүлмәсенең утын сүндергәч, Асаф малае янына кереп китә дә, аның юрганы астына чума, малайның аркасыннан кочаклап, борынын аның җылы, мамык чәчле ялган чокырына төртеп озак ята: рәхәт-рәхәт була, кан сафлана, әрнүләр юк була. Ә малайның ялган чокырыннан яңа чыккан каз бәбкәсе исе килә, малайның кечкенә йөрәге кош йөрәгедәй дөп-дөп килеп ашыгып, ваклап тибә, малай үзе борынын сызгыртып йокыга чума. Ата кешегә шуннан да ары тагын ни кирәк? Тик иркәләгәнне, сөйгәнне белмәсен генә иде бу бала, иркә булып үсмәсен иде бу. Андый балалардан начар солдат, начар матрос, начар офицер чыга. Иркәләрдән Ватан сакчысы чыкмый...

— Асаф, Асаф дим! Бу якта үземә генә күңелсез, — дип ике иренең тигез сулап ятуыннан көнләшеп тә, кызыгып та, сокланып та, алар янына Зәйтүнә керә, Асафның да, Илдусның да яңакларыннан сөя.

— Үземә иптәшкә бер кыз алып кайтмыйча булмас, — дип сагыш белән авыр сулап куя Зәйтүнә. Алып кайт, алып кайт, җаныкаем, әгәр ул сиңа ошаса, синең кебек кыйгач кашлы, тирән карашлы, озын толымлы бер кыз булып үсәрдәй булса, әгәр ул җир йөзендә туачак тагын бер егетне бәхетле итә торган булса, алып кайт, җаныкаем...

Мең тугыз йөз җитмеш дүртенче елның ахырында, сәламәтлеген исәпкә алып, Оборона министрлыгы Асаф Рәимовны тынычрак хезмәткә күчерергә карар бирде. Җитмеш дүртенче елның ахырында, семьясын хезмәт иткән шәһәрендә вакытлыча калдырып, ул Идел буе хәрби округы командующие карамагына «для дальнейшего прохождения службы» килеп төште.

Бөтен ил Бөек Ватан сугышында җиңүнең утыз еллыгын бәйрәм

итәргә әзерләнә иде. Шәһәр ресторанында ашап утырганда Асаф янына, кин елмаеп, күрше өстәлдән күчеп берәү килде.

— Сезнең тынычлыкны бозарга рөхсәт итегез, иптәш икенче ранг капитаны?

— Шәрәф! Ничек, нинди җилләр белән?

Шәрәф һаман елмайды.

— Гафу итәсез, иптәш икенче ранг капитаны. Мин — Шәрәф түгел, ә Ташлытау райкомының секретаре Шәрәф Җиһангирович Солтанов булам.

Кочешеп кочаклаштылар. Шәрәф үзенең тарелкасын күтәреп күчеп килде. Секретарьларның зона семинарында икән. Хәрби-патриотик тәрбия мәсьәләләре буенча киңәшмә уздырганнар.

— Яшьлегемә кире кайттым бит әле, туганкай, — диде Шәрәф. — Полигонда булдым, хәрби учениеләрне күрсәттеләр. Техника, осталык — гаҗәп. Хәер, син инде аның эчендә кайныйсыңдыр. Син нишләп йөрисең монда? Коры җирдә?

— Ә мин бит тегендә дә коры җирдә. Дәрес бирүдән ары узмадык инде без. Елына бер диңгез күреп. Кайчаннан бирле күрешмәгән? Илле өчтәнме? Әйе, мин шуннан соң кайтмадым. Ел саен санаторийда.

— Я,ниләр күрдең? Кайларда булдың?

— Гел бер урында дип әйтер идем, илле өчнең көзендә Лондонга барып килдек. Королеваның тәхет бәйрәменә. Шуннан бирле — укыту, бер үк шәһәр.

— Да-а... Без, парень, чумдык монда. Партшколаны бетереп кайтуыма — секретарь итеп. Сезгә ит, сөт, икмәк әзерлибез. Кительләрегезне, шинельләрегезне тегәр өчен сарык асрыйбыз. Шулай да кая барыш?

Асаф сөйләп бирде. Шәрәф аны тынлаган сыман итеп утырды, әмма Асаф сизде: Шәрәф нәрсәдер, башканы уйлый иде.

— Так-так, — диде ул кабызмаган сигаретын өстәлгә төрткәләп.— Так... Димәк — командующий карамагына. Так... Шуннан кая?

— Без — солдат. Син аны үзең дә беләсең.

— Ярый, ярый. Солдат дисең инде, алайса.

— Әйе, солдат.

— Ә син бу семинарда командующий белән минем лично танышканны беләсеңме соң әле?

— Нәрсә, сугыш буенча танышмы?

— Шулай булып чыкты. Минем соңгы «Слава»га представление ясаган начштаба булып чыкты.

— Кызык. Сөйләштегезме?

— Нинди ул сөйләшмәгән. Кыен хәлгә калдырды. Үзенең чыгышында әйтте: сезнең арагызда диде, полный кавалер «Славы» утыра. Андый батырлар юлда аунап ятмыйлар ди, а ну, товарищ Султанов, прошу встать! дип бастырып та куйды. Ни өчен семинарга орденнарыгызны тагып килмәдегез, иптәш Солтанов, дип кызартты.

— Шәрәф! Шулкадәр бәхетле син. Молодец син!

— Ярар, ярар. Значит, шуның карамагына. Партстаж? Кырык икедән. Бергә кергәнбез икән. Алай, алай...

— Син нәрсәдер мухлевать итмәкче буласың?

— Ә? Юк, просто бер идея бар иде. — Шәрәф сигаретын кабызды.— Слушай! Военком картайды, понял? Синең белән безне алганда ул өченче частьта утыра иде. Гомере буе бер эштә. Тузган, отставкага китә быел. Назиров, син аны беләсең.

— Шуннан?

— Вакансия! Менә дигән!

— Ну-у, ничек инде... Үз районыңа. Мине дөрес аңламаслар, туган. Беркайчан да, беркемнән дә үзем өчен берни дә сорамадым, дип әйтер

идем, кызым үлгәндә, әнине күмәргә — бер елда ике тапкыр рапорт язып сорарга туры килде.

— Да-а, сине дә тетрәтте бу тормыш. Димәк, килештек. Калганын мин үзем сөйләшеп карыйм.

Алар икесе дә бер үк гостиницага туктаган булып чыктылар.

Ә өч көн узгач Зәйтүнәгә телеграмма килде: «Ташлытауга военком итеп билгеләндем багажларны озатып бетерүгә рейсыгызны әйтеп телеграмма бирегез сезне сагынып эти».

## XXVII

Шәрәф биргән «Газик»та Асаф районның бөтен авылларын йөреп чыгарга булды. Райком, военкомат күрсәтмәләрен колхозларда, мәктәпләрдә ничек үтиләр? Хәрби патриотизм тәрбияләү эше ничек куелган? Июнь ахырында булачак райком пленумында яңа военкомны районда хәрби-патриотик тәрбия эшләренең торышы буенча тыңлаячаклар иде.

Капкаларда кызыл йолдызлар. Симетбаш урамыннан узганда Асаф шуларга игътибар итте. Бу турыда мәктәп директорларының моннан бер ай элек булган киңәшмәсендә ул ялкынлы чыгыш ясаган иде. Һәр фронтовикның капкасына кызыл йолдыз куярга. Фронтовиклар авылда аз калган хәзер. Капкалар яңа, каралтылар төзек, әмма йолдызлар аз. Менә машина аның туган нигезе турысына килеп җитте.

— Бер-ике минутка туктыйк әле, туган, — диде ул райком шоферына. — Бу нигез миңа таныш иде.

Нигез... Капка-коймалар күптән инде юк. Югыйсә, бер йолдыз монда да торыр иде. Йорт инде юк. Ерак елларның истәлеге булып ботаклары кайшалып сынган, кәкрәйгән бер алмагач утыра. Төймә кадәр генә алмалар әле дә ясала икән. Йорт урынында алабута, тигәнәк баскан бер чокыр — баз урыны. Күршеләр бу чокырга кипкән кура ботаклары, төбе төшкән чиләкләр, иске аяк киемнәре ташлаганнар. Бәрәңге бакчасы башындагы карт шомырт та әле исән икән, аның юан кәкре кәүсәсенә бозау арканлап куйганнар. Тагын нәрсәләр калган? Башка берни дә юк, берни дә калмаган. Күңелне караңгы уйлар басты. Моннан тиз генә китәргә кирәк иде. Фуражкасын салып авыр атлап чыгып барганда, каршысына мал эчерә торган чиләк асып бер карчык килеп чыкты. Күзләрен кояш нурыннан каплап, Асафка карап торды да, чиләген чирәмгә куйды.

— Әбәү, бәрәкәт, Асаф улым, синмени? — дип картаеп кипкән кулларын аңа сузды. Аннан елап җибәрде, коргаксыган беләкләре белән Асафның киң аркасына үрелеп кочакларга итте.— Синмени, балам? Туган нигезеңә килдеңмени? Безгә киттек, әйдә, улым да өйдә. Әйдә, наный, әйдә... — Бибиҗамал түти чын йөрәктән елый иде.

— И Асаф, картайдык бит инде,— дип күреште бер хатын.— Бер яшьтә бит без, бер яшьтә. Хәтерлисеңме, Миңлебай абзыйларның кыярына кергәч тотылганны? Миңлебай абзый шунда икебезне дә кычыткан белән...

— Ходаем, әллә Асаф инде...

Ул тагын бер хатын белән кочаклашты. Тамак төбенә төер утырды. Борынга таныш ис — Симетбаш суында юылып, Симетбаш җилендә киптерелгән баш яулыгының исе килеп бәрелде, моны тоймаганга утыз еллардан артыктыр. Тукта әле, дөрес эшләндеме соң үз районына кайтып? Шайтан, көчтәнәч аласы булган бит...

— Сездән аерыла алмадым инде мин, туганкайлар, — диде Асаф, һәрберсе белән күрешеп чыккач. — Булмады. Әйдәгез, бергә-бергә матур итеп картайыйк әле. Мин эш белән узып барышлый гына. Сез-

нең белән сөйләшергә аерым бер көн алып киләм. Киләм түгел, кайтам.

— Бирган булса, ходай кушсын.

Лап-лоп атлап бер ир йөгереп килеп житте. Гафур икән. Үзе быж-быж папирос суыра, үзе чак-чак тын ала, әллә каушаудан, әллә шатлыктан. Ул килеп Асаф белән күрешкәндә хатын-кыз читкәрәк китте. Асафның колагына кызгану сүзләре ишетелде.

— И-и, Фатыйма түти исән булсае...

— Йортлары да калмады шул, йортлары да.

Гафур исә, шатлыклы елмаеп, папиросын быжылдатты.

— Туры безгә китик, яшьти. Әле бүген мин дә өйдә, карчык та мунча якты.

Аннан тәмәкесен үкчәсе белән изде дә, тавышын бераз төшереп әйтте:

— Мин инде, яшьти, хатын-кызның төрлесен күрдем, күрмәдем түгел. Гаделия болай бик акыллы, сабыр булып чыкты. Дөрес, яшькә миннән зур инде ул, теге вакытта сиңа барасы килеп юләрләнеп тә йөргән. Йөрәгенә бәргән аның, яшьти. Шту син! Моның хәтле хина эчертсәң, атны үтереп була дип сөйләгәннәр духтырлар. Ә вчүже алып калганнар. Ярар инде, яшьти, ат иясенә килгәч аксамасын. Әй, яшьти, уйладым инде: хатын-кызның барысы да бер икән инде аның.

Асаф, әлбәттә, берәүгә дә кермәде. Рәхмәт әйтеп саубуллашты. Хатын-кыз елап калды. Мәктәп янындагы мәйданчыкка акшарлы обелиск куйганнар. Машина шунда туктады. Акшары яңгырда кубыкланган, урыны-урыны белән янган, корымлы кирпечләр күренеп тора. Сугышта үлгәннәрнең исемлеге куелган пыялалы рам эченә дә су үткән, исемлек юешкә җәелгән. Асаф та, шофер да баш киемнәрен салдылар. Исемлек... Һәрберсе бер кеше, үзенә генә бер кеше, кабатлагысыз шәхес иде боларның. Исемлекне, әлбәттә, үлгәннәрне белми торган яшьләр төзегән. Сорашып, эзләп язганнар. Шуңа күрә күп фамилияләрдә, исемнәрдә хата киткән. Асафның моңа йөрәге әрнеде. Обелиск яныннан ул авыр хисләр белән китеп барды. Ташкичүгә барышлый машинаны зират янында туктатты.

— Монысына мин үзем генә кереп чыгыйм, — дип шоферны калдырып, зират коймасыннан сикереп керде.

Менә, менә ул кадерле кешеләр урыны. Әтисенең кабере өстендәге агач чардуган череп авышкан, язулы такта авып төшкән, каберне тигәнәк баскан иде. Әнисенең кабере өстендә чардуган әлегә таза, таш-фәлән юк. Кемдер баш очына бер төп каен утырткан икән, аңысы яшел-саргылт вак яфраклар чыгарып үсәргә азапланып утыра.

Зиратта авыр тынлык. Черегән яфрак, кояшта җылынган черек такта исе. Кайдадыр карт агач шыгырдый, козгын коңгылдый. Монда ялгыз калып утыруы куркыныч. Йөрәк өчен, нервлар өчен хәтәр. Әмма кирәк. Вакыт-вакыт шулай кирәк. Габидулла әйтмешли, инагеда. Яшәү мәгънәсен аңлау өчен үзеңнең соңгы станцияңне искә төшергәләргә кирәк. Бу — намус белән яшәү өчен, кан юлларына утырган ташларны җебетү өчен кирәк. Асаф үлемне күп күрде — һәрберсе авыр иде, әмма бер генә тапкыр да аңа кабер янында утырырга туры килмәде. Симетбаштан киткән йөз егерме ир шулай билгесез каберләрдә Сталинградтан алып Прага, Вена, Берлинга кадәр чәчелеп калдылар. Кешеләр бу билгесез каберләр янында шулай утыргалап алсыннар иде, оныттырмаска иде... Ә Симетбаш мәктәбе директорын эссе табага бастырырга кирәк булыр. Мәгънәсез бер пижондыр, сугыштан соңгы елларда туып, шушы рәхәт заманда гына институт тәмамлагандыр, кулына винтовка алганы юктыр. Әмма кыздырырга кирәк аны, эшлексезне.

Ташкичү урамы нәкъ элеккечә — ямь-яшел тавык үләне баскан көе

икән. Боларда утызынчы еллардан ук килгән традиция — урамга машина кертмиләр. Машина һәркемнең бакча башына — ындыр артыннан килеп туктый. Бу тәртипне заманында Мөкаддир абзый керткән иде. Асафның йөрәге сулыгып алды, Ташкичү урамы кинәт кенә томанга төрелде дә, шул томаннан күзләрен зур ачып Сылу карап алгандай булды. Фу, шайтан, олайган саен күңел кузгалуы хәтәррәк була башлый икән — Асафның күз алды караңгыланып алды.

Тавык үләнле урамның уртасыннан бер үзе атлады. Аны берәү дә танымый иде, капкадан карап калганнар белән ул да исәнләшмәде.

Менә кызыл йолдыз беркетелгән җил капка. Минҗан карт йорты. Картны исән дигәннәр иде. Габделнур — фронтовик. Теге вакыйгадан соң язмыш аларны очраштырмады. Кызыл йолдыз икән, кызыл йолдыз, Габделнур да кан койды бит. Хәзер, озак еллар узгач, кешенең ул вакыттагы эш-хәрәкәтләренә бәя бирү, анализ ясау кыен түгел. Кешеләр тыныч вакытта гына бертөрле. Тыныч кына, вәкарь белән генә трамвайда баралар — һәркем әйбәт. Ә менә көтмәгәндә шул трамвайга үзенең «МАЗ»ы белән исерек шофер китереп бәрә һәм трамвайны юлыннан чыгара. Шул вакытта кеше өстенә кеше өелә, кабель яна башлый, балалар чырылдап кычкыра, пыяла коела, сүгенү, ыңгырашу. Шул вакытта акыллы булырга кирәк тә... Сугыш та шулай бит: тыныч кына барган кешелек җәмгыяте — трамвайга — юньсез шофер үзенең куәтле машинасы белән китереп бәрә. Кешеләр моңа әзер түгел, берәү дә бәрелермен дип юлга чыкмый.

Асаф җил капканы ачты. Ишегалдын үлән, ат кузгалагы баскан, сукмак та юк — ятимлек билгесе. Түрдә тузып, тишелеп беткән салам түбәле абзар. Шифер, калай түбәле авылда бу бердәнбер каралтыдыр. Тәрәзәләрдә гөлләр юк, ятимлек, салкынлык бөтен каралтыдан бәреп тора. Асаф биек үләнне аралап, йортка таба атлады. Шулчак абзар кырында — биек булып үскән сары чәчәкләр, алабута, ат кузгалаклары арасыннан нидер хәрәкәткә килде. Асафның күзләре алмашынды: яшел дулкын эчендә саргылт тонык адәм тәне ялтырап күренде. Аннан ниндидер металл капкач шалтыраган тавыш ишетелде...

Минҗан карт тәһарәт алып утыра икән. Торды, арты белән баскан килеш төссез соры чалбарын күтәрде, озаклап рәтләнде, аннан комганын шыңгырдатып кулын юды, муеныннан сөлгесен алып кулларын сөртте. Артында кеше барын ул, әлбәттә, сизгән иде, шуңа күрә кулларын озаклап сөртте. Аннан борылды, чепи күзләрен кысып, Асафка карады да алга атлады.

— Әссәламе галәйкем, кунак бар икән.

Асаф ике куллап күреште.

— Минҗан абзый, ниһәл? Узышлый хәлеңне белим дидем.

— Фатыйма малаемы дип әйтим? Фәнсхан улымы? Таныдыммы? — Карт ит аңкауларын ачып хәлсез көлү белән көлде.

— Ие, Минҗан абзый, дөрес, таныдың. Хәлләрең ничек?

— Ничек дип инде, энекәш, ярый бер көйгә. Әле җомга көн, җомга намазына бармакчы идем. Шуңа әзерләнеп йөрим.

— Син элек алай җомгаларга йөрми идең бугай? Мәчетегез дә тузып җимерелде бит сугышка хәтле. Муллагыз да юк иде бит?

— И-и, энекәш, картайгач йөрисең инде. Афзаллар каралтысында укыйбыз. Өч-дүрт карт җыела шунда. Аның рәте юк инде, болай гына очрашып хәл-әхвәл сорашып утырабыз шунда.

— Намаз да укыйсызмы?

Карт яңадан бөтен аңкаулары белән көлде.

— И-и, энекәш. Аны укысын Афзал, укыган җире абзар.

Асаф та көлеп җибәрде.

— Ни, энем, әйдә өйне карап чык.

Тузган баскычтан күтәрелделәр. Баскыч сайгакларының череп ярылган урыннарыннан әрсез алабуталар төртеп чыккан иде. Өйалдына керделәр — өйалдында әллә ничә еллар элек эленгән, файдаланмаган дегет чиләге, чалгы, юкәдән үрелеп ясалган сумка, ат аркалыгы. Ятим, моңсу. Өйгә керделәр. Түрдә ялгыз самавар, тузанлы тәрәзә төпләре, иске бүрәнә исе, самавар торбасы исе. Ярылгалап беткән мич бөтен йортка моңсулык биреп утыра. Асаф монда ук кергәненә үкенә башлады. Какшау, тәрәксез авыл урындыгын шыгырдатып утырды. Карт сәке кырына артын төртте.

— И-и, энекәш, — дип кызганыч елмайды Минҗан карт, хәлсез, мае кипкән күзләрен аңа текәп. — Картаю — карт аю булдым дигән сүз икән инде ул. Бер какшаса, бөтенесе берьюлы ычкына икән. Аның башкасына иялнгән инде, ну инде хәтер дигәннәреннән бер дә әлләтанагы калмады. Хәзер исем дә тапканнар икән инде. Афзал әйтте. Скелируз, диде. Әле кичә өй суынган сыман булгач, иртән ягып алганыем. Ярады, мамыкланып китте. Шуны онытып кичен тагын ягып җибәргәнмен. Җәй көне — ике тапкыр. Афзал карт килеп чоланны какты. Нәрсә ди, иртәле-кичле морҗаңнан төтен үрмәли, кыз алып кайтырга булдың мәллә ди, һе-һе. Шуннан су сибеп, кисәүләрен тартып, морҗаны яңадан ябып, һи-и. Аны һәркем дә сиксәнне узып яшәр иде шәп булса. Сиксәнне узып. Идрит-кудрит.

— Ялгыз гына яшисеңмени, Минҗан абзый?

— Ялгыз дип. Кияү белән кыз чакыра, Симетбашка күчеп мен дилэр. Нигез бит. Ташлап чыгасы килми. Шушында гына үләрмен инде.

— Ярдәм итәләрме соң? Балалар дим.

Асафның һич тә Габделнур исемен телгә аласы килми иде.

— Ярдәм дип. Минем пинзәм әйбәт. Мин бит гражданскийдан инвәлит. Утыз өч сум пинзә алам. Кая куйыйм аны. Кияү белән кыз гел килгәләп торалар. Әле бу арада эш өсте, атна инде, күренгәннәре юк.

— Малайдан хат-хәбәр бармы соң? — Асаф бу сорауны шактый авырсынып бирде.

— Хат-хәбәр дип. Әле кыш өстеннән бер пасылкалары килде. Өрек, как, чикләвекләре барые.

— Акча җибәрмиләрме соң?

Карт тагын аңкауларын күрсәтеп алды, һеһелдәп көлде.

— Ии-у-к. Миңа нәрсәгә ул. Бер башым, бер... Өтерге белән төртеп тишкән тамак түгел әле, туенып торам. Үз тормышларының башта әлэтанагы булмады. Иске воянкум әйткән иде, әйдә ди, малаеңны илиминткә бирик дип. Кеше арасында хурлыгы ни? Аннары миңа акча киракмени? Малайны акча алыштыра аламыни?

— Кайтырга уйламыйлармы соң?

— Менә язлыкта бер хатлары килде: Талангырда минем сеңелкәшнең малае партком булып эшли. Шунда кайтып урнашмакчылар. Белмим инде, Ташкичүгә аю мае сөрткәннәрме? Кайталар инде, пләмәш шулай диде. Колхозга туп-туры кайтартам диде. Шушы арада көтәбез.

— Трубканы ташладыңмыни, Минҗан абзый?

Аксыл аңкаулар юеш елтырадылар.

— И-и. Күптән инде. Картайгач килешми. Чәй куйыйм?

Асаф урыныннан торды:

— Ю-ук, Минҗан абзый, рәхмәт, мин — узышлый гына.

Карт артык кыстамады.

— Иә, ярар, исәнлектә күрешик. Әле каушап киттем: бу, минәйтәм, нинди янарал? Әллә, минәйтәм, Жуков үземе? һе-һе-һе...

Ат кузгалагы ерып, карт җил капкага кадәр озата килде. Капкадан чыккач, баганадагы калай йолдызга тузган, хәлсез уч төбен басты.

— Синең ваянкум булганыңны кияү сөйләде. Гафур, дим. Һәр фронтовикның капкасына бер йолдыз, бабай, ди. Моны ди, тоуариш Рәнмов

үзе кертте ди. Әйдә, бик әйбәт: минем улым да чисно кан коеп кайтты бит. Тик кайткач кына әллә ниткән фәрвайсыз булды. Бардыр инде, яшьләрнекен белмәссең. Хәл белүеңә рәхмәт. Мин әйбәт яшим, миңа нәрсә — ашарга сорап, елап торган сары чәчле малайларым юк.

Ташкичүдән Асаф авыр уйлар белән чыгып китте. Лесхозга кермәде, анда керсә Асафның бөтен көне зират, кабер карап үтәчәк иде.

Машина лесхоз басуы түреннән узганда Асаф чытырдатып күзләрен йомды. Коңгырт толымлы чәченә бантик таккан уймак авызлы Нәзирә күз алдына килде. Әллә каян:

— Әт-ти! Әт-ти-и-и! — дигән бәгырь өзгеч тавыш ишетелгәндәй булды.

— Нәрсә, иптәш подполковник (шофер званиеләрнең рәтен белми иде), әллә бераз акрынрак барыйммы? Сезне укшытамы әллә?

Асаф күзен ачып ясалма елмайды.

— Юк, брат, болай гына. Мин крейсерда Англиягә бардым. Штормнарны әйбәт кичердем. Тик коры җирдәге шторм кайчак авыррак була...

Лесхоз поселогының читендә ак обелиск күренеп калды.

## XXVIII

Гомернең соңгы еллары бик тиз тәгәрәде. Атнаны башлыйсың,— ял көне җитә. Ай башлана — сизми да каласың — бетә. Күтәренке күңел белән стенадан искергән табель-календарьны алып ташлыйсың, яңасын куясың, бу ел озынрак, бәрәкәтлерәк булыр сыман тоела, карыйсың — бер ел үткән дә киткән, син яңадан календарь алыштырып торасың...

Соңгы елларда Асафның характеры үзгәрде. Кичләрен арып кайтканын Зәйтүнә сизеп тора һәм мөмкин кадәр аңа карата саграк мөнәсәбәттә булырга тырыша иде. Еш кына Асафның нервлары ычкына, йөгәнсезләнеп ала иде.

Авыллар буенча йөреп кайтканнан соң ул райком пленумында чыгыш ясады. Чыгышының ахырында — Шәрәф аңа гаҗәпләнеп карап торды — Асаф кычкырына башлады.

— Симетбаш мәктәбенең директоры бармы монда? Бармы? Торып басыгыз әле! — дип ярсыды.

Шәрәф урыныннан торды. Ясалма кырыслык белән:

— Иптәш военком! Сез допризывниклар алдында түгел, райком пленумында, — диде. — Хәер, допризывниклар алдында да кычкырмаска киңәш бирер идем.

Әмма Асаф ычкынган иде — алдан өченче рәттә шакмаклы кызыл күлмәгенә яшел пластик галстук таккан озын буйлы кара егет басып тора иде. Шәрәф урынына утырды, трибунадан Асаф, залдан кара егет калкып калды.

— Сезме директор? Сез армиядә булдыгызмы? Сезнең әтиегез сугышта булдымы? Сезнең бу сугышта берәр кешегез катнаштымы?

Асафка җавап биреп бетерү мөмкин түгел иде, хәер, ул җавап көтмәде дә, ул кычкырды гына.

— Кем идеясе ул? Сугышта үлгәннәрне мыскыл итәргә кем рөхсәт бирде сезгә? Иске мунча ташыннан «һәйкәл» өеп куярга сезнең ничек кулыгыз барды?

Аннан Шәрәфкә карап әйтте:

— Менә мин бу иптәшне өч-дүрт айга переподготовкага җибәрим әле, басып торуыннан ук күрәм — стройга баскач «салам-печән-сулаяк»ка атлый торган егет булырга охшаган бу...

Кара егет ап-ак булып басып тора иде. Урынына утырганда аның

муены кызарып, шакмаклы күлмәгенә кушылып калды, пластик галстукның төене тагын да кирәксезрәк нәрсә булып җанга ябышты.

Шәрәф тыштан ачуланды, әмма эчтән шатланып утырды. Элеккеге военком, подполковник Назиров белән аның мөнәсәбәтләре киеренке иде. Назиров монда сугышка кадәр үк килеп урнашкан. Сугыш вакытында кайбер кешеләрне сугыштан калдырган, имеш, дип тә сөйлиләр. Шундый начар даны бар иде.

Һәм менә районга яңа военком — Асаф килеп төште. Назиров бу вакытта район больницасында, бер кешелек бүлмәдә, шул көннәрдә генә аның отставкага чыгуы турында приказ килгән иде.

Шәрәф больницага Асафны да алып барды. Алдан әйтмичә бардылар, больница хезмәткәрләре каушап калды, йөгерештеләр.

— Курыкма, мине күреп йөгерешәләр алар, — диде Шәрәф. — Район зур түгел, бөтен кеше таный. Аннан соң, бер атна гына элек сәламәтлек саклау эшенең торышын бюрода тыңлаган идек.

Назиров яткан палатада тавыш иде.

— Юк, син миңа шуны гына әйт: ни өчен менә мин егерме бер осколка саклап, хәзерге көндә раматиз белән җәфаланам? Нигә син теге вакытта Мингазов малаен алып калдың?

Дулаучы — яңак сөякләре калкып чыккан, зур батынкы күзле, чандыр гәүдәле озынча бер ир иде. Больница курткасы аның сөякчел җилкәсендә җилфердәп эленеп тора.

Кешеләр килеп кергәч, ябык ир кузгалды. Үзе һаман калтырый иде. Чыга башлады, әмма бәйләнде. Күрәсең, тәрәзә аркылы акча биреп берәр танышын кибеткә йөгертеп алган.

— Юк, син миңа менә шуны аңлат: ни өчен Мингазов малае фронтка бармады? Аның яшен ник киметтегез? Теге вакытта ул кинәт кенә егерме җиденчегә төшеп эләкми калды, ә җитмеш бишенче елның февралендә оятсыз рәвештә бөтен пачулык алдында илле еллыгын уздырды. Менә син миңа шуны әйт.

Ябык гәүдәле чыгып китте. Назиров, авыр ыңгырашып, урыныннан торды, күреште.

— Көн саен шулай, — диде. — Фронтовикларның һәрберсенең сүзе бар. Монысы — лесхозда трелевщик — аеруча теллесе...

Берничә көннән Шәрәф аны шәһәр больницасына күчерә алды. Назировның газаплы ыңгырашуын, күкрәк түреннән чыккан тавышын Асаф хәтерләп калды: бу тавыш аңа «син һәрвакыт гадел бул! Гадел бул!» дип тукып, янап тора иде.

## XXIX

Гафур белән Гаделиянең малайлары солдатка китә икән. Гафур туп-туры военкомның үзенә телефоннан дәште.

— Тоуариш Рәимов, сезме? — диде.

— Әйе, мин тыңлыйм.

— Ни бит, яшьти. Малай иртәгә солдатка китәргә тиеш бит.

Асаф калтырап куйды. Нәрсә, отсрочка сорыймы? Бу нинди оятсызлык? Нахал! Кем өйрәткән? Гаделия түгелдер бит? Н-н-не выйдет!

— Асаф! Ишетәсеңме? — Монысы Гаделия тавышы иде.

Асаф кыенлык белән җавап бирде.

— Да, слушаю. Я вас слушаю...

— Асаф! Иртәгә безнең Зиннур армиягә китә...

— Да, мин аңладым. Я вас понял.

— Асаф! Мөмкин булса...

— Юк, бу турыда мин сөйләшмим. Сау булыгыз.

— Тукта... Мөмкин булса, бүген кичкә безгә килегез. Иптәшегез белән. Озату мәҗлесе оештырмакчы идек. Олысынмасагыз...

Фу, шәйтан! Шундый мокытлык каян килгән! Чүт кенә кеше рәнҗетмәде бит. Аның муенын кителе кыса башлады. Телефон трубкасы тирләде. Хәер, микрофонына да кайнар, парлы һава бәреләэ иде.

— Асаф! Тукта, минә Гафурга бирәм.

Чыбыкның теге башында нәрсәдер кыдырдады.

— Яшьти! Үтенечебезне аяк астына салма инде. Кеше арасында безнең авторитны күтәрер идең. Карчыгың белән кил. Теләсәгез кунасыз, теләмәсәгез — «Жигули» баскыч төбендә. Яшьти, -ә?

Асаф җиңел сулап куйды. Рәхмәт, Гафур! Рәхмәт, Гаделия! Сез нинди әйбәт кешеләр...

— Ә, әйе... Әлбәттә. Тик, килешерме соң?

— Шту син, яшьти! Мундирыңны киеп кил! Орденнарыңны тагып!

— Ну-у... Бу инде «свадебный генерал» сыйфатындамы?

— Ә? Нәрсә дидең?

Гафур, әлбәттә, Чехов хикәясен белми, укымаган иде.

— Юк, болай әйтәм. Зәйтүнә өчен вәгъдә бирә алмыйм, әмма үзем киләм. Хәл иттек!

— Яшьти, алай итмә! Парлап! Машина белән килеп алыйммы?

...Һәм менә Асаф белән Зәйтүнә мәҗлеснең түрендә утыралар. Гаделия бәхетле — әйтерсең, теге вакытта берни дә булмаган.

Мәҗлестә күп төрле кеше бар иде. Хәер, ни Асаф, ни Зәйтүнә боларның берсен дә танымыйлар да инде. Гаделия үзе эшли торган район председателен дә чакырган, Зәйтүнә бөтен район халкы яраткан лесхоз кешесе Николай Ивановичны бераздан танып алды. Зиннур — китәсе егет — шыпырт, юаш адәм икән, өстәл почмагында тик утырды. Эчмәде дә, җырламады да. Шулай бит ул: Гафур бердәнбер малаен үзеннән дә уздырыр дип ышанып үстергәндер. Башта аңа велосипед, аннан мотоцикл, ә быел «Жигули» алып биргән. Гафур бит бу дөньяны җәяүләп кичте, җәяүләп рәхәт күрде. Гаделия бердәнбер малаен үзе кебек кайнар канлы, мәхәббәт утында дөрләп яна торган, яшьлегендә кызлар күңеленә ут чәчәге кебек шом сала торган бер егет булыр дип үстергәндер. Ә Зиннур «төкерәм мин сезнең планыгызга» дигәндәй, юп-юаш, тып-тыныч бер егет булган да калган. Әле кызлар белән дә йөргәне юк икән... Гафурмы? Бу яшьтә Гафур булсамы? «Жигули» беләнме? Һи-и-и...

Әмма агай-эне шәп утыра мәҗлестә! Ну, рәтең беләләр икән хәзер! Ашый беләләр, эчә беләләр, җырлый беләләр. Кәефләр бик тә хушланып киткәч, битләр пәрәмәчләнеп, дөньялар тигезләнеп алгач, Николай Иванович шәрран ярып җыр башлады:

Туда-сюда
Сюда йозаласынма,
Мен сэнэ курмый тузалмыйм,
Ә сэн тузаласанма...

Николай Иванович ялгыз килгән икән, рәхәт чикте. Теләгәнчә җырлады, янындагы кызлар белән теләгәнчә уен-көлке сөйләште. Бигрәк тә янындагы юантык бер кызга бәйләнде. Авылның фельдшерицасы икән. Асаф күзләрен йомып торды. Фельдшерица... Әйе, кырык беренчедә бу пунктта Сылу эшли башларга тиеш иде. Әйе...

Бу фельдшерица Сылу кебек түгел, бу — бик кыю. Тыгыз тәненә тар күлмәк кигән дә, тегеннән кыскан, моннан кыскан урыннардан бүселеп, тәне тышка бәреп чыга. Кашын беткәнче кырган, каш урынына тар сызык кына уздырган. Иреннәр дымлы, күзләр майлы. Күзләрендә «мәче тояклары» бар. Николай Ивановичка таба борылып, сызык каш-

ларын уйната-уйната, ул әйбәт тавыш белән җырлады. Болай гүзәл булмаса да, муены, авызы бик матур, күп ирләрнең уй-фикерләрен чыгырыннан чыгарырлык иде. Николай Иванович та үзе рәхәтләнде, үзе каушады. Матур авызлы яшь хатын гел аңа таба бөгелеп җырлады:

Ак дисең,
Күк дисең,
Сөйгән ярым юк дисең;
Сөйгән ярың бар синең,
Нигә аны сөймисең?

Матур авызлы мут хатын шунда урыныннан сикереп тора һәм, кулларын болгап, дирижерлык итә, бөтен кешене җырлата. Җырның кушымчасын ул Асафның күзләренә текәлеп, мут елмаеп җырлый.

Их-ха-ха,
Ух-ха-ха,
Көн дә күрердәй булам...

Бераздан авыл егетләре җырлый башлады. Гафур белән Гаделия бәхетле, шатлыклы чырай чыгарып өстәлгә ризык ташып, савыт-саба алмаштырып тордылар. Егетләрдән берсе — бичара, сакау булганлыгы аркасында аны солдатка алмыйлар икән, гарьлегеннәнме, мәҗлестә күбрәк төшереп алган, кычкырып җыр башлады. Николай Ивановичтан башка бу егетнең сүзләрен беркем дә аңламады. Ә Николай Ивановичка бүген бөтен нәрсә аңлашыла иде, ул инде кулы белән өстәл астыннан гына матур хатынның гаҗәп уйнак, йомшак тез капкачын тотып, сөеп утыра иде, шуңа күрә сакау егетне аңлаган сыман кыяфәт чыгарып, елмаеп утырды. Ә сакау җырлады.

Ыттакаййың тәбләйендәй
Тәңкә тыйпаттайы бай;
Ай күтәййеб, этиб дибәй,
Тәнгә тихәттәйе бай.

Җыр Асафка газаплы хисләр алып килде. Бичара, бу баланың кеше рәтеннән — яшьтәше Зиннур белән бергә солдатка китәсе киләдер. Башка егетләр кебек аның да ялт итеп чистарып, төзекләнеп хәрби форма киеп авылына кайтасы киләдер. Сакау егет бик чибәр иде, шәһәрчә итеп озын чәч үстергән, шәһәрчә модалы күлмәк кигән — күрәсең, апалары шәһәрдә эшлиләр һәм чибәр энеләрен киендерүдән үзләренә канәгатьлек алалар. Ах, кырдырсын иде ул озын чәчләрен, башкалар кебек ул да шулай «бүген монда актык кичем» дип сагышлап утырсын иде... Егет җырлап бетергәч, Зәйтүнә урыныннан торды да, чоланга чыгып, сулыгып-сулыгып елап керде.

Күзләре кызарып кергән хатынына Асаф бер сорау да бирмәде: Зәйтүнәнең күңелен яхшы белә иде. Юк, мәҗлестә боларны уйлап утырырга ярамый. Мәҗлестә иң яхшысы — җырлап утырырга кирәк. Яки эчеп. Әнә матур авызлы хатын баштарак кызды-кызды да, тынып калды. Нәрсә уйлый ул? Күзләрендә элеккеге мутлык урынына нәфрәт чыккан аның. Ирле хатыннарга ачу белән карап утыра ул. Бу хатыннарны белә ул. Болар берсе дә аннан артык түгел. Берсе дә фәрештә түгел. Ә менә моның ире юк. Ихтимал, ул шулай уйлый торгандыр.

Асаф иртәгесен военкомат коридорына килеп басачак кырган башлы кара егетләргә күз салды. Әйдә, иркенләп утырып калыгыз, егетләр. Асаф хәрби комиссия узган егетләрне карап утыра: элек кем керсә әзмәвер, кем чыкса — өрлектәй иде. Хәзер егетләр вакланды. Ат ялы кадәр итеп үстергән чәч өстенә вак эшләпә утыртып куялар да, болонья куртка кияләр дә, чыштыр-чыштыр килеп военкомат коридорына кереп тулалар. Ни рәтләп сөйгәннәре белән елап-җырлап аерылыша белми-

ләр, ни дөнья күчереп, «без китәсе кеше» дип шаулап йөрмиләр. Ярый әле Гафурлар оештыра белгән. Бу егетләр күреп калсыннар: солдатка бару — зур, күңел тетрәткеч бәйрәм булырга тиеш. Солдат кадерен белергә дә өйрәнеп кайтырсыз. Югыйсә, сезнең арада төрле кешеләр була.

Рәхмәт сезгә, Гафур, Гаделия, сез малаегызны солдатка матур итеп озатасыз.

Мәҗлестә Зиннурның укытучылары да, директор да — мунча ташыннан «обелиск» салдырган кара егет тә, шәп кенә шәһәрчә хатыны белән колхоз председателе дә бар иде. Хатыны затлы киенгән, чәчләр күпертелгән. Үзенә конкурент булырлык кеше Зәйтүнә генә дип белде, ахрысы, аңа бераз яны беләнрәк утырды.

Ә... Хатын-кызга мәҗлес, ул мәҗлеснең эчтәлеге нәрсәгә соң? Мәҗлес үзе түгел, ә шул мәҗлескә әзерләнү процессы гына кызык була аңа. Чәчне ничек ясатырга, кайсы күлмәкне кияргә, кайсы алканы тагарга, туфлинең нинди киеп барырга, нинди төреп алырга? Менә шунысы кызык. Килде, күрде, ә иң мөһиме — күренде. Әйе, нәкъ менә шул күренү моментыннан соң хатын-кызда битарафлык башлана, чөнки ир кеше өчен иң әһәмиятлесе — мәҗлеснең үзе. Мәҗлестән ир белән хатынның үпкәләшеп кайтуының төп сәбәбе әнә шунда.

— Я, нәрсә син җылкы итенә кызыккан урыс малае кебек утырасың, — диде Гаделия, бик тә якын итеп Николай Ивановичка. Николай Иванович кулын матур хатынның тез башыннан ять кенә алды. Гаделия аның артына килеп баскан икән.

— Николай Иванович! Зинһар, тагын бер җырла! Безнең халык үз җырын башкалар җырлаганны бик ярата.

Николай Иванович тагын очкынланып китте һәм матур хатынга карап җырлап җибәрде:

Ут-тыр алли яннарыйма,
Ял булсыйм яннарима;
Ут-тыр алли...

Ике хатын, кызып-кызып, чит ил турында сөйләп алдылар. Турист булып барганнар икән. Ул алар күргән хикмәтләр! Ул алар очраткан кешеләр! Менә алар дөнья күргәннәр... Чит ил күрмәгән кеше, гомумән, бик чикләнгән, артта калган кеше икән ул. Әле ул тышкы форма белән генә түгел (бер хатын моны Асафка карап әйтте), менә шулай яшәргә кирәк — дөнья күреп.

Болар колхоз экономисты хатыны белән сельпо бухгалтеры икән.

Асаф аларны рәхәтләнеп елмаеп тыңлап утырды.

Зиннурның укытучыларыдыр, өстәл янында пиджакларына сыек зәңгәр ромбиклар таккан ике егет утыра иде. Армия аркылы уздырасы иде бу егетләрне. Ромбик таксалар да, нидер җитеп бетми бит шул мәктәпне узмаганнарга.

Мәҗлес соң тәмамланды.

Гафур белән Гаделия гадәттән тыш бәхетле иделәр. Гафур үзенең хисен белдерү өчен Асаф каршына басып, кулына стакан тотып җырлады.

Син-син савытларым тулмый,
Син-синнәр тутырсамда лай,
Син-синнәр тутырсамдай.

Көр-тигез күкрәк тавышы белән җырның икенче яртысына Гаделия дә кушылды.

Синсез күң-гелләрем булмый
Кайларда утырсам-дай.

Чыксалар — төн икән.

Чур-чур килеп чикерткәләр канат кайрый, су буеннан бакаларның көн җылы булачагын белдергән тавышлары ишетелә.

— Кра-а-а-а...

Авыл төнгә тынып калган, урамнарга шомырт яфрагы исе таралган, акрын гына талпынып дулкынланган һава ат абзарлары ягыннан янган тирес исе алып килә, авыл уртасында, Асаф туып үскән нигез тирәсендәрәк, вак тавыш белән кечкенә генә бер эт өрә иде.

Матур бу дөнья, рәхәт бу дөнья. Сагышлы да...

Такыр башлы малайлар — бу дөньяның тынычлыгын сакларга китүче малайлар, мәҗлестән Асаф белән Зәйтүнә чыгып киткәч, иркенләп шаулаша, стаканнарны зыңгылдата башладылар.



## XXX

Военком өстәлендәге өч аппараттан берсе — яшел төслесе чылтырады. Бу — туры элемтә, өлкә Хәрби Комиссариатыннан иде.

Генерал үзе икән.

Асаф торып басты, кителенең төймәләрен тикшереп, кулын шудырып алды. Ә, әйе, генерал тегеннән торып сөйләшә бит әле, күрми. Ләкин урынына утыра алмады.

— Тыңлыйм сезне, иптәш генерал.

— Иртәгә сезгә чит ил кунаклары килә. Сезнең районга. ФРГдан. Унике кеше. Боларны каршы алу, чәй эчертү, озату сезнең өскә дә йөкләнә. Арада берсе — сугыш вакытында әсир булып сезнең район үзәгендә госпитальдә дәваланган кеше.

— Ясно. Ясно. Ясно... Есть. Есть. Есть...

— Кичен шул ук автобус белән алар китәләр. Протоколда каралганча, кичке алтыда алар сезнең район территориясен калдырачак.

— Ясно... Есть...

— Берсекөнгә иртәнге тугыз ноль-нольдә нәтиҗәсен миңа докладывать итәсез.

— Есть.

Шәрәф Солтановка да өлкәдән телефон булган икән. Конкрет эш планы төзүгә ярты сәгатьләп вакыт китте. Район үзәгенең ресторанында төшке ашка аерым бүлмә әзерләргә күрсәтмә бирелде.

Иртәгесен военкомат каршына зур автобус — «Икарус» килеп туктады. Военкоматның бөтен составы кунакларны каршы алды.

Автобустан чалбар кигән, сул иненә кара сумка аскан кып-кызыл юка иренле, кара күзлекле бер кыз бала чыкты. Әллә бераз гына мыегы да бар инде...

— Мин — гид, Ира, — диде.

Аннан берәм-берәм кунаклар чыга башлады. Хатыннары — ак-сары чәчле, барысы да кара күзлектән, тар чалбардан иде, чыгып исәнләшүгә, сигарет кабыздылар, кызу-кызу сөйләштеләр. Ирләре ахырдан, әдәп саклап кына чыктылар, берсе ярым хәрби формадан, уң кулы беләзектән юк, кул сөяге икегә аерылып яньлекә ясалган иде.

Аннан кабинетка керделәр. Урнашып бетүгә эшлекле әңгәмә башланды.

— Сезне бу район җиренә аяк басуыгыз белән тәбрик итәм, — диде Асаф. Кунаклар алдына ул яңа мундирына бөтен орден-медальләрен тагып килгән иде. Башка офицерлар да ишек катынарак тезелешеп утырдылар, барысы да яңа киемнәрдән иде. — Ватан сугышы елларында, инде сезгә мәгълүм булганча, Ташлытауда хәрби әсирләр өчен госпиталь булган. Монда, нигездә Сталинград кырында яраланган, өшегән

эсирләр дәваланган. Госпитальдә югары белемле күп санлы врачлар эшләгән, монда процедурный, лечебный кабинетларның авыру өчен кирәк булырдайлары барысы да оештырылган. Болардан тыш, әсирләр өчен бай китапханә оештырылган, ул китапханәдә немец, инглиз, итальян, румын, венгр телләрендә әдәбият булган. Әсирләр атна саен мунча кергәннәр, һәр кичне аларга кинофильм күрсәтелгән. Савыга алмаган әсирләр — авыру тарихларыннан күренгәнчә, аларның барысы да бик авыр яралы яки бик нык өшегән булганнар — аларны ике ай дәвалагач шәһәргә озатканнар.

Гид кунакларга карап тынып калды. Ак чәчле карчык нәзек бармакларына кыстырган озын сигаретыннан үрелеп көл какты да, «ы-ы» килеп сорау бирде.

— Аларга нәрсә ашаттылар икән, рационнарын әйтегезче, — диде. Үзе блокнотын чыгарып язарга әзерләнде. Гид тәрҗемә итә башлады. Асаф аны бүлдерде.

— Ich ferstehe, ferstehe ... Менә болай, фрау...

— Frau Gertruda...

— Менә болай, фрау Гертруда. Башта мин сезгә сугыш вакытында безнең тыл халкы нәрсә ашаганны сөйлим. Тылда болай: завод эшчеләренә карточка белән көненә биш йөз грамм ипи. Балаларына йөз грамм, ике йөз грамм. Колхозчыларга ул норма да бирелмәде.

— Алар нәрсә ашаган соң? Бу — булырга мөмкин түгел.

— Мөмкин. Безнең икмәкле районнарыбыз фашистлар кулында, ә икмәк үстерүчеләребез шул фашистлар белән сугыша иде. Колхозчыларның йорт янында бакчасы, бераз терлек-туары бар иде. Әмма колхозчы бөтен булганын фронтка — фашистларга каршы көрәшеп йөргән улларына, кызларына, аталарына җибәреп торды. Нәрсә ашаган дисезме? Он булмаганда кычыткан, алабута, бәрәңге яфрагы, чөгендер яфрагыннан аш, имән чикләвегеннән күмәч пешереп ашадылар.

Тәрҗемәче бу сүзләрне зур газап белән әйләндерде.

— Район җитәкчелеге — аристократия дә шулай яшәдеме? — Бу сорауны япьлекәле кул бирде. Асаф нәфрәтен эчкә яшерергә тырышты.

— Беренчедән, безнең илдә аристократия дигән төшенчә юк. Унҗиденче елдан бирле. Икенчедән, район җитәкчелеге тагы да кыен хәлдә иде, чөнки аларның бәрәңге бакчалары юк иде. Өченчедән... Без сезнең белән очрашмадыкмы икән? Сез кайсы участокта булдыгыз? Сухиничида булмадыгызмы? Мин дә беренче тапкыр шунда яраландым бит...

Ира соңгыларын тәрҗемә итмәде, Асафка карап елмайды гына...

Асаф үзен тыярга тырышты. Әмма япьлекә кулга ачуы килде: Сухиничи янында Асаф өстенә ут яудырган немец түгелме ул? Безнең авыл ларны яндырып йөргән кеше түгелме ул?

— Сезнең туганнарыгызны ничек ашатканнарын район белән танышып кайткач сөйләрбез, — диде Асаф, сәгатенә карап. Программа буенча сәяхәт вакыты җиткән иде.

Кунаклар тордылар. Чеч-беч килеп сөйләштеләр, бәхәсләштеләр.

Кайшалып үскән арыш басуы арасындагы асфальт юлдан егерме чакрымлап җир әйләнеп кайтканда гид Ира микрофонын элде дә, Асаф янына килеп утырды. Колагына иелеп үз итеп кенә әйтеп куйды:

— Теге кулсызы Сталинград янында яраланган, сездә дәваланган,— диде.

Асаф аңа карап мәгънәле елмайды.

Талангыр ягыннан килгән өермә машина тәрәзәләренә чытыр-чытыр китереп, шрапнель сипкәндәй, нәрсәләрдер китереп бәрде. Күк йөзен яшен камчысы сызып узды. Машина кузгалуга Ира тагын Асафның колагына иелде.

— Теге кулсыз шишка булган — штурмбанфюрер. Яшереп тә тормады, килгәндә сөйләп килде,— диде Ира.

Каракучкылланып калган басу өстендә күкне яра-яра яшен уйнады. Ул арада автобус тәрәзәсенә эре тамчылар да бәрелә башлады.

Ресторан ишеген ачып кергәндә кунакларны район җитәкчеләреннән бер төркем кешеләр каршылады.

Сәгать дүрттә төшке аш мәҗлесе башланды. Тышта һаман яшен уйный, меңләгән тимер вагоннар бәрелгәндәй итеп күк күкри, әмма яңгыр әлегә килеп җитә алмый иде.

Немецларның тәгәллеген бик нык белгән Шәрәф Җиһангирович сәгатенә карады. Нәкъ дүрт иде.

Шәрәф соры көмеш сыман костюмнан, эре сызыклар белән шакмак ясалган ак күлмәктән, затлы галстуктан иде. Орденнарын, әлбәттә, такмаган (Асафны мәҗбүр итте: күрсеннәр! диде), әмма үзен хәрбиләрчә тота иде.

— Хөрмәтле ханымнар һәм әфәнделәр, — дип башлап китте ул үзенең сүзен. — Сез бүген безнең күп авырлыклар, күп газаплар чигеп исән калган, бәхетле мул тормышка ирешкән җиребезнең кунаклары. Сез монда үзегезнең улларыгыз, әтиләрегез, абыйларыгыз, туганнарыгыз дәваланган җирне күрергә килгәнсез. Үткән эшләр өчен аларны сүз белән рәнҗетмик, без ышанабыз — ул кешеләрнең барысы да безнең җиргә яман уй белән килмәгәндер. Аларның кайберләрен (Шәрәф соңгы сүзгә басым ясады һәм өмет белән Ирага күзләрен текәде), аларның кайберләрен безнең илгә котырган Адольф мәҗбүри куып китергәндер. Ничек кенә булса да булган, әмма алар — кем булуларына карамастан, безнең халыктан күңел җылылыгы дип әйтмим, басып алучыларга күңел җылылыгы юк — икмәк, җылы сөт, кайнар аш, медицина дәвасы алганнар. Мин тост әйтер идем: киләчәктә кешеләр үз илләрендә генә дәвалансыннар иде. — Ул, мәгънәле елмаеп, Ирага эндәште: — Мондый тост ишеткәнегез бармы, туташ?

Кунаклар рюмкаларына барысы да ак аракы гына салганнар иде, үзара ыгы-зыгы килеп алдылар да, эчеп куйдылар. Өч-дүрт минут капкалап алгач, Шәрәф тагын торып басты.

— Ханымнар һәм әфәнделәр! Хәзер мин шушы районда туып үскән, фашизмга каршы көрәштә зур батырлыклар күрсәткән — мин басым ясап әйтәм — фашизмга каршы, ә бүгенге көндә бу районда хәрби комиссар булып хезмәт итүче, Ватан сугышы ветераны, икенче ранг капитаны Асаф Рәимовка сүз бирәм...

Ираның тәрҗемәсеннән соң зың-зың, чың-чың килеп үзара сөйләшеп алдылар.

Асаф урыныннан авыр торды. Нәрсә әйтәсен белми иде. Рюмкасын күтәреп озак кына билгесезлеккә карап торды. Рюмка тоткан кулы дердер килде. Тамагын кырды. Авыр башлады.

— Хөрмәтле кунаклар... — ул тагын тамак кырды. — Бүген военкоматта әңгәмә вакытында миңа сорау бирелде: «Госпитальдә рацион нинди булган?» Менә без сәяхәттән кайтканчы безнең иптәшләр бу очрашуга әсирләр госпиталендә шеф-повар булып эшләгән бер апаны чакырганнар. — Асаф иң артта, өстәл почмагында әдәп белән генә утырган бер апага мөрәҗәгать итте: — Нина Ивановна! Рәхим итеп, шул турыда берничә сүз әйтсәгезче. Аннары мин үземә бирелгән сүзне очлап куяр идем.

Иңенә үтә күренмәле аксыл шәл салган юантык, ак чәчле хатын — Нина Ивановна торып басты. Ул да тамагын кырды.

— Нәрсә әйтим мин, иптәшләр? — дип ул тынып калды. — Нәрсә әйтим? Калькуляция менә болай иде. Теләгән кешеләр архивтан карый алалар. Анда һәр көн мин кул куйган калькуляция, заявка кәгазьләре бар. Әсирләргә нәрсәләр ашатылды? Һәркөнне итле аш. Творог, май, сөт өстен молзаводтан ала идек. Чәйне шикәрсез эчерткәнне мин хәтер-

ләмим. Шоколад, печенье, рулет, кофе бирелгәли иде. Ак оннан пончиклар, кызыл карлыган кесәлләре, йомырка тәбәсе, селедка. Әле дә хәтерлим: ап-ак чырайлы, озын буйлы, күзлекле бер немец бар иде. Штутгардтан. Ул һәрвакыт обедка тозлы кыяр, бәрәңге пюресы һәм бер порция селедка заказать итә иде. «Русча ашарга иялэнеп беттек» дип, эчләрен уа-уа көндезге йокыга чыгып китәләр иде. Авыр хәлдәгеләренә сестралар палатага китерәләр иде. Минем белән эшләгән сестралардан ике хатын әле дә исән — Ташлытауда.

Нина Ивановна кып-кызыл булып бүртенде, читкә караш ташлады да, салмак кына урынына сеңде. Асаф шунда ук торып басты. Хәзер аның рюмка тоткан кулы дерелдәми иде. Ул кыюланып китте.

Кунаклар үзара сөйләшә-сөйләшә ризык турында бәхәсләшәләр, берберсенә тозлы гөмбә, кызыл балык кисәкләрен күрсәтеп фикер алышалар иде, Асафның көр тавышына әсәренеп тынып калдылар.

— Мин үземнең Parteįgenosse Шәрәф Солтановның сүзен кабатлый гына алам: әйдәгез, сезнең белән бергәләп безнең балаларыбыз авырган вакытта үз туфракларында дәвалансыннар өчен тост күтәрик. Без беләбез: авыру, дәва сүзен телгә алып тост әйтмиләр. Әмма без бүген шундый шартларда җыелганбыз: безнең җиребездә без чакырып китермәгән кешеләр дәваланган, алар сезнең милләттәшләрегез, безнең дошманнарыбыз булган; бүген без шулар — сезгә якын, безгә дошман булган кешеләр дәваланган җирдә бер өстәл янында утырабыз. Димәк, сугышмыйча, кан коймыйча менә шулай бер өстәл янында сөйләшеп утырып була. Әйдәгез, шуның өчен тост күтәрик. — Аннан арада иң яшь кызга таба борылып елмайды. — Минем немец телен ватып сөйләвемне гафу итегез... Без бөек Гейне, Шиллер, Гете, Маркс, Энгельс телен, сугыша-сугыша җиребезне азат итү процессында — дәрестә түгел— походта өйрәндек. Шулай да соңгы сүземне мин сезнең телдә әйтер идем.— Асаф торырак басып бөтен кунакларга таба борылды.

— Liebe Gasten! Wir wünschen Ihnen, teure Gasten und dem ganzen deutschen Volk auch wei terhin beste Erfolge [1].

Яшь кыз әсәренеп кызу-кызу сигарет суыра иде.

— Ich erhebe mein Glas auf die feste und unverbrüchliche Freundschaft zwischen unseren Völkern! [2]

Кунаклар кул чаптылар, Асаф рюмкасын тоткан килеш яшь кыз янына килде, аның белән чәкештереп алды. Яшь немка күз ачып йомганчы рюмкасын әйләндереп куйды да, чуп итеп Асафның битеннән үбеп алды. Колагына:

— O, kapitan, kapitan,— дип нәрсәдер пышылдады. Мәҗлес гөрләде, өлкән яшьтәге — бездә булса инде бабай чутында йөрерлек бер ябык немец, калын пыялалы күзлеге астыннан елмаеп, кызмача кычкырып җыр башлады:

Wol'ga, Wol'ga, mutter Wolgen
Wol'ga, Wol'ga — Rusland Flu-u-u-s... [3]

Кунаклар инде берсен-берсе тыңламый башлаганда гына исләренә төшерделәр: мәҗлеснең башыннан ук япьлекә кул юкка чыккан икән.

Иң беренче булып гид Ира чыгып йөгерде. Аннан кунаклар гөҗләделәр. Чит ил кунагының юкка чыгуы Шәрәф белән Асаф өчен дә шәп нәрсә түгел иде. Асаф кичә генә телефоннан әйтелгән сүзләрне хәтеренә төшерде.

---

[1] Кадерле кунаклар! Без сезгә, кадерле кунакларга һәм бөтен немец халкына киләчәктә зур уңышлар телибез.

[2] Мин безнең халыклар арасында дуслык какшамас һәм нык булсын өчен тост күтәрәм!

[3] «Стенка Разин» дигән җырдан:
«Волга, Волга, мать родная,
Волга — русская река.

— Барысы өчен дә сез җавап бирәсез, — дигән иде генерал.

Кузгалышып, мәҗлесне түгәрәкләделәр, җырлаган немец кунаклар исеменнән рәхмәт әйтте — әмма аны тәрҗемә итәргә Ира юк иде.

Тышта бөтен район үзәген томалап, бурый-бурый дуамал җәйге яңгыр ява, яшен сызылып киткәндә бөтен поселокта электр линияләре ыңгырашып ала, урамнар, тополь мамыкларына бөялә-бөялә, күбекле ак гөрләвекләр ага иде.

Яшен чытырдады да чытырдады...

## XXXI

Минҗан картның ишегалдына хәл белергә Асаф килеп кергән көнне Талангырга Габделнур белән Дуся кайтып төште. Яннарында өч-дүрт чемоданнары, сары чәчле ике кызлары бар иде.

«Партком туган» эшне тиз тотты: ике көн ял иткәннән соң (аның берсендә Габделнур партком туганның газигына төялеп, әтисе янына кайтып килде) кунакны идарәгә чакырдылар: Талангыр бүлекчәсенең бригадиры кинәт кенә авырып киткән һәм аны больницага салганнар икән. Дусяга да шул ук көнне эш табылды: авыл Советы аппаратында хезмәт урыны ачылган икән. Дусяның, гомумән, эштән бәхете булды.

Габделнур, инде иллене узган запастагы старшина, хәрби учетка авыл Советына гына басты. Районга йөрисе булмады.

Колхоз салып куйган ике квартиралы йортның бер ягына урнаштылар.

Эшнең беренче көнендә үк «партком туган» әйтә куйды:

— Менә нәрсә, Габделнур абый. Бездә таләпләр каты, шаляй-валяй йөрү юк. Кунак өстәле янында без синең белән туганнар, эштә — мин партком секретаре, син — бригадир...

Габделнур болай да аңлый иде инде.

Ул көнне кукуруз басуын карап кайтырга дип, Габделнур кырга җәяү генә чыгып киткән иде. Югыйсә, мотоцикл биргәннәр иде. Әллә нәрсәсенә иген басуыннан җәйге җилне ярып алга барасы, сагынган җир, үлән, иген исе тоясы килде.

— Анда синең таш юл кырыендагы бер клинең бик начар, — диде аңа «партком туган».— Узучылардан оят. Ул клинне кара әле син — июнь башы, берәр нәрсәгә файдаланып булмасмы?

Габделнур басуларны, чикләрне инде үзләштереп бетергән иде.

Бүген ул, күлмәк якаларын ычкындырып, дымлы җилгә күкрәген терәп, басу өстеннән атлады. Төштән соңгы рәхәт вакыт, табигатьнең җылынып бал, салат исенә эреп утырган вакыты иде.

Кинәт кенә еракта — әллә кайда! — шомлы гөрелдәү тавышы ишетелде, Габделнур башындагы киндер кепкасын салды. Алар яшәгән якларда мондый тавышны бер ишетү өчен әллә ниләр бирерсең! Күк күкрәү... Дымлы болыт исе, яңгыр җиле. Бу — бары тик безнең якның гына бәхете, безнең якның гына гүзәллеге. Дымлы җил тишелеп, калкып килгән кукуруз бәбәкләрен уйнатып алды, биек булып үскән арыш басуыннан каракучкыл дулкын булып йөгерде.

Яңгыр шаулап, тоташ дивар булып килде. Ышыкланырга урын эзләп, Габделнур басу уртасындагы яшел куаклыкка йөгерде. Абайлап алды: бу урында әсирләрнең яшелчә бакчасы—«подсобное хозяйство»сы булган дип сөйлиләр һәм менә ничә еллар инде бу урынны «немец бакчасы» дип йөртәләр иде. Канау аръягындагы биек үлән дуамал җилгә шаштырдап чайкала, егыла, тора, бөтерелә иде. Габделнур ышык урын эзләп чирәмле вал өстеннән салынып төшкән кәкре каен ботаклары астына керде. Күк йөзендә яшен уйный башлады. Каеннар сы-

нардай булып бөгелделәр, эре тамчылы яңгыр, боз катыш шаулап, чирәмле валга, аның өстендәге ялгыз баганага бәрелде, бу тавыш пехота һөҗүме вакытындагы пулемет, автомат тавышларына охшаш иде. Габделнур курка калды: бер ялгызы—кырда. Кинәт күк гөмбәзе чытырдады һәм югарыдан нечкә—ак сызык төшеп таш юл буендагы бер каенга тоташты. Җир ыңгырашып куйды. Шунда Габделнур чәчләреннең үрә торып юешләнгән киндер кепкасын кузгатканын тойды. Яңгырлы тыгыз һавага көек исе таралып китте. Габделнур чын-чынлап курка калды: мондый халәт аңарда Сухиничи янында танклар белән очрашкан чакта булган иде. Әллә, югыйсә, бу вал артыннан чыгып таш юл буендагы кюветка гына ятаргамы? Яшен уты калкулыкны ярата диләр. Тукта, булмаса торып йөгерергә кирәк... Монда, фашистлар бәрәңге, чөгендер үстергән җирдә гомумән, аннан башка да куркыныч. Тукта...

Яшен икенче тапкыр бәргәндә багана төбендәге бер тимер пластинканы ап-ак сөңгегә әйләндерде, ярты тонна чамасы кәс кубарылып күккә очты. Вал өстендә һава «зың-н-ң» итеп торды. Габделнурның колаклары ишетмәс булды, яшен һаман баш очында гына уйный иде.

Ул урынынан торырга курыкты, бары тик бу хәтәр җирдән ераклашырга гына исәпләп сулы үлән арасыннан шуышырга тотынды. Әмма беренче хәрәкәт ясауга аның колагы ачылып китте һәм нәкъ шул вакытта ул җан өшеткеч аваз ишетте. Чытырдап-зыңгылдап китереп салган яшен тавышына:

— А-а-а! А-а-а! — дигән, ачыргаланып кычкырган адәм авазы кушылды.

Габделнурның җаны өшеп китте, үзен-үзе белештермичә, ул сүгенеп куйды, сикереп торды.

— Кабәхәтләр! Гады! Фашисты!

— А-а-а!—Җан өшеткеч тавыш тагын кабатланды. Габделнур алга таба йөгерде һәм үлән арасындагы корыган кәскә абынып, гөрселдәп барып төште. Төште... һәм акылына контрольне югалтты. Аның каршына биек үлән арасыннан шуышып күк мундирлы фашист солдаты килә иде. Яшен бу юлы вал өстенә үк сызылып төште һәм баганадан ап-ак йомычкалар ясап, күз күреме җиргә очырды. Габделнур саташып кычкыра башлады.

— Кабәхәт! Сиңа ни кирәк? Тагын башладыгызмы? Тагын кабатланамы? Үтерәм! Сытам!

— Mein Gott! Mein Gott! Russisch! Kamarade! Helfe mir, bitte![1]

Габделнур үз каршысына шуышып килгән фашист солдатының җиң эченнән чыккан япьлекәсен күреп алды. Солдатның күзлегеннән бер пыяласы төшкән иде һәм ул ялварып ыңгырашты:

— Helfe mir, bitte! Das ist Bliz...[2]

— А-а, блицкриг, кабәхәт! Блицкриг!

Габделнур, күк гөмбәзе яңадан чытырдауга сискәнеп, яткан җиреннән чокырлы җиргә тәгәрәп төште дә, күзләрен күккә терәп тынып калды. Аннан кычкырып көлә башлады. Аның бу дөньядан кабул иткән иң соңгы информациясе шул булды: яңгыр стенасын ярып, аның гәүдәсе аша иләмсез сикереп ямьсез ак битле, япьлекә куллы фашист солдаты йөгерде. Габделнур һаман көлә иде әле. Әмма бер тын белән тотынган көлүен ул ахырына җиткерә алмады: күкнең нәкъ түбәсендәге кара болыт икегә ярылды да, аннан җеп нечкәлеге генә ак сызык туп-туры Габделнур өстенә сузылды һәм күк йөзе соң тапкыр зыңгылдап аның баш мие аркылы җир белән тоташты.

Арыш уҗымы арасыннан иләмсез акырып йөгереп килүчене таш юл өстендә кешеләр көтеп тора иде.

---

[1] Я алла! Рус! Иптәш! Миңа, зинһар, ярдәм ит.
[2] Миңа, зинһар, ярдәм ит! Бу яшен...

Ул ни өчендер ике кулын да югарыга күтәреп йөгерә иде.

...Немец кайчандыр кирәк, китмән белән үзе эшләгән җирне карый барган икән.

«Икарус» кузгалыр алдыннан Асаф кунакларның барысы белән дә күрешеп чыкты. Иң ахырдан гид Ира янына килеп болай диде:

— Әнә теге сары букет тоткан, сары кызга тәрҗемә итегез әле. Минем «ватык телем»нең андый ук көче юк. Безнең халыкта ут чәчәген үзеп алып кайтсаң, кыз баланың йөрәгендә давыл кузгала дип әйтәләр. Сак булсын...

Ира рәхәтләнеп тәрҗемә итте. Тегесе ашыга-ашыга «разговорник» актарды. Аннан елмаеп Асаф янына килде, аңа тагын бер тапкыр үзенең вак сөякле нәфис кулын бирде һәм театраль тавыш белән:

— О kapitan! Ви отшен красивый мужчина! Пусть пламя, буря останутся in meinem Herzen! Sie Sind герой! [1]

Аннан үрелеп, «чуп» итеп Асафны үбеп алды. Немец кызының иреннәреннән тоз тәме килә иде.

Асафның «Отечественная война» орденына кызның мохер кофтасыннан мамык кисәге эләгеп калды.

## XXXII

Илдусның чыгарылыш кичәсендә этисе катнаша алмады.

Алар моннан бер ел элек кенә шәһәргә күчеп килгәннәр иде. Отставкага чыккач Асафны «ветеран» исеме белән мәктәптән мәктәпкә, клубтан клубка йөрттеләр, күп җирдә чыгыш ясарга туры килде, ә менә Илдус укыган мәктәпкә аяк та басмады. Дөресрәге — бөтен чакыруларга Илдус аркылы төшеп килде.

— Син, папа, мине кыен хәлгә куйма,— диде.—Безнең мәктәп рабочий микрорайонда. Малайлар бик гади. Выпендриваться иткәнне бер дә яратмыйлар. Мин алар белән дуслашып өлгердем, син үзеңнең алтын нашивкаларың, погоннарың белән мине башкалардан аерып куярсың...

Егет логикалы, тыныч сөйли иде.

Асаф мәктәпкә бер тапкыр да бармады. Класс җитәкчесе белән дә таныша алмады. Югыйсә, сөйләшәсе сүзләр күп иде. Илдус белгеләр мәсьәләсендә бик тәкәббер булып чыкты. Әнисе шул мәктәпкә урнашты—Илдус моңа да риза булмады. Алган билгеләреннән канәгать булмый, «миңа синең малаең булганга күрә генә бишле куйдылар, минем җавабым бишлелек түгел иде», дип еш кына әнисенә үпкә белдерде.

Зәйтүнә—чәчләренә ак йөгергән, инде юаная барган хатын—улы белән бәхәсләшми, тик үҗәт, ябык, җитди кыяфәтле бу егеткә соклanып, эчтән генә изге теләк тели иде.

— И язмыш, миннән шушы баламны күпсенмә.

Асаф улының андый сыйфатларына шат иде. Укырга кая керү мәсьәләсендә дә гаиләдә бәхәс булмады.

— Эти, мин хәрби училищега китәм,—диде Илдус бер көнне мәктәптән кайткач.

Асафның йөрәге дерт итеп алды.

— Кайсы училищега?

— Хәрби диңгез училищесына.

---

[1] О капитан! Сез бик матур кеше. Давыл, ялкын минем йөрәгемдә калсын. Сез — герой.

— Формасы, ленточкасы кызыктырамы?

Илдус олыларча үпкәләде.

— Папа! Мине белмисеңмени инде син?

Асафның күңеле йомшады. Ата белән улы сөйләшеп торган бүлмәгә Зәйтүнә килеп керде.

— Иә, личный состав. Ашарга әзер, пробасы алынган, — диде Зәйтүнә гадәттәгечә икесенә дә сөеп карап.

— Менә, әнисе, малаең безне ташлап китәм ди бит әле...

Зәйтүнә әсәренде. Матур күзләрен зур ачып, бер улына, бер этисенә карады.

— Хәрби училищега китәм ди.

Әнисе җиңел сулады. Малае янына килде, җилкәсенә кулын куйды.

— Үзең белгәнчә хәл ит, улым. Әтиең каршы түгелдер бит?

— Юк, мин бик шат, — диде Асаф. — Тик менә хәрби училищеның нәрсә икәнен күз алдына китерәме ул? Ялган бравада гына кызыктырмыймы аны? Лейтенант погоннары такканга кадәр курсанттан җиде кат стружка каезланып алынганын беләме? Туалет чистартырга, бәрәңге арчырга, идән юарга, чүп-чар төяргә, үз кереңне үзең юарга син әзерме?

— Ну, эти...

Ул көнне семья өстәле янында шатлыклы, кечкенә генә бәйрәм ясадылар.

Ә икенче көнне ишекнең звоногын чыпчык ташы төсле егет басты.

...Асаф өч-дүрт көн өйдә ятты. Зәйтүнә, аның характерын яхшы белгәнгә, артык сорашмады. Асаф актыгына кадәр ачылып бетәргә яратмый иде һәм шуңа күрәдер, ахрысы, Зәйтүнә өчен ул гомер буе яңалык булды, гомер буе Зәйтүнә аны «ачты», гомер буе яратты, гел яңача яратты. Бу хәлгә дә ул зур фаҗига дип карамады.

— Нишләттеләр сине, героем минем? — дип аның битенә, иреннәренә примочкалар куйды, яратып сырпаланды.

Постельдә тик ятуны Асаф әйбәт файдаланды. Хәрби темага бии ел эчендә төннәр буе утырып язган истәлекләрен таныш язучысы тәкъдиме белән нәшриятка җибәргән иде. «Чыпчык ташы» белән очрашканның икенче көнендә үк почтальон аның исеменә калын бандероль китерде. Бандероль эчендә ниләр буласын Асаф сизде: аның тормышында бөтен хәлләр ниндидер бер закончалыкка буйсыналар иде. Әһә, кичә сине изделәрме? Бүген өстәячәкләр. Син нык булсын өчен. Җебеп төшмәсен өчен. Аннан рәхәт булыр. Бер көнне күңелеңә хуш килерлек хәбәр әйтерләр. Әзер тор: кичкә тагын булыр. Иртәгесен тагын да әйбәтрәк бер сюрприз булыр. Әмма чыда, кәпрәймә... Аннан тормыш сине икенче ягы белән сынар. Тормыш ул бер битен, бер артын күрсәтә.

Бандерольдә кулъязма һәм рецензия иде. Кулъязманың эчтәлегенә, стиленә, композициясенә дәгъва бик зур иде. «Композиция...» дип кара янган иреннәр белән авыр елмайды Асаф. Композиция... Дрезден урамына безнең батальон кергәндә нинди композиция булды икән? Асаф взводы Дрезден галереясын миналардан чистартканда бу рецензент нинди «композиция»дә булды икән?

Асаф яткан көе генә кулъязма кырындагы искәрмәләрне укып чыкты. Ачуы килмәде — көлде генә. Рецензент бер урында «ПТР» нәрсә ул? Аңлатырга иде» дип куйган. Икенче бер урында «сорокопятка» нәрсә соң ул? Саескан үкчәсе түгелдер бит?» дип язган. Тагын бер урында: «капитан-лейтенант» дигән звание буламыни? Капитаны ае-

рым, лейтенанты аерым түгелмени аның?» дип язып куйган. «Бу көе дигән, боларны басарлык түгел, кабат эшләргә кирәк».

Бу дөньяның кеме юк? Асафка җиңел булып китте. Көлә-көлә укыганда ул сызлануларын онытып торган икән...

Май ае беткәнче ул кулъязмасын төзәтеп утырды. Бу — яшьлеккә, сугышчан яшьлеккә кире кайту иде, үзенең һәлак булган иптәшләре, аларның батырлыклары турында язган урыннарны ул тагы да киңәйтте: Оборона Министрлыгының архивыннан почта аша ул бик күп справкалар алдыртты — рецензентның кире кагуы гел файдага гына китте. Актык чутта «чыпчык ташы» да файда эшләде: өйдән чыгарлык булса, май аенда ул очрашулардан кайтып керә алмас иде.

Май ахырында гына Зәйтүнә аңа санаторийга путевка алып кайтып бирде.

— Поездлар йөреп тора, атнасына бер кайтырсың, илле минутлык юл,— диде.— Без бара алмыйбыз — Илдусның иң җаваплы көннәре.

Аерылганда Асафның борын очыннан тотып шаяртып куйды:

— Син анда минем хатын үлде, ялгыз яшим дип төтен җибәреп, чамаңны югалтма, — диде. — Синең — бабай, минем — әби булыр вакыт җитә. Бу атнада Илдус көн саен ниндидер бер кыз белән телефоннан сөйләшә. Аделя исемле бугай...

Һәм менә Асаф мәһабәт нарат урманы эчендәге яңа бинаның бер кешелек бүлмәсенә килеп урнашты. Аның үз гомерендә беренче мәртәбә ялгызы гына ял итүе иде. Беренче көнне үзен кая куярга белмәде, медицина формальностьлары белән көн үтте.

Икенче көнне ул иртән торып чыкканда бер дә җилсезгә карт агач башлары шаулый иде. Бакчага чыгуга аның кәефе начарланды. Әллә нигә аның йөрәгендә хәсрәт катыш моң, нәрсәнедер сагыну хисе сызыпсызып ала, авыр хисме ул, җиңел хисме? Карт агач башлары шаулый, алар арасыннан зәп-зәңгәр күк кисәкләре күренеп ала, аның саен йөрәкне әлегә исемсез бер рәхәтме, газаплымы тойгы телеп-телеп ала. Ә-ә... Бу шау, бу зәңгәр шау яшьлекне искә төшерә икән...

— Хәерле иртә, исәнмесез!

Зәңгәр юка трико, кеды кигән егерме биш яшьләр чамасындагы егет аллеядан аның каршысына килеп чыкты. Ашханәдә бер өстәл янында ашыйлар, кичә сөйләшеп танышканнар иде, егет — юридик факультетны тәмамлап, милиция органнарында эшлим дип әйткән иде.

— Хәерле иртә, туган. Иртәнге зарядкамы?

— Әйе, системага кергән бер гадәтне бозмыйм дидем. Иртән һәр көнне унбиш километр. Кышын да, җәен дә.

Сөйләшеп киттеләр.

Сөйләшсәләр — гаҗәпкә калдылар.

Егет Асафлар белән бер урамда яши икән. Әмма иң гаҗәбе Асаф өчен булды. Егетнең исеме Илдар, фамилиясе... Рәимов иде.

Асаф барган җиреннән туктап калды.

— Ничек Рәимов? Без бер нәселдән түгелдер бит?

Егет көләч елмайды:

— Белмим тагын. Без — Кузнецк мишәрләре. Ә сез?

— Безнең нәсел моннан. Алай... Бик кызык булды бит әле бу. Һе... Фамилиядәш белән бер өстәл янында. Мин моңа шат, бик шат, туган.

Төшке аш вакытында Асаф бу егет белән иркенләп сөйләште. Сөйләшә торгач, тагын бер ачыш ясалды. Илдар район милиция бүлеге начальнигының яшүсмерләр арасында җинаятьчелек белән көрәш буенча ярдәмчесе икән.

— Газеталарга да язгалыйсызмы? — дип сорады Асаф йөрәге ети тибә башлаганны тоеп.

— Язгалыйм. Сирәк-мирәк кенә. Әле апрель башында гына яшьләр газетасында зур бер мәкаләм чыккан иде. Шау-шу куптарды. Яшүсмерләр арасында бик азынганнар бар бит... Газетасыз, радио, телевидениесез милиция үзе генә тыеп бетерә алмый аларны.

Асаф тирән сулыш алды.

— Алайса, бүген кичке аш алдыннан минем бүлмәгә кер әле, — диде ул, ниһаять, балаларча шатланып. — Минем мондагы киосктан алган бер шешә сухое вином бар...

— Нигә «алайса» дисез, Асаф абый? Милиция органнарына берәр гозерегез юктыр бит? Рәхим итегез, нигә аңа «сухое вино?»

— Юк, болай... Просто ял итәргә ияләнә алмыйм, эч поша.

Ул көнне Илдар белән алар бүлмәдә озак сөйләшеп утырдылар, әмма күбрәк Асаф сөйләде. Ул үзенең яшьлек истәлекләрен сөйләде...

Алар арасында шулай җылы мөнәсәбәтләр урнашты — ике-өч көн узуга Илдар иртәнге маршрутында Асафны да алып чыкты. Сәламәтлек мәсьәләсенә егет бик җитди карый икән.

— Көн саен ун километр йөгергән кешегә врачның кирәге юк, — диде ул аерылганда. — Сезгә бүген ике километр җитә, көн саен биш йөз метрга арттыра барасыз. Берничә көннән без сезнең белән бер режимда булачакбыз.

Илдар дөрес сөйләгән икән: Асафның утыз биш елларга сузылган, өч-дүрт төн саен кабатлана торган саташулы төше юкка чыкты.

Бары тик срок бетәргә ике көн кала гына — егерме беренче июньгә каршы төнне генә ул начар йоклады. Егерме беренче июнь... Кырык беренче елның егерменче июнендә ул урта мәктәпне тәмамлаган иде. Ул кичне алар ФАШ кызларының кичәсенә барганнар иде. Шул төнне аңа мәңге онытылмаслык өнме-төшме икәнлеген аерып булмаслык бәхет кояшы балкыган иде. Юк, кояш түгел, өстенә ай нуры яуган иде. Нинди кыска, ләззәтле бәхет иде ул. Әлеге бәхет бераздан сугыш гарасаты, кабат мәхәббәт һәм борчулар белән күмелде. Тик ара-тирә генә ул төннәрен яшькелт ай нурына — билгесезлеккә чума иде дә, аның каршына шул газәмәтле ай нуры арасыннан сагышлы күзле, калын толымнарын ефәк эчке күлмәгенә тараткан сихри кыз килеп чыга иде... Сирәк кенә ул кыз хәсрәт катыш елмая һәм сорап куя иде:

— Асаф... Җаныкаем минем! Син үлгән идең бит! Син исәнмени? Мине хәтерлисеңме?..

Санаторийдагы бер төн шулай борчулы узды. Иртәгесен умыртка сөягендәге осколок кузгалды, ахрысы, аркасы сызлаганга уянып китте.

Тышта егерме биш градус эсселек, җылы ылыс исе ургылып-ургылып тын юлына керә, дөньяны виктория җиләге исе баскан иде.

Ул көнне төштән соң кучтәнәчләр күтәреп улы Илдус килде. Телефоннан чылтыратып әтисе аның имтихан нәтиҗәләрен белеп барган иде. Дөньяда улың булсын...

Ата чандыр улының ныгып килә торган кулын кысты. Аннан чандыр аркасыннан сөйде.

— Молодец, улым, синең уңышың — безнең өчен зур шатлык, — дип әллә нинди формаль җөмләләр әйтеп бетерде.

— Бүген безнең чыгарылыш кичәсе, әти, — диде Илдус нәрсәнедер әйтеп бетермәгән кебек.

— Соң, бик әйбәт. Костюмың шәп чыкканмы?

— Шәп анысы.

— Ә нәрсә кирәк? Акчамы? Безнең арада бу мәсьәләдә бер дә аңлашылмаучылык чыкканы юк иде кебек...

— Юк, эти. Акчам бар, әни бирде ун сум.

— Ә нәрсә соң? Я, әйт, ирләр бит без.

— Эти... Малайлар әйтәләр... Өстәл саен берәр сухое вино куйыйк диләр. Ты не возражаешь? Рөхсәтме? Әни синнән рөхсәт сорарга кушты.

— Нәрсәгә рөхсәтме?

— Ну инде... Бер рюмка эчәргә. Үзең шулай дип әйтә идең элек. Унынчыны бетергәч дип. Эчмәсәм, миннән көләчәкләр, хатын-кыз заты дип.

Асаф улын кочаклап алды.

— Рөхсәт, улым, рөхсәт. Менә шул: син бүгеннән башлап мөстәкыйль тормыш юлына басасың. Һәр адымыңа үзең җавап бирәсең. Карарны үзең кабул итәргә өйрән.

Малай башын аска иеп бәхетле кызару белән кызарып тора иде.

— Аннан, эти. Тагын бер просьба.

— Әйдә, әйдә, Илдус! Мин монда просьбаларны сагынып беттем инде.

— Ни... Как бы это сказать. Класссташ кыз белән килдек без монда. Аделя. Аның әнисе ял йортында врач булып эшли. Аделя әнисе янында калды, ярты сәгатьтән монда санаторийга киләм диде. Керсенме? Рөхсәтме?

— Отлично, улым! Яле, карыйк әле, булачак килене нинди икән ветеранның?

— Ну инде, эти...

Ишекне шакыдылар. Илдус сикереп торды.

— Да, да, пожалуйста, — диде Асаф, караватын тиз генә төзәтеп.

Бүлмәгә июньнең үзе кергәндәй булды. Җинсез сыек зәңгәр күлмәк кигән, карлыгач канатыдай кыйгач кашлы, тупырсык иркә иренле, озын чәч толымнарының берсен алга салындырган зифа буйлы бер гүзәл килеп керде. Я, алла! Унынчы классны тәмамлаганда кызлар шулай җиткән булалармыни соң?

— Исәнмесез, Асаф абый, — диде кыз, җанга ятышлы күкрәк тавышы белән. Бу тавыш секунд эчендә Асафны яшьлегенә кайтарды. Әйе, әйе, бар иде алар яшь вакытта мондый тавышлы кызлар.

Шуннан кызык булды: Илдус та, Аделя да үзләрен иркен тоттылар. Асаф кына каушады. Нәрсә әйтергә белмәде.

— Сезнең берәр банкагыз бармы? — диде Аделя.

Асаф аңламады.

— Ә? Банка? Нинди банка? Флотта урындыкны «банка» диләр.

Кызыкай көмеш табакка мәрҗән койгандай итеп көлде.

— Сезгә чәчәк җыйдык, әни белән, — диде. Шул арада тумбочкадан бер стакан алды да, ялт итеп су салды, чәчәкләрен утыртып куйды.

— Ярый, без китик, — диде Илдус. — Значит, син, эти, берсекөнгә кайтасың...

— Ә... Әйе, берсекөнгә... Әйе, кайтам.

— Безнең әни сезне белә икән, — диде Аделя чын күңелдән. — Әллә инде бер гарнизонда торгансыз. Минем әтием сынаучы-очучы иде. — «Иде» сүзен Аделя авырдан әйтте, күз керфекләрен түбән төшерде. Без әле быел гына монда күчеп килдек. Әтием һәлак булгач. Әнием дә монда вакытлыча эшли. Ул сезнең янга керәм диде.

Асаф бүлдереп, сорап куйды:

— Әтиегез нинди званиедә иде? Фамилиясе ничек?

Аделя моңсу караш ташлап, акрын гына әйтте:

— Әтием подполковник. Сынаучы-очучы. Фамилиясе — Керимов Азис. Ул — Судакта туган. Әбием — Алма-Атада яши.

Яшьләр хушлашып киткәндә генә Асаф кызыйдан сорап куйды:

— Әниегезнең исем-фамилиясе ничек соң?

— Исән-сау кайтыгыз, Асаф абый! Әниемне пациентлары Сылу Мөкаддировна дип йөртәләр.

— Хуш, эти, исән-сау кайт.

Асафның күз аллары караңгыланып китте. Караватына барып утырды. Тамагы кысылды, тын алуы кыенлашты. Өстәлдәге чәчәк бәйләме бүлмә эчендә йөзеп йөри башлады.

Коридорда биек үкчәле туфли кигән таза хатыннар гына басып йөргәндә чыга торган шыкылдау тавышы ишетелде.

Ишек кактылар.

— Әй-йе. Кере-гез... Керегез.

Чәчәк бәйләме һаман бушлыкта йөзә иде.

## XXXIII

Кинәт дымлы җил исеп китте, күк йөзенең урман белән тоташкан ягыннан шомлы гөрелдәү ишетелде, яңгыр җиле уйнаклап күл кырыендагы сары иңкүлекне бөтерә башлады, ул арада кечерәк кенә зәңгәр-кара болыт кояшны каплады. Шомлы җилгә күл буендагы сары чәчәкләр борчулы бөтерелделәр, сазлык исе борынга бәрелде — давыл чыгар алдыннан гына исә торган уйнак җил күл өстенә төрле яклап килеп бәрелде. Күл буенда камышлар шыгырашты.

Чү! Ерак тугай артында ук сузылып яткан зәңгәрсу тау бите, үлән исе, тыгыз җил — сез кинәт кенә күңелне кузгаттыгыз. Тукта, исмә, җил, син, болын, җир исе алып киләсең дә, тын юлларын кытыклыйсың, хәтерне тирәнәйтәсең, элеккеге кадерле минутларны, йөрәк җәрәхәтен яңартасың...

Чү! Тукта, җил... Яшьлек гомеренең газаплы, ләззәтле башланган сукмагында утырган ветеранның аксыл чәчләренә кагылма, ул чәчләрне таратма.

Тукта, исмә, җил...

*1978 ел, Казан.*

## Нури Арсланов

# ЯЗГЫ ТАҢДА

### Юк

— Ник борчылам!— димә бер дә,
Вөҗданлы кешенең җирдә
Борчусыз булганы юк.

Сиздермәскә теләп тыштан
Күпме кыланма, сагыштан
Котылу юллары юк.

Масаясың икән данга, —
Бел, бер кемнең, бер кайчан да
Мактанып уңганы юк.

Патшалар да дәуран сөргән...
Тик бер кем кеше гомереннән
Артыгын торганы юк.

Аягыңны суз чамалап,
Тормышның аякка карап
Юрганнар сырганы юк.

Җан — җан инде, күпме янсын —
Талпынмасын, нишли алсын?! —
Аягы-куллары юк...

Бәхетем минем бер яклы:
Булса да күкләрем якты, —
Ае бар, Чулпаны юк.

Күз яшьләрем, таммасана,
Яңгырлар күпме яуса да
Диңгезләр тулганы юк.

Көннәре үтте язымның,
Шулай да күңел сазымның
Кыллары тынганы юк.

Хикмәт тә килми иптәшкә,
Инде җитәм җитмеш яшькә —
Нәфеснең туйганы юк.

## Җир әйләнә

Әйләнә ут күбәләге-
Җир кояш тирәсендә.
Кешеләр яши бәлале,
Бәхетле тирмәсендә.

Көн-кояш бизи тирмәне,
Төн-кукләр балкып тора. —
Космонавтларга тиңнәрне
Үзенә тартып тора.

Бер карасаң табигатьнең
Бәхетле җаннары без:
Хуҗасы шушы рәхәтнең,
Солтаны, ханнары без!

Бер карасаң үзебез тапкан
Атом тетрәтә безне:
Имкян бармы котылмакка? —
Ватам, ди, җирегезне!..

Кеше, арын киртәләрдән,
Атомны кулга алчы! —
Саклап калчы шул бәладән
Җир шарын, ярылганчы.

Җир әйләнә, җир әйләнә
Кояшы тирәсендә, —
Гел сагалар микән бәла
Кешелек тирмәсендә?!

## Тылсымлы иртә

Болыт кызы уйный
Кояш арфасында, —
Язгы иртә тыңлый
Яшел арбасында.

Ул атларын җиккән,
Бар да яшел яллы,
Япмалары чиккән,
Һәр бизәге җанлы.

Калгый серле моңнар,
Җир тирән тын ала,
Сызыла алтын кыллар —
Чыңлап тора һава.

Яфраклардан тама
Чык — яшь бөртекләре,
Баллы дымын кага
Чәчәк керфекләре...

Миңа язгы назның
Сере аңлашыла:
Мин утырам язның
Яшел арбасында.

Менә чыгам юкка —
Эреп бетәм мин гел —
Мин һавада, чыкта...
Мин — беркем дә түгел.

Аң шат — ирек тоеп, —
Ни сан — матдә тәнгә!
Калгыйм татлы оеп,
Бөтен дөньям — мәгънә.

Тәмам әсир иткән
Сере хәят көенең...
Болыт кызы кигән
Купшы көмеш киемен;

Мине чакыра көлеп;
Рухым күккә менә —
Гаҗәп моңнар кереп
Тула күкрәгемә!..

## Томан

Яшермәкче икән җирне кемнән:
Каплап алган томан.
Битен юа кояш томан белән,
Тагын иртә торган.

Әйтерсең лә томан таң кояшын
Чыккан каршыларга.
Белми аның тиздән нур коясын
Чыклар, тамчыларга:

Белми томан үзенең шул ук нурдан
Эреп бетәчәген,
Үзгәрешсез кояш иске юлдан
Дәвам итәчәген...

Гомерләр дә томаннардан туып,
Томаннарга китә.
Ә Мәңгелек, гел күрмәгән булып,
Үзенекен итә.

## Шулдыр инде

Бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү,
Без аны кайдан белик, мескен үлеп аңлатмагач?!

Г. ТУКАЙ.

Уйлый китсәң, башны гынамыни,
Күрәлмыйлар хәтта бүркеңне:
Кеше кадрен кеше беләмени
Үлеп күрсәтмәсә бер көнне...

Вөҗдан әйтте: ирлек шунда, имеш,
Туз, тупаслык йөзеңә бәрсә дә, —
Кеше күңелен син күрергә тиеш!
Синең күңелең аңа... нәрсәгә?!

Көчле идем, тик көч күрсәтергә
Теләмәдем, ектырмасам да,
Тинтәкне дә егып кимсетергә
Ашыкмадым, тик тормаса да.

Ярым уйнап, күпме ярым чынлап
Сынаучылар булды ирлеген:
Мин барсына сабыр тордым чыдап,
Тарайтмадым күңел киңлеген.

Урамнарда каршы атлап килгән
Пәһлеваннар күрә идем мин,
Якынайсам... алар кайтыш миннән! —
Үз-үземнән көлә идем мин.

Хатом-Тайдай юмарт, ә дуслыкта
Охшаш булыйм дидем Пиладка:
Янды йөрәк бик еш әрнеп юкка,
Татлы уйлар калды тозлакка [1]...

Шулдыр инде кече күңеллелек —
Үземне зур саный алмадым,
Масаймадым үз чамамны белеп,
Гел үземне үзем алдадым...

Юкка гына язмыш көләмени?!. —
Сагынып әле саулар төркеме:
Кеше кадрен кеше беләмени
Үлеп күрсәтмәсә бер көнне.

## Ә күк исән

Зөһрә кызның шуклыклары хәттән ашкан —
Айның алтын иягенә менеп баскан,
Ул тамаша кыла өстән якты җирне,
Ә мин балкып торган күккә карыйм астан.

Менә утыра аякларын салындырып,
Бер уйный төн сазында, бер кала тынып,
Шаян кызый алып китә хыялларга,
Борынгыны, узганнарны сагындырып.

Күпме гасыр бу йолдызлар күзләнмәгән?!
Күпме гашыйк айдан сердәш эзләмәгән?!
Туып-үлеп иске тузса-үзгәрсә дә,
Узганнардан тик күк кенә үзгәрмәгән.

Ничә миллиард һәлакәтен [2] өстән торып
Ай күзәткән бүгенгедәй салкын, тынып,
Бүгенгедәй айның алтын иягенә
Зөһрә яткан, аякларын салындырып...

Күл-Тегиннәр, Күли-Чурлар [3], айга карап,
Йөргән диләр ирек яулап, Чинны [4] камап:
Ай астында яна гомер — яна кеше,
Гүя ул ут күбәләге, алтын канат.

Баһадирлар янган, илләр, җирләр янган,
Заманалар янган — көлләр генә калган...
Ә күк мәңге исән, балкый борынгыча,
Сихерле кыз Зөһрә карап тора айдан.

---

[1] Тозлак — корылыктан ярылып яткан җир.
[2] Соңгы биш мең ел эчендә сугышлардан 3,5 миллиард кеше һәлак булган.
[3] Күл-Тегин, Күли-Чур — төрки дәүләтләрнең полководецлары.
[4] Чин — Кытай.

## Язгы таңда

Ак бүреген кигән болыт артыннан
Кояш нуры җепләр булып тартылган:
Җәеп салган да таң яшел аркавын
Келәм тукый, бизәкләре алтыннан.

Космонавтлар башлыгыдай гөмбәзен
Өскә ябып куйган да күк-көязең
Карап тора биекләрдән, масаеп,
Гүя санга санамый җир-иясен.

Белми микән әллә кемнең-кемлеген,
Кем ачканын зәңгәр тирмә төнлеген? —
Шул төнлектән бер-бер артлы атылып
Җир уллары эзли галәм «кендеген».

Ни эзләп, ни тапмас адәм баласы!
Таң нурына чумган күңелем даласы, —
Мин сокланып туймыйм, шушы мохиттан
Миңа ләззәт аласы да аласы!..

Шигърият бит — җирне җәннәт санауда,
Фән-мохитны матдә итеп карауда:
Беркайчан да кешегә юк котылгы —
Һәр икенең әсире ул, камауда.

Камалса ни! — күңел бәхеткә тулса
Зыянмыни фән дә үзенчә кылса?!
Ә шагыйрьнең бар тылсымлы канаты —
Космонавттан һич ким түгел атылса!

Хыялларда мин дә күккә талпынам
Кояш дигән җанлы йомгак артыннан;
Көмеш чыкта язгы таңның аркавы,
Келәм тукый, бизәкләре алтыннан.

## Бик бәхетле чагым

Хыял була киләчәгең түгел,
Хәтта борынгылар:
Кайтар мине далаларга, күңел —
Ал канатлы толпар.

Ял итимче, ыгы-зыгылардан
Арыныймчы мин бер.
Тилмер, күңелем, онытылмыйча калган
Сагышлардан тилмер...

Өзгәлән дә сызлан, шундый татлы
Була сагыш назы!
Шуңа, ахры, ахирәтен тапты
Миндә дала сазы.

Кыз Җебәкнең Түләгәне шунда
Ауган диләр яуда.
Баян Сылу, байгош, һаман юлда,
Кузы Күрпәш ауда...

Шул далада, менеп асыл атка,
Абай йөргән диләр,
Абай моңын һаман тирә-якта
Сызгыралар җилләр.

Җәйләүләрдә, дала кочагында
Көй чыгарган Майра:
Татар, казакъ моңы учагында
Ян син, күңел, сайра!

Сагын, сагын нәни Нәфисәңнең
Ялан аяк чагын,
Тик ул яшьли сулган, белми, бәгърем,
Нурые сагынганын...

«Гашыйк бала», хадисәләр [1] кичереп,
Инде бабай булды:
Гомер җамын тутырып эчеп, исереп,
Язмышыннан уңды.

Сагышлары исә әле дә яшь,
Элеккедәй үреләә.
Ие, миңа һаман дөнья көләч,
Матур булып күренә.

Кабын, күңелем, гел картаймый торган
Сагышлардан кабын.
Рәхәт миңа — күңелләрем тулган —
Дулкынланган чагым!

Ә бит бәхет яше шундый татлы,
Татлы сагыш яше!..
Шуңа минем күкрәгемдә якты,
Ә күзләрем яшьле.

## Бичара эт язмышы

Кешелексез кеше «этлек» кыла.
Кеше түгел шул эт, нишләсен,
Закон язылмаган аңа бола,
Эт язмышы башыңа төшмәсен!

Утермиләр нәрсә өчен генә...—
Рәхимсезләр азмы дөньяда?!.
Этне түгел, хәер, кешене дә
Сагалаучан андый шобага.

Бер явызы аңа төзәп аткан
Көчекләрен ялап торганда:
Ике күзен төн карасы япкан,
Дөньяларга ак көн туганда...

Көчекләре утын аранында,
Үксезләрне инде кем карар?
Буам дигән чакта аларын да
Яклап калган диләр балалар.

Балада шул бәллүрдәй саф күңел,
Ул — фәрештә, аңа кагылма! —
Бүре дә бит бер дә ерткыч түгел
Ана сөте имгән чагында.

*1979*

[1] Хадисәләр — вакыйгалар, хәлләр.

Гариф Ахунов

# ЙОЛДЫЗЛАР КАЛКА

ПОВЕСТЬ

## Багышлау



Мәскәүгә, язучыларның иҗат йортына китәргә җыенып беткән идем инде. Чемоданымны тотырып ишек төбенә куйдым. Җиде яшьлек улым, сикереп, муенымнан кочаклады да, саубуллашып мәктәбенә чыгып йөгерде. Бәләкәй кызым: «Әти, курчак алып кайт, яме, кечтекине алып кайтма, зурны алып кайт, яме», — дип янымда бөтерелә башлады.

Ул арада әниләре дә килеп җитте:

— Тыңлале сүземне... болай ит... Романың язылмый торган араларда көндәлек яз. Иҗат йортында бит анда берьюлы дистәләгән язучы ял итә. Үзебездә дә бит очрашулар гел булып тора. Китапларыгыз белән җенләнеп, төннәр буе сөйләшеп чыгасыз ич. Җилгә очмасын иде шулар, кәгазьгә төшә барсын иде. Үзең дә беләсең, кеше хәтере — тишек капчык: барысын коеп бетерә...

Бу сөйләшү моннан егерме еллар элек, без Әлмәттә яшәгәндә булды. Шуннан мин яза башладым. Очрашуларны. Җыелышларны. Әдәби бәхәсләрне. Тау чаклы материал җыелды. Монда Гомәр Бәширов белән Ибраһим Гази, Гази Кашшаф белән Хатип Госман, Мостай Кәрим белән Сибгат Хәким бар. Монда мине колагымнан тартып әдәбиятка алып кергән укытучыларым бар. Монда Хәсән Туфан — үзе бер дөнья. Мәскәү язучылары Леонид Соболев, Сергей Михалков, Антонина Коптяева. Минем гомерлек кумирым Михаил Александрович Шолохов. Урта Азия, Украина язучылары, Һиндстанга, Бельгиягә сәяхәтем, Италия язучысы Джанни Родари белән очрашулар...

Мин бу китапны үзем исән чагында, бәлки, дөньяга чыгармам дигән идем. Ләкин бездә, татар әдәбиятында, язучылар тормышы, язучылык хезмәте турында китаплар булмау мине уйланырга мәҗбүр итте. Истәлек-мемуар жанрына керә торган китапларыбызда да бу язучы хезмәтенең кухнясы, ягъни китап язылуның иң-иң кызыклы мизгелләре кәгазьгә төшерелми, өлкән язучыларыбыз, автобиографик әсәрләр язганда күбесенчә балачакларын тасвирлау белән чикләнәләр.

Ә мин язучыларның байтак китабы дөньяга тууына шаһит булдым. Шуны үземдә генә саклап калыргамыни? Ә, бәлки, минем бу язмаларым әдәбият мәйданына әлерәк кенә аяк баскан яшь иптәшләргә файдалы булыр?..

Әнә шундый изге ният белән, язучылар турындагы бу әсәрне, гадәти булмаган повестьны, укучылар карамагына тапшырам.

Рәхим итеп, Әдәбият иленә сәяхәткә чыгыйк.

АВТОР.

1979, август.

# ЮЛ БАШЫ

## Җуелмас яра

Татарстанда Тукай Казан арты дип билгеләгән бер як бар. Себер тимер юлы белән Казаннан алтмыш чакрымнар киткәч, Арча булыр. Автобуска утырып шул чама баргач, Кенәрләр, Әтнәләр булыр. Әнә шул инде ул — Казан арты. Дан булып җырларга кергән Иделләре, Агыйделләре, Чулманнары да юк аның, көмеш күлләре дә күренми. Әмма урманнары бик матур, кешеләре киң күңелле. Булдыклылык, тырышлык дисәң, аларга тиң бар микән?!. Нәкъ Казан артында, Арча белән Балтач арасында, тау башына менеп кунаклаган унөч кенә йортлы кечкенә Өчиле авылы бар иде. Өч йөз ел буе яшәп тә, унөч өйдән артмаганга, кешеләр аны шүрәле каргаган дип йөртәләр иде. Әнә шул кечкенә Өчиленең урта хәлле крестьян Ахунҗан гаиләсендә өченче бала булып мин дөньяга килгәнмен.

«Ачлык елдан соң дүрт ел үткәч, бәрәңге алганда тудың син, балам. Әтиең, син тугач, ак күлмәкләр тектерде, туган-тумачаны чакырып, зур бер бәйрәм ясады»,— ди торган иде әни. Бәрәңге алганда дигәне 1925 елның 18 сентябре булып чыкты.

Әти-әнием дөньяга минем ир малай булып тууыма сөенгәннәр сөенүен, ак күлмәкләр киертеп, курчак-бәби итеп тә йөрткәннәр, ләкин мин үзем әти-әниемне сөендерергә ашыкмаганмын, әллә җиде айлык булып, җитлекми туганга, нечкә сыйраклы, дәү корсаклы чирләшкә бер малай булып үсәм икән. Бер ел тулыр-тулмаста, сеңелем Сәҗидә тугач, мине имидән аерганнар. Сөтсез яшәүдән мин бөтенләй кәеккәнмен. Үлем фәрештәсе минем баш өстемдә канат кагып тора башлаган. Күрсәтмәгән врач, өшкертмәгән ырымчы калмаган — берсенең дә файдасы тимәгән. Шуннан әни үзе тотынган. Дөньяда бик күпне күргән, авыру ирен шифалы үләннәр белән дәвалап аякка бастырган күрше карчыгының киңәше буенча, бик кызу итеп мич яккан, күмерен алып, мичне томалаган да мине ипи көрәгенә утыртып, мичкә тыгып «җылытып» алган, аннары сеңелем белән икебезне ике тезенә утыртып имезә башлаган. Ана кулыннан да шифалы, ана күңеленнән дә җылы тагын нәрсә булуы мөмкин? Шуннан мин тернәкләнеп киткәнмен.

Боларны мин ишетеп беләм.

Дөньяны аңлый башлагач алган беренче ярам — этисез калу. Этиемне авыл кешеләре әле дә сагынып сөйлиләр. Тәбәнәк буйлы булса да, төптән нык булып үскән бик гайрәтле кеше иде диләр. Авылда ул беренче коммунист була, Өчиледә колхоз оештыра. Аның, урта хәлле крестьянның, коммун булып китүе Сукыр Аптул белән бәйле. Бездән өч кенә чакрымда Казанбаш исемле авылның «ата пролетары» Габдулла Заһидуллин, Донбасс шахталарын айкап, дөньяның кая таба барганын тоеп кайта. Минем этине үз юлыннан әнә шул кеше алып китә. Эти председатель булып эшләгәндә, шкафтан алып, ниндидер сары кенәгә ертканымны хәтерлим. Хәтерләвемнең сәбәбе — эти минем арт чүмечкә кизәнми генә берне салды һәм мин, егылып, борынымны канаттым.

Алтынчы яшем белән барганда, аны кулаклар үтерде. Өчиледә җыен-сабан туй чаклары. Бездә — өй тулы кунак. Эти кара туры айгырны җигеп, иртүк Төрнәле авылына чапты. Без, күрше малае Мансур белән, урамда шырпы тартмасына бал корты ябып, умарталы уйнап йөри

идек, безнең йөрәк кагып чаба торган кара туры айгыр томырылып авылга килеп керде.

Тарантаста эти юк. Тарантаста — җиңнәренә кызыл бәйләгән чит кешеләр. Айгыр ак күбеккә баткан.

Әни ишегалдына утын алырга чыккан иде. Кызыл тасмалы кешеләрнең, тарантастан сикереп төшеп, аңа нидер әйтүләре булды, әнинең кочагына күтәргән утыны, дөбердәп, җиргә коелды. Кызыл тасмалылар, аны тарантаска утыртып, киредән чаптылар.

Аннары авыл купты. Аннары бөтен авылның ир-атын җыеп, безнең амбарга яба башладылар. Җылау-сыктау, тиргәү һәм каргану белән тирә-як тулды. Мансур белән мин ак күбеккә баткан айгырны кызганып йөрдек.

Безгә этине юып, киендереп, табутка салгач кына күрсәттеләр. Кара костюмнан, көл кебек ак йөзле, көрәктәй дәү кулын күкрәк өстенә куеп, күзләрен йомган иде ул. Мин аның үлгәненә ышанмадым. Аның йөрәгенә пычак белән кадаганнар, ул гүя йөрәк ярасын кулы белән каплап кына ята кебек тоелды.

Этине бездән өч чакрым ары Казанбаш дигән авылга, авылның Арча ягыннан керә торган башына япа-ялгызын күмделәр. Байтак еллар үткәч кенә, мин бу зиратның авыл коммунистларын хөрмәтләп күмә торган аерым зират икәнен белдем.

Этине күмгәндә яңгыр сибәли иде. Бик күп, бик күп булып халык агыла, табут янынннан атка атланган кешеләр бара, җиз торба кычкырталар, «параман» кагалар иде.

Өч мәртәбә мылтыктан гөрселдәттеләр.

Мин, куркып, җиргә утырдым, җылый башладым. Кемдер мине күтәреп алды, җилкәсенә утыртып, кабер янына алып китте. Актыктан Габдулла агай Заһидуллин мине күтәргән кешенең драматург Кәрим Тинчурин булганын әйтте. Тере язучы белән минем беренче мәртәбә очрашуым әнә шулай булды. Кәрим Тинчурин әсәрләрен укыган кешеләр хәтерлиләрдер: «Кандыр буе» пьесасында кулаклар тарафыннан үтерелгән Ахунҗан эпизоды бар. Этиемнең үтерелү вакыйгасы да, кечкенә Өчиле авылы да — барысы да тормыштагыча, үз исеме белән алынган. Соңыннан, үзем әдәбият белән шөгыльләнә башлагач, мин Кәрим Тинчуринның безнең авылларга ничек килеп эләккәнен аңладым: «Кандыр буе» пьесасына материал җыеп йөргән заманы булган икән.

## Алма апа

Беренче сыйныфтан мин күчми калдым.

Хәер, аны сөйләп тормасам да ярар иде, ләкин минем тормышымда бик тирән эз калдырган бер ягы бар аның. Сөйләми булмый.

. Әни кулында без дүрт бала өелешеп калдык: ике кыз, ике малай. Эти үлгәннән соң, бер ел узар-узмас, иң кечкенәбез, бер яшьлек Марат үлде — төерчек кенә булса да ир заты иде, минем иптәш иде, ул үлгәч миңа — алты яшьлек сабыйга — аеруча күңелсез булып китте: кызлар икәү, апалы-сеңелле, ә мин япа-ялгызым. Юк, болай булмый, болай ярамый. Бездән тугыз чакрымнар ары Югары Пошалым дигән авылда эти белән бертуган тутәй яши иде. Без аны Алма апа дип йөртә идек. Аның кияүгә чыккан олы кызы, унбиш яшьләрендәге үсмер улы бар иде. И дә оста иде соң әнә шул унбиш яшьләрендәге Хәкимулла абый уенчык ясарга! Ул канатларын чәп-чәп сугып йөрүче күбәләк арба дисеңме! Ул тәгәрмәч өстендә әйләнүче күз нярмәс бөтерчекләр дисеңме? Югары Пошалымнар, гомумән, авыллары белән бик оста һөнәрчеләр иде. Этием булмагач, миңа уенчык алып бирүче дә юк, башка малай-

лар кебек, миңа чана, чаңгы, тимер аяк ише нәрсәләр дә эләкми — шулай булгач, нигә мин өйдә әрәм булып ятыйм ди әле? Киттем Хәкимулла абыйларга!

Мине бигрәк тә өзелеп чакырган кеше Алма апа үзе булды.

Соңыннан, бер ел чамасы аларда яшәгәч, мин моны аңлап та алдым. Алма апа колхозга кермәгән, аның ялгыз хуҗалыклы җир кишәрлекләрендә эшлисе бар, ә мин өй саклап утырырга тиеш икәнмен. Алма апаның сандыгында беләзек ише, хәситә ише бизәнү әйберләре күп, әлбәттә, җитмеш яшендәге карчыкка аларның инде берсенең дә кирәге юк, ләкин ул аларны көн саен диярлек актарып, пар атлар белән кияүгә чыккан заманнарын сагынып, мөнәҗәтләр укып утыра торган иде. Әнә шул мөнәҗәтләрнең җанны актарып ала торган моң-сагышы мине әйтеп бетергесез тәэсирләндерә. Кышкы озын кичләрдә, җиделе лампа яктысында Алма апа куркыныч әкиятләр сөйләргә ярата. Әкиятләре янына солдат ире Гыйбадулланың ярман сугышында үлеп калуын китереп куша. Шунлыктан мөнәҗәт һәм әкиятләр, солдатның җан өшеткеч үлем хәбәре белән бергә үрелеп, минем нәни күңелемдә әллә ниткән шомлы-сихерле дөньялар тудырырга җитә кала иде.

Серле, томанлы, моңлы бер дөнья, үзең яшәгәннән бүтәнчәрәк дөнья тудыру ягыннан Алма апаның үзе дә сизмәстән эшләгән эше — минем әдәбиятка якынаюымда юл башы булмадымы икән дип уйлыйм мин. Алма апа мине байтак кына догалар укырга, ашаганда авызны чәпелдәтмәскә, өстәл астында аякны селкеп, «шайтан чакырмаска», ипине бер генә куллап сындырып, фәрештәләрнең канатын каермаска, олылар сөйләгәндә тыңлап утыра белергә өйрәтте. Утыз еллар чамасы узгач, Алма апаны миңа тагын бер мәртәбә күрергә туры килде. Олы кош кебек дәү гәүдәле, керфекләре коелып бетеп, керфек төпләре алсуланып торган йөз яшәр бер карчык иде инде. Әмма тавышындагы, сөйләү рәвешендәге дәһшәт, ягъни куркыныч вакыйгаларны куркыныч итеп сөйли белү — аңарда таң калырлык көчле иде.

Минем балалык тормышымны бизәүче икенче кеше — Хәкимулла абый. Уйлап табу, нәрсәдер оештыру, көн саен нәрсәдәндер кызык эзләү — аерылгысыз сыйфаты иде аның. Әле ул, беркемнең дә башы җитмәгән уенчык ясап, безнең урамны шаккатыра, ул да түгел, ун чакрымнар ераклыктагы Чиканас авылына мәктәпкә барган җиреннән үзеннән олы малайларны кыйнап кайтып, дан ала. Алма апа тарафыннан каргыш алмаган бер генә көне дә юк иде аның. Ләкин минем өчен ул аерылгысыз дус, иптәш, сиенер абый һәм — беркем тота һәм гаепли алмастай шулер, артист, баш бирмәс, боекмас бер могҗиза иясе иде. Уйлап чыгарасы нәрсәләрнең барысы уйланып бетеп, алынасы җәзаларның барысын алгач, каргалгач һәм тиргәлгәч, ул көннәрдән бер көнне сулышлары кабып, ах-ух килеп кайтып керде.

— Әни, беттек, харап булабыз! Алтын-көмешне җыялар. Кемнең дә кемнең ике килодан арта, башын себер җибәрәчәкләр икән ди!

— Китсәнә! Ай аллам, менә син тамаша, нишләек, кайларга яшерик? Утка атар иең, утта янмый, кешегә бирсәң, дус бар, дошман бар, ай аллам, менә син тамаша... — дип, Алма апа үзенең тумыштан килгән хәфевле тавышы белән безнең өскә ябырылган кайгыны тагын да арттырып җибәрде.

Төнге уникеләр тирәсендә мине йокларга салып, фонарь тотып, өйалдына чыгып киттеләр. Йокылы-уяулы килеш, мин ишек ярыгыннан ут шәүләләрен күреп, өзек-төтек сүзләрне ишетеп яттым.

Бер елдан соң өйдә гауга купты. Алтын-көмешне, Алма апага күпме мөнәҗәт көйләткән чулпыларны, йөзек-беләзек ише кыз малларын урлап киткәннәр.

Тагын бик күп еллар узганнан соң мин ул хәзинәне Хәкимулла абыйның юри яшертеп куюын, берәм-берәм алып сата барганын белдем.

Акча аңа Казанга китәргә кирәк булган икән. Башында көн саен мең төрле кызыклы уй, хыял туып тора торган егеткә Алма апа белән ялгыз хуҗалыкчы булып, үз яшьтәшләре — комсомоллардан көлдереп йөрү туйдырган. Казанга барып, ул заводка эшкә урнашты. Гомерендә бик күп мактау кәгазьләре алды, заводка рационализаторлык тәкъдимнәре биреп, үзе төсле үк шаян-шук, эчкерсез хатыны белән гөр килеп яшәде, ике шәп егет үстерде. Ә авылдагы гөнаһсын — «чулпы-беләзек» саткан акчаны ул, мөгаен, әнисенә бише белән кайтарып биргәндер инде. Алма апа соңгы сулышына тикле авылдан купмады...

Минем беренче класстан күчми калуым әнә шул Хәкимулла абый белән бәйле. Алты яшемдә ул мине, тирги-тирги, укырга өйрәтте. Мин әз генә төртелеп тордыммы — шундук кызарып-бүртенеп кычкыра башлый торган иде. Педагогик такт дигән нәрсә бер дә булмаган, күрәсең, үзендә.

Ул кычкыра. «Баланың йөрәген аласың бит, юньсез! Сабакны шулай укыталармыни?!» — дип, Алма апа аны тирги. Көннәрдән бер көнне Хәкимулла абый миңа бик каты янап әйтте:

— Бел аны, малай актыгы, әгәр сыйныфыңнан күчми калсаң, урамга алып чыгам да, бүрәнә башына бастырып: «Бу малай күчмәде!» — дип бөтен урамга кычкырам, — диде.

Бик куркытып әйтелгән сүз булса да, мин ул елны сыйныфымнан күчми калдым.



## Беренче укытучым

Күчми калу белән мин бер нәрсә дә оттырмадым. Ул елларны укырга сигез яшьтән алалар иде. Ә күчми калганда, миңа җиде яшь тә тулмаган иде әле. Күчмичә генә букча күтәреп йөргән әнә шул бер ел минем өчен хәзерлек курслары кебек бер нәрсә булып чыкты. 1933 елны мин, Югары Пошалымнан үз авылыбызга кайтып, күршедәге Көтек авылына укырга кердем. Кергәндә үк укый-яза белү, ун эчендә исәп-хисап йөртү ул чакта малайларга тәтегән нәрсәмени?! Китте минем эшләр худка! Җиденчене тәмамлаганчы, мин яхшы укучылар исемлегеннән төшмәдем.

Мин мәктәпкә кергән елларны авыл хәлләре бик кискен үзгәреп китте. Кара-каршы ике йорты, ике аты булган кешеләрне авылдан сөргәч, унөч йортлы кечкенә Өчиле тугыз гына йортлы булып калды. Бездән ярты гына чакрым ары Каенлык дигән авыл бар иде, кулаклардан тазарткач, ул бөтенләй дә алты гына йортлы булып чыкты. Икесен бергә кушканның соңында да алар аерым колхоз булып яшәрлек түгелләр иде, шуңа күрә Өчилене, Каенлыкны күршедәге алтмыш йортлы Көтек белән кушып, бер колхоз ясадылар да «Кызыл Көтек» дип исем бирделәр.

Без, Өчиле, Каенлык балалары, «Кызыл Көтек»кә беренче сыйныфтан башлап мәктәпкә йөрдек. Турыдан исәпләсәң, «Кызыл Көтек»кә барып кайту өч чакрым булыр иде, ләкин без турыдан йөрми торган идек. Үзебез ясаган имән чаңгыларда иртән кырга чыгып чабабыз. Кар өсте каты, дулкын-дулкын, чаңгылар таеп-таеп китә, без аңа-моңа карамый, бара бирәбез, кем беренче булып кар дулкыннары арасыннан куян куркытып чыгара — ул иң бәхетле кеше. Ә без үскәндә куян бик күп иде, кыр тулы иде куян. Шуңа микән:

— Куян, син кайда?

— Кара урманда,

— дигән шигырь юллары безнең иң яратып кабатлаган шигыребез иде. Көтек белән Өчиле арасындагы очсыз-кырыйсыз кар даласы, кояш ну-

рыннан балкып, күзләрне камаштырып ята. Чыңлап торган музыкасы, колакларны чеметтереп искән җилләре, яктылыгы, пакьлеге белән гомерлеккә безнең хәтергә сеңеп калды ул. Колак төбендә әле дә булса яңгырап торган икенче музыка — мәктәп үзе. Өчиле белән Каенлык малайлары, ягъни без ташбашлар, көн саен диярлек ун-унбиш минутка соңга калып киләбез. Коридор тын, сыйныф бүлмәсеннән кайсыдыр бер малайның: «а-ыр-бы-а арба» дип көйләп-көйләп укыган тавышы ишетелә, без, соңга калганнар, ишек төбенә өелеп, аны тыңлыйбыз. Кар даласының моңы минем күңелемдә әнә шул көйләп укыган китаплар белән дә, башлангыч мәктәпнең сыйныф бүлмәләре һәм коридорлары белән дә аваздаш булып яши. Карлы яланнарны яки самолетта очканда ак болыт өемнәрен күрү белән, үзәкләрне өзеп, мәктәп еллары искә төшә...

Беренче укытучым минем Зәки абый булды. Заманында ул мулла булган, совет чорында муллалыгын ташлап, балалар укытырга керешкән. Зур борынлы, шуңа күрә авылда Тукран кушаматы алган бу кеше безне, башлангыч сыйныф балаларын, җәй буе мәктәп янындагы яшелчә бакчасында кыяр, кишер, чөгендер, бәрәңге үстертә, куян карата, ә кышын безгә итле, яшелчәле кайнар аш ашата иде. Эш яратырга, тырыш булырга, гаделлеккә беренче мәртәбә ул өйрәтте. Юморга да бай булган булса кирәк, мин уен уйнаганда яки китаптан дәресне укып биргәндә, катырак кычкырып җибәрсәм:

— Гарифҗан, ул хәтле кычкырма, тәрәзәне ватасың бит! — ди торган иде.

Зәки абый мине, икенче сыйныфтан башлап, плакат язарга, стена газетасы чыгарырга, рәсем ясарга өйрәтте. Дәрестән соң икәү калып, без аның белән сәгатьләр буе рәсем ясыйбыз, май бәйрәменә мәктәпне бизәр өчен плакат язабыз, аннары икәү кара-каршы утырып, аш җылытып ашыйбыз. Ятим бала боегып йөрмәсен, кеше булсын дигәндерме, ул минем укуымны гел кайгыртып тора торган иде. Көтек мәктәбендә дүрт сыйныф. Ике сыйныфны Зәки абый укыта, ике сыйныфны җиденчене бетергән яшь кенә бер үсмер укыта торган иде. Үсмер егетебез үсеп житеп, аны Кызыл Армия сафына алгач, Зәки абыйның берүзенә дүрт сыйныф өелеп калды, шунлыктан безгә — өченче, дүртенче сыйныфтагыларга — Өчиледән өч чакрым ераклыктагы Казанбаш урта мәктәбенә йөреп укырга туры килде. Без өченче чиректә Казанбашка төшкән идек, мин ул чирекне бик әллә ни элдертеп китә алмадым (укытучысы ияләнмәгән кеше бит!). Дүртенче чиректә шул хәтле дә тырыштым, Зәки абыйның йөзенә кызыллык китерәсем килмәде, тырыша торгач, тәки үземнекен иттем, дүртенче сыйныфны тоташ отличного тәмамладым. Хәтеремдә әле, Казанбашта сабан туе иде, мин елны әйбәт тәмамлаган өчен мәктәптән бүләк итеп бирелгән кара сатин күлмәгемне, бүләк итеп бирелгән өр-яңа кепкамны киеп, яланаяк сабан туена төштем. Тактадан кормаштырып куйган кибет янында кәнфит алучыларга кызыгып карап тора идем, Зәки абый килеп чыкты.

Мине, үз иптәше кебек итеп, җилкәмнән бер кулы белән кочаклап, мәйдан кырыеннан әйләндереп алып килде, хәлләремне сорашты, минем кулларны учына алып:

— Молодец, энем, йөзгә кызыллык китермәдең! Әтиең исән булса, нишләргә белми сөенер иде, — дип, мине такта кибет янына янә дә алып килде һәм кепкамны тутырып кәнфит-пәрәннек алып бирде. Үз гомеремдә бик күп бүләкләр алганым бар, Зәки абыйдан алган бүләк кебек кадерле бүләкне күргәнем юк.

Аннары озак та тормый без аерылдык. Сугыш алды елларында ул каядыр китеп югалды, аның кая киткәнен белүче булмады. Авылның иң усал, иң гайрәтле бер егете ниндидер мәҗлестә: «Мин башына җиттем аның», — дип мактанып сөйләгәнен генә әйттеләр.

Бу хәлләргә инде кырык еллар вакыт узган, хәтер күгеннән бик күп фаҗигаләр, кайгы-шатлыклар, тагын әллә ниләр узган. Ә менә Зәки абый: «Кычкырма, Гарифҗан, тәрәзәне ватасың бит!» дигән сүзе белән, балаларга яшелчә үстертә, куян карата белүе белән, кыш буена үзебез үстергән яшелчәдән кайнар аш ашата белүе белән, ниһаять, үзе укыткан балаларның уңышына башы күккә тияр дәрәҗәдә сөенә белүе белән бик еракта калган беренче укытучым, изге күңелле бер кеше булып, онытылмый күңелдә саклана. Чыңгыз Айтматовның «Беренче мөгаллим» хикәясен укыганда, мин гел Зәки абыйны искә төшерәм.



## Икенче укытучым

Икенче укытучым — Һидият Зиятдинов — Арча районының Күлтәс авылы егете. Без дүртенчегә житкәнче укытучыларыбызга абый дип дәшә идек, дүртенче сыйныфта исеме, әтисенең исеме белән дәшәргә куша башладылар. Шулай итеп, Һидият абый Һиди Зиятович булып китте. Ләкин ул аңа карап минем өчен абый булудан туктамады. Һиди Зиятович белән дә без дәрестән соң стена газетасы чыгара идек, плакатлар яза торган идек. Ләкин инде хәзер безнең бергәләп эшләгән эшләребез аның белән генә бетми иде. Һиди Зиятович мәктәптә кулъязма әдәби журнал чыгара башлады. Инша язарга, рәсем ясарга сәләтле булган укучыларны үз янына җыеп алды. Беренче журналның тышлыгына без каен рәсеме белән сыерчык оясы ясадык. Төрнәле авылының Исмәгыйлов белән мин, бер-беребездән уздырып, шигырь яза башладык. Бу хәл дүртенче сыйныфта укыганда булды. Көн саен бер дәфтәр шигырь язып киләбез, аны утыз минутлык озын тәнәфестә, балалар әйләнә-бәйләнә уйнаган чакта, уртага басып укыйбыз. Шигырь язгы гөрләвекләр турында, чаңгы шуу турында, шомырт урлау турында була, безнең шигырьләрдә кәккүк кычкыра, сандугач сайрый, куяннар чабыша, болыннарда сыер-сарыклар йөри... Тыңлаучыларга рәхәт, алар көлә-көлә кул чаба, безнең башлар җиденче кат күк артында.

Дүртенче сыйныфны тәмамлаганда бугай, безгә Казаннан язучы килде: Әхмәт Гыймадов. Кап-кара татар. Һиди Зиятович шигырь язучы бала-чаганы аның янына җыеп алды. Хәзер нинди киңәшләр биргәнен аермачык кына хәтерләмим, әмма шигырь һәм хикәя яза торган, аларны бастырып та чыгара торган тере язучы белән очрашу бик зур тойгы калдырган иде. Шуңа күрә хәзер дә мин, язучылар, мәктәпләргә барганда аеруча житди әзерләнеп, җаваплылыкны нык тоеп барырга тиешләр дип уйлыйм. Шушы очрашудан соң язгы гөрләвекләр турындагы бер шигыремне «Яшь ленинчы» газетасына җибәрдем. Әминә апа Бикчәнтәевадан: «Гарифҗан энем, каләмең өметле күренә, бер куплетың шигырь була язган, шундый куплетларың күбрәк булса, басып та чыгарырга булыр», дигән хат алгач, сөенечемнән, тере тиен тоткандай, бөтен мәктәпкә кычкырып йөргән идем.

Һиди Зиятович минем шигырь чыгаруымны хуплый, шул эштән туктамасын дип мине дәфтәр белән тәэмин итеп тора иде. Ул чорда дәфтәр бик санаулы, бала саен билгеләнеп кенә бирелә, шуның өстенә минем кебек ятим малайның дәфтәр-китап алырга акчасы да булмый бит әле аның. Җиденче сыйныфка житкәнче мин Һиди Зиятович дәфтәрләренә язып, ул бүләк иткән китаплардан укып бардым. Барысы өчен дә рәхмәтем итеп мин аның өлгереш ведомостьларын күчереп бирә торган идем. Хәтта бер елны тарих укытасы конспектларын да күчереп биргәнем хәтеремдә. Анысы җәйге каникул вакытында булды.

Һидият абыйны мин дөньяга педагог булып туган кеше дип исәплим. Мин бу фикергә кырык елдан соң килдем. Җиденче сыйныфта укып

йөргән чакларымда мин ул хакта уйлый алмый идем әле. Ул минем укытучым, Өчиледә, Каенлыкта, Казанбашта иң олы кеше иде. Мин аны ярата идем. Ул пөхтә киенеп йөри, ул без исәнләшкән чакта, ник исәнләшкәнеңә үкенмәслек итеп, бөтен йөзе белән балкып елмая, ул менә дигән спортсмен; турникта атына, бик җитез йөри, укытучылардан аның бер үзендә велосипед, шул велосипедына атландырып ул мине Казанбаштан Өчилегә алып менә, үзе белән Казанка елгасы буена балыкка алып төшә. Мондый икәүдән-икәү генә калулар атнасына ике яки өч тапкыр була, чөнки Һиди Зиятович Каенлык авылында олыларны укыта, аларга газета хәбәрләрен укый, ил турында сөйли, хәзерге термин белән әйткәндә, ул агитатор, пропагандист иде бугай. Юл уңаенда ул мине велосипедына атландырып алып менә, мин аның үз җилкәм аша руль тоткан көчле кулым тоям.

— Иә, Гарифҗан, хәзер куян килеп чыкса, без нишлибез? — ди ул.

— Велосипедтан егылып төшәбез! — дим мин.

Ул рәхәтләнеп көлә.

— Дөрес бит, әй... — ди ул, минем белән килешеп. Без, велосипедтан төшеп, чирәмле тау өстенә чүмәшәбез. Һиди Зиятович Тәрнәле буе ягыннан узган баганалы олы юлга, офык буендагы ак мамык болытларга карап утыра. Әллә сагышы бар инде аның? Күзләре моңсу, коңгырт чәчләре колак янына сибелгән, ул көтмәгәндә мине чандыр җилкәмнән коча.

— Әйт әле, Гарифҗан, сиңа Рәшидә апаң ошыймы?

— Ә нигә?

— Башта син минем сорауга җавап бир.

Мин сүз белән җавап бирмим, озак кына тастымал букчамны актарам, китапларым эченнән унлап рәсем алам. Алар безнең авыл күренешләре: урам, өйләр, болын буендагы әрәмәләр, өй арты бакчабыздагы шомыртларның чәчәк аткан чагы. Мин шигырь язу белән бергә рәсем ясарга ярата идем. Ат, сарык, каз рәсеме, табигать күренешләре. Үзебезнең авылны мин гомеремдә йөз мәртәбә рәсемгә төшергәнмендер. Мин хәтта апам Гайшә белән сеңлем Саҗидәнең бер генә мәртәбә дә рәсем ясарга омтылып карамауларына сәерсенеп йөри идем. Мин Өчиле күренешләрен Һиди Зиятович алдына тезеп куям.

— Сезгә боларның кайсысы бик тә ошый, Һидият абый? — дим.

Ул минем рәсемнәрне озаклап карый, арадан берсен, Өчиленең кояш чыккан чактагы күренешен аеруча ошата.

— Алыгыз, сезгә бүләк булсын, — дим.

Мин моны берәр төрле мәгънә салып эшлимме, юкмы икәнне белү өчен булса кирәк, ул минем күзләремә карый, кинәт дулкынланып:

— Рәхмәт, Гарифҗан, син минем чын дустым, — ди.

Каты итеп кулымны кыса.

Алар мин җиденчедә укыган чакта Рәшидә апа белән өйләнештеләр. Ул мине ниндидер йомыш белән өйләренә чакырды. Мин стена сәгате янында Өчиле авылының кояш чыккан чактагы рәсемен күрдем.

Озак та үтми, аны Кызыл Армия сафына алдылар.

Ул миңа, үзенең укучысына һәм дустына, ике хат язарга өлгерде. Беренчесендә миңа Казан художество училищесына укырга керергә киңәш иткән иде. Ләкин мин Казанны белмим, художество училищесына керү тәртипләрен дә белмим, аннары минем кебек этисез малайны анда кем асрасын, кем аның тамагын туйдырсын! Мин, җиденчене Мактау кәгазе белән тәмамлаган үсмер малай, Арча педучилищесына барып кердем. Анда керүемнең бер сәбәбе — Арчаның безгә уникe генә чакрымда булуы булса, икенче сәбәбе — Һиди Зиятовичның үзенең дә Арча педучилищесын тәмамлаган укытучы икәнен белә идем.

Укытучымның икенче хаты мин Арча педучилищесына кергәч килде.

Бу вакытта аның улымы, кызымы туган, һәм ул миңа, элекке укучысына һәм дустына: «Шул бәләкәчемне кайтып күрер көннәр насыйп булыр микән?» — дип язган иде.

Аңа сабыен кайтып күрергә насыйп булмады. Тиздән Бөек Ватан сугышы башланды. Август аенда Арча районының Күлтәс авылы егете Һидият Зиятдинов хәрби корабта һәлак булды. Шул ук көнне аның энесе самолетта һәлак булганын әйтеп кара язулы конверт килгән.

Җир йөзендә, минем язмышка дучар булып, тагын бер ятим бала һәм ике улын берьюлы югалткан хәсрәтле ана торып калды...

## Ике капчык бәрәңге һәм ак чалбар

Көтек һәм Казанбаш мәктәпләрендә Зәки абый белән Һидият абый үз канатлары астына сыендырып, минем язмышымны күздән ычкындырмый саклап килгән булсалар, Хәнифә апа Абдуллина мине әдәбият юлына турыдан-туры этәрүче булды. Ул бишенче-алтынчы сыйныфта татар әдәбияты укыта иде. Кагыйдә ятлаткан байтак укытучыларны беләм мин, әмма Хәнифә апаны кагыйдә ятлатучылар рәтенә түгел, матур әдәбиятны яратырга өйрәтүчеләр рәтенә кертәм. Хәнифә апа Сибгат Хәкимнәр, Гали Халитлар белән бергә Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаган, аннары Казанбаш мәктәбенә укыту эшенә килгән. Ул безгә олы булып күренә, ләкин ул бик яшь булган, биология укытучысы Абдуллин белән тормышларын башлап кына җибәргән икән. Алар икесе дә балаларны ятаталар, дәресләренә бөтен күңелләрен салалар. Абдуллин абыйның күгәрченгә операция ясап, аның эчке әгъзаларын безгә бик җентекләп күрсәткәне хәтеремдә. Операция вакытында ул никтер гел иренен кыймылдатып торды, миңа ул күгәрченгә ясин чыгадыр кебек тоелды. Югары Пошалымның Алма апа биргән дин тәрбиясен мин җиденче сыйныфка кадәр саклап килдем. Хәнифә апа— чем кара чәчле, алсу йөзле, күперенкерәк иренле, гаять тыныч табигатьле һәм матур тавышлы кеше — бишенче сыйныф балаларына озын тәнәфестә дә, кайвакыт дәресләр беткәннән соң да русча китаплар кычкырып укый, шундук татарчага тәрҗемә итеп тә бара иде. Алтынчы-җиденче сыйныфларда укыган елларны без, сыйныфыбыз белән җыелып, утызлап китап укып чыкканбыздыр. Жюль Верины, Пушкин хикәяләрен, «Доктор Айболит»ны без русчадан башладык, аннары аларның татарча тәрҗемәләре басылды. Хәнифә апаларның шактый зур китапханәләре бар иде, мин мәктәп китапханәсендәге китапларны укып бетергәч, әдәбият укытучымнан атна саен бер китап сорап алып укый торган булдым.

Алтынчы сыйныфта укып йөргәндә мин ак белән караны аера башлаган идем инде. Әтисез үскән балаларга хас сыйфаттыр дип беләм, ел әйләнәсе өскә җүнле-рәтле кием, тау шуарга матур чана эләкмәгәнгә, мин, тора торгач, бер йөрәксенеп, дөньяда булмаган бер нәрсә уйлап чыгарырга, шуның белән башкаларны узып китәргә ярсына башлый торган идем. Казанбаш кибетенә ак чалбар кайткан. Ак чалбарны бездә авыл кешеләре кими, сабан туй вакытында бик пөхтә киенүләре белән дан алган бер-ике укытучы кия дә, шаукымлы булганга Чәпүр дип ат алган балта остасы гына кия иде. Кинәт минем дә ак чалбар киясем килде. Моның өчен миңа унбиш сум акча табарга кирәк. Җәй буе урманнан кура җиләге җыеп, Арча базарына илтеп сатсам да, биш-алты сумнан арттыра алмадым. Көзен колхоз кырыннан бәрәңге алып бетергәч, балалык дустым Мансур белән икәүләп, атна буе кырдан бәрәңге җыйдык. Миңа ун сум акча табу өчен ике капчык бәрәңге җыярга кирәк иде. Шул бәрәңгене җыю өчен без Мансур белән икәү-

ләп, кимендә ике гектар җир актарып чыкканбыздыр. Хәзер инде шуны сатып җибәрергә кирәк. Мин аны, әлбәттә, Арча базарына алып бара алмыйм. Ике капчык бәрәңгене уникe чакрымга кечкенә арба белән тартып барулары — ай-һай! Ат бирмиләр, ат колхозның үзенә кирәк, чөнки бу вакытта егермешәр-утызар олау Арча стансасына бәрәңге ташый. Шулай булгач, бер генә юл кала: Казанбашка кул арбасы белән тартып алып төшеп, укытучыларга сату. Тәвәккәлләдем.

Тимерче Ычтапаннарда укытучы апалар тора. Ычтапан абыйлар, бердән, авыл башында, икенчедән, укытучы апаларның бәрәңге бакчалары юк. Минем белән аларның өлкәне, география укыта торганы сөйләште. Бәрәңге эре. Мин кырдан җыйганны үзебезнең бакча бәрәңгесенә алыштырып алган идем. (Сыерга ашатырга ярар дип әни риза булды!) Бәрәңгене ошатты укытучы. Бәясенә мин артык та, ким дә түгел, төп-төгәл ун тәңкә сорадым. География укытучысы кара бөдрә чәчләрен җилкәсеннән артка чөеп җибәрде, якты күзләрен балкытып миңа карады:

— Ике капчыкка сигез сум булыр, үскәнем.

— Юк, апа, миңа ун сум кирәк.

— Ни өчен?

— Кибеттә ак чалбар саталар. Унбиш тәңкә. Минем биш тәңкә бар. Тагын ун тәңкә кирәк.

— Ак чалбар белән нишлисең син, Ахунов? Син бит аны бер көн эчендә каралтып, чирәмгә буяп бетерерсең.

«Бетерәмме, бетермимме, анысы минем эш»,— дип гарьләнеп уйладым, ләкин гарьлегемне сүз белән әйтмәдем, сүз белән дә әйткән булыр идем, җылак тавыш белән әйтермен дип курыктым, шунлыктан тукран кебек бер генә нәрсәне тукылдаттым:

— Миңа ун тәңкә акча кирәк.

— Ярар, бушат, Ахунов, — диде география укытучысы.

Өч потлы бәрәңге капчыгын күтәрер өчен мин гадәттән тыш чандыр идем, капчыкларны черәшә-черәшә өйгә сөйрәп алып кердем, авызларын чишеп, өй асты чокырына аудардым: бәрәңгеләр бер-берсенә бәреләбәрелә, дыбыр-дыбыр сөйләшеп төшеп киттеләр. Кулга ун тәңкә акча керер минутны мин өзелеп көтеп алдым.

— Менә сиңа, Ахунов, ике капчыкка тугыз сум акча, менә тагын егерме тиен, сукыр карта сатып алырсың, — диде география укытучысы.

Күрәсең, минем чыраем көл кебек агаргандыр, укытучы куркынып:

— Ни булды сиңа, Ахунов? — дип сорарга мәҗбүр булды.

Мин, җылап җибәрмәс өчен иренемне тешләп:

— Миңа ун тәңкә кирәк, — дидем.

— Тугыз тәңкә дә бик зур акча бит.

— Миңа ун тәңкә кирәк.

— Тугыз сумга бирмисеңме?

— Миңа ун тәңкә кирәк.

— О, кире беткән малай! — диде география укытучысы, авыз эченнән ботка пешерә-пешерә, өй астына төшеп китте. Ул анда өзлексез сукранып, миңа уникe чиләк бәрәңгене киредән тутырып бирде, һәм мин, ике капчык бәрәңгемне кул арбасына салып, Хәнифә апаларга юнәлдем.

Хәнифә апа мине бик яктырып каршы алды, чәй эчертте, соңгы көннәрдә нинди китаплар укыганымны сорашты, сорашуы шуңа: мин алардан китап алмый башлаган идем.

Китап укырга вакыт юк, сентябрь — тоташы белән — бакча бәрәңгесе казып узды. Бәрәңгене ишегалды чирәмендә киптереп, эресен базга, ваграгын малга ашатырга сайлап куйдык. Ә бу ике капчык бәрән-

гене кырдан җыйганымны һәм миңа ун тәңкә акча кирәклеген сөйләп бирдем.

Хәнифә апа миңа, сатулашмый-нитми, ун тәңкә акча тоттырды, шуңа өстәп тагын бер бишлекне сузды.

— Ә монысы нигә? — дидем мин.

— Монысына ботинка алырсың.

Каршы сүз әйтмәдем. Язын-көзен яланаяк пычрак ерып, аяклар чебиләнеп бетә иде. Ботинкалы булу уен эшмени! Укытучы апам үзе бeләдер.

Мин Хәнифә апага Казанбаштан Өчилегә менеп җиткәнче рәхмәт укып мендем, шул биш тәңкә өчен тагын ике капчык бәрәңге җыеп бирергә күңелемне беркеттем. Әмма көндәлек мәшәкатьләр миңа вәгъдәмне үтәргә ирек бирмәде. Ул бурыч шушы көнгә тикле минем өстемдә асылынып тора.

Казанбаш мәктәбендә җиденче сыйныфны бетергәнче бик яхшы билгеләренә генә укып барган булсам да, ул елны минем эшләр географиядән кәегәеп китте. Башта мин «яхшы» билгесенә төштем, аннары «уртача»га тәгәрәдем. Мине директор бүлмәсенә чакырып, озак кына сораштылар, мин чын дөресен әйтергә теләмәдем, бүлмәдәгеләр моның төп сәбәбен белми калдылар. Озакламый география укытучысын эшеннән бушаттылар. Шуннан соң гына мин «отлично» билгеләре ала башладым.

Ләкин миңа ак чалбар насыйп булмаган икән, мин аяк киенгәләгәнче ул беткән, ботинканың миңа яраклысы юк иде. Акчаны кыш буе берәүгә бер бирмичә саклап чыксам да, ак чалбар белән ботинка язын да булмады. Арча базарына барган җирдән ике кило чамасы майлы буяу алып кайттым. (Төрле төсен сайлап алдым.) Ул минем гомерлек хыялым иде. Иске фанер кисәкләрен, ташландык мич капкачы калаен зур бер агач рамга кадакладым да җирлеген күк йөзе төсле ачык зәңгәргә буяп, аңа җилфердәп торган кызыл байрак ясадым, «Яшәсен Май бәйрәме!» дип, җете ак буяу белән плакат яздым. Плакатның биеклеге метр ярымнар булгандыр. Мин аны үзебезнең капка түбәсенә менгереп кадакладым.

Минем плакатны Өчиледән, Каенлыктан килеп карамаган бер генә кеше дә калмагандыр. Башны кыек салып, тел шартлатып тордылар, мактадылар. Әнинең генә минем иҗатка исе китмәде:

— Йөри шунда акча бетереп, — диде.

## Беренче мавыгулар

Әдәби очрашулар вакытында укучылар безгә: «Язасы килү нәрсәдән башлана?» — дип еш кына сорау бирәләр.

Бу сорауга бер генә язучы да аермачык итеп, төп-төгәл җавап бирә алмастыр, мөгаен.

Кайберәүләрне зур кайгы тетрәткән. Икенче берләрен бәхетсез мәхәббәт сагыш утына салган. Өченче берсе әле малай чакта ук Кырымда, пионерларның бөтен илгә атаклы «Артек» лагерында, ял итеп кайткан, ул анда, әйтик, балалар язучысы Аркадий Гайдарны күргән, аны тыңлаган, аның белән рәсемгә төшкән. Күңеленнән язгы ташкындай шаулап узган хис-тойгыларын әлеге малай үзендә генә саклап калырга теләми, башкаларга да әйтәсе килеп тора.

Һәрхәлдә, бер нәрсә ачык: язасы килү теләге күңелендәге серләренне кемгәдер әйтеп бирәсе, кайгы-шатлыкларыңны кем беләндер уртаклашасы килүдән башлана. Башкалар бу мәсьәләгә ничек карыйдыр, минем үземдә гел шулай булды. Минем кешеләргә әйтәсе килгән сү-

зем — әтисез үсүем. Ятимлекнең, адәм баласы бәхетле булырга зур хокуклар яулап алган безнең илдә, хәтта социализм илендә дә, үз кыенлыклары бар. Мин сул як күршебез Шәйхетдин абыйларга барып керәм. Аларның малае Шамил урамда бер кечкенә малайны кыйнап кайткан, Шәйхи абзый чабата үреп утырган җиреннән сикереп торды да, чабата юкәсе белән Шамилнең сыртына берне салды. Шамил яшен ташы кебек атылып урамга чыгып китте, чабата юкәсе төшкәннән соң кара янган аркасын миңа күрсәтеп мактанды. Әнә нинди эз төшкән! Ә ул шулай да җыламады. Әти суккан урын тәмугта янмаячак. Ә мин нәрсә белән мактанырга тиеш? Минем бит әти юк.

Уң як күршебез Салих абзый улы Мансурга чаңгы ясап биргән — Мансур шуны киеп чыга да мактана, киеп чыга да мактана. Мактанмый буламы соң — әтисе ясап биргән бит аны! Имәннән. Имән чаңгы, имеш, дөньяда иң шәп чаңгы, аучылар да урманга куян атарга барганда, гел имән чаңгы киеп кенә баралар...

Әнә нинди хикмәтләре бар әтиле булуның!

Казанбаш мәктәбенең дүртенче сыйныфында укыганда, Төрнәленең Исмәгыйлев белән узыштан шигырь яза башлавыбызны әйткән идем. Ул елны безгә шигырь җене кагылган иде. Озын-озын поэмаларны, хәтта чәчмә белән язылган әкиятләрне без яттан беләбез. Тукайның «Шүрәле»сен, «Су анасы»н, «Такташның «Нәни разбойник», «Мокамай» поэмаларын, Пушкинның «Алтын балык һәм балыкчы турында әкият»ен, тагын әллә күпме шигырь-поэманы, тыңлаучыларны таң калдырып, без сәхнәдән сөйлибез. Хәтта клубка баруга бик әллә ни исләре китмәгән ата-аналар, балалары сөйләгәнне тыңлар өчен, клубка килергә атлыгып торалар иде.

Бездә хәзер «шигырь уку» дигән сүз бар. Без бәләкәй чакларда берәү дә сәхнәдән шигырь сөйләүне шигырь уку дип әйтми, китаптан карап укыганны гына уку диләр иде. Шигырьне яттан сөйләү декламация дип атала иде безнең дәвердә, әнә шул декламация сөйләүдән дә кадерлерәк, аңардан да бәхетлерәк минутлар юк иде безнең өчен.

Шигырь сөйләүгә, күрәсең, шундый да остарып киткәнбез, бер елны хәтта безне Арча хәтле Арчага алып барып сөйләттеләр. Район ярышында алдынгы урынны алганыбыз өчен Исмәгыйлевкә Такташ китабы, миңа акварель буяулар бүләк иткәннәр иде. Шуннан соң безнең шигырь ятлау, гомумән, әдәбият белән җенләнү бермә-бер артты.

Дүртенче сыйныфта чакта мин «Агыйдел» повестен укып чыктым һәм чын-чынлап Артыкбикәгә гашыйк булдым. Аның сөйгән егете Гаязны кулакларның балта белән сугып үтерүләре мине миңгерәүләтеп калдырды. Китапны укып бетерүгә, мин кычкырып җылап җибәрдем. Төн уртасы иде, әни сискәнеп уянды да, берни аңламый, күзләрен уа-уа, тирә-ягына каранырга тотынды. Минем җылап утырганымны күреп, бик курыкты, ни булганны кат-кат сорашты, мин әйтмәдем, ул аптырашта калды, күзләрендә хәреф, икеләнү, гаҗизлек билгеләре күренде.

Аннары ул минем янда яткан китапны күреп алды.

— Әле һаман китап белән җенләнәсеңмени син, җүнсез малай? Сүндер хәзер үк утны! Керәчин мае бетереп утырма, — диде.

Ләкин мин «керәчин мае бетереп» утыруны дәвам иттем. Бишенче сыйныфта укыганда, әтиемнең үлеменә багышлап, хикәя язарга тотындым. Ул ансат эш булып чыкмады. Әтинең, күкрәгендәге пычак ярасын кулы белән каплап, кан эчендә яткан чаклары күз алдыма килә, җаннар айкала минем, шуны сүз белән кәгазьгә төшерә башлыйм. Сүзләр әллә ниткән коры, төссез, ятышсыз чыгалар, мин әйтәсе килгәннең чиреген дә, мыскалын да әйтеп бирә алмыйлар.

Әти, кояш чыккан чакта, безнең кара айгырны тарантаска җигә башлаган иде — миңа шуны тасвирларга кирәк. Кояш Көтек авылы ту-

рысына житкәч, кара айгырны ак күбеккә батырып, ике милиционер безнең капка төбенә туктады — миңа кояшның төшлеккә житкәнен, баш түбәсендә аяусыз кыздырып торуын бирергә кирәк. Һич кенә дә биреп булмый шуны. Аптырагач, Галимҗан Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендәге табигать күренешләрен укып карыйм — искиткеч. Сүзләре бер-бер артлы тезелеп кенә тора. Ул язганнан мин әллә ниләр күз алдыма китерәм, мин язганнан берни дә күз алдына килми.

Бер көн, бер төн азаплангач, язуны ташлыйм. Атна буе берни дә язмыйм, тегермәнче Константин абзый булышлыгы белән үзем ясаган имән чаңгыда тау шуам, кырлардан куян куам, ә язу...

Әйе, күпмедер вакыттан соң мин, янә дә язасым килеп, төнлә, энидәр йоклагач, сукыр лампа яктысында, сәке йөзлегенә чүмәшәм. «Горурлы һәм шатлыклы таң атты», — дип беренче җөмләне язып куям. Шулар янына җәен булган хәлләрне — су коенуларны, урамда чабып йөрүләрне, күршебез Салих абзый малае Мансур белән бал корты тотып, шырпы тартмасына ябып куюларны, шул шырпы тартмасына тишек тишеп, бал кортыннан бал җыйдырырга теләгәнебезне язам — болары әзме-күпме үземне канәгатьләндерерлек була, ә менә үлем.... этинең кан эчендә ятулары... Юк, алары чыкмый. Безнең чабып йөрүләргә бәйләнми.

Башкача булдыра алмагач, мин булачак хикәямнең баш өлешен Һидият абый Зиятдиновка күрсәтеп карыйм. «Горурлы һәм шатлыклы таң атты», — дип укый ул. Көлемсерәп куя.

— Әйт әле, Гариф, син моны төнлә яздыңмы?

— Төнлә! — дим мин, аның серемне белүенә куанып.

— Алай икән. Алай. Әниең йоклый идеме?

— Ийе шул. Ә сез каян белдегез?

— «Горурлы» дигән сүз әнә шул гыр-гыр йоклаудан килгән инде,— ди Һидият абый һәм, ирен чите белән елмаеп, миңа карап тора.

Һидият абый минем иң яраткан укытучым булса да, алдарак әйткәнемчә, аның миңа эшләгән изгелекләре өчен җанымда рәхмәт хисләре саклап йөрсәм дә, бу юлы үпкәләдем. Үпкәмне сүз белән әйтмәдем. Язуларны җыеп алдым да, дәшми-тынмый кайтып киттем. Ай буе, ярты ел буе берни дә язмадым. Җәй көне бигрәк тә язып булмый — кырлар, урманнар, елга сулары сине чакырып тора. Алар «шигырь чыгарудан» да, хикәя язам дип черәшеп утырудан да мавыктыргычрак бит.

Минем дус Мансур — дөньяда иң булдыклы, иң хыялый малай — Казанка елгасында су коенуын санап барырга керешкән. Көненә ул ун мәртәбә коена ала. Май уртасында коена башлаган иде, июнь уртасында инде аның су коенуы өч йөздән артып киткән. Өчиле малайлары моны ишетүгә елгага ташланды. Бер-ике мәртәбә чумып чыгалар да күлмәкләрен киеп алалар — әнә шул бер коенуга исәпләнә. Китте узышу, китте ярыш!

Су коенуны санау белән без шул хәтле дә мавыгып киттек, бер көнне Гайшә апа, сеңлем Саҗидә энинең кырдан кайтышына бәрәңге пешереп куясы барын да онытып җибәргәнбез.

Эни, — тол хатын телчән була, — су буена кычкырып-дулап төште дә өчебезне тиң кычыткан белән чапты. Йомшак җирләр әчетүдән без җыладык, гарьлектән эни җылады.

Кычыткан бүрттергән урыннар төзәлүгә без энигә булган үпкәбезне оныттык, әмма энинең гарьләнеп җылаганын оныта алмадык. Бигрәк тә аның: «Этиегез булса болай кыланмасыегыз»,— дип такмаклап җылавы үзәкне өзде. Без энине бәхилләтергә уйладык.

Каен җиләге пешүгә, энидән рөхсәт алып, Гайшә апа, Саҗидә һәм

мин урманга киттек. Башлап йөрүчеләр, әлеге дә баягы Салих абзый малайлары Шәкүр, Мансур, Гариф булдылар.
Урман бездән ике-өч чакрымнар ары иде. Килдек урманга. Төрнәле. Казанбаш басулары аркылы, ызаннан килдек. Кыр уртасындагы, ызаннардагы ялгыз агачлар янына туктап-туктап, шаярышып-уйнашып килдек. Кыр уртасында ялгыз утырган агач күрсәм, мин хәзер дә моңаям, күңелләр кузгала. Күрәсең, шул сабый чак хатирәләре уянудандыр.
Урманга килдек. Җиләкле аланнар эзләп, ярты көн йөрдек. Үзебез белән алган савытларыбыз (бер литр сыешлы коштабак) ярты булганчы җыйдык җиләкне. Арыдык. Һич кенә арттырып булмый бит шуннан.
Ни булса да уйлап чыгарырга бала-чагадан да тапкыррак берәү дә юктыр. Салих абзыйның олы малае Шәкүр, әтисе төсле кап-кара малай, җиләкләрне бергә кушып, башта берәр савытны тутырырга, аннары бушап калган савытларга җыярга дип киңәш итте. Киңәш безгә ошап куйды. Гайшә апа, Сажидә, Гариф (анысы Салих абзыйның өченче малае, минем адаш һәм кордаш) үзләренең җиләкләрен Шәкүр савытына тутырдылар. Шәкүр җиләкне баса-баса тутырды. Әмма без, Мансур белән мин, аларга кушылмадык. Мансур белән икебезнең җиләкне Мансур савытына тутырып куйдык та, ашыгып-ашыгып, икенче савытка, минем савытка җыя башладык. Икенче савытны тутыру дәрте бездә шундый көчле иде, Мансур белән без икебез, аланнарны айкап чаптык, ашыктык. Көндезге сәгать икеләр тирәсендә икенче савытны да тутырып куйдык. (Беренче савытны без билгеле бер куак астында яшереп тоттык). Әйе, безнең савыт тулды, кайтып китсәң дә була. Әмма дүрт кешелек беренче «кампаньяның» икенче савыты гына тулган, тагын ике савытлары буш иде әле. Өйләдән соң каңгырып йөрсәк тә, җиләк бүтән табылмады. Без чәй эчәргә дип, Салих абый эшләгән чүннеккә («пчельник»тан алынган сүз, умарталык) килдек. Салих абзый безгә мәтрүшкә чәе кайнатып эчертте. Кап-кара сакаллы, кара кашлы, төп кебек таза, тышкы кыяфәтенә һич тә туры килмәгән мәзәкчән бер кеше иде ул. Олы улы Шәкүрнең борын очы, маңгае кайнар чәйдән тирләп чыкканны күреп, ул әйтә куйды:
— Чык күп төште, ходай кушса, бал күп булыр быел.
Каяндыр бер умарта корты очып кереп, безнең һәммәбезгә дип бирелгән бер кашык бал тирәсендә быжылдап йөри башлады. Мин селтәнергә тотындым.
— Селтәнмә, — диде Салих абзый.
Кая сүз тыңлау! Мин селтәнүемне беләм, бал корты минем борын тирәсендә быжылдый хәзер.
Салих абзый, селтәнмә, дип икенче мәртәбә әйтергә дә өлгермәде, мин ике куллап бутана башладым, кортны ялгыш битемә кысып та алганмын, ул минем күз төбенә угын кадап алырга да өлгерде, Салих абзый иплән кенә аның угын алды:
— Галимнәр алар — бал кортлары, селтәнә белми селтәнсәң, күрмәгәнеңне күрсәтәләр алар, — дип сөйләнә-сөйләнә, бал корты килсә тыныч кына утырырга, селтәнмәскә кирәклеген тагын бер мәртәбә аңлатырга кереште.
Шуның белән бездә чәй эчү кайгысы бетте. Әллә ни арада минем күз төбе йодрык чаклы булып шешеп чыкты. Аның өчен Салих абзый миңа бер кашык артык бал бирсә дә, минем бал ашарлык хәлем юк иде инде. Өстәвенә Шәкүрләр, Гарифлар: «Ай-яй матур булдың!» — дип мине үртәргә, миннән көләргә дә керештеләр. Тик Мансур гына мине үртәмәде, ул мине ярата, без аның белән икәү бик дус идек, күп вакыт урманга икәү генә йөри идек. Әмма... миннән көлгән Шәкүрләргә озакламый җыларга туры килде.
Чәй эчкәннән соң без өйгә кайтырга булдык. Ләкин бит әле Шә-

күрләрнең ике савыты гына тулган, калган ике савытны нишләтергә. Кич якынлашып килә иде инде. Бүтән әмәл калмагач, Шәкүрләр җиләкне бүләргә утырдылар.

Бүлделәр, җиләк бергә кушкандагыча чыкмый, чөнки ул тыгызлап салып сытылган, боламык булган. Башта минем Гайшә апа, аз бу, дип җылый башлады, аннары Гариф шыңшырга тотынды, Сәҗидә бик усал кызый иде, ул шыңшып-нитеп тормады, җиләген ашады да бетерде. Аңа карап Шәкүр дә, Гайшә апа да, Гариф та ашап бетерделәр.

Өйгә кайттык. Әни әле кырдан кайтып җитмәгән, көтәбез. Дөресрәге, җиләк тулы савытны тотып мин көтәм, Гайшә апа белән Сәҗидә өстәл астына кереп качтылар.

Бу, бәлки, минем тормышымдагы бер борылыш ноктасы булгандыр. Савытларны тутырып, җиләк алып кайту, аны ашамый түзү, аны әнигә тапшыру шатлыгын кичерү кебек төгәллек, ныклык минем тормыш максатыма әйләнде. Мин, үз дигәнемә ирешмичә, бер генә эштән дә туктамый торган булдым...

## Чабатасыз студент

Казанбаш урта мәктәбендә җиденчене мин гел «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамлап, Мактау кәгазе алып чыктым. Ул миңа техникумнарга сынаусыз керергә хокук бирә иде.

Миңа укытучыларым булачак рәссам итеп карыйлар, бик зур өмет баглыйлар иде. Моның сәбәпләре бар. Мәктәптә укыган елларымда мин икенче сыйныфтан башлап стена газетасы чыгарып килдем. Яраткан язучыларымны: Тукайны, Такташны, Пушкинны дәфтәргә кара белән күчереп ясадым. Авылыбызны, сыер-сарык, ат-этләрне, каз-үрдәкне, агачларның төрле төрен, коймаларны, сыерчык ояларын төсле буяу белән дәфтәргә төшердем. Рәсем белән мавыгу шулкадәргә барып житте, мин дәрестән соң мәктәптә калып, рәсем укытучысы Хәмзә Закировның рамга тарттырылган ак материягә портрет ясаганын сәгатьләр буе карап тора башладым. Көз бәйләнә башлагач кына кайтырга кирәклек исемә төшеп, чыгып йөгерәм дә, Казанбаш белән Өчиле арасын — өч чакрымны ярты сәгатьтә узам, мышкылдап өйгә кайтып керәм. Әни мине: «Кайларда югалып йөрисең, гамьсез, өйгә булышмыйсың?» — дип гаепли, мин аңа каршы сүз әйтмим, шуның белән гаебем йомыла иде.

Ләкин мин рәссам булырга кайда укытуларын белми идем. Кешедән нәрсәнедер сорарга уңайсызлану гадәтем минем гомер буе сакланды, ул миңа вакыт-вакыт бик зур зыян китерә, бик кыен хәлләрдә калдыра, әмма — нихәл итим — кешегә, бигрәк тә чит кешегә сүз катудан мин яшеннән курыккан кебек куркам, үземә тиешлене газетадан, белдерүләрдән укып, кешеләр сөйләшкәнгә колак салып йөреп беләм, холкымдагы бу кыен сыйфатның азактан миңа бик күп файда китергән чаклары да булды: мин күзәтүчән, кызыксынучан, читтән карап торып, күргәннәремне хәтердә калдыручан булып киттем. Ә бу минем кебек язусызу белән шөгыльләнгән кеше өчен бик тә кирәкле, хәтта файдалы сыйфат булып чыкты. Тик ул елларны чамадан тыш оялу сыйфаты мине рәссамнар мәктәбенә керттерми калдырды, мин, үземә кирәкне район газетасында басылып чыккан белдерүдән укып, Арча педагогия училищесына документларымны илтеп бирдем.

Бая әйткән Мактау кәгазем булганга, мине имтихансыз алдылар. Ул елларны махсус уку йортларына керә алган кеше иң бәхетле кеше санала иде. Рәсем мәктәбенә керә алмасам да, мин педагогия училищесына эләгүемә бик тә канәгать идем, мөгаен, үзебезнең кечкенә Өчи-

ле авылына кайтып, дусларым Мансур, Гариф, Шәкүр, Шамилләр алдында мактанып та йөргәнмендер әле...

Күңелдә берәүгә дә әйтми торган әчке бер сөенеч тә бар иде: шушы училищеда минем яраткан укытучым Һиди Зиятович укыган. Ул инде Кызыл Армия сафында хезмәт итә, мин аңа, шатлыгымны әйтеп, хат яздым. Һидият абыйдан озак та тормый хат килде, ул мине мактаган, студент булуым белән котлаган, мине сагынуын, миңа уңышлар теләвен әйткән, кыскасы — мин айлар буе шатланып йөрерлек хат язган иде.

Тик озакламый минем шатлыгыма корт төште.

Бер дә бер көнне педучилище директоры укырга яңа кергәннәрне зур коридорга җыйды да, барыбызның аякларын карап чыккач:

— Педучилищега чабата киеп йөрү тыела. Әти-әниләрегезнең ботинка алырлык кына рәте бардыр, — диде.

Минем, әтисез малайның, ботинка алырлык рәтем юк иде. Әнигә ул хакта әйтеп, күз яше белән ялварсам да, ул миңа хәзер үк ботинка алырга вәгъдә итмәде, җирләр туңып, бер сарыкны суеп саткач кына ала алырбыз, диде.

Мин, чабатамны салып ташлап, җир туңдырганчы яланаяк йөрдем училищега, миңа берәү дә чабата белән килгәнсең дип бәйләнә алмый иде хәзер...

## Чишмә белән әлифба

Минем өчен тормышта ике нәрсә гомер буе могҗиза булып саклана килә: берсе — Чишмә, икенчесе — Әлифба. Аларны бер генә кеше дә уйлап чыгара алмый, алар дөньяга үзләреннән үзләре туалар һәм шулай гомер буе яшиләрдер кебек тоела иде миңа. Өстәвенә алар икесе дә сусауны басу өчен яратылган: Чишмә — суга сусаганны, Әлифба — белемгә сусаганны.

Чишмә белән Әлифба турындагы уйлар миндә Арча педучилищесында безгә татар телен укыткан укытучыбыз Рәмзия апа Вәлитованы искә төшергәч тудылар. Педагог һәм Әлифба авторы булганчы Рәмзия апа зур юл узган, «1922 елның пионеры мин» — дип бик тә горурланып әйтергә ярата иде Рәмзия апа безне укыткан елларны. Бу очракта да Чишмә образы Рәмзия апага туры килә: Бөтенсоюз яшь ленинчылар оешмасы оешкан елны ук пионерга кергән ул. Ул моның белән үзен бик тә бәхетле саный, без тормышыбызны Чишмә башыннан башладык, ди. Әмма аның бәләкәйдән үк саклап йөрткән кайгысы да бар: 1921 елгы ачлыктан аның әти-әнисе үлә. Совет власте сигез яшьлек баланы ятимнәр йортына ала, муенына кызыл галстук тага, белем алырга, бәхетле булырга ирек бирә.

Боларның барысы Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә була. 1928-1931 елларны үсмер кыз Рәмзия, педагогия техникумын тәмамлап, Стәрлебаш авылында балалар укыта башлый. Анда пионер оешмасы оештыра. Ул чагында «Коммунистик балалар оешмасы» дип исемләнгән оешманың рәисе, ягъни председателе була. Татарстанда чыга торган «Яшь ленинчы» газетасын үзенең пионерлары арасында тарата.

1934-1937 елларда Рәмзия Вәлитова, Казан педагогия институтын тәмамлап, Арча педагогия училищесына татар теле, әдәбияты укытучысы итеп җибәрелә.

Әнә шул көннән башлап, пенсиягә чыкканчы, ягъни 1969 елга кадәр, ул Арча педагогия училищесында булачак укытучыларны тәрбияли. Утыз ике ел буена әзерли ул аларны. Бу үзе генә дә һәркемне сокландырырдай озын гомер, һәркемне таң калдырырдай зур хезмәт! Мин аның нинди әйбәт укытучы булганлыгын ак кәгазь бите янына утырган саен искә төшерәм. Ул бездә туган телебезгә, Тукай мирас итеп кал-

дырган телгә мәхәббәт уятты. Телнең грамматикасына, синтаксисына өйрәтергә мөмкин, дөрес итеп нокталы өтер куярга өйрәтергә мөмкин, әмма туган телгә карата мәхәббәт тәрбияли алмасаң, өйрәтеп йөргәннәрем бушка китте дип исәплә. Теле булмаган язучыны, телгә битараф калган язучыны мин начар педагогтан, телгә үзе дә формаль караган, битараф караган педагогтан белем алган язучы дип саныйм.

Туган телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли алган укытучы бәхетле укытучы ул. Кеше рухын тәрбияли алган укытучы ул. Рәмзия апаны мин әнә шундый укытучы дип саныйм һәм шуңа күрә дә без, аның шәкертләре, аңа карата күңелебездә рәхмәт хисе саклап йөрибез. Аны хөрмәтләп баш иябез.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Рәмзия Гыйләҗ кызы Вәлитовага Татарстанның атказанган укытучысы дигән данлы исем биреп, аның утыз елдан артыкка сузылган педагогик хезмәтен зурлады.

Рәмзия апаның, тау-ташлар актарып чыккан саф сулы чишмә шикелле, гел яктыга омтылуы, илебез биргән белемне үзендә генә калдырмыйча, меңләгән балага күчерүе — бу үзе үк инде саф суы белән кешеләрнең сусынын баскан Чишмә образын хәтерләтә.

Әмма Рәмзия апаның хезмәте балаларга белем бирү белән генә чикләнми. Шул хезмәте белән бергә, ул мәктәпләргә кирәкле күп кенә дәреслекләр язды. Арча педагогия училищесының укытучысы, гомер юлдашы Сәләй ага Вагыйзов белән бергәләп, Рәмзия Вәлитова сигез китап иҗат итте. Аларның бу эшкә никадәр җаваплы караганлыгын бер мисал белән исбатлый алам. Моннан берничә ел элек, балалар әдәбияты һәм сәнгатенә багышланган зур бер киңәшмәдә мин башлангыч мәктәпләр өчен чыгарыла торган кайбер дәреслекләрдә әдәби әсәрләрдән алынган өзекләрнең югары таләптән чыгып сайланмаганлыгын әйтеп узган идем, киңәшмә хакында газетада репортаж басылган иде. Берничә көн узуга Сәләй ага белән Рәмзия апа, гаять дәрәҗәдә борчылып, минем янга килеп җиттеләр. Нәрсә турында сүз барганлыгын каткат, төпченеп-төпченеп сораштылар, мин сүзнең алар әзерләгән китаплар турында түгеллеген әйтсәм дә, тынычлана алмыйча, Арчага кайтып киттеләр. Шуннан соңгы чыккан китапларда мин аларның тагын да зуррак таләпләр куеп эшләгәннәрен күрдем. Менә бу, ичмасам, хезмәт! Моңардан барыбызга да үрнәк аласы бар.

Рәмзия Вәлитова белән Сәләй Вагыйзов чыгарган китаплар арасында минем үземне иң нык дулкынландырганы — Әлифба.

Әлифбаны кулга тоту белән мин кояш нурында җемелдәп яткан карлы яланнарны, капка-коймаларны күмеп киткән бураннарны, язгы гөрләвекләрне, мәктәп коридорына килеп керү белән көйләп-көйләп китап укыган балаларның сыйныф бүлмәсеннән ишетелгән тавышларын искә төшерәм. Балачагым, мәктәп елларым, газиз укытучыларым мәңге онытылмаслык булып күңелемдә яңара.

Балачагымның якты көннәрен кабат искә төшергәннәре өчен дә Әлифба авторларына мең-мең рәхмәт әйтәсе килә минем. Шушы әлифбаны укып күзләре ачылган меңләгән, ун меңләгән бала, еллар узгач, зиһеннәре арта төшкәч, Рәмзия апа белән Сәләй агага, минем кебек үк, рәхмәт әйтерләр әле дип ышанам.

## Тәнкыйтьче хөкеме

Икенче мәртәбә минем тере язучыларны күрүем Арча педагогия училищесында укыганда булды. Бездә рус телен һәм рус әдәбиятын әле яңарак кына Казан педагогия институтын тәмамлап кайткан, әмма

инде әдәбият дөньясында исеме шаулый башлаган яшь тәнкыйтьче, Габдулла Тукай турында беренче китабын чыгарырга өлгергән егерме биш яшьлек егет — Гали Халит укыта иде.

Коңгырт чәчен матур итеп як якка тарап куйган, чигүле ак күлмәкне чуклы билбау белән буган, төз гәүдәле, җиңел сөякле Гали абый ишектән, балет артисты кебек, очынып кына килеп керә, ниндидер бер шаян сүз әйтеп куя һәм, барыбызның да симпатиясен яулап алгач, дәресен бик җитди итеп башлап җибәрә.

Без, авыл мәктәбеннән русчаны ярым-йорты белеп килгән малайлар, аның русча шартлатып сөйләшүенә таң калып, авызыбызны ачып тора торган идек.

Бераздан аның әле укытучы гына түгел, язучы да икәнен белеп алгач, инде ул чыгарган китапны да кулга тотып карагач, Саба малае Муса Гайсин белән икебез, аны күзәтеп, аның гамәлләренә күз салып йөри торган булдык.

Бу 1940 ел азаклары иде.

Шул елны көзен Гали Халитның «Совет әдәбияты» журналында Нәби Дәүли шигырьләре хакында усал гына бер мәкаләсе басылды. Озак та тормый, Арчага, тәнкыйтьче белән аңлашу өчен, шагыйрь үзе дә килеп җитте. Алар берме-икеме көн педучилище каршындагы урамда «зат-пирут» йөреп тордылар. Муса белән без, тере язучыларны якыннан күрү, аларның ни сөйләшкәннәрен ишетү өчен, дәрестән качып, урамга чыктык һәм, озак сагалап торганнан соң, ниһаять, аларның безгә таба килгәннәрен күреп, куркып калдык. Юк, без Нәби Дәүлидән түгел, Гали Халитовтан курыктык. Аның безгә: «Нигә сез, сыбызгы борыннар, дәрестә түгел әле?» — дип бәйләнә башлавы мөмкин иде. Әмма безнең язучыларны күрәсе килү теләге шундый зур иде, тиргәлү куркынычы да безне туктатып кала алмады. Без аларга каршы атладык. Килеп җитә башлагач, кырт уңга борылдык та койма буена килеп сөялдек. Шуннан күзәтәбез тегеләрне. Аларның бәхәсе бик хәтәр көчле иде булса кирәк, кулларны шундый да бутап сөйләшәләр, безне күрмәделәр, игътибар да итми узып киттеләр. Аның каравы, без аларны күрдек, Нәби Дәүли базык гәүдәле, кара бөдрә чәчләре көнҗәлә чаклы, ул, трибунага чыккан оратор кебек, кулларын өзлексез селтәп килә иде.

Шунда без язучының гадәти кеше түгеллегенә ышандык. Юкса, тиктомалдан, бер-беренә этлек эшләмәгәндә, кемнең инде урамда шаулап-дулап, бутанып-селтәнеп йөргәне бар?! Югары Пошалымның Алма апа мине урамда һәм кеше-кара барында кычкырып сөйләшмәскә, кычкырып көлмәскә, авызны зур ачып иснәмәскә өйрәтте...

Арча педучилищесында укыганда, мин әдәбият кебек серле дөньяга аяк басарга икенче мәртәбә талпынып карадым. Монда мине педучилищеда әдәби түгәрәк булуы, ул түгәрәкне тәнкыйтьче Гали Халитның җитәкләве этәрде.

Без үскән чакта безнең як урманнарында каравылчы булып Мостай исемле кеше эшли иде. Тирә-якта аның усаллыгыннан, тотса җәзасыз калдырмавыннан зарланалар, Мостайдан уттан курыккандай куркалар иде.

Аның хакында инде безнең як авылларында легендалар да туа башлаган иде. Ул, имеш, Шәкүр карак шайкасыннан качып котылган кеше. Башкаларны атып үтергәнне ишеткәч, гомерем булса, Совет власы муеныма тишек тишмәсә, җаным-тәнем белән шул власка хезмәт итәр идем дип ант иткән, имеш. Аның хакында: ул йоклавын да аяк өсте генә йоклый икән, урманның һәр агачын биш бармагы кебек белә икән, алар белән хәтта сөйләшеп йөри икән, диләр иде. Без, авыл малайлары, бер-беребезне куркытырга кирәк булса: «Стой, Мостай!» — дип кычкыра торган идек.

Көннәрдән бер көнне әнә шул легендар урман каравылчысының үтерелүе хакында хәбәр таралды. Берәүләр, аны кыска мылтыктан атканнар дип, икенчеләре, башына балта түтәсе белән сукканнар дип, өченчеләре өстенә агач аударганнар дип сөйләделәр.

Бу хәбәр өч-дүрт ай сөйләнеп йөрде дә тынды. Шуннан соң Мостайның яңадан урманда йөрүен, урман урлаучыларны рәхимсез рәвештә җәзалавын әйттеләр. Ул безгә, авыл малайларына, әкият батыры кебек, диюләр белән сугышканнан соң үлеп терелгән кебек тоелды, күңелгә балачак истәлекләренең иң көчлесе булып сеңеп калды. Педучилищеда әдәбият түгәрәге эшләвен ишеткәч, түгәрәкне юк-бар кеше генә түгел, безнең укытучыбыз, өстәвенә язучы кеше үзе җитәкләвен белгәч, янә дә бер мәртәбә бәхетне сынап карамак булдым.

Атна буе төннәр йокламыйча, «Урман каравылчысы» дигән хикәя яздым. Аны әдәбият түгәрәгенең бер утырышында язучы Гали Халит катнашында укырга батырчылык иттем.

Педучилище малайлары минем хикәяне авыз ачып тыңладылар. Укып бетергәч, кул чаптылар. Ләкин мин андый кул чабуларны Казанбаш мәктәбендә күреп килгән кеше идем инде. Миңа тәнкыйтьче абыемның хөкемен ишетү кадерлерәк иде.

Күптәннән билгеле бер хакыйкать бар: гадәттә, олы язучы энекәшенең хәтерен калдырмаска, әсәрнең кимчелекләрен мөмкин кадәр җайлырак итеп аңлатырга тырышучан була. Гали абый минем белән алай уен уйнап маташмады. Ул туп-туры әйтте:

— Синдә өмет бар, Ахунов. Хикәя өчен кирәкле вакыйга тапкансың. Ләкин осталыгың шул вакыйга табудан ары узмаган. Дошманың ышандырмый, урман каравылчысын үтерергә ул куркып килми...

Бу сүзләрнең мәгънәсен мин ул чакта аңлап җиткермәдем. Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, әллә ничә еллар журнал редакциясендә эшләгәч, ниһаять, үзем берничә әсәр язып бастыргач кына аңладым. Урман каравылчысына кул күтәргән кеше, явыз кеше, минем хикәямдә куркыныч булып чыкмаган, агачтан юнып ясалган курчак кебек кенә булып чыккан. Үтерүче никадәр генә кансыз булмасын, ул үзе эшләячәк явызлыктан курка, тотылмагаем дип тетрәп тора икән бит. Әнә шуны аңлатырга теләгән миңа Гали Халит. Ләкин әле ул чакта мин кеше психологиясен тирәнтен аңларлык хәлдә булмаганмын шул.

## Тормыш баскычлары

Арча педучилищесында мин ике мәртәбә укыдым.

1942 елны укуны өзеп торырга, дүрт баланы бер үзе карап барган әнигә булышырга туры килде.

Авылда мин җир сукаладым, ат көттем, кырчылык бригадасы бригадиры һәм клуб мөдире булдым. Аннары Красноярск краеның Березовка поселогында ике елдан артык маляр булып эшләдем. Йортлар буяудан башлап пианино полировать итүгә хәтле өйрәнеп, буяу эшендә алтынчы разряд алдым. Хәзер инде андый разряд бардырмы-юкмы, белмим, әмма ул чагында бу иң югары разряд санала иде.

Болар минем алдагы язучылык эшемә бик күп материал биргән, мине эшчеләр һәм игенчеләр турында китаплар язуга алып килгән чорым, минем тормыш баскычларым, хәзергә мин аларны җәелеп язмыйм, чөнки болар — минем язучылык планымда үзләре бер повесть булып бөреләнеп киләләр.

1946 елны мин, авыр сугыш елларында өзелеп торган укуымны дәвам иттерү өчен, тагын Арча педучилищесына кайтып кердем. Элекке укытучыларымнан ул чакта, ихтимал, Рәмзия апа Вәлитова гына кал-

гандыр, башкалар кайсы кая китеп беткәннәр, пенсиягә чыкканнар, ил буйлап таралганнар иде.

Рәмзия апа мине онытмаган икән, миннән нидер чыгачагына өмет баглап тотынды ул, ана телебезнең байлыгын аңлатуга чамадан тыш күп көч куйды. Сугыштан соңгы беренче елның материал кысынкылыклары да, суык баракларда яшәп, туңу-күшегүләр дә, бернинди мәхрүмлекләр дә аны безгә таләп, хәтта әйтер идем, аяусыз зур таләпләр куюдан туктатып калмады. Ул чагында бик кыенга туры килсә дә, хәзер без моның өчен Рәмзия Гыйләж кызы Вәлитовага кат-кат рәхмәт әйтәбез. Әдәби хезмәт өчен һава кебек кирәкле тел нечкәлекләренә беренче ныклы нигезне без — Яхъя Халитов, Мөхәммәт Мәһдиев һәм мин — аңардан алдык.

Педучилище дигән сүз безнең өчен аның стеналары дигән сүз түгел. Педучилище безнең өчен, беренче чиратта, аның укытучылары дигән сүз. Һәм ул шулай булып гомер буена безнең күңелдә яшәр.

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

# УНИВЕРСИТЕТ

## Укырга кая керергә?

Арча педучилищесын без нибары тугыз кеше тәмамлап чыктык. Сугыштан соңгы беренче елларны рус теленнән инша дәүләт имтиханына беренче итеп куела һәм аны ким дигәндә «өчлегә» яза алмаган кеше алга таба имтиханнарга кертелми иде. Шул сәбәпле училищены 1947 елны кырык алты кешедән тугызы гына тәмамлый алды. Калганнары имтиханнарын читтән торып тапшырдылар.

Әнә шул бик кадерле аттестатларның берсе Яхъя Халитовта, берсе Мөхәммәт Мәһдиевтә, берсе миндә иде. Мөхәммәт шундук укыту эшенә китте. Яхъя белән миңа, училищены ударник булып тәмамлаганыбыз өчен, алга таба вузда укырга рөхсәт бирелде.

Киттек без Яхъя белән Казанга. Кайсы вузга керәсебезне аермачык кына белми идек әле. Безнең каршыга, әлбәттә, иң әүвәл ак колонналары белән күз явыбызны алып, университет килеп басты.

Анда Ленин укыган булуы, бинасының мәһабәтлеге, дөньяга таралган даны белән университет хыял ирешмәс биеклектә иде. Без анда керергә бик тә тели идек, шул ук вакытта керә алачагыбызга ышанып бетми идек.

Әнә шулай икеле-микеле йөргән көннәрдә, минем алда балачак хыялларым калкып чыкты: мин Казан художество училищесын карап кайттым. Анда ничек алуларын белештем. Училищега җиденче класстан соң алалар икән. Минем бит урта белем — укып уздырган өч ел кызганыч. Мин ныклы бер карарга килдем: художество училищесына укырга керергә һәм шул ук вакытта Казанның педагогия институтында читтән торып укырга. Димәк, мин рәссам булып чыгам, югары белемле укытучы да була алам. Нотариаль конторга барып, өлгергәнлек аттестатының ике данә күчермәсен алдым. Барлык документны икешәр данә итеп әзерләп бетердем дә, инде кабул итү комиссияләренә илтеп тапшырыр көн килеп җиткәч, янә икеләнә башладым.

Нишләргә?

Өстәвенә, Казанда йөри торгач, ул еллардагы коточкыч кыйбат бәя белән базарда туклана торгач, кесәдә сукыр бер тиен дә акча калмады.

Нишләргә?

Туган як бар бит әле. Арча бар — киттем мин поезд түбәсенә менеп, куян булып Арчага.

Барып кердем педучилищега. Керүемнең сәбәбе — киңәшү. Рәсем училищесына керергәме, пединститутны сайларгамы, әллә бәхетне университетта ук сынап караргамы?

Киңәштем Рәмзия апа белән — ул пединститутны киңәш итә, киңәштем рәсем укытучысы Носов белән, ул, әлбәттә, художество училищесын каера, киңәштем география укытучысы Шәмиев агай белән — ул университеттан башка җиргә авызны да ачтырмый.

Нишләргә?

Очрады педучилище директоры Табаров. Бу озын-озак сөйләнеп тора торганнардан түгел.

— Син, Ахунов, маляр һөнәрен беләсең түгелме?

— Беләм, мин әйтәм, Табаров агай!

— Безгә малярлар бик кирәк, училищены ремонтлыйсы бар, укуларың башланганчы син бездә унбиш-егерме көн эшләп алмассыңмы? Бәясеннән тормабыз. Тамагың тук, өстең бөтен булыр, өстәвенә вузда укыр өчен бер йөк дәфтәр дә биреп җибәрербез.

Производствода ике елдан артык маляр булып эшләгән кеше бит әле мин, алтынчы разрядым бар. Нигә шуны файдаланмаска? Өчилегә кайтып, истәлегем итеп саклаган буяу пумаласын алып килдем, Казанбаш тимерчесе Степан агайдан мастерок ясатып алдым да тотындым училище бинасын буярга.

Нәкъ егерме көн эшләдем. Баш күтәрмичә. Пумала белән ярты училищены буяп чыктым (сиптергеч машинам юк иде). Өскә начармы-яхшымы, кеше арасына чыгарлык костюм алып кидем. Бераз гына булса да кесә акчасы да юнәттем. Ә иң мөһиме — бер йөздән артык дәфтәр тоттырып җибәределәр миңа.

Утызынчы июль көнне Казанга килеп төштем. Яхъя мине дүрт күз белән көтеп утыра. Кая илтәбез, янәсе, документларны?

Киттек чыгып пединститутка дип, юл өстендә биек ак колонналары белән университет ымсындырып утыра, керттек тә бирдек документларны университетка.

Өстән Каф таулары ишелеп төшкәндәй булды.

Беренче август көнне килдек имтиханга.

Тырышып-тырмашып сигезәр битле инша язып чыктык. Хәбәр көтәбез. Нәтиҗәсен әйтмиләр, имтиханнарны тапшыра бирегез, диләр. Эчкә җылы керде. Димәк, безнең иншалар «икеле» яки «берле» алмаган, алган булса, имтиханнарга кертмәсләр иде.

Рус теленнән без имтиханны дөбердәтеп кенә биреп чыктык. Хәтта укытучыларның күзләре шар булып калды. Баштарак без моның, ягъни «күз шар булуның» мәгънәсен аңламадык. Азактан, иншаларыбызда егерме бишәр-утызар хата чыкканлыгын белгәч, аңладык. Рус теленнән имтиханны шартлатып бирә алган, һәрбер кагыйдәне яттан белгән авыл «мокытлары» язмадан ничек соң шул хәтле дә күп хата ясадылар икән? Әнә шулай дип аптыраган икән укытучылар.

Ә безнең өчен бу бик тә гадәти хәл иде. Арча педучилищесында безгә рус телен дә, татар телен дә бик каты укыттылар. Барлык кагыйдәләрне без яттан беләбез, хәл әйләнмәләрен татар җөмләсендә дә, рус җөмләсендә дә күзне йомып әйтеп-күрсәтеп бирә алабыз, әмма телнең практик байлыгы, сүзлек запасы рус теленнән бик әллә ни мактанырлык түгел иде шул.

Ничек булса булды, рус теленнән бишлегә белүебез белән иншадагы утызар хатабызны бергә кушып, безгә өчле чыгардылар.

Татар теленнән һәм татар әдәбиятыннан имтихан тапшырганда, без үзебезне судагы балык кебек сиздек. Өчме-дүртме көн эчендә тарихны ботарлап аттык: имтиханы,— хәтерем ялгышмаса,— дүртле булды шикелле. Без, әлбәттә, моны укытучының кин күңелле булмавыннан күрдек, безнең шул хәтле дә тырышуны ул аңларга, безнең университет

чаклы университетта укырга элэгүнең безгэ ни хэтле бэхет икэнен ул безнең күзлэребездэге очкыннардан ук белергэ тиеш иде.

Һэм, һичшиксез, бишле куярга тиеш иде.

Э ул, хэерсез, безгэ дүртле куйган. Тарихтан дүртле алганнар уз-мый икэн дигэнрэк хэвефле сүз ишетеп, икеме-өчме көн хэсрэт эчендэ, утта янып йөрдек тэ чит телне тапшырырга кердек.

Безнең белэн бергэ кергэн Уфа малае Роберт Бикмөхэммэтов ишек яныннан ук имтихан алучы педагог белэн немецча сөйлэшэ башлагач һэм, күзлек пыялаларын ялтыратып, бөтен бүлмэне яктыртып елмаеп та жибэргэч, безнең күңеллэргэ тагын шом төште.

Дөресен генэ эйткэндэ, сугыштан соңгы авыр кырык алтынчы елны без, укытучы булмау сэбэпле, немец телен бер генэ ай укып калган идек. Бу юлы имтихан алучы олырак яшьтэге апа безнең белэн пыр-дымсыз кыланмады, киң күңелле булып чыкты, кайсын үзе эйткэлэп, кайсын сүзлеклэр аша бездэн таптырып, бер сэгать чамасы азаплангач, ягъни безгэ немец теленнэн бик тэ нык тырышырга кирэк булачагын эш-гамэле белэн аңлаткач, имтиханнар кенэгэсенэ чабата чаклы итеп өчле куеп чыгарды.

Энэ шул өчледэн дэ зуррак һэм куанычлырак билге алганны мин гомумэн дэ хэтерлэмим.

Тагын бер көннэн Яхъя белэн икебез, курка-курка, белдерүлэр так-тасы янына килдек. Университетка кабул ителгэннэр исемлегендэ фа-милиялэребезне күргэч, түшэмгэ кадэр сикердек.

Ура! Без — студент. Ленин укыган университет студенты!

## Кайда яшэргэ?

Жир йөзендэ үтэ дэ булдыклы кешелэр була. Имтиханнарын эйбэт тапшырган егет-кызларның үткенрэклэре, һэммэ нэрсэне алдан беле-шеп, алдан хэстэрен күреп, тулай торакка урнашып алганнар. Яхъя бе-лэн безгэ торак калмаган, без урамда торып калганбыз.

Сентябрьгэ чаклы эле ун көн чамасы вакыт бар иде, без бөтен Ка-занны бетереп фатир эзлэргэ тотындык. Университет администрациясе безгэ шулай кушты.

«Сезнең өчен фатирга аена ун сум акча түлибез, икеме-өчме кубо-метр утын бирэбез», — дилелэр.

Казанда инде байтак еллардан бирле яшэгэн абзыйлар бар иде ми-нем. Таза тормыш белэн яшилэр. Эскадулла абзый известь-алебастр за-водында ат карый, малайлары белэн кызлары — кайсы пекарнидэ, кай-сы кибеттэ эшли. Болар — минем эти ягыннан иң якын туганнар. Хэ-зерге аңлавымнан чыгып эйтэм, тормышка чатырдап ябышкан, тормыш-ны бик тэ аңлап, аның жаена төшенеп яшэүче, ифрат дэрэжэдэ булдыклы кешелэр иде.

Киттем мин боларга. Хэллэрне сөйлэп бирдем. Университет админи-страциясе эйткэн икеме-өчме кубометр утынны да, ун сум акчаны да эйтеп кызыктырдым.

Эскадулла абзый, алтмыш бишлэр тирэсендэге чал сакаллы карт, мыегын чэйнэштереп торгач, миңа таба күзенең агын эйлэндереп ка-рады да:

— Уттай урак өстендэ, эниеңэ булышмыйча, нинди эшсез йөрү ул?! —диде.

Кая ул аларда яшэү, алга куйган чэйне дэ эчэсе килми башлады минем. Кузгалдым да ишеккэ таба киттем. Туктатучы булмады. Эска-дулла абзый минем арттан:

— Үзеңә күрә түгел, кыланышы кырга сыймый! Кара нинди тәкәббер! — дип әйтеп калды.

Шул чыгудан Казандагы икенче бер кешегә — Хәкимулла абыйларга юнәлдем. Бу — мин бәләкәй чакта, эти үлгәннән соң, Югары Пошалымда яшәгән Хәкимулла абый бит инде! Завод эшчесе.

Хәкимулла абый да, аның көләч хатыны Асия апа да мине караңгы чырай белән каршыламадылар. Минем укырга керә алуымны мактадылар.

— Бәрәкалла, безнең нәселдән дә бер пырафисыр чыга икән,— диде Хәкимулла абый, чәй эчеп утырганда.

Мин аларда дүртме-бишме ай тордым. Алар миннән чәй-шикәрне, тәмле сүзләрен кызганмадылар. Бер генә мәртәбә дә караңгы чырай күрсәтмәделәр. Икесе тиң иртүк эшкә китәргә тиеш булсалар да, мине чәй эчертмичә, минем тамакны туйдырмыйча китми торганнар иде.

Эшче кешегә булган ихтирамым әнә шулардан башланды бугай һәм — азактан — ул ихтирам минем иҗатымның төп юнәлешенә әйләнде.

Ләкин бик авыр еллар иде бу. Сугыштан соң әле икмәкне дә, башка продуктларны да карточка белән генә алган заман иде. Хәкимулла абый белән Асия апа икесе эшләп тапкан акчага өч малайны, ягъни үзләре белән биш җанны, шуның янына мине дә китереп кушсаң, алты җанны туйдырып барырга тиешләр иде.

Бу мине кыенсындыра, мин чәй янына утырырга уңайсызлана башладым. Әмма тиктомалга күчеп тә китеп булмый иде. Эзли торгач, сәбәбе табылды. Хәкимулла абыйлар Ягодный бистәсендә торалар, алардан университетка автобус белән кимендә 40—50 минут килергә кирәк, мин еш кына соңга да кала идем. Әнә шуны сәбәп итеп, университеттан бер квартал гына ары бер йортка фатирга кердем. (Ул чагында «Чернышевский» урамы дип атала иде, хәзерге Ленин урамы.)

Фатирга без чуваш малайлары Гена Хубльдиков һәм Коля Ермошкин өчәү бергә кердек. Фатир хуҗасы Николай Осипович инде илленә узып киткән маляр, искиткеч оста маляр иде, ял көннәрендә үзе белән бергә ул мине дә буяу эшенә ала, кайвакыт мин базарда сатар өчен аккош сурәтләре дә ясый идем. Базарга күкәй-май сатарга килгән авыл җингиләре, берсеннән-берсе уздырып, әнә шул аккош сурәтен алалар, өйләрендә шуны караватт буена эләләр иде.

Николай Осиповичларның квартирлары биек түшәмле, өч бүлмәле, утын белән ягыла, алар безне, күрәсең, утынына кызыгып керткәннәрдер.

Менә шушы эшче кешеләр, — Хәкимулла абыйлардан кала икенче эшче гаилә, — безгә искиткеч якты күз белән карады. Без укудан кайткан чагында, электр плитәсендә пешеп торган ашлары булса, алар аны шундук алалар, студент халкын кызганып, тизрәк безгә аш пешерергә ирек куялар иде. Шул яхшылыклары өчен мин Николай Осиповичны, үзебезчә әйткәндә, «дядя Коляны» бер җәйне Арча педучилищесына бөтен бер бригада итеп җыеп алып кайттым, һәм ул җәйне без ярыйсы гына акча да төшерә алдык.

Николай Ермошкин белән Геннадий Хубльдиков минем күңелемдә чуваш халкына карата искиткеч матур тойгылар уятып калдырдылар. Иң әүвәл, алардагы тырышлык, булдыклылык мине таң калдырды. Алар барлык дәресләрен бик төгәл эшлиләр, семинар дәресләренә беркайчан да әзерләнмичә бармыйлар, гомумән дә, әзерләнмичә баруны үзләренә хурлык саныйлар иде. Шушы тырышлыклары, төгәллекләре белән алар дядя Колялар гаиләсендә бик тиз ихтирам казандылар. Коллегасы буларак, дядя Коля мине беренче көннәреннән үк үз итте,

яратты, колер төзәргә кирәк булган чакларда һәрвакыт минем белән киңәшә, буяп бетергән биналарын миңа күрсәтә торган булды.

Март айларында микән, гомумән, язга таба булса кирәк, аларның кайсыдыр бер шәһәрдә хезмәт иткән кияүләрен — офицерны Казанга күчерделәр, ул, хатыны һәм кечкенә кызы белән, төянеп, дядя Коляларга кайтып төште.

Без тагын фатир эзләргә мәҗбүр булдык.

Алай да бәхетебез бар икән, бу юлы фатир безгә университет ишегалдындагы йортта, өч кыз үстергән тол бер апада туры килде. Үзебезнең тырышлыгыбыз, утын кисәргә, кар көрәргә иренмәвебез, гомумән дә эшкә сәләтле булуыбыз белән без аларның да ихтирамын казандык. Аларның олы кызлары Рая банкта эшли, уртанчы кызлары Валя унынчы класста, кече кызлары Нина дүртенче класста укый иде.

Минем сеңлем Сәҗидә Арчадан Казанга мал куып килгән җирдән бәкәйләгән бер сарыкның бәкәен алып килгән боларга. И дә ярattылар соң шул бәкәйне! Кадерләп кенә, сөеп кенә, ашатып кына асрадылар. Кечкенәләре Ниночка, бәкәй белән уйный-уйный, гел дә дөньяларын онытып җибәрә иде. Ике ай тулганда, нәни бәкәебез күпереп торган ап-пак йонлы зур гына бәти булып, ишекле-түрле чабып йөри башлады.

Апрельнең бер кояшлы көнендә аны урамга алып чыктылар. Аның ишегалды бетереп чабып йөрүенә мавыгып, онытып җибәргәннәр, бәтинең аягына суык тигән булып чыкты һәм ул... аяксыз калды.

Аны барыбыз да кызгандык. Нина, дәресеннән соң, аның янында көннәрен үткәреп, сабактан артка кала башлагач, кызый юк чакта әниләре аны суйдырды.

И елап та карады соң Нина. Күз яше чишмә булып акты, каргышрәнҗеш бөтен өйгә ишетелеп торды.

Бала җанының җанлы-тере әйберләргә карата никадәр мәрхәмәтле, никадәр нечкә икәнен мин әнә шунда күрдем. Кайвакыт хайваннарга карата кансызлык эшләгән балаларны күргәндә, әле һаман да Нина искә төшеп, җаннарым тетрәп китә...

Уку чоры — педучилищеда булсын, университетта булсын — минем өчен ифрат та кыен булды. Дәресләргә төшенү түгел, материаль яктан. Әти-әниләреннән ярдәм алып торган егет-кызлардан гына түгел, хәтта әтиләре алардан ярдәм сорамый торган егет-кызлардан да үлеп көнләшә идем мин.

Безнең группадагы унөч студентның берсе дә бик әллә ни рәхәтлектә яшәмәгәндер. Азмы-күпме иркенрәк яшәгән, азмы-күпме иркенрәк киенгән бер Резеда гына бар иде бездә. Әти-әниләре тигез булганлыктан, өстәвенә укытучылар да булганлыктан, ул беркайчан да ризык кытлыгы, кием кытлыгы күрмәде, курчак кебек матур киенеп, шат күңелле булып яшәде. Ашау кайгысы, кием кайгысы булмагангадыр, аның уку, дәрес әзерләү өчен дә вакыты безгә караганда күбрәк кала, аңардан шатлык, муллык, «кылтаю-әртислек» ташып тора иде.

Калганнарыбыз көнне көнгә ялгап алып бара, Яхъя белән минем хәл аеруча кыен иде.

Рәттән өчәр көн ашамыйча лекциягә барган чаклар да булды.

Без дәүләт биргән 180 сум (хәзерге белән исәпләгәндә 18 сум) стипендиягә ашарга да, киенергә дә, уку әсбаплары алырга да тиеш идек. Шушы акчадан әле мин әниләргә дә өлеш чыгарырга тиеш идем. Ник дисәң, ул елларны колхозда хезмәт көненә берни дә тими диярлек, шунлыктан мин әниләргә кышкылыкка берәр центнер бодай, арыш алып бирергә, дүрт-биш ат йөге утын әзерләргә тиеш идем. Боларны бары тик җәйләрен, башкалар ял иткәндә буяу эше эшләп, маляр булып та-

барга туры килә, җәен (ял көннәрендә хәтта кышын да) кулдан буяу пумаласы төшми иде.

Әйткәч, әйтеп бетерим инде: икенче курс ахырында мин шундый да авыр хәлдә торып калдым, инде укуны ташларга, читтән торып укырга күчәргә кирәк дигән уйга килергә мәҗбүр булдым.

Имтиханнар вакытында буяу эше белән шөгыльләнеп булмый, базарда сатар өчен картон кәгазенә аккошлар да ясарга вакыт юк, өйдән соратыр идең, язга таба анда да умачлык та он калмый, бәрәңге белән генә тукланып яши башлыйлар.

Соң чиккә җитеп гасабиланып, ачлыктан тәмам интегеп, укуны ташларга дип университет ректорына гариза язарга утыргач, мине — әлеге дә баягы — искиткеч тырыш, искиткеч булдыклы һәм төгәл егетләр, чуваш малайлары туктатып калды.

— Гариф, син укуыңны ташларга ашыкма, — диде миңа Коля Ермошкин.— Ташлавы ансат аны, дәвам итүе кыен. Әнә бит син бер мәртәбә училищены ташлап торгансың, ә ул ташлау өч елдан артыкка сузылган.

— Ач утырып та булмый бит, туганкаем, профессорларның лекцияләре башка бер дә керми, бар уйлаган уй: каян бер телем ипи табарга, дигән уй гына бит, — дидем мин.

— Син муллыкта яшәгән егет түгел, көненә бер кружка тары ярмасы сине коткара аламы? — диде ул, миңа дусларча карап.

— Коткара ала. Мин аңардан өч мәртәбә ботка пешереп ашый алам, — дидем мин.

— Алайса, мин сиңа көн саен бер кружка тары ярмасы биреп барам, шуның белән быелгы уку елын тәмамлап тор, университет бетергәч түләрсең миңа бәясен, — диде.

Әйе, ул миңа көн саен төп-төгәл бер кружка тары ярмасы биреп барды. Ике ай буена. Әнә шул дуслык ярмасы мине университетта саклап алып калды.

Тары ярмасын аңа этисе капчык белән авылларыннан китерә иде.

Тарының бәясен мин аңа университетны бетергәнче үк түләдем. Аны җәен үзем белән бергә Арчага, педучилищены буярга, үзем төзегән бригада составында алып кайттым. Ермошкинның буяу эшендә бер разряды да юк иде, ә бригада акчаны разрядка карап бүлә, без — алтынчы разрядтагы малярлар — алты өлеш алсак, яңа гына бригадага ялланган Коля Ермошкин бер генә өлеш алырга тиеш иде. Чөнки ул бит әле беренче разрядлы гына санала иде. Коляның тырышлыгын, мичкәләргә суны йөгерә-йөгерә ташуын, буяу сиптергеч насосны армый-талмый басуын күргән бригада егетләре барысы бер авыздан аңа өченче разряд бирергә кирәк дигән фикергә килделәр. Шул җәйне Коля үзенә бик матур костюм сатып ала алды, мин дә аңа тары өчен бурычымны түләдем. Бик күп дигәндә ул ике йөз сум булгандыр (хәзерге белән егерме сум!)

Әйе, мин аңа университетны ташлаттырмый калганы өчен күңелемдә рәхмәт хисе саклыйм. Мин аны «Яшьлек яме» повестена да керттем.

Бераз алга сикереп булса да әйтим, Николай Васильевич Ермошкин — хәзер зур галим, геолог, ул Куйбышев өлкәсенең Жигулевск шәһәрендә яши, фәнни-тикшеренү эшләре алып бара. Казаннан узышлый, күптән түгел минем янга сугылып чыкты, вакыты бик тар иде, шулай да без аның белән яшьлегебезне, университет елларын искә алып, бераз сөйләшеп, чүкердәшеп утыра алдык.

Җанда мең төрле кадерле мизгелләр кузгалды...

Университет безнең яшьлек елларыбызга туры килде. Никадәр генә кыенлыклар кичермик, никадәр генә ачлы-туклы яшәмик, без беркайчан да борын салып йөрмәдек, мең төрле хыял, мең төрле ашкынулар белән янып, ялкынланып яшәдек.

Ә хыялый ашкынулар, сагыш һәм моңсулыклар күңелеңә ятышлы берәрсе булганда була бит.

...Университетка керү өчен имтиханнар тапшырып йөргән чагында, минем күземә дулкынланып торган кара чәчле, шәрык кешеләренәрәк охшаш түгәрәк, кара тут йөзле, күперенке алсу иренле бер кыз чагылды. Ул безнең белән бергә имтихан биреп йөргән бер генә кызга да охшамаган иде. Мин аның чәчрәп дулкынланганын да, кайгырып аһ органын да күрмәдем. Имтиханнарын ул тигез генә биреп бара, үзен сабыр-тыныч тота, әмма аның бераз шешмәгрәк кабаклы коңгыртмыяшькелтме күзләрендә, салмак-сабырлык белән бергә, йөрәккә ут сала торган бер көч тә бар иде.

Имтихан тапшырачак аудитория ишеге төбендә күренүгә үк, ул минем күңелемне кузгатты.

Мин, әлбәттә, аңар бу хакта бер генә сүз дә әйтмәдем. Әйтә дә алмый идем. Аның зифа гәүдәсенә ятышып торган көрәнсу-кызыл төстәге путалы күлмәге дә, иңнәренә сибелеп киткән куе кара чәче дә, матур төз аяклары да, үзен искиткеч сабыр һәм тыйнак тотуы да — авылдан килгән тотнаксыз бер малай өчен түгел, шәһәрдә үскән интеллигент кешеләр өчен яратылган кебек иде.

Дөресен әйткәндә, мин аңар нәфесемне сузарга батырчылык та итә алмадым. Аннары ул мине бик әллә ни санга да сукмады шикелле.

Күңелне кымырҗытып, рәхәт кенә авырттырып торган газаплы-татлы тойгы әле һаман миндә яши иде. Мин әлеге кызның — Шәһидә Максудованың Чернышевский урамыннан барганын, зур матур.бер йортның парадныеннан кереп киткәнен ике-өч мәртәбә күреп калдым.

Күңелдә бик азга гына: «Әллә ходаем, ул да мине күзәтеп йөриме?» — дигән ымсыну сыман бер тойгы уянып калды.

Тик тагын бер атнадан, мин аны очраткач, әлеге тойгы, челпәрәмә килеп, җилгә очты.

Мин, карточкага алган ипигә һәм студентлар ашханәсендә ашаган ашка гына риза булмыйча, кибеткә кереп, бер ярты кило прәннек сатып алдым. Беренче прәннекне авыз тутырып чәйнәп кайта идем, әлеге кыз парадныйдан чыгып килә. Чәйнәлеп бетмәгән прәннекне көч-хәл белән йотып җибәрдем дә сүз куштым:

— Нәрсә, Максудова, китапханәгә барасың мәллә?

— Ийе шул, — диде кызый, мөлдерәтеп кенә миңа карап алды. — Университет китапханәсенә барам, әйдә, минем белән барасызмы?

Сөенечемнән: «Барам!» — дип чак кына кычкырып җибәрмәдем.

Киттем мин моңа ияреп. Кердек университет ишегалдындагы китапханәгә.

Максудова анда беренче көннән үк язылган икән инде, миңа язылу тәртибен өйрәтте, һәм без, аның белән икебез, кирәкле китапларны алып, өстәл янына барып утырдык.

Утыру белән ул китабына кадалды. Мин дә бераз вакыт укыган сыман кыланып утырдым. Минем күңелем китапта түгел иде шул. Яннан кызның профиле матур булып күренә: кара тутлы, алсуланыбрак торган битләре, китапка төбәлгән күз карашлары мине яндыра иде. И дә теләп карадым соң мин аның сүз кушуын, ләкин ул китабына багынды да калды. Күтәрелеп тә карамый, сүз дә кушмый. Ахырда мин түзмәдем:

— Нәрсә, Максудова, әллә бик кызык җире туры килдеме? — дидем.

Бик беркатлы, үтә дә беркатлы, «Ата казың күкәй саламы?» дигән сыманрак сорау иде бу. Кызый сорауны колагына да элмәде, сәерсенеп бер күтәрелеп карады да, тагын үз дөньясына чумды.

Авыл гыйбаты булсам да минем үз горурлыгым үзем белән иде, тәмәке тартып керәм әле дигән сылтау белән, мин аның яныннан кузгалдым да бүтән әйләнеп кермәдем.

Ул елны мин дүрт-биш ай китапханәгә бармадым. Аның очравыннан, арттан йөри бит мәгънәсез дип әйтүеннән курыктым. Өченче курска җиткәнче без аның белән аңлаша алмадык.

Һәр елны без Октябрь бәйрәмен, Яңа елны, Беренче майны группабыз белән җыелып, бергәләп бәйрәм итәбез. Шул бәйрәмнәргә дип мин бер ак күлмәгемне саклап тотам, олтаны куба башлаган ботинкамны стипендиянең соңгы тиеннәренә яматтырып алам, ә җанны иң ачыттырганы — бәйрәм саен Максудованың җылы карашын тоймый кайтып китәм.

Без группада җиде малай, биш кыз. Миңа калса, биш кызның бишесе дә бер егеткә — Уфадан килгән, русчаны да, немецчаны да су кебек эчә торган, тик татарчаны гына сакаурак сукалый торган кара бөдрә чәчле, туры борынлы, горур табигатьле Роберт Бикмөхәммәтовка гашыйк иделәр. Ул үзен тотышы белән дә, имтиханнарын гел бишлегә генә биреп, исемле стипендиат дәрәҗәсенә күтәрелүе белән дә безнең группа кызларының күз явын алып тора иде.

Безнең исә группа кызларына үлеп ачуыбыз килә, әмма эчтә янган утны беркайчан да тышка чыгармый идек.

Хәер, Роберт Бикмөхәммәтов безнең бәйрәм мәҗлесләренә бик әллә ни катнашмады да. Я ул әниләре янына Уфага кайтып киткән була, я берәр йомыш табып, Мәскәүгә юл тота. Аның каравы безнең икенче Робертыбыз, фамилиясе белән әйткәндә, Гатауллин мәҗлесләрнең җаны иде. Ул холкы белән Роберт Бикмөхәммәтовның капма-каршысы. Беренчедән, ул, дәрестән арттарак барганга күрә, гел шелтә алып, группа «Яшен»енең берәр санына гел эләгеп тора. Бу аның сәләтсез булуыннан түгел, дәрес хәзерләргә вакыты җитмәгәнлектән. Бу Роберт — аксыл чырайлы, гаять ишле гаиләнең сигезенчеме, тугызынчымы баласы, сөйләсә — теле телгә йокмый, җырлап җибәрсә, гел дә менә авызына карата торган ут егет иде югыйсә. Безнең группаның бәйрәмнәрен әнә шул Роберт Гатауллин белән Сания Сибгатуллинадан башка күз алдына китереп булмый. Алар рәхәтләнеп җырлыйлар, рәхәтләнеп биләр, гадәттә аз сүзле Шәһидә Максудова да, мәҗлес барышында авыл кызы икәнен исенә төшереп, җанланып китә. Шуннан без «Галиябану»ны, «Сарман»ны, «Зөләйха»ны, Гамир Насрыйның «Алтын көз» музыкаль драмасыннан кайсыдыр арияләрне, тагын бик күп, бик күп җырларны җырлап чыгабыз. Фәрит Хатипов — Минзәлә егете — гармун уйный, минем дус Яхъя гармун уйный, ул бии белми, әмма мәҗлес артык җанланып китсә, бөтенебезнең күзен шар итеп, дөньяда булмаган биюләр уйлап чыгара.

Таң атканчы, көн-ай җәелгәнче фатир безнеке!

«Фатир безнеке» дип шуңа әйтәм, я без Шәһидә Максудоваларның, я Розалина Сабироваларның квартирында үткәрәбез бәйрәмне. Шәһидәнең җизнәсе белән апасы — берсе врач, икенчесе инженер кеше, квартирларын безгә ышанып калдырып, үзләре кунакка китеп баралар. Розалиналарда исә тагын да иркенрәк, алар Яңа бистәдә үз йортлары белән яши, анда инде без туйганчы җырлыйбыз, туйганчы биибез, туйганчы күңел ачабыз — өйнең астын өскә китерәбез.

Безнең кызлар — Шәһидә, Сания, Розалина, Резеда, Әлфия — аш-су пешерергә, өстәл әзерләргә, савыт-сабаны юырга, безгә квартирала-

рын ышанып калдырган хуҗаларның өен ихтирам итүдә әйтеп бетергесез намуслы, булдыклы, «кулларыннан гөл тама торган» кызлар иде.

Без — авыл гыйбатлары, егетләрне әйтәм, аларны «подводить итмәскә», аларга тиң булырга тырыша торган идек.

Яшьлек — кеше гомеренең иң матур, иң кадерле чагы. Һәркем яшьлеген узып киткәч сагына. Күзәтеп йөрим: бүгенге яшьләр дә үзләренчә күңел ачалар, әмма колаклар тонарлык итеп музыка акыртуны, үзләре мәҗлестән таралгач, ризык тәлинкәләренә, ашалып бетмәгән бәрәңге яки ботка өстенә тәмәке төпчекләре батырып калдырганны күреп, болар да бәйрәм итәбез дип йөриләр микәнни, дип әрнеп уйлаганым бар.

Барлык халыкларда да чисталык-пөхтәлек иң матур гадәт санала, традиция булып, буыннан буынга күчеп килә, әнә шул традицияләрне һәрбер гаилә, һәрбер ата-ана үзенең баласына, баласының баласына иң изге бер нәрсә итеп өйрәтеп калдырса, әйбәт булыр иде.

Олыларны ихтирам итү кече яшьтән үк, ризыкны ихтирам итүдән үк башлана бит ул...

## Без ачкан дөньялар

Без ачкан дөнья берничә. Шуларның иң зурысы, әлбәттә, бөтен дәверләрнең әдәбият хәзинәсе. Татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укучылар, ягъни без, ихтимал, өстебезгә иң зур йөк алучылар булганбыздыр. Без факультеттагы рус филологлары узганны тулысынча узабыз: рус телен, рус әдәбиятын безгә иң борынгы заманнардан башлап укыталар, борынгы славян телен укыталар, рус халык иҗатын, тел белемен, әдәбият теориясен укыталар, немец телен укыталар, марксизм-ленинизм нигезләрен, диалектик һәм тарихи материализмны, политэкономия, философия тарихын, СССР тарихын, логика, педагогика, психология, чит илләр әдәбиятын, СССР халыклары әдәбиятын укыталар, бөтен факультет белән бергә, без физкультура дәресләренә, педагогик практикага йөрибез. Моңардан тыш, рус филологларыннан аермалы буларак, без өстәмә рәвештә, борынгы һәм хәзерге татар телен, аның диалектологиясен, фольклорын, гарәп телен өйрәнәбез, Шәриф Камал, Һади Такташ иҗатлары буенча семинарларда катнашабыз, тел һәм әдәбият укыту методикасы кирә безгә, татар әдәбиятының борынгысы һәм бүгенгесе, татар әдәбияты буенча махсус курслар узу, курсовой эшләр язу йөкләнә. Кыскасы — безнең өскә төшкән нагрузка йөз илле процентка җитә.

Авыл мәктәбендә укып йөргән чакта вузларда шулхәтле дә күп укыталардыр дип мин башыма да китерми идем, һәм менә хәзер дә шул хәтле үк белем төяүнең бигүк дөрес булуына ышанып җитә алмыйм. Бәлки шуны бездән алданрак аңлагангадыр, Роберт Бикмөхәммәтов лекцияләргә сайлап кына йөри, китапханәдән чыкмый ята иде; әмма ышанып, бирелеп укучылар да җитәрлек. Марат Сәгыйтов белән Резеда Вәлиева имтиханнарга килеп җиткәнче дәреслекләрне өчәр мәртәбә укып чыгарга өлгерәләр, хәтта барлык курсын яттан белә башлыйлар, Роберт Гатауллин исә билетта чыкканны сөйләми, Нух заманнарыннан башлап үзе белгәнне сөйли, укытучы аны, ул түгел дип, күчерә тора, Гатауллин үзе белгәнне сөйли тора, шулай итеп, билет соравына килеп җиткәнче укытучы аның пулеметтан аткандай сүзен тыңлап арый, билеттагы сорауны оныта һәм Роберт Гатауллин — ак чырайлы көләч егетебез, дүртлене эләктереп, көмеш акчадай ялтырап килеп чыга; Сания Сибгатуллина имтихан бүлмәләреннән, тере тиен тоткандай, зачеткасын баш түбәсенә югары күтәреп шаулап чыга, менә ул, ичмасам, сөенечне җиренә җиткерә белә, көлсә, бөтен кешене үз артыннан ияртерлек итеп көлә; Шаһидә Максудова артыгын көенми дә, артыгын сө-

енми дә, икенче курстан башлап тоташ бишлегә укый, Тукай стипендиясе ала; Розалина Сабирова дәресләрен үз вакытында әзерләп бетерә алмаган ташбашларның, ягъни безнең, хәлебезне белешеп йөри; соңгы кеше булып диярлек, ах-ух килеп, Васил Һадиев килә, озын буйлы, күзлекле, керәчтәй ак тешле, матур гына итеп, тотлыгыбрак сөйләгән бу егетебезгә чаңгы җене һәм бию җене кагылган, ул университеттагы үзешчән сәнгатьнең һәм чаңгы кроссларының үзәгендә дә, уку ягыннан ул таманча гына укып килә, алга чыктым дип тә, арткарак калдым дип тә кайгырмый — аның тоташ үз дөньясы. Фәрит Хатиповның имтиханнарны ничек тапшырганы никтер минем исемдә калмаган, ул төпле нык холкы белән авыл агайларын хәтерләтә, шуңа күрә кызлар аңа, шаяртып, колхоз председателе дип кушамат та таккан иде. Фәритнең аңа да исе китми, колхоз председателе дигәнгә, күзләре кысылып беткәнче кинәнеп бер көлә иде — кызлар аны үрти дә алмый калалар иде. Әлфия Зәйнуллина — бодай капчыгы кебек нык, саллы кызыбыз фән йөген бераз авырданрак тарта, кызлар барысы аңа булышып, аның өчен кайгырышып йөриләр, аның «тиешле» билге алганын белгәч, бергәләп сөенәләр.

Безнең группада имтиханнарга, белемгә мөнәсәбәттә үзенчәлекле тагын ике кеше бар. Берсе аның — Мәхмүт Хөсәен. Безнең группада ул — бердәнбер шагыйрь. Әлбәттә, шигырь язгалап, иптәшләренә дә укыштырып йөрүчеләр бар, ләкин ул булачак шагыйрь һәм язучыларны без әле санга сукмыйбыз. Мәхмүт — хәрби гимнастеркасын каеш белән буган фронтовик, җиңел хром итектән, иңенә планшет асып, очынып университетка килеп керә, аның инде беренче китабы басылып чыкты, радио атна саен Мәхмүт Хөсәен төзегән әдәби-музыкаль монтаж тапшыра, без аны шаяртып: «әдәби-музыкаль шантаж» дип йөртәбез. Мәхмүт безнең группаның старостасы, оялу-тартынуны белми торган, үзенә һәм группага кирәкне умырып ала белә торган кыю егет. Кирәксә ул безнең имтиханнарның урынын алыштыра, деканат аша бирәр имтиханның тапшыру срогын озайта, университет әдәби түгәрәгенә шагыйрьләрне, артистларны күпме тели, шул чаклы китертә, шул эшләр белән йөри торгач, имтиханнарга әзерләнергә өлгерми дә кала, әмма аз гына белеме белән дә имтиханнарын кыенсынмый-нитми тапшырып чыга, ник дисәң — телгә бик оста, җавап бирергә бик кыю, белемне азмаз җыюның алга таба аңа файдасы булырмы-юкмы, ул хакта уйламый Мәхмүт, аңа бүгенгесе кадерле, уза торганы кыйммәт. Мәхмүт тә материаль яктан беренче елларны бик әллә кем түгел иде, аңа тол әнисен, сеңлесен һәм үзен карап барырга кирәк, стипендия акчасы да, шигырьләрдән килгән акчасы да җитми, ул үзен саклауның башка хәйләсен дә уйлап тапкан, көн саен балык мае эчә икән. Көннәрдән бер көнне без аңа: «Мәхмүт, синнән балык исе килә, әллә син балыкчылар артиленә язылдыңмы?» — дигәч ул, үз гомерендә беренче мәртәбә уңайсызланып, эшнең нидә икәнен әйтеп бирергә мәҗбүр булган иде.

Имтиханнарны тапшыруда, семинар занятиеләренә әзерләнүдә иң үзенчәлекле кешеләр — Яхъя белән мин. Әгәр безгә вуз дәреслеген бер мәртәбә укып чыгу бәхете эләксә, имтиханнарны ике дә уйламый бишлегә бирәбез, яртысын гына укып чыгарга туры килсә, дүртледән артмый, чирege генә эләгеп калса, без имтихан тапшырасы ишек төбендә шатыр-шотыр конспект актарабыз, китап укыйбыз, ихтимал, без иң күп белемне әнә шул имтихан бирәсе ишек төбендә алганбыздыр.

Күңелгә сызылып калган бер хакыйкатьне әйтергә тиешмен: татар мәктәбен авылда бетергән бала гуманитар вузга килгән чакта рус әдәбиятын һәм дөнья әдәбиятын бөтенләй дә диярлек укымаган була. Чит ил әдәбиятларыннан без укыганнар нәрсә? «Серле утрау» белән «Сиксән мең километр су астында». Болар — татарча тәрҗемә ителеп чыккан китаплар. Ә бит әле дөньяда Бальзак бар икән, Джек Лондон бар икән,

Стендаль һәм Дюмалар, Тагорлар һәм Шекспирлар бар икән! Аларның барысын бер-ике семестрда ничек укып бетермәк кирәк. Менә шуңа күрә дә мин әле бүген дә, балаларыбыз хәтта авыллардан ук русчаны әйбәт белеп килгән заманда да, чит ил һәм рус әдәбияты классикларын татарчага тәрҗемә итеп бастырып торырга һәм бу эшне эзлекле рәвештә эшләп барырга кирәк дип саныйм.

Унтугызынчы гасыр рус әдәбиятын узган чакта, лекцияләрдә белем конспект рәвешендә генә бирелә, оригинал белән танышу лекциядән соң эшләнәсе эш итеп үзебезгә калдырыла иде. Мин, мәсәлән, бер семестрга бирелгән дүрт ай эчендә унтугызынчы йөз рус әдәбиятыннан бер Толстой мирасын гына җентекләп укып чыга алдым. Әнә шул Толстойны укып чыгу гына да минем күземне ачып, әдәби офыкларымны әллә кайларга тикле киңәйтеп җибәрде. Ә башка классикларны, әйтик Достоевскийны, Гогольне, Чеховны, Горькийны һәм дистәләгән башка бөек кешеләрне мин университеттан соң, мең тырышлык белән генә җиңеп чыктым. Бәлки шуңа күрәдер, елына ике-өч мәртәбә мин төшемдә университет бетерә алмаганымны күреп, куркып уянам да бик озак вакыт тынычлана алмый ятам...

Университетта без ачкан икенче дөнья — үз ана телебездә иҗат ителгән әдәбият хәзинәсе белән танышу һәм үзебезнең дә иҗат эшенә тартылуыбыз булды.

Тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге беренче көннәреннән үк (аны 1944 елны, авыр сугыш елында ачалар) әдәби хезмәткә омтылучыларга киң юл ачты. Фронттан кайткан егетләр Ибраһим Нуруллин, Рашад Гайнанов без укырга кергән чакта ук инде «Әдәби сүз» исемле стена газетасы чыгарып килә иде. Озаклamый ул эшкә мине дә тарттылар. Стена газетасының рәсемнәрен ясау белән генә чикләнмәдем мин, мәкаләләр, шигырьләр, әдәби парчалар язу белән дә мавыгып киттем. Университет каршысында татар әдәбияты түгәрәге булу да моңа нык кына ярдәм итте булса кирәк.

Стена газетасында безнең «каләм тибрәтүләр» күренгәләп барса да, ташка баскан әсәрләребезне күрү бәхете безгә бик озак эләкмәде. Мин моны үземнең булдыксызлыгымнан гына дип санамыйм, газета-журналларда эшләгән, яшь каләмнәрне үстерүдә җаваплы булган кешеләрнең үз эшләренә бигүк җаваплы карамауларыннан да дип беләм. Минем үземне, мәсәлән, чын мәгънәсендә рухландыручы, иҗатка тартучы кеше бик соң табылды.

Беренче курста укыган чагында без, факультет комсомолларыннан иллеләп егет-кыз, беренче семестр узгач, кышкы каникул вакытында Кокушкинога, Ленинның беренче мәртәбә сөргендә булган җиренә, чаңгы походына бардык. Бу миңа гаять көчле тәэсир итте. Походтан кайтуга, төн буе утырып, ун битле репортаж яздым. Күңелемдә йөргән барлык изге тойгыны, барлык сәләтемне салдым мин аңа.

Икенче көнне шул репортажны «Яшь сталинчы» газетасына, әдәбият бүлегенә алып бардым.

Шагыйрь Әхмәт абый Юныс, күзлеген бер салып, бер киеп, репортажны бик озаклап укыды, аннары миңа бер сәгать буе әдәби әсәрнең ничек язылырга тиешлеге хакында сөйләде. Никадәр бирелеп тыңласам да, мин ул әйткәннәрне аңламадым. Күңелгә сеңеп калганы «вчюже» дигән сүз генә булды. Мин аның яныннан язу-сызу белән бүтән шөгыльләнмәскә дигән нәтиҗәгә килеп чыктым. Чыннан да, икенче курсны бетергәнче бер шигырь кисәге дә, бер генә репортаж да, хикәя-мазар да язмадым. Гайрәт чигү шул хәтле дә көчле булган, күрәсең.

Икенче курсны бетергәч, безне Юдино районындагы бер колхозга буа төзелешенә җибәрделәр. Без барлык группабыз белән бардык анда. Сайгак җәйгән юллардан йөгерә-йөгерә, тачка белән балчык ташу, шаугөр килеп, күмәк табында ашау, күл суларында аяк тибә-тибә йөзгән

кызларга сокланып караулар күңелне кабат кузгатты, группаны тагын да ныграк якынайтты һәм әнә шул хәл минем күңелдә посып яткан илһам чаткысын янә дә кабызып җибәрде.

Буада эшләгән көннәр хакында мин янә бер очерк яздым. Һәм монысының басылып чыгачагына инде һич кенә дә икеләнмәдем.

Тагын киттем Әхмәт абый янына. Ул күзлеген бер салып, бер киеп, минем очеркны бик озак укыды. Аннары, әллә минем теге юлы килгәнемне онытып, әллә белеп, тагын бер сәгать чамасы әдәбиятның нәрсә икәнен аңлатты. Ул юлы да — ни хикмәттер — минем хәтеремдә аның «вчюже» дигән сүзе генә торып калды.

Шуннан соң мин үз гомеремдә бер генә юл да язу язмаска дип ант иттем. Мин үземнең әдәби яктан сәләтсез икәнемә бөтенләй ышандым. Шулай булгач, нигә мин үземне алдап йөрим, нигә юк эш белән шөгыльләним?..

Казанда, тулай торакның буш бүлмәсендә мин төне буе йоклый алмый яттым.

Әхмәт абыйга ышанмаска хакым юк иде минем. Ул минем өчен шагыйрь, талантлы шагыйрь иде. Өстәвенә шул елларны университетның әдәбият түгәрәгендә без аның «Уңыш» исемле бик матур яңа поэмасын тыңладык. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә инде азау ярган тәнкыйтьчеләр дә аның поэмасының уңышлы икәнен, татар поэзиясенә яңа бер өлеш булып керүен язып чыктылар. Үзе фронтовик, үзе стажлы шагыйрь, үзе яшьләр газетасында бүлек мөдире булган кешегә ничек ышанмыйсың! Ләкин минем эчне өзгәне — аның мин аңларлык итеп сөйләмәве булды.

Мин Арчага кайтып, буяу эшенә, материаль хәлемне рәтләүгә керештем. Авыр физик эш, Арчадагы яңа дуслар минем әлерәк кенә булган чамадан тыш зур уңышсызлыкка очравымны оныттырды, күңелсез уйларымны таратып ташлады...

## Фәнгә бер адым

Татар телен безгә Рәбига Афзаловна Хәкимова укыта иде. Кыска итеп кискән шомырт кара чәчле, кысып куйган юка иренле, кырыс чырайлы бу апа безнең күңелләрдә усал, нык холкы белән тирән уелып калды. Ул факультетта Татар теле һәм әдәбияты кафедрасының җитәкчесе дә иде әле. Татар теленең байлыкларын биш бармагы кебек белгән бу житди (дәрәҗәсе буенча — фәннәр кандидаты, галим) безгә беренче көннәрдә үк: «Тел галиме булырга теләсәгез дә, әдәбият галиме булырга теләсәгез дә, беренче чиратта телне ныгытып өйрәнегез! Телне яхшы белсәгез, калганына ирешеп була», — диде. Әнә шуны истә тотып, мин яңа уку елы башыннан гыйльми түгәрәккә язылдым. Телгә фанатик дәрәҗәдә гашыйк кеше, миннән ике курс алдарак укыган Фазыл Фасеев миңа «Татар телендә ымлыклар» дигән тема бирде һәм мин, ымлыкларны эзләп, татар телендәге әдәби әсәрләрне һәм Ашмаринның чуваш теле сүзлеген бөтенләе белән актарып чыктым. Әнә шул чагында тел гыйлеменең язучылык эшенә караганда да мавыктыргычрак булуын күреп, таң калдым. Бу минем тагы да бер мәртәбә университетта яңа дөнья ачуым иде.

Ымлыклар белән мин нәкъ ярты ел баш күтәрми утырдым. Әдәби әсәрләрдән меңләгән ымлык җыйдым, картотека белән эш итәргә өйрәндем.

Гыйльми түгәрәк утырышында да, Рәбига Афзаловна тарафыннан да минем беренче фәнни эшем, студентлык эше әйбәт бәя алды. Аны шәһәр күләмендәге студент эшләре конкурсына тәкъдим иттеләр.

Мин шәһәр күләмендәге конкурсның йомгакларын көтеп, дулкынланып яши башладым. Әмма шул көннәрдә Рәбига Афзаловна белән безне кабат очраштырган зур бер вакыйга булып алды.

Без кыш уртасында имтиханнарга әзерләнеп йөри идек. Алдан сөйләшенгән буенча, татар теле һәм әдәбияты кафедрасына җыелдык. Өйрәнгәнне, күңелдә калдырганны тикшерер өчен, билетлар буенча берберебездән сорашып чыгабыз.

Хәзерләнү унтугызынчы гасыр рус әдәбиятыннан иде. Без, егетләр, Гогольнең «Үле җаннар»ы хакында сүз алып барабыз. Чичиков белән Маниловның бүлмәгә узу картинасын күз алдына китерергә тырышабыз. Алар бит, бер-берсен алдан керергә кыстый-кыстый, берни дә барып чыкмагач, икәүләшеп, ишектән берьюлы кысылышып кергәннәр.

Без Чичиков белән Маниловның ишектән бергә кысылышып керүләрен практик рәвештә, сәхнәдәге кебек итеп, сынап карамакчы булдык. Роберт Гатауллин белән мин кабинет ишегеннән (ике якка ачыла торган ишекнең тик берәве генә ачык иде), кысылышып керә башладык. Кермәкче булабыз, сыймыйбыз. Ярдәмгә килеп җиткән Яхъя Халитов белән Фәрит Хатипов аяк терәп безне этәләр. Этә торгач, ничектер ишек беркетелгән стена селкенеп китте дә, стена буендагы шкаф дөберләп идәнгә ауды.

Куркуыбызны күрсәң!!!

Шкаф ауган тавыш, күк күкрәгән төсле булып, бөтен университетка таралды. Шуның өстәвенә шкафның пыяласы чәлпәрәмә килеп идәнгә чәчелде, пыяла белән буталган китаплар да сибелде идәнгә.

Башта, дәшми-нитми генә, китапларны аралап алдык, аннары пыяла ватыгын чиләккә җыеп, чүп чокырына чыгарып аудардык. Шунда кызларыбызның безгә шелтә белдермәүләре, кабинетны тизрәк тәртипкә китерергә тырышулары — аларга булган ихтирамыбызны тагын да арттырды.

Кабинетны тәртипкә китерүен китердек, ләкин бит шкаф пыяласыз, җитмәсә — китаплар да Рәбига Афзаловна тезеп куйган тәртиптә түгелдер әле. Нишләргә? Уйлаша торгач, шундый бер фикергә килдек: мин, буяучы кеше, күптәнге танышым маляр дядя Коляны күрәм, аңардан берәр пыялачыны эзләп табуын, иртәгә безгә, университетка җибәрүен үтенәм. Ә пыяла хакын, күпмегә төшсә дә, бөтен группабыз белән бергәләп түлибез.

Әйбәт кеше иде дядя Коля, табып бирде безгә пыялачы. Әйбәт иде безнең группа, бердәм иде — пыяла бәясен тигез түләдек.

Рәбига апа килсә — шкафта ниндидер үзгәреш бар. Хәтере аның шул хәтле дә әйбәт иде, китапларның тәртибе бозылганын күреп ала да старостабыз Мәхмүт Хөсәенне чакыра: ни булган бу шкафка?

Мәхмүт ул чагында безнең белән түгел иде, ни булганны белми.

Шуннан соң Рәбига Афзаловна бөтен группаны чакырта. Без нишли алабыз — булган хәлне сөйләп бирүдән башка чара калмады. Төп гаепне мин үз өстемә алдым. Мәхмүт Хөсәеннән кала группада өлкәнрәк кеше мин идем.

Рәбига Афзаловна, ифрат дәрәҗәдә кырыс, караңгы чырайлы кеше, үз гомерендә беренче мәртәбә ирен чите белән генә елмайды да папирос алып кабызды. (Хатын-кызлардан тәмәке тартучыны беренче күрүем.)

Аның әнә шул «йомшаклыгына» бәлки, минем «Татар телендә ымлыклар» дигән хезмәтне уңышлы язуым да сәбәп булгандыр. Ул елны минем эшне комсомол өлкә комитетының Почет грамотасы белән бүләкләделәр

## Рәссамнар

Рәссамнар без икәү: Яхъя белән мин. Без, университетта укыган елларны, биш ел буена, тарих-филология факультетының ун-унике метр озынлыгындагы стенгазетасын рәсемнәр белән бизәп килдек.

Бу урында минем сабакташ дусым, иптәшем һәм соңыннан каләмдәшем дә булып киткән Яхъя Халитов турында күбрәк язасым, аның әдәби портретын укучы күз алдына күбрәк бастырасым килә.

Мин аны үземне белә башлаганнан бирле беләмдер кебек. Без аның белән Казанка елгасының бәләкәй генә бер чишмәдән бәреп торган җирендә, Түбән Пошалым, Тылангыр, «Үрнәк» совхозы янында таныштык. Арча педагогия училищесы ул чагында әле һаман «Үрнәк» совхозында, хәзерге механизаторлар әзерли торган мәктәп бинасында яши, сугыштан соң Арчага күчеп кайтмаган иде әле. Тукайның әкият-поэмаларында язган карагайлы урманнарны, чылтырап аккан саф сулы инешләрне без шунда күрдек. Без — икебез дә авыл малайлары — рәсем белән мавыгып, һәр матурлыкка авыз ачып, таң калып йөргән заманнар иде ул. Безне берәү дә өйрәтмәде рәсемгә, берәү дә безгә аның теориясен дә, практикасын да аңлатып-күрсәтеп бирмәде, безгә атлар, казлар, йортлар, кешеләр ошый иде, безнең аларны карандаш белән дә, акварель буяу белән дә гел ясыйсыбыз килеп тора, рәсем безнең күңелләрне сафландырган, ашкынулы иткән бер хоббиебыз иде.

Тормышта бер генә нәрсә дә сәбәпсез булмый, аннан да бигрәк, нәтиҗәсез калмый. Рәссамлыкның махсус мәктәпләрендә укымасак та, художество институтларын тәмамлый алмау безне рәсем сәнгатенең югары баскычына алып менмәсә дә, әмма шул һәвәскәрлегебез безне китаплар дөньясына, әдәбият дөньясына алып килде. Ул хакта мин соңыннанрак сөйләрмен, хәзергә стенгазетаның рәссамнары булуыбызны сөйлим әле.

Тарих-филология факультетының унар-уникешәр метрлы стена газетасы безнең катнаштан башка чыкмый иде.

Кеше типларын Яхъядан остарак каләм очына эләктергән берәүне дә белмим мин. Гармун уйнап, кичке биләмнән кайтып килгән авыл малайлары, лекциядә йоклап киткән студентлар, мода чире йоккан чибәр туташлар, берәр фәнен икелегә тапшырып, ташбакага атланып барган ялкау егетләр аның карандашыннан, борчак коелгандай, коелып кына торалар, стенгазетаның баш редакторы, доцент Григорий Наумович Вульфсон, Яхъяның рәсем ясаганын карар өчен, кичләрен махсус килә, безнең ач студентлар икәнне белеп, сохаримы, печеньемы кыстырып килә, тамак ялгап алгач, без рәсемне тагын да бирелебрәк ясыйбыз. Григорий Наумович Яхъяның каләм очыннан төшкән рәсемендә берәр танышын — укытучыны яки студентны танып, аның мәзәк позасыннан эчләре катып көлә, тыела алмыйча, ишекле-түрле көлеп йөри торган иде.

...Менә хәзер, ул көннәргә утыз елдан артык вакыт узып киткән, Яхъя Халитов республикабызның күренекле тәрҗемәчесе, СССР Язучылар союзы члены, үтә дә җитди редактор булып өлгергәч, мин ул көннәрнең хикмәтләрен исемә төшереп, уйланып утырам. Михаил Шолоховның «Тын Дон» эпопеясын тәрҗемә иткәндә, андагы искиткеч юморист типларны татар теле ярдәмендә яңа баштан дөньяга тудырган чакта, Яхъя Халитовка рәсем сәнгате аша чынбарлыктагы көлкеле хәлләрне тотып алу, аларның позаларын, буй-сыннарын, елмаю яки ачулану рәвешләрен көлкеле итеп ясау аңарда күзәтүчәнлек сыйфатларын, ягъни язучы яки тәрҗемәче өчен бик тә кирәкле сыйфатларны үзендә тәрбияләргә, үстерергә, камилләштерергә ярдәм иткәндер дип уйлыйм.

Табигать сәләтлелекне Яхъядан бер дә кызганмаган, өч-дүрт кешегә җитәрлек итеп биргән. Ул — менә дигән гармунчы, беренче кул шахматчы, бик оста бәхәсче, өстәвенә, педучилищеда чакта, математикадан да иң алда баручы иде. Иҗат эшендәге кешегә бу сыйфатларның һәммәсе кирәк. Логика, эзлекле рәвештә уйлый белү — зур-зур романнарны, повестьларны редакцияләү өчен кирәк. Музыкадан сәләтле булу табигать авазларын тою, стильне тою, лирик-интим хисләрне ана телебездә барлык нечкәлеге-нәфислеге белән тудыру өчен кирәк. Яхъя сабакташымның тагын бер әйбәт сыйфатын әйтеп китәсем килә. Ул университетта чакта да, университетны тәмамлаганнан соң да күңеле кушмаган бер генә эшне дә эшләмәде. Тумыштан ук салынган принципларына ул гомере буе турылыклы булды.

Мин аны үзем белән бер елны Арчага, педучилище бинасын буярга алып кайттым. Без Яхъяларның кодагыйларында яшәдек. Җәй эссе килгән, яңгырсыз килгән ел иде ул, безнең карамакка хуш исле яңа печән өелгән печәнлек бирелде.

Буяу эшеннән без кичке тугызларда гына кайтабыз. Арылган. Тамак ялгап алу белән, суга чумган төсле, йокыга чумабыз. Сәгать иртәнге икедә, татлы таң йокысында, кодагыйларның әтәче безне кычкырып уята. Мин торып, киенеп, юынып, тамак ялгап, эшкә китеп барам, Яхъя әтәчне тибеп төшерә дә йоклап кала. Бу очракта да ул үз принцибына турылыклы: йокысы туймыйча тормый. Кодагыйлары аны: «Мастерың китте бит инде, ә син, подмастерье, нишләп йоклап ятасың?» — дип оялтмакчы булганнар, ә ул ике дә уйлап тормастан: «Сатыгыз әле шул әтәчне, суеп ашыйк әле шуны, йокларга ирек бирми бит», — дип ирен чите белән генә елмаеп куйган.

Әмма соңрак килсә дә, Яхъя көнлек нормасын үти, бер тотынса, ике-өч сәгать рәттән, тәмәке дә тартмый эшли иде.

Аның үзе белмәгән эшкә бик тиз төшенә белүе дә мине сокландыра иде. Ике-өч көн эчендә ул гомер буе буяу эшендә эшләгән маляр кебек итеп пумала тотарга өйрәнде.

Ул елны безгә штукатур эше белән дә шөгыльләнергә туры килде. Минем үземнең дә, стена буяганда кирәк булган, вак-төяк җимерекне ямаудан башка штукатур эше эшләгәнем юк иде. Директорга эшкә ялланган чакта, штукатур эшен белмибез дип әйтмәдек. Белмәү безне шактый ук уңайсыз хәлгә дә китереп куйды.

Беренче көнне үк ике-өч квадрат метр зурлыктагы штукатуры коелган түшәм туры килде. Ун чиләк керешле агач ящикка алебастр белән бергә комны издек тә тәмәке тартырга утырдык. Тәмәке тартып торгач ,карасак, алебастр чыйраган, измә катылана төшкәч, ящик эченә ялан аяк кереп, таптап йомшарта башладык. Тапталган алебастрҗилеме бетә икән, аны чын штукатурчылар ярты чиләк кенә ясыйлар да шундук, тын да алмыйча, түшәмгә ыргытып та бегеләләр икән, ә безнеке, кабат таптаганы, түшәмгә ябышмый җанга тиеп бетте. Ничек кирәк алай ябыштырдык та, өйгә кайтып киттек. Иртән килсәк, бер ящик алебастр бөтенләе белән идәндә ята.

Гөнаһ шомлыгы — шул мәлне директор Табаров килеп кермәсенме!

— Нәрсә бу, егетләр?! — диде ул, әле идәндә яткан алебастрга, әле безгә карап.

— Кичә кичен, без киткәч, морҗа башын сүткәннәр, кирпечне түшәм өстенә ыргытып торганнар, кибеп җитмәгән измә коелып төшкән, — дидем мин, күземне дә йоммыйча.

Чыннан да, кичә анда морҗа башын сүттеләр сүтүен, ләкин алебастр аңардан коелмаган иде.

— Я, нишләтәбез инде моны, әрәм бит? — диде директор.

— Бирегез бер капчык цемент, эшкә җигәбез аны, — дидем.

Бер сәгатьтән безгә цемент китерделәр. Идәндә яткан алебастрны киредән ящикка салып, цементны мул гына өстәп, яңабаштан изеп, түшәмгә аткан идек, бер генә бөртеге дә коелмады. Кая коелу! Икенче елны нәкъ шул турыга моржа башы чыгарырга кирәк булгач, түшәмдәге без ябыштырган штукатурны кувалда белән суга-суга көчкә кубарып алганнар. Ул хакта завхоз безгә көлә-көлә сөйләде.

Түшәмнән коелган алебастр безгә сабак булды. Штукатур эшендә без, измәне болгату белән, — кая ул тәмәке тартып, җәелеп утыру! — сәгате-минуты белән атып бетерә торган булдык. Яхъя Халитов бу эштә шул хәтле дә остарып китте, бер көнне моржа башы янындагы почмакка, ярты метр калынлыктагы арага, алебастр сылады, егерме минут эчендә сылап бетерде, ник кенә бер коелып карасын!

Тормыш безнең эшебезгә әнә шулай үз төзәтмәләрен кертә торды.

## Илһамлы яз

Тора-бара, әкрен-әкрен, егет-кызларыбызның үзара мөнәсәбәтләре ачыклана башлады. Иң башлап Ибраһим Нуруллин белән Розалина Сабирова бер-берсен таптылар. Ибраһим — рәхмәт яугыры! — безнең группада ике ел рәттән агитатор булып йөргән иде, юкка йөрмәгән икән. Бәйрәмнәрдә гел безнең белән бергә булуы да юкка түгел икән. Озакламый алар өйләнешеп тә куйдылар. Мәхмүт Хөсәен Казанның педагогия институтыннан Дания исемле бер чибәрне әләктереп алып кайтты. Озакламый аларның кызлары туды һәм без аңа, барыбыз бергә җыйнаулашып, Йолдыз дип исем куштык. Рус халык җырында: «А потом как по маслу пойдет» дигән хикмәтле сүз бар. Мәхмүттән соң Яхъя Халитов белән Сания Сибгатуллинаның өйләнешергә сүз куешканы билгеле булды.

Безнең озын толымлы, алсу-ак битле Резедабызга Төзүчеләр институтыннан Фәршад исемле бер егет иярәште. Озын буйлы, кызлар кебек чибәр һәм оялчан ул егет безнең мәҗлесләрдә дә катнаша, әдәби кичәләрне дә калдырмый иде. Ләйләсенә гашыйк булган Мәҗнүн кебек, ул мәгъшукасыннан күзен дә алмый иде.

Мине озак вакытлар санга сукмый йөргән Шәһидә Максудованың да көннәрдән бер көнне күңел гөле бөреләрен ачты. Ул хәл өченче курсны тәмамлагандарак булды шикелле. Май бәйрәменә атап үткәрелгән бәйрәмебездә Шәһидә Фатих Кәримнең «Кемгә сөйлим серләремне?» дигән шигырен сөйләде. Шактый ук каушап, дулкынланып сөйләде ул аны. Ә без фәкыйрегез:

> Кемгә сөйлим серләремне,
> Йөрәгем ялкын кебек,
> Ялкынланган йөрәгемә
> Бераү бик якын кебек,

дигән сүзләрне үз исәбенә алып куймасынмы!

Кичен мәҗлестән таралгач, тулай торакның аулаграк бер почмагында, тәрәзә буена сөялеп, чын ахмак хәленә калып каушап, Гариф дигән егетебез аның кайчандыр Шәһидә дигән кызга муеннан гашыйк булганын әйтеп салды да, тирән итеп, өстеннән тау төшкән кебек итеп сулыш алды.

Әнә шуннан башланды аларның бер-берсен күргәч каушаулары, семинарларда сөйләгән чакта, бер-берсе өчен ут йотып утырулары.

Күңелдәге татлы-газаплы тойгылар әдәбият җенен тагын кузгатып чыгарды. Гариф дигән тәртипсезрәк, дуамалрак егетебез басынкырак йөри, күзләрендә сизелер-сизелмәс ут көйри иде. Әнә шул иләс-миләс

йөргән көннәрендә ул «Галләм сорау бирә» дигән хикәя язып ташлады. Аны хәтта «Совет әдәбияты» дигән журнал редакциясенә хәтле алып барырга җөрьәт итте, әмма журналның әдәби хезмәткәре Әнәс ага Камалдан үтергеч җавап алып кайтты.

— Монда берни дә юк, өстәвенә Сталинны идол итеп чыгаргансың, — диде аңа әдәби хезмәткәр.

Гариф дигән егетебез, инәлеп:

— Нүжәли берни дә юк, Әнәс абый? — дип сорады.

— Телең бар, әлбәттә, ничә ел буе университетта укып, телең дә булмаса, карга күтәреп китәр иде сине, — диде әдәби хезмәткәр һәм, тәмәке төтененнән саргаеп беткән ике бөртек тешен күрсәтеп, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

Гариф дигән егетебез моңа рәнҗеде рәнҗүен, әмма күңел тулы илһам булганда, татлы-газаплы хисләрдән бөтен дөньяң чыңлап торганда, бер хикәяне юкка чыгару малмыни ул!

Шуннан соң озак та тормый, Казанга Уфаның яшь шагыйрьләре Гыйлемдар Рамазанов, Шәриф Биккол, Локман Хәким килеп төштеләр. Алар университетта, зур аудитория алдында чыгыш ясадылар. Кичен без торган йортка аларның берсе кунакка килде. Без торган дигәнен ачыклап узыйм: без ул чакта Чернышевский урамының уртасындагы атаклы бер йортта, элекке Гажур (газета-журналлар) йортында Советлар Союзы Герое Павел Гурьяновларда Яхъя Халитов, Мәхмүт Хөсәен һәм мин яши идек. Мәхмүт иртә-кичен, койкага атланып утырып, «Павлик Морозов» поэмасын яза. Яхъя белән мин аны көн саен юкка чыгарып бара идек. Нәкъ менә шушы квартирга кунак булып Шәриф Биккол килде. Тумбочка өстендә мин кайтарып аткан «Галләм сорау бирә» хикәясе ята иде. Шәрәф Биккол аны алды да, әллә ни арада укып та чыкты.

— Кем хикәясе бу? — диде.

Ул чакларда әле мин кульязмаларым өстенә исемемне куярга ояла идем.

— Минеке, — дидем уңайсызланып кына.

— Нишләп бастырмыйсың? — диде кунагыбыз.

— Басмыйлар бит.

— Юк, моны бастырырга кирәк. Хикәя бу. Тик беләсезме, кустым[1] моның соравын хәйләкәррәк итеп бирергә кирәк. «Нишләп безнең колхоз артка кала?» — дип сорый Галләм. Хикәядә колхоз чыннан да артта. Ә ул артта булмасын, алда булсын, шул алдынгы колхозның артка калачагын алдан күреп, житәкчесенең тиеш түгел эш эшләвен тоеп әйтсен Галләм. Менә ул чагында барып чыга. Сизденме?

— Сиздем, — дидем мин, шатланганны артык сиздермичә, ә күңелдә әллә нинди аллы-гөлле төсләре белән салават күпере кабынып китте.

Бер көн утырып хикәяне төзәттем дә «Үсү юлы» дигән альманахның редакторы, язучылар союзының әдәби консультанты Газиз абый Иделле янына йөгердем.

Тәбәнәк буйлы, маңгай турысында чәче коелган, ирен кырыена сүнгән папирос ябыштырып куйган, үтә дә тыныч, тик күзләре генә җемелдәп, чаткыланып яна торган бер кеше каршылады мине. Кульязманы өстәлгә салды, укырга ашыкмады, энәсеннән җебенә чаклы минем тормышымны, кайда укуымны, кайчаннан бирле әдәби эш белән шөгыльләнүемне сораштырды, озаклап, тәфсилләп, бер дә иренмичә сораштырды.

[1] Кустым (башкортча) — энем.

— Ярар, энем, иртәгә сәгать уннарга минем янга килеп чык, — диде ул миңа.

Мин, әлбәттә, аның иртәгә чаклы хикәяне укып чыгарына ышанмадым. Әнәс абый да мине, иртәгә килерсең, берсекөнгә килерсең, бер атнадан килерсең ди торгач, нәкъ ай буе йөрткән иде. Ә бит ул нибары унике битле хикәя.

Ни булса булды, ышанмасам ышанмадым, әйткән вакытка төп-төгәл унга язучылар союзы бүлмәсенә килеп кердем. Газиз абый бу юлы да мине бик сабыр каршылады, өстәле тулы кәгазь, ирен читенә сүнгән папиросы ябыштырылган иде.

— Укыдым, энем, хикәяңне... кил утыр.

Мин битемә шаулап кан йөгергәнне тойдым.

Шуннан соң ул минем сюжет-композиция корудагы кимчелекләрне сөйләп чыкты, бер-ике урында тел кимчелеге барлыгын әйтте.

— Рәхмәт сезгә, Газиз абый... хикәяне... кайтарып бирәсезме? — дидем.

— Юк, мин аны печатькә бирдем инде.

— Ә кимчелекләре?

— Син аларны, Гариф, дөресен әйткәндә, өч елдан соң гына аңларсың әле...

Әнә шул көннән башлап миңа канатлар үсте. Мин туктаусыз яза башладым. Күңелемдәге уемны әйтеп узасым килә: яшьләр белән эшләү кебек нечкә һәм сак эшкә үтә дә сизгер, ягымлы, теләктәш кешеләрне куярга кирәк икән. Әдәбиятны яраткан кешеләрне. Әдәби зәвыгы һәм сиземе зур булган кешеләрне. Газиз Иделле — шундый язучы. Мәрхүм Гали Хуҗи, Гази Кашшаф, Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов шундый кешеләр иде.

1951 ел минем өчен илһамлы һәм шактый ук мәшәкатьле яз булды. Нәкъ имтиханнар вакытында Шәһидәне больниска «ашыгыч ярдәм» машинасы белән алып китеп, операция ясадылар.

Аның янына больниска барырга, чәчәк һәм күчтәнәчләр алып барырга кирәк, минем бер тиен акчам юк. Оялып-шүрләп булса да, китап нәшриятына киттем. «Галләм сорау бирә» дигән хикәям өчен, аванс рәвешендә, акча бирә алмыйсызмы, янәсе. Бәхетле сәгатьтә килгәнмен икән, хикәям өчен алтмыш проценты исәбенә алты йөз сум акча биреп җибәрделәр. Хәзерге белән исәпләгәндә, 60 сум! Шаккатырлык акча да түгел. Әмма язу язган өчен әле беркайчан да миңа акча биргәннәре юк иде. Бигрәк тә менә шушы бишкә ярылырга йөргән кытлык заманда уч тутырып акча алу әйтеп бетергесез бәйрәм булды.

Алты йөз сум акчаны, беренче гонорарны кулга йомарлап, базарга чаптым, җиләк-җимеш һәм чәчәк сатып алдым. Шуларның барысын Шәһидәгә илтеп бирдем. Аның хәлсезләнебрәк калган аксыл чыраен күреп кайгырсам да, иң кирәкле чагында хәлен белә алуыма, тойгыларымны белдерә алуыма чиксез шат идем.

Терелгәч, мин аны такси белән апаларына алып кайттым. Аның янына безнең группа егетләре-кызлары җыелды, мин аларга бераз гына сөйләшергә ирек бирдем дә, ардырасыз дип, куалап диярлек кайтарып җибәрдем.

Шушы язны мине «Совет әдәбияты»на эшкә алдылар.

Анысы бөтенләй дә көтмәгәндә, истә-оста югында килеп чыкты. Мин «Совет әдәбияты» журналының укучылар конференциясендә катнаштым. Ул хәл 1951 елның май башларында Республика Үзәк китапханәсендә булды. Анда китапны һәм укучыларны бик яраткан олы яшьләрендәге Саҗидә апа эшли иде, ул миңа «Совет әдәбияты» журналының теле хакында сөйләргә кушты. Үзегезгә мәгълүм, остару ягына студент халкын уздыручы табылыр микән? Журналның телен мин бер селтәнүдә

юкка чыгарып ташладым. Баштарак әйткәнемчә, Рәбига Афзаловна, аның белән бергә фәннәр докторы Латыйф ага Җәләй безгә тел гыйльмен бик яхшылап өйрәткәннәр иде шул.

Журналда Фатих Хөснинең ниндидер повесте басылган иде. Мөгаен, «Авыл өстендә йолдызлар» булгандыр. Мин әнә шул олы язучының теленә ябырылдым.

— Фатих Хөснинең теле кытай фокусы кебек, — дидем мин, — ниндидер аллы-гөлле шарлар чөя фокусник, тасмалар очыра, аннары «өфф!» итеп бер өреп җибәрдеме, каршыңда бер генә нәрсә дә калмый, барысы тәтендәй таралып бетә.

Конференциягә җыелган язучылар, шул исәптән журналның җаваплы редакторы Гази ага Кашшаф елмаешып куйдылар, халык кул чапты, автор үзе елмаймады да, кул да чапмады. Тубал чаклы кара чәченә олы юл булып сузылган ак кашканы кулы белән баса-баса, башын борып, мине озатып калды.

Конференциядән соң мине үз янына Гази ага чакырганлыгын әйттеләр. Ул, «Совет әдәбияты» журналының баш редакторы булып эшләү белән бер рәттән, безнең кафедрада Шәриф Камал иҗаты буенча спецсеминар алып бара иде. Юаш-сабырлыгын, студентларны үз иптәшедәй якын итүен белә идек без аның. Үзебез дә аны бик ихтирам итә идек. Ник дисәң — ул укыту эшенә, имтихан алуга беркайчан да формаль килми иде.

— Дата ятламагыз. Сез аны, дусларым, беркайчан да ятлап бетерә алмассыз. Егерме ел әдәбият укытып, мин аны үзем дә белеп бетергәнем юк әле. Аннары бит... кирәк чагында аны китаптан да карарга була, — ди иде ул.

Әнә шул без яраткан һәм ихтирам иткән кеше янына мин куркыбрак килдем. Бүгенге чыгышым өчен тиргәргә чакырмыймы, кыланды̦ң дип әйтмиме?

Юк, ул мине тиргәмәде, шелтә белдермәде. Киресенчә, әйбәт сөйләдең, үзеңчә иттереп әйттең, Фатихны бик каты кысып алдың, күрдеңме, сиңа таба ничекләр борылып карады, — дип кеткелдәп кенә, йомшак кына итеп көлеп куйды.

— Әйт әле, Гариф, синең бездә эшләргә ниятең юкмы?

Каушап киттем.

— Кайда ул сездә?

— «Совет әдәбияты» журналында.

Тагын да ныграк каушадым.

— Мин бит, Гази абый... анда бит, ни бит... язучылар эшли бит.

— Син дә булырсың язучы.

— Булмаганны...

— Нигә булмаганны, бер язучы да күктән төшми. Гәзит-журналларда эшләп өйрәнә. Рас минем сиңа күңелем төшкән икән, бу юкка түгел, энем. Уйла син, уйла. Иртәгә миңа занятие вакытында нинди карарга килгәнеңне әйтерсең.

— Туктагыз әле, Гази абый... мин бит әле укыйм.

— Берәү дә сиңа укыма дип әйтми. Занятиеләргә йөрерсең. Мөмкинлек бирербез. Мин синең тормышың белән кызыксындым, этиең дә юк икән, тормыш алып барулары да җиңел түгелдер. Кыскасы — уйла, уйла.

Уйладым мин, төрлесен уйладым, бер батырайдым, бер шүрләдем. Шулай да иртәгесен Гази абый каршысына килеп: «Мин риза»,—дидем.

Бу — майның уннарында иде. Минем алда ун имтихан, тугыз зачет өелеп тора иде.

Гази абый миннән әдәбият буенча һәм спецсеминар буенча имтиханны вакытыннан элегрәк алып, башка имтиханнарга вакытны иркенрәк калдырды.

Әдәбияттан ул миңа Такташ турында сөйләргә кушты. Такташ авыл малайларының иң яраткан шагыйре бит ул, мин аның хакында университетта укып белгәннәремне, үзем аңлаганнарымны берсен бер калдырмый сөйләп бирдем. Гази абый мине бүлдерми тыңлады, азактан: «Мокамай»ны яттан беләсеңме? — диде.

— Беләм, «Нәни разбойник»ны да, «Тун трагедиясе»н дә, «Киләчәккә хатлар»ны да беләм. Малай чакта без аларны сәхнәдән сөйли торган идек, — дидем. Сөйләп киттем.

Газиң абый, ике кулы белән өстәлгә таянып, башын кырынрак салып, мине ихлас күңелдән тыңлап утырды. Ни яхшыдан, ни яманнан бер сүз әйтмәде, минем зачетканы алып «бишле» билгесе куйды.

— Иртәгә редакциягә кереп чык әле, занятиеләрең беткәч, документлар тутырырсың, — диде һәм, өстәл яныннан торып, папкасын култык астына кыстырып, аксак аягын яннан селтәп ала-ала ишеккә таба юнәлде...

Журналга эшкә керү, беренче хикәямнең типографиядә басылып ятуы, күңелдәге яшьлек тойгылары миңа шул хәтле күп көч бирде ки, ун имтиханның тугызын мин «бишле»гә тапшырдым, ярты ел буена җыелган немец теле «внеаудиторкасын» бер биш көн эчендә өстән алып аттым, зачетлардан котылдым... Инде нәчә ел сынаганым бар, сөенеч миңа беркайчан да үзе генә килми, көенечне дә җитәкләп килә. Унынчы имтиханда миңа рус совет әдәбиятын укытучы Валентина Сергеевна «Чапаев» романының кайбер даталарын белмәгән өчен «икеле» билгесен, күзен дә йоммыйча, куеп чыгарды. Шул «икеле», гүя мине үчекләргә теләгәндәй, тугыз «бишле» янына лаҗыраеп төшеп утырды.

Башка чакта булса, мин моңа үләр чиккә җитеп борчылган булыр идем, чөнки бер генә «икеле»ң булса да ул елларны стипендия бирмиләр иде. Ә нәрсә миңа хәзер — сигез йөз сиксән сум хезмәт хакы билгеләделәр, аның миңа ярты айлыгын бирделәр дә инде, ник шунда биш укытучы җыелып биш җиргә лаҗырайтып «икеле» куймыйлар, исем дә китәсе юк!

Әлбәттә, батыраям гына. Берьюлы биш «икеле» алып кара әле, китмәс ди исең, бар!

Шәһидәнең еллар буе җыйган белем запасы күп икән, больнистан чыгуга ул ун имтиханның унысын дә әзерлексез-нисез тапшырды.

Июль-август айларында безнең факультет егетләрен ике айлык хәрби өйрәнүләргә алырга тиешләр иде, шуңарчы дип без, ял көненә туры китереп, Шәһидә белән минем туган якларга китеп бардык. Без аның белән өйләнешергә сүз куешкан идек инде, аның минем әниләрне, апасеңелләрне күрү теләге бар иде, тик минем өйдә авырып яткан бер энем булганлыктан, мин кәләшемне алып кайтырга бик әлләни ашкынып тормый идем. Кем белә, авыру баланы ничек кабул итә бит әле ул...

Минем икеләнеп калуымны күргәч, аның кәефе китте, сәбәбен сораша башлады, мин сәбәбен әйткәч:

— Җүләркәй, андый нәрсәне яшерәләрмени?! Кайтабыз, бәлки, әле мин аңар ярдәм дә итә алырмын, минем апам врач бит, — диде.

Тәвәккәлләп, без Өчиле ягына кузгалдык. Арчага чаклы поезд белән, Арчадан соң юлаучы машинага утырып кайттык. Көтек авылы турысында, олы юлда, машинадан төшеп калдык.

Ул кич хәтеремдә бик матур булып калган. Кояш баеган иде инде. Офык читен алтын сыман сары төстәге үтә күренмәле болытлар бизәгән, җил-мазар юк, талгын тынлык, җир өстенә көннәр җылынгачрак була торган рәхәт бер салкынчалык җәелгән иде.

Без, кулларны тотынышып, басу юлыннан Көтеккә кайтабыз. Заманында мин анда башлангыч мәктәптә укыдым, азактан кырчылык

бригадасы бригадиры булып, председатель янына нәрәт алырга ярдәм һәм, ниһаять, сугыштан соң бер ел клуб мөдире булып эшләдем. Бу — мин беренче мәртәбә тальян гармунга җырлап урам әйләнгән авыл...

Көтектә мине белмәгән кеше юк. Без кулларны тотынып узганны карап калалар. Олы, яшьләрдәге бер карт, Фазылҗан бабай, түзмәде, мыек чалгыйларын бөтереп карап торгач:

— Бу кемең була соң, Гарифҗан? Хатының мәллә?— дип сорады.

— Хатыным, — дидем, ике төрле сөйләргә урын калдырмадым.

— Бәрәкалла, бик чибәр күренә, төкле аягы белән килсен! — диде Фазылҗан карт.

Мин күтәрелеп Шәһидәгә карадым: рәнҗемәгәнме, янәсе.

Юк, рәнҗемәгән, мыштым гына елмаеп кайта, вакыты җиткәч, хатын дигән сүзне ишетү дә рәхәттер, күрәсең.

Өйдә безне әни, Гайшә апа, бәләкәй энем Ризуан, авыру энем Рамазан каршы алдылар. (Болары икенче ата балалары). Сеңлем Саҗидә өйдә юк, ул Арча ягында тракторда эшли иде. Без кайтканга сөенделәр. Дөресрәге, әнидән калганнары. Минем әнинең шатлыктан кычкырып сөенгәне, кайгыдан кычкырып кайгырганы булмады.

— Менә, әни, киленегез буласы кешене алып кайттым, карагыз, күрегез, — дидем мин уенчаграк тавыш белән.

Әни минем «җиңеллекне» бигүк өнәп бетерми иде, тыныч-сабыр тавыш белән мине урыныма утыртты.

Чәй куеп эчтек. Тегене-моны сөйләштек. Килен булачак кеше дә, кайнана булачак кеше дә әле бер-берсеннән тартыналар иде. Ул кичне бик җәелеп китә алмадылар.

Әни килене булачак кешене үз ягына, олы якка алып кереп китте, мин караңгы чоланда бер үзем торып калдым.

*

... Көзен сентябрьнең егерме берендә, укулар башлангач, без Казанда туй үткәрдек. Башта студент иптәшләребез җыелды. Аннары Шәһидәнең апасы үзләрендә туганнарын җыйды. Ул туйга әни килә алмады, авылга, Өчилегә кайтып, янә туй үткәрергә булдык. Анысын Октябрь бәйрәменә туры китереп эшләдек.

Язучылардан безнең туйга Мәхмүт Хөсәен кайтты. Мәзәклеге белән, телгә осталыгы белән, гармунны артистларча уйнавы белән әйләнә-тирәне шаккатырып китте.

Туйга без әти-әни ягыннан булган туганнарны, тирә-күршене чакырдык. Азактан безнең туй дан булып таралды:

— Өчиленең Ахун малае туйга бөтен авылны җыйган икән.

Бу сүздә дөреслек бар. Тик безнең авылда Шәһидә белән мин туй ясаган елны нәкъ алты йорт торып калган иде.

*Дәвамы бар.*

## Фәнис Яруллин

### Күңел күзем

Маңгай күзем күрмәгәнне
Күрә күңел күзем.
Шуңар кылган эшем өчен
Һич кызармый йөзем.

Бар минем илем каршында
Шагыйрь дигән атым.
Шул атыңа тугры бул ди,
Күңел күзем, халкым.

●

Туа, үлә
Гел җай гына —
Яфрак гомре
Бер җәй генә.
Юкка түгел
Яшәүләре,

Шулай бик тиз
Үлсәләр дә:
Гомерләрен
Бирә алар
Күк терәге —
Кәүсәләргә.

●

Кайгылыны бик тиз таный
Үз кайгысы бар кеше:
Кайгылар төрле булса да
Бер төсле бит күз яше.

●

Кемгә булса да
Охшарга теләп,
Кеше үз-үзен
Җуя әкренләп.

●

Тупаслыклар үтеп китми
Күңелләргә салмыйча эз.
Кыш өшегән агачны да
Яз җиткәч кенә беләбез.

### Ярам

Бәрмим, сукмыйм, читен юлда
Гел саклап кына барам.
Ялгыш бәрелсә дә каный,
Син — иң авырткан ярам.

●

Аны һичкем ега алмас,
Анда гайрәт-көч, димә.
Пуля куып җитмәс кош юк,
Гайбәт үтмәс стена.

●

Басу өстендә очына
Җанлы нокта — күр әле.
Әллә тургай, әллә инде
Игенченең йөрәге.

●

Биектә, бик биектә,
Болытсыз зәңгәр күктә
Күрсәм дә торна барын,
Сузмыйм инде кулларым.

Карыйм да тик сокланып,
Уфтанып куям юкка,
Һәм өрәмен сулышны
Кулымдагы чыпчыкка.

## Җәйге көн

Баш очымда кояш яна,
Сулап та булмый, эссе.
Яфракка яфрак бәрелсә,
Кабынып китәр төсле.

## Сорау

Сугыш беткән еллар иде бугай,
Сорау бирде сеңлем бер чакны:
— Әти кешеләр Галим абзый төсле
Буламыни агач аяклы?

●

Узган көннәр өзгән гөлләр икән,
Терелтмәкче булып шул гөлләрне,
Очрашулар, күрешүләр көтеп
Ярсыттык без тыныч күңелләрне.
Очраштык та чиксез гаҗәпләндек,
Чынбарлыкның карап күзләренә.
Хыялларның хәрабәсе бары
Өелеп калган яшьлек эзләрендә.
Бик озаклап нидер эзләдек без
Шушы хәрабәләр арасыннан —
Тарихчылар шаһит эзләгәндәй
Үткәннәрнең җимерек каласыннан.
Бу очрашу юкка булды ахры,
Элеккечә калсын иде бар да.
Мин Таһирың, ә син Зөһрәм булып
Яшәр идек һаман хыялларда.

•

Син килдең дә китеп бардың,
Хушлашып горур гына.
Калды өйнең һәр җирендә
Күзләрең нуры гына.

Син килдең дә китеп бардың,
Әйт, килүләрең нигә?
Калды чыңлап кыңгыраудай
Шат көлүләрең генә.

Син килдең дә китеп бардың,
Күрдем дә, күрмәдем дә.
Моңарчы таныш булмаган
Җыр калды йөрәгемдә.

Син килдең дә китеп бардың...

•

Бар ул син эзләгән кеше,
Бар ул, тик ышан гына.
Табарсың хыялларыңа
Гел тугры булсаң гына.
Табарсың, ышан гына.

Бар ул син эзләгән кеше,
Бәлки яныңда гына.
Тик табылмый эзләгәннәр
Яшьлек таңында гына,
Көткән чагында гына.

Бар ул син эзләгән кеше,
Бәлки еракта гына.
Өметең өзеп, сереңне
Чишмә тик ятка гына.
Бик кыен чакта гына.

Бар ул син эзләгән кеше,
Эзлә тик армый гына.
Ул үзе дә сине эзли,
Очрата алмый гына.

Бар ул син эзләгән кеше.

................

## Шамил Рәкыйпов

# КОМБАТ ИСТӘЛЕГЕ

чын хикәя



Быел җәй мин Кара диңгез буенда ял иттем. Ниһаять, тәүлекнең егерме дүрт сәгате дә минеке дип, үзем белән шактый гына эш алып килгән идем. Ләкин кая ул — өстәл янына барасы да килми, каһәр. Кояшы шәп, аннан да бигрәк диңгез шәп. Янәшәдә генә, назлы тирбәлеп, җәйрәп ята ул. Иртәнге җидедә сикереп торам да, сөлгене култык астына кыстырып, ялан аякка кигән чүәкләремне яссы ташларда чәпелдәтә-чәпелдәтә, бакча аркылы диңгезгә юнәләм. Вакыт иртә булганлыктан, кырыйлары тимер челтәрле таш сукмакта кешеләр күренми диярлек. Чыпчыклар чыркылдаша, тагын мин белмәгән нindидер кошлар тыныч иртәне мактый; кайсыдыр, кыз чакыргандай сызгыра, сак кына тукылдый, нәрсәдер кыштыр-кыштыр килә. Кыштырдаганы кош тавышы түгел икән. Бу — бакча каравылчысы, аз сүзле кырыс карт Михаил Максимович сукмак себерә.

Безнең төбәкләрдә себеркене яшь каен ботагыннан бәйләгәнгә, ул коры көннәрдә дә ямьсез тавышлар чыгармый. Биредә исә каен юк, себеркене чәнечкеле карсак куак ботакларыннан, кырыкмыш койрыгына охшатып тумалдырып бәйлиләр. Кырыкмыш тай койрыгы көдрә һәм йомшак була, ә бакчачы кулындагы себерке һич андый түгел. Хуҗасы кебек төксе, тырпаеп тора. Максимыч диңгезгә килүче кайбер яшь-җилбәзәкләрне өнәп бетерми. Шуңа күрәдер, ахры, янышнан яшь-җилкенчәк узганда себерке аеруча каты кыштырдый. Картның байтактан кырынмаган яңагында чәч бөртекләре тырпая, куе кашлары җәяне хәтерләтеп дугалана, кабара.

Миңа аның хакында: элек ул нindидер генералның денщигы булган, Жуков, Василевский, Конев кебек мәшһүр полководецларны күргән, фронт тормышыннан гаять кызыклы вак-төякне белә, тик теләсә кемгә сөйләми генә дигәч, карт белән чын-чынлап кызыксына башладым.

Бирегә ул, сугыш бетәр-бетмәс үк, Украинадан күчеп килгән, Ярым гарип, колаклары начар ишетә, әллә Германиягә озатылып, анда үлеп калган хатынын оныта алмаганмы, яңа гаилә корып җибәрмәгән. Кечкенә генә өй салып кергән, бакча утырткан. Тик бары-

бер үз җирендә казынып кына йөрәгенә тынычлык тапмаган. Ял йортына эшкә урнашып, еллар дәвамында сукмак себергән, агач-куакларны тәрбияләгән, яңаларын утырткан. Яраткан шөгыле — гөлчәчәкләр үстерү. Сәер гадәте дә бар: ял йорты тирәсендә үзе утырткан гөлчәчәкләр ныгып, шаулап чәчәк ата башлады исә, күчеп китә икән. Яңа җирдә эшен яңадан башлый һәм берничә елдан соң кабат күченә. Аны һәркайда ике куллап каршы алалар. Чөнки бирeдә тәрле дәва йортлары, яңгырдан соң калкып чыккан гөмбәләрдәй, арта гына торалар. Аннары бакча бит ул мәңгелек түгел. Агачлар сына, картая, аларны яшь үсентеләр белән алмаштырмый чараң юк. Ә Михаил Максимыч, әйткәнебезчә, сипләү-төпләү белән генә шөгыльләнми.

Бу ял йорты икенче сезонын гына эшли әле. Гөлчәчәк куаклары да буй җибәреп кенә киләләр. Аларның һәммәсен Михаил Максимыч утырткан. Һәр куак тиешенчә киселгән-кыркылган, төпләре йомшартылган. Болар өстенә, карт бирeдә дворник хезмәтен дә башкара. Монысының тарихы мәхәббәткә барып тоташа дип сөйлиләр. Имеш, фронтта очраткан бер кызны ул еллар буе хат язып эзләгән. Тапкан, ял йортына чакырган. Аңа баш врачтан путевка даулаган. Путевка сатып алырга акчасы җитмәгәч, денщикларга гына хас тапкырлык күрсәтеп, тоткан да ярты хакка ишек алды себерүче булып урнашкан. Хәзер сөеклесе ел саен килә ди һәм Максимыч ел саен җәй айларында ике эшне үтәп акча җунәтә ди.

Гадәттә ике көймәнең койрыгын тотып булмый диләр. Ә Максимыч менә булдыра. Ул бирeдә хуҗаларча каты-каты басып йөри. Пөхтәлек, тәртип ярата. Әгәр бу ял йортына килеп, иртән иртүк берәүне таш сукмак беткән җирдә очратсагыз, аның мыгыр-мыгыр кемнедер тиргәвен ишетеп гаҗәпләнмәгез, Максимыч булыр ул. Монда диңгез ярына күтәрелер өчен цементтан баскыч койганнар. Тик ул, гөнаһ шомлыгына каршы, чак кына читкәрәк карап тора. Моны Максимыч көн саен күрә һәм бакча читендә көн саен тиргәү тавышлары ишетелә.

— Пыяла күзле өчаягына төртелеп өч көн үлчәде, бәбәге чыккыры нәрсә. Чалыш икәнлеге пыяласыз да күренеп тора бит!..— Себерке, картны куәтләгәндәй, катырак кыштырдый, ботакларда берсеннән-берсе уздырып сайраган кошлар сагаеп калгандай була. Сукмакның ике ягына ике рәт тезелгән купшы гөлчәчәкләр исә, үз бәяләрен бик белеп, назлы елмаялар сыман.

Мин бакчачы картка хәерле иртә теләп, аның теләсә кем кулыннан алмавын белгәнгә, бәхетне сынап, затлы сигарет сузам. Әмма Максимыч читтән килгән елтыр капларны яратмый, борынын гына җыера.

Әйткәнемчә, язу-сызу эшем чыгымлап торганга, коенам да кызынам, кызынам да коенам. Әмма бер үк шөгыль тиз туйдыра бит ул. Укырга тотындым. Китапханәдәге хәрби мемуарларны су уырына эчәм. Маршал Жуковның «Уйланулары һәм истәлекләре»нә чират җитте. Аерыла алмыйча укыйм. Вакыт әрәм үтмәсен өчен, китапны пляжга төшкәндә дә үземнән калдырмыйм. Бакчачы карт нәрсә укуымны күреп өлгергән бит. Имән бармагын кыймылдатып кына үз янына чакыра бу. Йөзе тыныч, мөлаем.

— Китапның кәттәсен укыйсың икән,— ди.— Сеңдереп укы, хөрмәтлем. Юкса хәзерге яшьләр: сугышның беренче айларында сез, пешекләгән тараканнардай, чигенгәнсез дә чигенгәнсез дип рәнҗетәләр. Ә без, хөрмәтлем, саранча өере кебек ишелеп килгән немецның арт сабагын укыттык. Беренче атналарда ук. Әйе. Ике каланы, өч авылны кайтарып алдык. Жуков китабында да язылган иде шикелле бу хакта. Китаптан шул җирен тапкач миңа әйтерсең.

Аннары әңгәмәне дәвам итәрбез. Казан кешесе дә булгач, сиңа әйтәсе сүзем бар әле минем! Әйе, әйе, сүзем бар!

Бакчачы карт сөйләгәннәрне китаптан чыннан да таптым мин. Бу аның абруен күтәреп җибәрде. Димәк, дидем, карт буш шалтыравык түгел. Ышанырга була. Миңа нинди сүзе бар икән соң аның?

Икенче көнне маршал Жуков истәлекләреннән мин билгеләп куйган урыннарны бергәләп укыдык. Максимыч офыкта өрфия пәрдәгә төренеп күкселләнеп торган тауларга карап беразга тынып калды, аннары тамак кыргалап:

— Ә беләсезме, китапта язылган ике каланы, алар тирәсендәге авылларны алуда катнашучыларның иң батыры, әйе-әйе, иң батыры, Казан егете бит,— диде.

— Кем ул, Максимыч?

— Комбат Баталов. Минем командир. Гайрәтле егет. Мин дигән кеше. Абзаң шул азамат ирнең алмашсыз ординарецы иде.— Михаил Максимович чаларган куе мыегын бөтереп куйды. Аны үзенә тынгы бирмәгән хәлләрне сөйләү теләге тәкатьсез итте ахры: коңгырт күзләре очкынланып китте, себеркесенең тимер боҗра утырткан очлы башлы сабын кыса төште.

— Бу гыйбрәтле тарихны, хөрмәтлем, сиңа сөйләми ярамый. Комбатны Казанда да белергә тиешләр. Әйе. Карты-яше белергә тиеш. Ул моңа лаек. Анда хәзер аның бер кеме дә юк. Димәк, искә төшерүчесе дә юк. Монысы — миңа билгеле. Менә утыз сигез ел буена Баталов турында белмисез бит. Советлар Союзы Герое турында белмисез. Болай онытылып ятучылар бер Баталов кына да түгелдер әле. Бардыр андыйлар. Тагын бардыр. Башкаларның язмышын белмим. Ә менә Казанда туып үскән Баталовның онытылуы күңелне әрнетә. Болай ярамый. Ул чын кеше иде. Әйе. Менә тыңла әле...

Без хөрмә агачы күләгәсендәге рәшәткә эскәмиягә утырдык. Әйләнә-тирәбездә уңда да, сулда да ап-ак, кып-кызыл, җете шәмәхә, алсу һәм тагын әллә ничә төсмердәге гөлчәчәкләр. Безнең яннан, гөлчәчәкләргә ымсынып карый-карый, үзләре дә кырым розаларыннан ким булмаган яшь кызлар көлешеп узды. Чәчләреннән, киемнәреннән хушбуй исе бөркелде.

Бакчачы карт сүзен дәвам итте:

— Сугышның егерме икенче көне иде. Күп түгел дә кебек. Ай да үтмәде. Ә шул егерме ике көн эчендә дошман Днепрга чаклы килеп җитте. Туктатып булмый гына. Сәбәпләре бар. Шуның берсе — техникасы күп. Көн-төн тукталмыйча, урыны-урыны белән бик нык каршылык күрсәткән безнең гаскәрләрне урап үтеп һәм тәэмин итү юлларын кисеп, мәкерле планын гамәлгә ашыра-ашыра килә бәдбәхет! Ә планы аның чыннан да «яшен тизлегендә» җиңүне күздә тота иде. Фашистларның ничаклы мәмләкәтләрне тиз арада тез чүктерүен искә алсаң, нәкъ шулай булырга тиеш иде ул. Гитлерчылар сугышның беренче айларында сан ягыннан ике-өч мәртәбә артык булса, аның артиллериясе, авиациясе, танклары безнекеннән өч-дүрт тапкыр күбрәк иде. Шуны җилкәсендә татыган сыеграк буынлы бер ише кешеләр тәмам боегып, мескенәеп калды. Күзләрендә аптырау. Көн саен, сәгать саен без көчле, бездә беренче класслы техника бар дип ышандырдыгыз, кайда соң алар диялэр иде сыман ул күзләр. Ашау турында әйтмим дә. Мәгәр дошман солдатларының шоколадка чаклы тыгынулары сер түгел иде.

Тамак тәмугка кертә дигәндәй, миңа үз командирыма аш-су хәзерләү җиңел булмады ул чакта. Ә комбат, Федор Алексеевичны әйтәм, үзе турында кайгырта белми иде. Хәзерләп алдына куймасаң,

яки окопта ятканда фляганнан агызып кайнар чәй бирмәсәң, тәки йөри онытылып. Менә күз алдыңа китер. Кояш кыздыра. Чыдар әмәл юк. Бала-чага, карт-коры, яралылар су сорый. Ул да булмый, дошман самолетлары килеп җитә. Тапыйлар гына халыкны.

Комбатның күзләре — утлы күмер. Кодрәтеннән килсә, һәр самолетны яндырып кисәү ясар иде. Мылтыклардан, пулеметлардан ату белән генә чикләнәбез. Тилгәнне «Кеш! Кеш!» дип куган кебек була инде бу. Җитмәсә коралларны экономия белән тотарга кирәк. Кич җитә. Ашык-пошык окоплар казып урнашабыз. Комбат төрле якка разведка җибәрә. Дошман турында мәгълүмат җыя. Штабка шалтырата, киңәшә, үтенә, даулый. Тамагы карлыгып бетә бичараның. Ул да булмый, чыгып китә. Уяулыкны тикшерә, кызылармеецларның күңелен күтәрә, взвод яки рота алдындагы бурычларны аңлата.

Әйтсәм әйтим, мең тугыз йөз унсигезенче елдан Кызыл Армия сафында булган кадровик Баталов батальондагы сугышчыларга үзенә ышанган кебек ышана иде. Әмма хәзер бу төбәктә алар гына түгел бит. Бөтен бер корпус. Шушы алтмыш өченче корпус фашистларның «Үзәк» исемле армия төркеменә каршы тора. Бугазга-бугаз килеп каршы тора. Капитан Баталов фикеренчә, хәзер контрһөҗүмгә дә күчәргә мөмкин. Һәм бу мөмкинлекне һич кулдан ычкындырырга ярамый. Барып чыкса, бу — Европаны авыз гармуны уйнап узган гансларның кикриген шиңдерү белән бергә, өметсезлеккә бирелә башлаган кайбер сугышчыларыбызның күңелен күтәреп җибәрәчәк.

Үз колакларым белән ишеттем: Федор Алексеевич алгы сызыкка килгән начальствога нәкъ шул хакта сөйләде. Кызып-кызып сөйләде. Ышандырды. Корпус командиры генерал Петровскийның талчыккан чыраенда канәгать елмаю чагылды.

— Әйбәт инициатива. Армия штабы каршы килмәсә, тәвәккәлләрбез,— диде генерал.

Шунда бакчачы карт сөйләвеннән туктады һәм бераз вакыт еркта-еракта күкселләнеп торган тауларга карап торды. Кояшта янган киң маңгаендагы җыерчыклар тирәнәя төштеләр, сирәк керфекле тонык зәңгәр күзләрендә сагыш чагылды. Беләм: әнә теге тау итәгендә ак һәйкәлле туганнар кабере бар. Аның тирәсендә нәкъ менә шушы бакчадагы сыман шаулап гөлчәчәкләр үсә. Мөгаен, аларны да Максимыч утырткандыр. Шулай булмаса, бакчачы карт хәзер тауларга карап тирән кичерешләргә бирелеп торыр идеме? Әнә ул бирчәйгән каты тиреле бармаклары белән ияген сыйпаштыра. Үзенең берничә көн кырынмаган булуын килештермидер, күрәсең. Чын командирлар һәрвакыт чисталык, тәртип яраталар. Үз кул астындагылардан шуны таләп итәләр.. Максимыч — шул мәктәптә чыныгучыларның берсе. Мондыйлар армия тәртипләренә гомергә турылыклы булып калалар.

Максимыч күлмәк якасын төзәтте, гадәт буенча бил каешы буларга тиешле урынны сыпыргалады һәм уйларыннан бүгенгегә кайтты, нәүмиз генә елмайды. Әллә ничек канатсыз, ятим иде бу елмаю. Ахыр чиктә карт болай нечкәреп китүен килештермәде, ахры. Чөнки тиз-тиз сүзгә кереште:

— Беләсезме, хөрмәтлем, алгы сызыкка килгән генералның кем улы икәнлеген? Белмисездер. Кая инде!.. Җае чыкканда белеп калыгыз: әлеге генерал Бөтенукраин старостасы Г. И. Петровскийның улы иде. Ә Петровский, үзегезгә мәгълүм, бөек Ленинның якын көрәштәше булган. Менә ничек!..

Зерә дә зирәк акыллы, тирән белемле бу командирны Баталов бик хөрмәт итә иде. Үзең уйлап кара: ашык-пошык комплектлан-

тырылган барлы-юклы бер корпус фашистларның карталарын тәмам буташтыра, тоткарлый. Дөрестерме, юктырмы, анысын белмим, безнең юнәлештә һөҗүмнәре тукталгач, Гитлер көн саен 63 нче корпусны сытып узарга боерык биреп торган ди. Юк, булмады! Тешләре үтмәде!

Янә генералга борылып кайтыйк әле. Авыр туфрагы җиңел булсын, моңа лаек ул. Искә алырга дим. Әйе. Менә, хөрмәтлем, үзең уйлап бак: бөтен фронт тоташтан чигенгәндә, нинди дер бер йокысы качкан капитан кисәге таккан контрһөҗүм планына колак салуы аның үз кул астындагыларга ихтирамы турында сөйләмимени? Минемчә, генерал Петровскийның 21 нче армия штабында абруе зур иде. Шулай булмаса, иң соңгы резерв саналган «бәләкәчләр» батальоны калдыгын аңа бирерләр идеме? Т—60 дип йөртелгән җиңел танклар турында сүз. Аның юка бронясын немец снаряды тишә дә керә. Ә пехотага каршы сугышканда «бәләкәч» алтын бәясе тора.

Комкорның алгы сызыктан китүенә өч-дүрт сәгать үтмәде, әлегә җиңел танкларның икесе Баталов карамагына келтерәп килеп тә җитте. Өстәмә көч сыйфатында. Шәп. Һөҗүмгә боерык юк, ә танклар килде. Өр-яңалар. Пулемет борыннары гына тәтәсләнгән. Моннан нинди нәтиҗә чыга? Нәтиҗә шул: димәк, Петровский 21 нче армия штабыннан боерык буласына ышанып эш итә. Хәер, армия штабы начальнигы генерал Гордов, Федор Алексеевич әйтмешли, карт чыпчык: кибәктән бөртекне тиз аера...

Алгарак китеп булса да әйтим, һөҗүмгә күтәрелергә боерык килде безгә. Килде, туган. Комкор эшне сөйләп бирүгә, штаб начальнигы:

— Яхшы. Баталов инициативасын хуплыйм. Мин аны күптәннән беләм, аңа ышанам! — дигән.

Белмичә! Штаб начальнигы генерал Гордов үзе дә Татарстан егете бит. Минзәлә районыныкы ул. Алар күптәнге танышлар. Идел буе хәрби округы командующие булган чакта Баталовка ул үзе укырга китәргә тәкъдим итә. Әтисен дә белгән.

Разведка мәгълүматларын искә алып, комбат үзенчә нәтиҗә ясады: дошманның төп көчләре артта калган, алар килеп җиткәч тә Днепрны кичә башлаячаклар. Кызыл Армия бөтен фронтта чигенгәндә биредә контрһөҗүмгә күчәрләр дип кем уйлар.

— Ярый, — диде Баталов. — Дүртенче рота командирын чакырыгыз! Тиз булыгыз!

Элемтәче китте. Мин, тарлавыкка төшеп, тәтен чыкмасын өчен коры чыбык-чабыклардан учак терелтеп җибәрдем.

Көн эссе булачак: кояш кызарып зур шарга охшап күтәрелә. Күк чалт аяз. Кояш нурлары чык бөртекләрен бистә кызлары калфагындагы энҗеләр кебек җемелдәтәләр... Нәрсә, туган, бу сүзләрем гаҗәпләндерәме? Аларны мин Федор Алексеевичтан хәрби өйрәнүләр вакытында ишеткән идем. Мари урманында. Әйе. Баталов матурлыкка гашыйк җан иде. Матурлыкны күрә, бәяли белә иде. Һә-әй без аның белән серләшеп тә карый идек инде! Ашка урман хәзинәсеннән нинди тәмләткеч салудан алып, мичне нәрсә утыны белән ягуга чаклы белә иде бит ул! Боларны кайдан өйрәнгәнме? Тормыш өйрәткән! Федор Алексеевич унбер яшеннән күмәчче ярдәмчесе булган. Камыр изгән, камыр баскан. Өстенә мәк сибеп клиндер, булки пешергән. Казан малае булган, ул сезнең чәк-чәк, бавырсак, өчпочмак кебек затлы ризыкларыгызны пешерү серләрен дә белә иде. Ягулык мәсьәләсен пароходта кочегарлык иткәндә өйрәнгән. Ул елларда, үзегезгә билгеле инде, ташкүмер дигәнең җитенкерәми. Сызылып аткан таңнарны, Идел-суның матурлыгын җәһән-

һәм эссесеннән палубага чыккан санаулы минутларда гына күргән. Әйе, кадерле була андый минутлар!

Федор Алексеевичлар Казанның Яңа бистәсендә яшәгәннәр. Яңа бистәнең нинди булуы сезгә билгеле инде. Яңгыр яуса тездән пычрак, коры айларда күз ачкысыз тузан. Шуның өстенә Крестовниковларның сабын заводы ел әйләнәсе төтен һәм сасы ис тарата. Шушы авыр ис җәйләрен тәмам теңкәгә тигәнгә Федор Алексеевичның әнисе бәләкәй агач өйнең тәрәзә төбенә чәчәкләр утыртa торган булган. Комбатның чәчәк яратуы да шуннан. Нәкъ минем кебек. Бакчачы булырга мине дә әнием өйрәткән иде. Әйе...

Әмма сүз читкә китте. Дошман төп көчләрен көтеп Днепр янында ята дигән идем. Һәр якның үз матурлыгы бар. Ул иртә бик матур иде. Елга, ефәк чаршаулы ятагындагы сылу кыз кебек, зәңгәр томан эчендә. Талгын җил уң яктагы бодай басуында «куян куа». Тургайлар сайрый. Һавада бал исе, ипи исе. Ашлык өлгереп килә, ләкин аны кем урыр? Бакчаларда мул уңыштан ботаклары салынып төшкән алмагачлар, тып та тып итеп, җиргә алма коя.

Шушы гүзәл иртәне җирне җәрәхәтләп, кешеләрне кырып сугыш белән килү түгел, бу хакта уйлау гына да зур җинаять тоела. Әмма теге якта дошман. Без авылга һөҗүм итәргә ниятләнәбез. Бу — кузна уены түгел. Гадел хезмәт җимеше булган матур өйләр җимереләчәк, бакчалар көлгә әйләнәчәк. Һөҗүм итмәс идең, анда — немец, чакырылмыйча килеп түр башына менеп утырган кунак. Юк, кунак түгел, инквизитор, илбасар, палач — менә аның чын йөзе!

Шулай уйланып комбатны чәй эчергәндә, көтмәгәндә секретта утырган сугышчылар ялгыз көймәдә елганы кичеп чыккан бер кызны тотып китерделәр. Кыз өстенә иске-москы кигән. Төсе уңган кофтасы ярыйсы ук мул, бәлки анасыныкы булгандыр. Итәге чәчәкләнеп сизерәгән юбкасы исә бераз кыскарак. Ләкин ни әйтсәң дә бүген табып алынган бу иске киемнәр кызның чибәрлеген барыбер яшерә алмыйлар иде. Чибәр иде, шайтан алгыры! Чын мәгънәсендә чибәр иде бу кыз. Кыскасы, бер күрүдә ошады бу миңа. Су кызы. Әйе...

Кыз, мылтыгын әзер тоткан кызылармеец алдыннан атлауны өнәмичә, әледән-әле туктала, ачуы килә, үзен тизрәк командир янына илтүне даулый иде.

Комбат бил каешын, гимнастерка якасын төзәткәләде дә:

— Чакыр бирегә,— диде.

Кыз шыр ачык землянкага керде. Дулкынланудан булса кирәк, ешеш сулап: «Исәнмесез»,— диде.

— Исәнмесез. Ни йомыш, чибәркәй?— диде комбат.

Кыз башын күтәрде, өстәл сыман нәрсә өстендәге сулы банкага күзе төште, кечкенә авызы ярым ачык калды:

— Сугыш... һәм розалар. Гаҗәп...

Комбат, менә бит синең нечкә күңеллелегең нинди җайсыз хәлгә куя дигәндәй, миңа кырын карап алды. Мин үз нәүбәтемдә:

— Сугыш мәңге бармас. Кыргыйланырга димәгән,— дидем.

Кыз сизгер икән:

— Алар әнә кыргый! Пычракка китаплардан юл түшәделәр, парталарны ватып яктылар.

Баталов тамак кырды:

— Шуларны хәбәр итәр өчен генә бире килмәгәнсездер бит?

— Юк-юк, командир абый,— диде кыз.— Күпме икәнлекләрен әйтергә килдем. Авылның бу читендә ике пулеметлары бар. Макар тавында пушкалары... Кәгазь-каләм бирсәгез, сызып күрсәтәм. Тавыкларны тоталар да, пешертеп аракы чөмерәләр...

Баталов планшетын ачты. Кыз туган авылын карбызга охшатып кәгазьгә төшерде дә, чит-читләренә хач галәмәтләре куя-куя, борчак шикелле түгәрәк саннар тезде.

— Бу тыкрык башында өч пулемет, бер сакчы. Монысында бурзайга охшаган калын көпшәле нәмәрсәкәйләр. Тугыз...— Ул сызып бетергәч, комбат: Фашистлар шулай тыгыз урнашкан булгач, авылдан сез ничек чыгып китә алдыгыз соң? — диде.

— Елан тарлавыгыннан шуышып...

— Шәп разведчик чыгар сездән, сеңлем! — дип Баталов кызның кулын кысты.

Сизеп торам: комбат хәзер кыз үткән тарлавыктан дошманга сиздерми генә отделение дә уза ала бит дип уйлый. Безнекеләр эчтән гранаталар белән дөмбәсли башлауга ике взвод белән ике яктан бәрергә кирәк...

Комбат телефонга ябышты. Ләкин полк штабы начальнигы майор Вайнтрауба һөҗүмгә күтәрелү турында дивизиядән дә, корпустан да әлегә бернинди боерык алынмавын әйтте. Ахырда ул Баталовның кичә комкор белән бу хакта сөйләшкәнен белгәч:

— Һөҗүм итәргә рөхсәт бирәм, әмма ләкин бу тиктормавың барып чыкмаса, башың белән җавап бирәчәгеңне онытма! — дип кисәтте.— Һәрьяктан немец көн-төн килә. Әнә Смоленскидан чигенәләр. Ә сез... Сездә тынлык. Ну, тәвәккәллә, комбат!..

Смоленскидан чигенәләр... Димәк, дошман Мәскәүгә илтә торган олы юлга чыккан. Әнә кайда аның төп удары! Хәзер Днепрны кичеп, Жлобинга таба кузгалырга кирәк. Паника тудырырга! Маневр ясый-ясый гел алга барырга! Бу хәл «Үзәк» армия төркемнәре командующие фельдмаршал фон Бокны борчуга салачак һәм төп көчләрнең бер өлеше безгә таба борылачак. Шул арада күршеләр азрак сулу алып, талкынган гаскәрләрен тәртипкә китерергә өлгерерләр.

Шулай фикер йөртте комбат. Тәки дөрес булып чыкты бит. Жуковтан укыдым. Ахырдан[1].

Маңгае тирләп чыккан Баталов, рота командирларын чакырып, заданиене аңлатты, аннары урман аланлыгында стройга тезелгән сугышчыларга:

— Бу безнең беренче һөҗүм. Дошман көчле, ул безнең Кызыл Армияне тар-мар иттем дип уйлый. Без моның болай түгеллеген исбатларбыз. Без җиңәргә тиеш. Фашист моннан Мәскәүгә йөз тота. Моңа юл куймагыз! Кирәксә, үләрбез, ләкин барыбер җиңеп үләрбез! Тарих безне онытмас! — диде.

Беренче булып разведчиклар кузгалды. Аннары беренче, икенче роталар китте. Кичү уңышлы чыкты. Куе камыш арасыннан чыгып өч юнәлештә ярга мендек. Граната шартлаулары, мина чинаулары, көчле «ур-ра!» тавышлары иртәнге тынлыкны бозды. Немецлар, геббельс радиосы хәбәр иткәнчә, «пыр туздырылган» совет гаскәрләренең Днепрны кичеп, контрһөҗүм ясауларын бөтенләй көтмиләр иде. Саперларга ике бәләкәй танкны да кичүгә хәзерләргә боерык биреп калдырган комбат үз сугышчыларын атакага күтәрде. Авыл халкыннан казытылган траншеяларда аяусыз кул сугышы башланды. Батальон Придорожье, Заградье һәм Заводная авылларын бер үк вакытта камады. Көчләрнең яртысыннан күбрәге әле елгада, тик аларны көтеп вакыт әрәм итмәдек.

---

[1] 21 нче армия бу контрһөҗүме белән 8 немец дивизиясен тоткарлады. Бу хәл ул чакта зур әһәмияткә ия булды. 13 нче армиянең Могилев районында ныклы оборонасы, 21 нче армиянең Бобруйск янындагы һөҗүм операцияләре Рославль юнәлешендә дошманның алга баруын шактый тоткарлады. Немец «Үзәк» армияләре төркеме командованиесе 21 нче армия хәрәкәт иткән районга башка участоклардан берничә дивизия китерергә мәҗбүр булды.

Г. К. Жуков. Истәлекләр һәм уйланулар, 307 бит.

— Беренче рота, уңнан кама! Икенче рота, сулдан! — дип команда бирде Баталов.

Әйткәнемчә, контрһөҗүмне һич көтмәгән фашистлар, «ике ротага» кичүдән дә шактый ярдәм агылуын күреп, ашыгыч төстә чигенү ягын карадылар...

Ямь-яшел агачларның киң яфракларын лепердәтеп, диңгез җиле исеп куйды. Чәчәкләр дәррәү җиргә таба иелеп алдылар. Янәшәдәге эскәмиядән газета очып төште. Газета астыннан буяулы рәшәткә тактасына пәке белән: Люба+Гоша=мәхәббәт дип уелган сүзләр күренде.

— Менә безгә разведка мәгълүматлары китергән кыз куйган кебек, биредә дә хач галәмәте бар, — диде кинаяле итеп әңгәмәдәшем. — Кеше артын куясы җиргә язып киткән бит... Шул да булдымы мәхәббәт?! Тьфү!, Бозганнар эскәмияне. Бер төрле дә җәза бирмәгәнгә шулай майлары котыра. Бөтен Кавказда, Кырымда юллардагы тукталышларга соңгы өч-дүрт ел эчендә төрле диңгез җанварларына охшаган нәмәрсәкәйләр ясалды. Әкәм-төкәм, сигезаяк, кысла, диңгез йолдызы — ни генә юк! Һәммәсе бетоннан, төрле төстәге пыяладан, чынаяк кисәкләреннән. Күз явын алырлык. Менә шулар хәзер кубарып алынган, купмаганы сугып чәрдәкләнгән. Корчаңгы ат тәненә охшап калган ялангач стенада мең төрле исемнәр. Нәкъ эскәмиядәге кебек. Җитмәсә кызлар үз исемнәрен яза: Аня, Люба, Маня... Тыйнаклык, пакьлек үрнәге булган кыз баланың шундый әшкә кулы күтәрелсен әле!.. Бу инде уйланырлык хәл. Дөньяның оҗмахы булган урыннарга килеп болай шөкәтсезләнү акылыма сыймый минем. Кеше бәлки гомерендә беренче кат аяк баскандыр бу кадерле җиргә? Мең төрле мәңге яшел агачлар, җитедән-җите, көләч чәчәкләр, көләч диңгез, зәп-зәңгәр күк, киң тигез юллар... Һәм көтмәгәндә шушы язулар. Кешенең кәефе китә, билгеле. Китмини! Матурлык, бөтенлек бозылган. Мондый кыргыйлык табигатьтә юк ул! Кеше тәртипсезлектән, усаллыктан тәм таба башласа — яман! Ник ваталар тукталыш урыннарындагы бизәкләрне, ник тырныйлар затлы стеналарны, эскәмияләрне? Нинди афәт бу?

Кемгә ачу тоталар? Үзләрен ашаткан-эчерткән, киендергән, белем биргән ата-анасына, кырда, фермада, завод-фабрикада эшләүчеләргәме? Миндә хаклы сорау туа: ни кылган әле бу яшьләр шушы матурлыкны булдыруда, үстерүдә, сыңар кадак кактыларммы, бер төп куак утырттыларммы? Юк бит, юк. Узындырдык без аларны! Нигә узынмасыннар, соры корт күк әзергә-бәзер ашап яткач!! Өстәвенә, андыйларны тәртипкә чакыру буенча рәтләп пычагым да эшләнми. Тезгенләү җитми. Әйе. Үзебез, ата-аналар да инде, әйтер идем. Менә бу имзаларның хуҗасын табу белән кем кызыксына? Бер мин. Инвалид карт. Ә башкалар? Борын гына җыерала р. Янәсе, шул да булдымы эш... Любалар, Гошалар биредә меңәрләп түгел бит. Иң әүвәл бу исемнәрне укып ата-ана борчылырга тиеш иде. Диңгезгә шуннан узып йөриләр бит. Күреп узалар. Ник берсе кыл кыймылдатсын! Милиция дә узды — күрмәмешкә салынды. Вәт ничек бит эшләр. Хәерлегә илтми мондый ваемсызлык. Илтми!.. Мин зур укыган кеше түгел. Барлы-юклы биш класс. Уйлап-уйлап карыйм да мондый нәтиҗәгә киләм: җәзасыз калу — җинаятькә капка ачу бит ул! Йөрәк әрни, туган. Кан коюларыбызның бәясен арзанайтуга йөрәк әрни. Ярар, сүз сугыш турында иде. Дәвам итик...

Заградьеда хәл авыррак булды. Немецлар инде үз күршеләренә ике рота түгел, барлы-юклы ике взвод авылдан бәреп чыгаруын хәбәр итеп өлгергән иде. Шуңа күрә баталовчыларның кисәк бәреп

керергә омтылулары барып чыкмады. Җиргә яттылар. Моның шулай буласын алдан ук күпмедер сизенгән комбат та килеп җитте. Билгеле, мин аңардан бер адым калмыйм. Мин аны сакларга тиеш... Баталов шунда ук хәлне чамалап алды. Кичекмәстән икегә бүленеп, як-яктан һөҗүм итәргә кирәк иде.

Бәләкәй куаклар артына яткан комбат, ярым күтәрелеп:

— Лейтенант Гарнага! Шуышып беренче взвод белән уңга! Һөҗүмгә күтәрелү сигналы — яшел ракета. Башкалар — минем арттан! — диде.

Пулялар куаклыкны кыеп-кыеп төшерәләр. Миналар ухылдый. Бернигә карамыйча калкулыкка чаклы шуышып баргач, комбат яшел ракета атарга боерды.

Кабат бик каты «ур-ра!» кычкырып, комлы һәм эссе һава сулап, алга йөгердек. Егылып калучылар да булды. Сөякне нык чәрдәкләмәсә, җәрәхәтләрне сизмисең аны. Кан, тир исе бергә кушылды. Пулеметын бу якка борырга маташкан фашистка комбат атып өлгерде. Икенче номерның күкрәгең ординарецның штыгы үтәли чәнчеп чыкты.

— Алга! Алга, егетләр!

Тагын ун-унбиш минуттан дошманның эшен бетердек. Флягалардан ирен чылатып, яралыларны җыеп алгач, кәтүкләрен тартып, элемтәчеләр үтте. Батальонның бу якка күчеп өлгергән радиостанциясе комбатны полк белән сөйләшергә чакырды.

— Корпустан боерык килде,— диде штаб начальнигы Гордов.— Комкор Петровский авылларны алырга һәм Бобруйскига чаклы һөҗүм итәргә рөхсәт бирә...

— Батальон авылларны алды,— диде Баталов.

— Котлыйм, комбат.

— Алу әле эшнең яртысы гына...— Баталов фикерен тәгәлли алмады, лейтенант Гарнага дошманның һөҗүмгә күтәрелүен әйтте. Ике ара якын иде инде. Әллә тагын штык сугышына күтәрелергәме? Билгеле, егетләр сынатмаячак. Тик мондый алышу корбансыз булмый. Сугышчыларны сакларга кирәк. Көн башлана гына. Гомумән, солдат гомеренең кадерен белү — Баталовның канына сеңгән иде. Гранаталар аз-азын, ләкин иң кулае хәзергә шул.. Комбатның кысыла төшкән күзләреннән шуны укыйм.

— Гранаталарны әзерләргә! Якын ук җибәрергә!.. Минем боерыкны көтәргә...

Бераздан аның «Пли» дигән командасы ишетелде.

Шартлаулар тынар-тынмас, кечкенә танкларның кичүдән исән-аман чыгуларын белеп өлгергән комбат, операциянең үзе уйлаганча баруына куанып, сикереп торды:

— Рота, минем арттан, алга!

Хәрби фортунаны үзләренең гомерлек юлдашы дип санаган вермахт гаскәрләрен бүгенге җиңелү тәмам шашындыра иде, әлбәттә. Эфир элеккеге позицияләрен һаман әле кайтарып ала алмаган группенфюрерларны сүгү белән тулды. Фашистлар бу төбәккә яңадан-яңа көчләр тарттырдылар. Ләкин туган җир туфрагына тирән окоплар казып урнашкан батальон чигенмәде. Ярсып алты тапкыр өскә ташландылар. Окопларыбызны ике мәртәбә самолетлар «сөреп» китте. Югалтулар булмады түгел, булды. Шулай да батальон сугышырга сәләтле иде әле. Дивизия тарафыннан кирәк-ярак белән азмы-күпме тәэмин ителгәч, үлгәннәр урынына штабчыларны һәм хуҗалык ротасындагыларны да сафка бастыргач, Жлобинны алырга кузгалып киттек. Каш астындагы күз кебек саклаган танклары-

быз ярап куйды — утырып киттек. Билгеле инде: һәммәбез түгел. Күз алдыма китерәм дә әле дә йөрәгем әрни: иңдә скат, биштәр, билдә фляга, гранаталар, кулда мылтык яки карабин... Июль ае бит, кояш рәхимсез кыздыра. Биттән тир елга булып ага, аркалар тозланып брезентка әйләнде. Әмма солдат түзә, кушканны үти. Йөгерә. Фриц кереп оялаганчы барып җитәргә кирәк. Вакыт кадерле, вакыт.

Берзаман барып җиттек без. Фриц өстенә күктән төшкән кебек булдык. Жлобинның кырыендарак торган тимер юл корылмалары тирәсенә килеп чыкканбыз. Күңеле сизенепме, Федор Алексеевич, ягъни комбат, ул чакта әле капитан, бу юлы бөтен бер полк белән җитәкчелек иткәндәй:

— Полк, танклар артыннан алга! Дошманны юк ит! — дип кычкырды. Рациядән дә шул ук боерыкны кабатлады. Чак кына алгарак китеп булса да әйтим: бу сугышта немецлар полк командирын үтерделәр. Полк Баталовка тапшырылды. Мин әүвәлгечә һаман аның янында, һәммәсен күреп-ишетеп торам, тән сакчысы да булам, кирәксә, элемтәчесе сыйфатында боерык тапшырырга китәм. Ярый әле радиостанциябез төгәл эшли — донесение-фәлән ташыйсы түгел.

Батальон тулысынча килеп җитмәгән әле. Мондый чакта алдан баручылар аларны көтеп тора аламыни? Скатларны, биштәрләрне җиргә ташладылар да, изүне ачып, әйдә җан-фәрманга дошман өстенә! Кайберәүләр ялан баш, кайберәүләр гимнастеркасыз. Чәч туздыган, тирләгән, бит ком гарәбенеке төсле кап-кара. Бик яман «ура!» тавышы яңгырый. Түзмәдем, комбаттан рөхсәт сорап, мин дә йөгердем. Чөеп аттык фрицны деподан. Йөзләп мәет аунап калды. Исәннәре корал ташлап качтылар. Шушы сугыштан соң, ахры, 21 нче армиянең Идел буенда төзелүен белеп, дошман безне кыргыйлар берләшмәсе дип атады.

Эшне бетергәч, сорыйм бер мәл егетләрдән: бу юлы иң авыры ни булды? — дим. — Пулеметка каршы баруммы, әллә штык сугышына керүме? Ничек дип җавап бирделәр диген!? Гвардеецларча!

— Иң авыры полк чаклы иттереп «ур-ра!» кычкыру булды, — диделәр.

Куа киттек фрицны. Күршедәге 61 нче дивизияләр дә булышты — алдык Жлобинны.

Югалтуларыбыз күп түгел, әмма берәгәйле иде — полк командиры һәлак булды.

Шәһәр халкы подвалларлардан чыкты. Без кайтканга ышанмыйча торалар. Зур хәсрәтебез аларга мәгълүм түгел — үбәләр, кочалар, тамак ялгарга чакыралар.

Берсе миннән:

— Командирыгыз нәрсә ярата? — дип сорый.

Шул чакны арадан бер кычыткан чыпчыгы:

— Мин беләм: бу командир абый бик тә чәчәк ярата. Розалар! — диде.

Текәлебрәк карасам — елга аркылы көймәдә чыккан кыз. Разведчик. Танымаган да булыр идем — сул күз кабагы өстендәге мәхәббәт миңе кылт итеп искә төште. Башына ураган беләк юанлыгы толымы өстенә пилотка чәпәгән, гимнастерка белән чалбар киеп алган. Билен ике кат буган каешы да бар. Итекләре генә зуррак — һәр кунычына өстәп берәр шешә салып куярга була. Аңлашылды: комсомолка Маша Большакова үз теләге белән Кызыл Армиягә язылган. Безнең полкның икенче батальонына беркеткәннәр. Андагы егетләр киендергән аны шулай җиңел кулдан. Язылган-язылган, нигә инде беренче батальонга җибәрегез дип әйтмәскә иде? Без инде

аңа итекнең кирзасын түгел, хромнан теккәнен тапкан булыр идек. Хәер, бу зур итекләрен тиз алыштырды ул. Теге чакта комбат әйткәнчә, менә дигән разведчица чыкты үзеннән. Иске-москысын киенеп ала да, капчыгын асып, авылларга чыгып китә. Толымнарын кистермичә саклап калуы иллә дә ярады кызга! Шик тудырмый. Шулай итеп дошман гаскәрләренең кайда урнашуын белеп кайта. Нәтиҗәдә, тәки «Наша Маша» булышлыгы белән камалыштан чыктык бит, әй. Монысы инде — аҳырданрак. Ә хәзергә кыз Жлобин урамнарының берсендә үзе ише җилкенчәкләр китергән гөлчәчәк бәйләменә карап елмая иде.

Алды чәчәкләрне комбат, бераздан аларны үзәк мәйданда калкып чыккан кабер өстенә салдык...

Сугыш. Рәхимсез ул! Әх, бөтен дөнья малына алыштыргысыз күпме ирләрне вакытсыз күмдек бит ул көннәрдә! Ашык-пошык күмелгәннәре дә булмады түгел. Еш кына окоп төбенә ләхет уеп казып кәрәсең дә битенә пилоткасын каплыйсың: бәхил бул, рәнҗемә, туган... Яталардыр ул бәгырькәйләрнең сөякләре билгесез окоп төпләрендә. Немец андый окопларның күбесен, тере солдат бардыр дип, танк белән тигезли иде. Вакыт-вакыт безнең «мәетләр», көтмәгәндә терелеп, тегенең иманын укыталар иде бит... Калды алар аста. Шома ташлы һәйкәл дә юк өсләрендә, кызыл йолдызлы калай пирамида да... Ә синең, хөрмәтлем, калаларыбыздагы каберлекләргә барып зиярәт кылганың бармы? Туганнар кабере булганнарын әйтмим, андыйлары чәчәкле, мәрмәр ташлы — шәп. Гражданский каберләр турында сүз. Анда рәтле тәртип юк безнең. Тигезлек сакланмый. Кем ничек булдыра ала, шулай күмә. Аннары: ни пычагыма анда чуеннан, корычтан эшләнгән рәшәткәләр?! Мәетләр чыгып китмәсен өченме?! Кайда бар тагын шундый хәл?.. Инде килеп каберлекнең түренәрәк күмелүчеләргә игътибар итик. Советлар Союзы Герое, дәүләт эшлеклесе, генерал, атказанган табиб, профессор, әдип, артист, композитор һәм башкалар — боларына һич сүзем юк. Дөньялыкта ил, халык өчен күп көч сарыф итүчеләр — инде тыныч кына йоклый бирсеннәр. Кабер өстендәге мәрмәр һәйкәлләре дә — ихтирам-хөрмәт билгесе. Андыйларга безнең хөкүмәт үзе һәйкәл куя һәм, әйтергә кирәк, бик дөрес эшли. Тиешенчә хезмәт итсәң, үлгәч тә онытылмыйсың!.. Моннан нинди нәтиҗә килеп чыга? Нәтиҗә шул: каберлек ул мәет күмү урыны гына түгел, тәрбия кылу урыны да. Һәм бик үтемле тәрбия кылу урыны! Шулай икән, нигә соң әле кайчакларда затлы һәйкәлләр, еллар узу белән онытылып, кызганыч хәлгә килә: буявы уңа, цементы ярыла? Аларны карарга совет хөкүмәтенең акчасы юкмы? Бар! Бик бар! Тик кул җитми. Теләк җитми. Шундый мескен хәлгә калган һәйкәл янына тукталып, теләсәң-теләмәсәң дә: «Бу гүр иясенә бүгенге башлыкларның сукыр бер тиенлек ихтирамы юк икән»,— дип уйлый башлыйсың.

Моның тагын бер ягы бар: каберлектә акчаның һәрнәрсәдән өстен икәнлеге күренә. Ничек күренәме? Менә күз алдыңа китер: болары ил, халык эше өчен җан атып яшәгән мәхтәрәм кешеләрнең каберләре. Инде стоп! Янәшәдә генә, рус миче чаклы шома мәрмәргә алтын хәрефләр белән туу һәм вафат булу еллары язылган гүр иясе кем? Мәһабәт таш астында кем сөякләре? Болар бөө санап үткән герой да, дәүләт эшлеклесе дә, атказанган җырчы да түгел. Ә кабер өстендәге һәйкәлләре җырлап тора! Тик безгә кирәкле җыр түгел ул! Түгел... Берәүнең сөекле ире, хатыны яки бердәнбер газиз баласы булган өчен генә болай алтынлап зур мәрмәр ташлар бастыру тыйнаксызлык түгелме икән? Әткәңнән яисә әнкәңнән дип ташка имзасын салган бәндәләрнең кереме дәүләт белән ярышырлыкмы, хәләл көчкә салынганмы?

Заманында байгураның урыны һәрвакыт түрдә булган. Кешене изү юлы белән табылган мал-мөлкәтне без бүген өнәмибез. Һәм дөрес эшлибез. Әйе. Ул чакта яраган. Патша үзе дә меңәрләгән дисәтинә җирнең хуҗасы саналган. Байны патша законы яклаган. Ә хәзер байлык җыю чире баш калкытып, чын-чынлап лаек булмый торып үзеңә почет даулауны безнең закон каты тыя. Шуларны истә тоткан хәлдә янә каберлеккә әйләнеп кайтыйк. Мирас булып күчкән байлыгы да, ил, халык ихтирамын казанып яуланган хокукы да булмаган бу бәндәләр ничек болай түргә үк узганнар соң? Авыр туфраклары җиңел булсын, мин аларны кыерсытырга җыенмыйм. Аларга — барыбер. Аларга хәзер берни кирәкми. Тереләргә менә барыбер түгел.

Чөнки боларны күреп тормыш итә башлаган яшь кеше мондый нәтиҗә ясарга мөмкин: дөньяның да, ахирәтнең дә иманы — акча икән! Акчаң булса, монда да урын түрдән икән! Давай, нәзбереклэнеп торма, түл җый! Акча ашарга сорамый. Кайдан алдың дип сораучы да күренми. Дуй, әйдә!

Вәт кайларга китереп чыгарды билгесез окоп төпләрендә күмелеп калган солдатларның газиз сөякләре!

Күмдек шул, бик күпләрне шулай окоп төпләренә күмеп калдырдык ул көннәрдә. Безне фашист тәмам кырып бетерергә теләде. Дөнья җимереп Мәскәүгә таба ыргылганда шәһәр, авылларны кире биреп чигенү немецның кәтигенә кадалмагандыр дисеңме? Алгарак китеп булса да әйтим: Жлобинда тукталып калмыйча, Рогачев дигән каланы да алдык әле без. Бобруйскига җитә яздык. Әгәр техника булган булсамы? Тылдан бернинди ярдәм килмәде бит безгә. Ник дигәндә, безнең 21 нче армияне урап узып, немец әллә кая чаклы киткән иде инде. Боларны без ахырдан гына белдек, әлбәттә.

Онытканчы тагын шуны әйтим әле: Баталов ифрат та тапкыр командир иде. Бер мисал гына китерәм, Рогачевны алдык дигән идем бит әле. Кала алу тел белән тегермән тарттыру гына түгел ул. Гарьлегеннән шартларга җитешкән генералларның безнең окопларны артиллериядән һәм минометлардан ничә рәт утка тотуын сөйләп тә тормыйм. Ә Федор Алексеевичка янә бер кат рәхмәт әйтүне кирәк табам: безне җиргә тирәнрәк казып керергә мәҗбүр итте ул. Дошман минасы лепкәнә төшеп шартламаса, селкенеп өстеңнән туфракны кагасың да — бетте-китте. Ул самолетларның кайчан бомба ташлаячакларына кадәр белә иде. Баштарак, үзең беләсең, солдатның тәҗрибәсе ташка үлчим. Үкереп-гүләп өскә килә башласалар, котың ботыңа төшә. Көпчәкләрен эчкә алмаганга шыксыз булып тырпаеп торган «Юнкерс»ларны бик мыскылласак та, алар, ай-һай, җанны кыйнады безнең. Ир мактана, корал эшли дигән борынгылар. Җир куенына сеңәрдәй булган мескен солдатны әнә шул «чабатачы» ничә рәт килеп дөмбәсләп китә.

«Юнкерс»лар турында иде гәп. Федор Алексеевич шуны чамалый иде. Серен безгә дә өйрәтте. Менә килә тегеләр җәелеп, масаеп. Киң җилкәле, баһадирдай таза гәүдәле комбат, коңгырт күзләрен кыса төшеп, кара тәреле самолетларны күзәтә. Аннары чырайлары агарынган яшьрәк солдатларга карап:

— Баш ияргә ашыкмагыз, егетләр. Дошманны танырга өйрәнегез. Киң фронт белән килгәндә — үтә ул,— ди.

Ә кайвакыт тиз-тиз каскасын батырып кия, җиргә тирәнрәк яшеренергә куша:

— Шуны исегездә тотыгыз: чылбырдай тезелә башласалар — цельгә керү өчен ул, егетләр.

Чинап, үкереп, кояшны каплап баш очыннан газраил уза. Җир селкенә. Колак тона. Самолетлар бер-бер артлы үтеп беткәч, икенче әйләнешкә керәләр. Алар киткәч, артиллерия атарга тотына. Аннары пехота кузгала. Исән калучылар бик аздыр инде дип уйлыйсың. Менә оясыннан чыккан йомрандай берәү баш калкыта, икәү, өчәү... Карыйсың, беркадәр халык исән. Болар белән эш майтарып була әле!.. Комбат акыллы иде шул безнең: әле алдавыч окоплар казыта, әле фанердан пушкасын, танкын әмәлләтә. Тегеләр еш кына шуларны дөмбәсли. Ә төп көчләр киң кырга сибелеп яшеренгән була. Шуңа күрә бомбежкаларның, туптан атышларның безгә күп зыяны тими иде.

Немец очучылары, тупчылар үз башлыкларына кыргыйлар корпусын, ягъни безне, тулысынча юк иттек дип кат-кат мактангannардыр, мөгаен. Кулдан ычкынган позицияләрен хәзер ансат кына кайтарып алабыз дип килә берзаман җиңнәрен сызганып фрицлар. Ә без аларга янә күрсәтәбез күрмәгәннәрен. Фашистларның ачудан янә үт куыгы шартларга җитешә. Янә төп юнәлештән алып, өстәмә көчләрне бире ташлыйлар. Бервакыт Бобруйск янында хәл тәмам мөшкелгә әйләнде: тегеләр кара болыт кебек өскә ябырылды. Комбат каш астындагы күз кебек саклаган теге ике «бәләкәч»не засададан чыгарырга боерык бирде. Бер тапкыр гына йолып алмады алар безне бәладән. Бу юлы да шулай булды. Су сиптерүче машинадай, коендыралар фашистны кургаш яңгыры белән. Кайберәүләр дошманны тәмам ахмак итеп күрсәтә. Булыр немец ахмак, тот капчыгыңны! Безнең ике танкны шундук күреп алдылар. Күрмичә, йөздән артык гитлерчыны тиз арада кырып салдылар ич. «Бәләкәчләрне» трофей итеп алырга чамаладылар, ахры, арттан килеп өскә үрмәләделәр. Йөртүче карый торган ярыкларны томалагач, «бәләкәчләр» туктадлы. Сукыр килеш кая барасың? Калды безнекеләр чебен сарган баллы телемнәр сыман уртада. Без читтә. Безгә каршы, төз басып, бер рота психик атакага килә. Мондый атаканың ни икәнен сөйләп тормыйм. Әмма дә ләкин күңелле нәрсә түгел ул, шайтан алгыры!..

Кызылармеецларның күзе майорда. Баталовка яңа звание биргәннәр иде инде. Нишләр, нинди карарга килер полк командиры мондый кыен хәлдә? Тозакка эләккән танкларны йолып алырга җибәрергәме, әллә «психлар»ны ут ачып каршыларга боерыргамы? Тегеләй дә вай, болай да...

Шул арада әрсез немецлар, люк түбәсен шакып:

— Рус, сдавайсь! — дип кычкыра башладылар. «Психлар» да якын килде.

— Федор Алексеевич, башта танкларны коткарыйк,— дим.— Юкка әрәм булалар бит! Давай кул пулеметлары белән бәрик!

— Ә монда ни кала? Танклар бу психларның артына төшәргә тиеш. Шуны көтәм мин.

— Ничек артка төшсеннәр? Күрмиләр бит алар.

— Күрерләр... Әрсез десантны да юк итәрләр.

— Ничек?..

Федор Алексеевич бинокльдән бу якны күзәтә иде. Ул салкын кан белән генә: «Танкистлар үзләре искәрмәсә, син барып әйткәч, Миша,— диде.— Бар, сержант, радистка минем боерыкны тапшыр: танклар кичекмәстән бер-берсенә атып, чакырылмаган кунаклардан чистарынсыннар да һөҗүм итүче ротаның артына төшсеннәр...»

Ну баш үзендә! Үзе бер Верховный Совет! Гади генә чишелеш, югыйсә. Безнең «бәләкәчләр», моторларын көчлерәк эшләтеп, шул тавышка бер-берсенә ата башладылар. Пулемет утыннан үзләренә пычак та булмады, ә фриц күкрәге бронялы түгел...

Кыскасы, янә измәсен издек дошманның. Немец тәненә каен шырпысы булып кадалган безнең гаскәрләрне үз тылында калдыра алмый иде инде. Мәскәүне тез чүктерергә билгеләгән берләшмәләрне безгә каршы ташладылар. Безгә ярдәм булмады. Болай да аз калган идек инде. Каты сугышларның берсендә яраландым. Мине, Маша булышлыгы белән, урман каравылчысы өендә сәндерәгә салып киттеләр. Машага: «Барыбер эзләп табармын мин сине!» — дип кычкырып калдым.

Мылтык тотып сугышырга ярамадым. Ләкин барыбер тылда кала алмадым. Хуҗалык ротасында хезмәт иттем. Һаман элеккеге иптәшләрне эзләдем. Фронт юллары очраштырыр сыман тоелды. Кая ул! Берәү дә очрамады. Күбесе һәлак булган, бүтән частьларга күчкән. Баталов турында да төгәл мәгълүмат бирүче булмады. Кайсылары аны минага шартлады дип язды, кайсылары хәбәрсез югалды диде. Андый кешеләр хәбәрсез югала димени?! 1941 елның 9 августында Федор Алексеевич Баталовка Советлар Союзы Герое исеме бирелгән булып чыкты. Игътибар итегез: 9 августта. Сугышның кырык сигезенче көне иде бу. Менә шулай чигендек без...

Эзләгән — таба, ташка кадак кага дигәндәй, язмыш, беләсезме мине кем белән очраштырды? Әйе, кече лейтенант Маша Большакованы эзләп таптым мин. Хат язышып, билгеле. Камалыштан чыккач, кыз бүтән частька эләккән. Дөресрәге, Маша бер фырт кына диңгезчегә гашыйк булган. Диңгезчеләр, туган, кыз-кыркынның башын әйләндерә белә ул. Нишлисең, җаны теләгән — елан ите ашаган... Диңгезче белән хезмәт итәргә туры килмәгән килүен. Фронт юлларында аерылышканнар. Табышулары кызык. Большакова 21 нче армия составындагы баталовчылар әллә рейхстагка килеп җитә, әллә юк дип, комбатның кырык бердә әйткән сүзләрен исенә төшергән дә: «Без рейхстагка килеп җиттек!» — дип язып үз фамилиясен сырлаган. Диңгез пехотасында сугышкан фырт егеткә дә Берлинга керү насыйп икән. Рейхстагка килсә, стенада сөйгән кызының сәламе көтә. Элемтәләре өзелгәч, һәлак булгандыр дип уйлаган егетнең өмете яңарып китә. Эзли кызны. Таба. Өйләнешәләр. Өлгер егет икән шул. Алгарак китеп булса да әйтим: диңгез пехотасында вакытта, «Кече җир»дә иптәш Брежнев кызыл кенәгәне аңа үзе тапшырган... Боларны мин ахырдан гына белдем. Машаның кияүгә чыгуын белмичә, аңа хат арты хат язып тордым. Сәламәтлеге чамалы икәнен белгәч, бераз гына өметләнеп тә йөрдем. Санаторийда баш врач белән ныгытып сөйләшкәч, «непременно кил!» — дип телеграмма суктым. Килеп төштеләр икәүләп... Сер бирмәдем, әлбәттә. Башта Машаны танымадым. Ул чакта кычыткан чыпчыгы иде бит. Ә монда — юанаеп баручы ханым. Калын толымнарын да кистергән. Сул күзенең кабагы өстендәге тары ярмасы хәтле генә мәхәббәт миңенә күзем төшкәч кенә таныдым. Бу миңне аның белән урман каравылчысы өендә саубуллашып үбешкәндә күргән идем. Әйе... Теләсәгез, хөрмәтлем, Машаны үзегез дә күрә аласыз. Монда ул. Ире белән. Озакламый коеныпга төшәрләр. Көн җылыткач төшәләр алар. Нәкъ сигездә. Әнә... үзе дә. Бүген нигәдер үзе генә. Әллә карты чирләп китте микән.

Бакчачы картның уйчан йөзендә әчке мөлаемлелек балкып китте. Кабаланып урыныннан торды, көмеш чәчле ханым утырырга тиеш эскәмиянең тузанын сөрткәндәй итте.

Мин, үземне артык санап, диңгезгә төшеп киттем. Диңгез, хәләлен көткәндәй, назлы елмая иде бүген. Талгын су шатлыклы күз яшьләре кебек үтә күренмәле. Төбендә мәрҗәннәр сыман ташлар сибелгән.

*
* *

Бакчачы картның кунаклары белән якыннан танышып, тора-бара алардан күп истәлекләр сөйләттем. Иң куандырганы — Жлобин шәһәрендәге бер урамга Советлар Союзы Герое Федор Алексеевич Баталов исемен кушу булды.

Без күбесенчә диңгезгә төшә торган сукмак читендәге эскәмиядә — як-ягыбызда үскән гөлчәчәкләр хозурлыгында очраша идек. Михаил Максимыч монда яшәреп киткәндәй була, мәзәк сөйли, күзләрендә шаян очкыннар чагылып-чагылып уза. Чәнечке кермәслек булып каешланган калын имән бармагы белән тамыр тирәсендәге туфракны йомшата, яшь сабакларны төзәткәли. Телендә һәрвакыт комбат Баталов була. Дәһшәтле сугыш күренешләрен хәтерендә яңарта, мәңгегә ятып калган полкташларын искә төшерә.

Цементтан коелган кәкре баскыч янындагы эскәмиягә килеп утырган теге кызлар март чыпчыкларыдай чыркылдашалар. Бу якка әледән-әле күз сирпүләренә караганда, безгә гаҗәпләнәләр шикелле: нигә инде шул дәһшәтле елларны искә алып утырырга? Үткән — беткән. Фирәзә шикелле диңгез буйларын, төпсез күкне, шушы матур чәчәкләрне ташлап ничек инде утка кермәк кирәк?!

Ә бакчачы карт кырык бернең июле турында сөйли дә сөйли. Утыз сигез ел гомер үткән. Кеше хәтере — төпсез хәзинә икән. Ни генә юк анда...

Фронтовиклар бүген өчесе дә шат. Аларга бернәрсә кирәкми. Хәрәкәтләреннән бер-берсенә ихтирам бөркелә.

Беркөнне Михаил Максимович кунаклары белән теге матур чәчәкләр үсеп утырган куентыкта басып тора иде. Аяк өсте булулары кургәч күңелгә шом йөгерде. Бакчачы картның кыяфәте йортҗире янган кешенекедәй иде. Күзләрендә аптырау, әрнү. Иреннәре дерелди, куллары хәлсез салынып төшкән.

— Кирәк бит, — диде ул, үкенечле тавыш белән, — нәкъ көнендә. Юри эшләгән кебек... Ничә ел тырышып... Шушы өч чәчкәне калдырып, бөтен бакчаны өзсәләр дә болай әрнемәс идем. Читләре кара каймалы, бик тә нәфис алсу иделәр бит ул розалар. Бу сортны «Комбат истәлеге» дип атаган идем... Аһ, кулыгыз каймыккырылар!.. Җәзасыз үтмәс бу эшегез! Төшәр чәчәк каргышы, төшәр!.. Ярый әле башка түтәлдә шушы сортның үсентеләрен калдырган идем...

Максимыч мәет озаткандагыдай моңлы тавыш белән сөйләнүендә булды. Аны юату мөмкин түгел иде. Моны беребез дә кирәксенмәдек. Әйдә, бушатсын хәсрәтен.

— Тукта,— дидем мин шунда,— бүген кайсы число соң әле? 18 июль бит. Утыз сигез ел элек бу көнне комбат Баталов һәлак булган.

Сул күз кабагында мәхәббәт миңе булган Мария Васильевна да, ире Николай Владимирович та, иреннәрен тешләп, тынып калдылар.

Җил исеп куйды. Эскәмия тирәсендәге чәчкәләр, кайгы белдергәндәй, башларын түбән иделәр. Иртән явып узган җылы яңгыр тамчылары чәчәкләрдән карт йомшарткан җиргә коелды.

Мин диңгезгә юнәлдем. Әле кичә генә фирәзәдәй саф диңгезнең чырае караңгы иде. Зур-зур дулкыннар, бер-бер артлы килеп, ярга ыргыла һәм, авыр көрсенеп, анннары кире чигенә. Һәм тагын шулай кабатлана...

*Июль — август, 1979 ел.*

**Диас Вәлиев**

# ПОРТРЕТ

хикәя

## I



Көн уртасы. Кызу. Асфальт тәмам йомшарган. Калкулыкка урнашкан чал Кремльнең ак диварларын урап алган бульварда кеше-фәлән юк. Бульвар ґүя бөркү һавада асылынып калган да, әкрен генә каядыр йөзә; кояш нурлары да иң элек шул бульварга төшә сыман. Калкулык итәгендәге үзәнне тутырып саргылт сулы елга ага, анда-санда карамчык сыман көймәләр йөри, җәелгән суны икегә бүлеп торган дамбаларны чыккач шәһәр урамнары башлана. Рәшә сулышына өртелгән шәһәр елганың аргы ягында да дәвам итә. Моторлы көймәләр, машиналар тавышы бульварга җитәр-җитмәс зәгыйфьләнә, шәһәрнең башка авазлары да шушы эсселектә эри, йотыла бара һәм калкулыктагы кешегә ниндидер гүләү булып кына ишетелә.

Башта бульварда бер ир-ат күренде. Төз гәүдәле бу кеше көн кызуын сизмәгән дә кебек салмак кына атлап килә иде. Озын буйлы, ак күлмәк-чалбардан, күлмәгенең җиңнәре сызганылган, сул кулында каяндыр өзеп алган әрем сабагы. Шул әрем белән атлаган уңайга ботына суккалый. Бульвар кырыена җиткәч, ул шактый вакыт саргылт елгага карап торды, аннан акрын гына кире борылды. Күп тә китмичә, киң ябалдашлы тополь күләгәсендә торган эскәмиягә килеп утырды, аягын чалыштырып куйды, кулларын эскәмия аркасына җәеп күзләрен йомды.

Аннан бульварда бер хатын күренде. Башын аскарак иеп сумкасы белән уйнап килә иде ул. Коенып чыкканга күрә, арыш саламы төсендәге юеш чәче кояшта ялтырап тора иде. Адымнары җиңел, хәрәкәтләре иркен, гәүдәсенә килешеп торган чәчәкле күлмәге дә аңа комачауламый кебек. Күләгәдә эскәмия күреп, ул башын күтәрде, кулында сумкасын әйләндергәләп торды да, ниндидер бер ният белән килеп утырды.

Беравык эскәмиядәге бу ике кеше бер-берсенә игътибар итми утырдылар.

Яннарыннан өч кыз йөгереп үтте. Аннан чемодан тоткан кара киемле карчык узды. Хатын аның артыннан сәерсенеп карап торды

һәм шунда якты күзләре эскәмиянең теге башында утырган ирнең йөзенә тукталды.

Ул торган саен гаҗәпләнә барып иргә карап торды, ир кеше исә үзенә текәлгән карашны сизеп, ниһаять, күзләрен ачты, аңа борылды һәм шунда бу ике кеше берсен-берсе күреп алдылар.

Күктән самолет очып узды, гүләү тавышы Кремль диварларына сугылып җиргә сеңде. Тавышны шәһәр өстенә асылынган бөркүлек йотты.

Бер мәлгә алар шулай бер-берсенә караган килеш утырдылар. Бу минутта әйләнә-тирәдәге бөтен нәрсә көннең кызулыгыннан әлсерәп, хәрәкәтсез һәм куе һавадан гаҗиз булып, шуннан котылу чарасын эзли иде сыман. Җилнең әсәре дә юк. Һәм бөтен нәрсә нидер көткәндәй тынып калган. Бу ике кеше дә бер-берсенә төбәлеп хәрәкәтсез утыра бирделәр.

Ир кеше үзен зур кызыксыну, әйтергә кирәк, күзгә бәрелеп торган кызыксыну белән күзәткән хатынны күреп торды. Хатын үзенең кызыксынуын яшерми һәм яшерергә дә теләми иде булса кирәк. Аның куе керфекләр күләгәсеннән караган күзләрендә ниндидер эчтән сирпелә торган яктылык бар иде сыман. Бу яктылык хатынның сизелер-сизелмәс елмаеп алуында да күренеп калды. Шул ук вакытта аның бөтен халәтендә ниндидер хәвефләнү, борчылу, хәтта куркуга охшаган бер тойгы сизелә иде. Ир кеше хатынның чиста ак муенына, әле ияге, әле ирене тирәсендә йөренгән озын бармакларына игътибар итте. Ул гүя ялтыраган күзләрен каплап, аларның ялкынын сүндерергә тели, ләкин көче җитми, шуңа кулы хәлсезләнеп тезенә килеп төшә иде. Ир кеше боларның барысын да күреп торды.

Хатын күзен текәгән ак чырайлы, тыныч йөзле ир кеше тураеп утырган да эсселекне сизми дә кебек. Сул кулында кечкенә генә әрем сабагы. Иң гаҗәбе дә шунда: әрем, бульвар, шәһәр, бу бөркү көн — болар барысы да гап-гади, көн дә күзгә чалына торган нәрсәләр һәм шулар белән янәшә — ул, боларга катнашы да юк шикелле утыра бирә. Хатын гаҗәпләнгәннән-гаҗәпләнә барып аның йөзен күзәтте. Аннан түземе бетеп:

— Сез бик тә охшагансыз,— диде.

— Кемгә?

— Үзегезгә. Әйе-әйе... Әйе! — хатын кинәт калтыранып көлеп куйды.

Аңа каршы ир кеше сүрән генә елмайды. Хатынның кинәт көлүендә һәм шулай сүз башлавында ниндидер сәер логика бар иде сыман. Беренче мизгелдә ир кешенең күңелендә бу хатын акылга зәгыйфь микән әллә, дигән шик тә туды һәм ул тагын аның күзләренә карады. Юк, күзләре нурлы, алардан саф яктылык сирпелә.

— Әйе, әйе, бу сез бит... Сез!

Хатын кинәт чытаеп калтыранып куйды.

— Мин сезне үзегезгә охшагансыз дидем,— дип кабатлады ул, үзгәргән тавыш белән.— Беләсезме... Мин сезгә ничек... Ничек аңлатырга да белмим, чөнки бу мөмкин түгел!.. Сез менә монда, бульварда, өстегездә ак күлмәк һәм шушы килеш нәкъ гадәти кешеләр шикелле үк. Ягъни минем әйтәсе килгәнем шул: иң гаҗәпләндергәне — без сезнең белән бер үк вакытта менә шушында, җир йөзендә яшибез. Һәм безнең сәгатьләр дә бер үк вакытны күрсәтә? Хәзер төш вакыты, мин пляжга су коерга бардым. Нинди очраклылык!.. Мин бит институтка астан гына кайтмакчы идем, соңгы минутта нәрсәдер менә монда, бульварга тартты,— дип тезеп китте ул нәрсә сөйләгәнен дә уйламыйча һәм ир кешедән күзен алмыйча.— Ә монда — сез? Сәер бу, бик тә сәер!.. Шундый сәер, миңа беренче минутта куркыныч та булып китте.

Аның күзләре ялтырый иде. Гашыйк хатыннарның күзләре генә шулай ялтырый. Ир кеше моны яхшы белә иде. Аңа мондый ялтырау таныш. Ләкин ул шуны да яхшы белә: аның бу хатын белән бер генә тапкыр да күрешкәне юк иде.

— Шулай да мин берни аңламыйм,— диде ул кырыс кына итеп.— Сез мине кем beләндер бутыйсыз, ахры.

— Юк, юк!

— Сез мине электән үк белә идегезмени?

— Әйе! Менә шул шул! Мин сезне бик күптәннән беләм!

— Монда ниндидер хата булырга тиеш. Минем бу шәһәрдә беренче көнем. Мин — килгән кеше.

— Аңлыйм! Минем сезне беркайчан да күргәнем юк... Ягъни менә бу килеш, ак күлмәктән, әрем сабагы тоткан килеш!.. Сөйләшеп утырганыгызны! Ләкин мин сезне барыбер бик күптәннән беләм! Сәер бит, шулаймы? — дип сорады ул.— Бу мөмкин түгел, әмма бу — шулай!

Хатын тагын көлеп җибәрде, аның күңеле тәмам ачылып, шатлыгы көлү авазы булып тышка бәреп чыкты. Менә ул урыныннан торып аның белегеннән тотты, үз артыннан тартты һәм кинәт ир кешенең аптыраулы йөзеннән һәм үзенең бәхетле таркаулыгыннан тагын бер көлде дә (урындыкта сумкасы онытылган) сумкасын килеп алды. Аннан бәхетле кыяфәттә гади генә итеп иргә кулын сузды.

— Мин сезгә хәзер барысын-барысын аңлатам,— дип пышылдады аның иреннәре.

Көн тагын да кыза төште. Кремль диварлары буйлап барганда аларга берәү дә очрамады...

## II

Бу хәл мең тугыз йөз кырык тугызынчы елның җәендә Казан шәһәрендә булды.

Яшәгән мохитыңда гел салкын акыл һәм көнкүреш мөнәсәбәтләре генә хөкем сөргәч, мондый хәлләрнең булуына авырлык белән генә ышана башлыйсың. Андый хәл булган очракта да, үз тәҗрибәң киресен әйтеп торгач, ничек инде ышанмак кирәк.

Әйе, дөньяда барысы да гади, бөтен нәрсә дә аңлашыла, аңлашылмый икән, аны аңлатып та була, дип йөрүчегә бу дөнья чыннан да кирәгеннән артык гадәти һәм күңелсез була башлый. Ләкин табигать менә кемгәдер шундый сыйфат бүләк итә һәм ул зат вакытның гадәти агышыннан тамыры-ние белән суырып алына; бу хәл кеше өчен ничек кенә тәмамланмасын, аның үзенә дә һәм боларны читтән генә күзәтүчегә дә, бу — күктән иңгән бүләк булып кала. Инде бөтен нәрсә актарылып ташланган, барысы да үз урыныннан купкан һәм чынбарлык белән хыял арасындагы сызык та, сөртеп ташлагандай, юкка чыккан. Хәзер синең алда җиһанның кинәт киңәеп, башың әйләнер дәрәҗәдә киңәеп киткән кырлары җәелеп ята һәм син шул кырларга хәйран калып карыйсың. Әмма читтән күзәтүче генә буларак, син ул затны көнлисең, әйе, көнлисең, чөнки күкләр сине түгел, аны сайлаганнар...

Шәһәрнең тарих музеенда ул картинаны беренче тапкыр күргәндә бу хатын яшь-яшь кыз иде әле. Ул чактагы тетрәнүен ул гомер буе оныта алмады.

Ул елларны аның күңеле нигәдер шаян һәм тапкыр яшьтәшләренең берсенә дә тартылмады. Дөньяда мондый акылсызлыкның булуы мөмкинме соң?

Көн дә музейга килеп портрет каршында озаклап басып торган

айлары да булгалады аның. Озак карап торсаң, аларны аерган стена үзеннән-үзе эри, юкка чыккан кебек була һәм портреттагы кеше иреннәрен кыймылдата сыман тоела иде. Андый чакта портреттагы күзләр дә икенче төрле нурлана башлый... Музей хезмәткәрләре кызны беләләр иде инде. Сагышка батып музей залларында йөргәндә дә кызның күз алдында шул ук йөз, шул ук күзләр тора иде. Еллар үтә торды, бу сәер мәхәббәт, тормышка ашмаган хыял кебек, һаман яши бирде.

Берзаман портрет юкка чыкты, аны нигәдер фондка күчерделәр һәм ул ел ярым экспозициядә күренмәде. Бу хәл кыз өчен чып-чын фаҗигагә әверелде, ул гүя якын кешесеннән аерылды. Соңрак портретны кабат элеп куйдылар һәм бу аның өчен озак күрешмәгәннән соң кавышу төсле булды. Ә бераз вакыт үткәч, билгесез мастер тарафыннан киндергә сурәтләнгән бу кеше һәр төн диярлек аның төшләренә керә башлады. Ул чорда кызның рухи тормышы төшләренә кергән шушы зат белән кушылу омтылышыннан тора иде. Төшләре дә бик сәер, андагы тормыш та әллә нинди ят, борынгы, кешеләре һәм гореф-гадәтләре дә үзгә. Кыз боларның нәрсә икәнен, портретның нилектән алай үзенә тартканын аңламаса да, күзгә күренмәгән җепләр аны мәңгегә шушы иске полотнода сурәтләнгән кешегә бәйләгәнен сизенә иде.

Ничек тә картиналар галереясына эшкә урнашып, һәрвакыт портрет янында булу теләге аны, мәктәпне бетергәч, Ленинградның Художество академиясенә алып китте. Аннан ул сәнгать белгече булып әйләнеп кайтты, әмма музейга урнаша алмады — эти-әнисе аяк терәп каршы тордылар. Аның этисе шәһәрнең медицина институтында профессор иде. Ул кызын бу өлкәдәге атаклы таныш-белешләренә дә күрсәтеп карады. Кызның бернигә карамастан фәкать музейда гына эшләргә теләве рецидив, ягъни үткән дип саналган авыруның яңаруы турында сөйли иде. Моннан соң кызга үзенең теләкләрен, омтылышларын бик тирәнгә күмеп яшәргә туры килде.

Вакытлар үтеп, ул кияүгә чыккач та, портретның аңа булган тәэсире һич кимемәде. Яңа туган кечкенәсен имезгәндә дә, баланың җыерылган йөзеннән этисе чалымнарын эзләмәвен сизеп, ул калтыранып куя иде... Нәкъ менә шушы бөек һәм сәгадәтле мизгелдә полотнода сурәтләнгән кеше белән аның арасында булган роман — мәңгелек роман икәнен ул ахырынача төшенде кебек. Үз ирен түгел, ә ире кыяфәтендә аны ярата иде ул. Димәк, баласын да ул ireннән түгел, а н н а н тапкан булып чыга түгелме?..

Һәм менә аның янәшәсендә мәңгелек романның герое басып тора. Ялгыш кына кулына орынсаң, картина салкынын түгел, тән җылысын тоясың. Хәзер аңа хәтта сүз катып та була.

Әйе, бу — ул иде. Сәер һәм аңлавы авыр булса да, бу — ул иде... Мөмкинме соң мондый охшашлык?

Төрле ниятләр, уйлар, теләкләр белән өзгәләнеп яшәүче, күп көч сарыф итүдән кайвакыт тәмам бетешеп, үзенә хәтле башкарылганны узып китәргә ашкынуы аркасында яңадан аякка басучы һәм хәтсез омтылышларында ару-талуны белмәгән бу кеше (без аны Иван Никольский дип атыйк) хәзерге минутта үзенә ике тамчы су кебек охшаш портрет каршында басып тора иде.

Ул чакта, мең тугыз йөз кырык тугызынчы елны, ул инде тәмам җитлеккән кырык яшьлек ир иде. Аның язмышын абсолютка ирешү теләге билгеләде. Бу идея аны тулысынча буйсындырып, кеше күз алдында үткән тормышында гына чагылып калмыйча, бөтенләе белән күңеленә кереп оялады, канына сеңде, холык-фигыленә әверелде һәм төрле борчулар, газаплар аша үзенә хезмәт итүне таләп итә иде. Тормыш хәлләре, язмыш борылышлары һәм юлында очраган хатын-

кызлар аңа тәэсир итә алмады. Һәр яңалыктан, һәр яңа хистән тәм табып яши белсә дә, сайлау мәсьәләсенә килгәндә ул үз табигатенә, фикер юнәлешенә, токтан мәсләгенә һәрвакыт тугры булып кала. Тормышының котылгысыз законнар буенча баруына караганда, үз көче, үз ихтыяры белән үзгәрә баруы аңа күбрәк ошый һәм шул гына канәгатьләндерә иде. Юк, хатын-кызлардан ул беркайчан да качмады. Аның тынгысыз күзләре бер генә гүзәл йөзне дә игътибарсыз калдырмады. Күзе төшкән бер кешедән ул сеңлесе һәм әнисе, хатыны һәм ярдәмчесе, кызы һәм якын дусты булырдай зат табарга өметләнде, бу затта бөтен сәләтләр дә бер үк дәрәҗәдә чәчәк аткан булырга тиеш иде. Шундый хатын-кыз табып аның белән язмышын бәйләү — Никольскийның тормышка ашмаган хыялы иде. Бу омтылыш та әлеге абсолютка ирешү теләгенең бер чагылышыдыр. Ләкин һәр очрашуда каһәр суккан берьяклылык калкып чыга торды. Хатын-кызда ул әле бер якны, әле икенчесен тапты, әмма бөтенесен берьюлы — беркайчан да очрата алмады. Шуңа күрә, эзләгән камиллекне, абсолютны таба алмыйча тиз суына иде. Һәм бу минутта портреттагы төстәшенә карап торган Никольский аның күзләрендә дә шул ук тойгы — эчке бөтенлеккә, тынычлыкка, гармониягә омтылыш сизде. Портретта — мәңгелек качкын, тынгы белмәс адәм сурәтләнгән иде.

Янәшәсендә кинәт:

— Сезгә хәзер минем гаҗәпкә калуым аңлашыладыр бит? — дигән хатын-кыз тавышы ишетелде. Аннан тавыш: — Мин әле һаман да ышанып бетә алмыйм,— диде.

Никольскийга кинәт әллә ничек булып китте. Тәненә суык йөгереп, калтыранып куйды. Мондый охшашлык чыннан да мөмкин микәнни? Раслауны өмет иткәндәй, ул як-ягына каранды һәм шунда теге хатынның кызарган йөзен күрде; аның самими, якты күзләрендә тәвәккәллек, чаялык һәм тану, әйе, тану тантанасы балкый иде — һәм ул кабат портретка төбәлде.

Портретта ул үзен күрде, шул ук вакытта бу сурәт ничектер ят та кебек иде. Ул ят, чөнки ул аның үзе була алмый, анысы ачык, әмма шуңа да карамастан портретта ул үзе, фәкать үзе иде. Шушы мизгелне гүя ике «мин» бер-берсенә төбәлгәннәр дә, ике дөнья арасында үткән чикне ул аера алмый тора; бөтен нәрсә — әйберләр дә, хисләр дә — табигый бәйләнешләрен җуеп, вакыт һәм киңлек бердәмлегендә эри баралар... Кылыч сабына таянган уң кулы арыды, ул кулын күтәрмәкче булды, ләкин кул күтәрелми, аны нидер тота иде. Иңеннән асылынып төшкән алтын чылбыр күкрәген басты...

Никольский айнып киткәндәй булды. Төстәшенең соры күзләрендә ниндидер мөһим сорау калгандай яшерен сагыш сизелә. Төс-битенә килгәндә ул шактый чибәр, барысы да үз урынында, ләкин анда, күләгә кебек, ниндидер катылык, ныклык бар иде. Портретны кеч-кенә генә авыз һәм кысыла төшкән дәртле иреннәр төгәлли... Ләкин бу аның төстәшеме? Алай дисәң, кылыч сабын үз кулы белән кысты лабаса! Ул картинада үз бармакларын таныды. Йөзе дә нәкъ аныкы иде! Үз йөзе!

«Билгесез рәссам. XVI гасыр. Италия мәктәбе. Дон-Жуан портреты (?). Киндер, майлы буяу. Дәүләт тарих музееның картиналар галереясы». Калын рамга ябыштырылган бу язуны ул кат-кат укып чыкты.

Әйе, бу ул иде. Шул ук чәчләр, хәтта карашы да аныкы — кырын караган күзләр.

Дон-Жуан?.. Әйе, аны да кайчак шулай атыйлар. Аның да шундый даны чыккан. Ләкин моңа аны бөтенләй белмәгән кешеләр генә

ышана. Аңламаган кешеләр шулай ди! Ә Дон-Жуанның үзен аңлаганнармы соң?..

Әйе, Никольский ата буйдак, әйе, яшерен-батырын түгел, гомерендә хатын-кызларны шактый күрде һәм киләчәктә тагын күрер дип уйларга кирәк... Никольскийга бәйсез кешеләрдә була торган үз-үзенә ышану һәм гамьсезлек хас иде; бәлки нәкъ шушы сыйфатлар тарткандыр да әле хатын-кызларны?.. Ләкин берәү дә аның бердәнбер хатын-кыз турында хыялланганын белми иде шул! Әлеге хатынны ул гомере буе ярата шикелле һәм аның алыштыргысыз зат булачагына да ышана; ул хатын — аның гомер буе эзләп тә һаман табылмаган, ирешелмәгән бәхете — идеал рухтан туган кулсыз-аяксыз шәүлә кебек күз алдында тора.

Никольский борылып артка карады. Музейның түшәменә бизәк төшкән зур залы буш һәм салкынча иде. Тик ишек төбендә генә күзәтүче апа йокымсырап утыра. Мондагы бөтен әйбер, ыгы-зыгыдан ерак булса да, гадәти һәм реаль иде.

— Сәер. Бик тә сәер,— диде ул ниһаять.— Дон-Жуан чыннан да тарихи шәхес түгелдер бит? Портрет авторының шушы көнгә хәтле билгесез булуы бик тә сәер. Менә дигән әсәр.

— Әйе, бу бик яхшы портрет.

Алар урамга чыктылар. Тышта баягы шикелле кызу. Көн аксыл рәшәгә төренгән.

— Көтелмәгән мизгел өчен сезгә зур рәхмәт,— диде Никольский.— Ләкин миңа китәргә вакыт...

— Сез китәсез? Сез ничек шулай китеп бара аласыз? Сез киткәч, болар тагын төш шикелле генә булып калса, мин бит акылдан язачакмын!

Ир кеше кесәсеннән сигарет пачкасы чыгарды.

— Сез нигә дәшмисез? Нигә бер сүз дә әйтмисез! Сез бит... минем каршымда? Зинһар, менә бу зажигалканы миңа бирегез,— дип сорады хатын көтмәгәндә.— Сезне күрүемнең шаһиты булыр.

Җыйнак кына көмеш зажигалка әле Никольский кулында иде. Ул аны хатынга сузды.

— Мәгез, рәхим итегез... Мин менә безгә инде хәзер нишләргә дип уйланып торам,— диде ул, үзе белән сөйләшкәндәй итеп.

Кызган мәйдан аша тонык кына тавыш ишетелде. Кремль сәгате суга иде.

Алар дәшмичә тагын бераз тордылар. Экскурсантлар төялгән автобус килеп туктады. Һәм ул хатынның йөзенә карамыйча гына әйтте:

— Бу очрашуның сезнең өчен нәрсә икәнен мин яхшы аңлыйм. Иске портрет, мәхәббәт, көтмәгәндә очрашу... Минем беләнме, аның беләнме, ул кадәресе миңа караңгы... Мондый очрашуны күз алдыгызга да китерә алмагансыздыр. Мин үзем дә сәер төстәшемнең мәгънәсен аңлап җиткермим! Әйе, без чыннан да бер-беребезгә абсолютно охшаганбыз. Ләкин бу әле мәсьәләнең бер ягы гына. Аның икенче ягы — алда нәрсә көтә? Әйе, сез мине очраттыгыз, мин иске картинада үземне очраттым, ә алда нәрсә?

— Мин белмим,— диде хатын аптырап.

— Мин дә белмим. Нәкъ сезнең кебек үк.

— Сезнең исемегез ничек? Сез үзегезне читтән килгән кеше дигән идегез. Кем соң сез?

— Кем соң мин? — ул сүлпән генә елмайды.— Әйдәгез, менә нәрсә турында килешеп куйыйк.— Ул инде елмаймый иде.— Сез хәзер туп-туры эшләгән җирегезгә кайтасыз. Сезнең моңа кадәрге тормышыгыз — уйлап чыгарылган тормыш ул.

— Әйе-әйе!.. Әйе!

— Юк, сез мине аңламадыгыз. Әшегез, әегез, хәтта бармагыгыздагы бу балдак та — сезнең реаль тормышыгыз. Ә мин — хыял! Бүген булган нәрсәләр — барысы да хыял гына. Берни дә булмады, булганы юк! Бу галлюцинация галәмәте генә... Бүген аның һавасы да әллә нинди, бөркү... Берни дә булмады. Тормышыгызда беркайчан да боларның булганы юк.

— Нигә? Нигә? Мин сезне аңламыйм... Нигә сез болай мәрхәмәтсез?!

— Матурлык ул дөнья белән һәрвакыт каршылыкта була. Миндә сез эзләгәнегезне барыбер таба алмаячаксыз, мин дә эзләгәнемне сездә таба алмам. Максатлар уртак булса да, төрлене эзлибез. Сез миндә бала чакта ук портретта күргән сыйфатлар эзлисез. Сезнең идеалыгыз конкрет. Ә минеке? Минеке нинди соң?.. Әгәр мин сезне аңламасам иде. Ләкин безнең арада шактый уртаклык бар. Сез — бердәнбер уйга, хискә бирелгән кеше, ләкин мин дә бит мономан! Аңлыйсызмы, мин дә мономан! Без менә бер үк нәрсә эзләсәк иде!

— Мин сезне аңламыйм! Аңламыйм.

— Без фәкать бер-беребезне генә эзләсәк иде! — дип кабатлады ул.— Бу чыннан да бәхетле итәр иде. Менә сез минем исемемне сорадыгыз? — Ул моңсу гына елмаеп куйды.— Дон-Жуандыр, мөгаен. Оныттыгыз дамыни? Әйе, мине чыннан да шулай атаганда дөресрәк булыр иде. Ләкин мин сезне берничек тә өметләндерә алмыйм. Һәм үзем кебек... дучар булуыгызны да теләмим.

— Мин сезне аңламыйм,— дип хатын тагын аны бүлде.

— Нәрсә генә булмас бу дөньяда... (Кемгә сөйли ул? Үз-үзенәме? Аңамы?) — Әмма тормыш-көнкүреш, реаль тормыш бар бит әле.— Ул хатынның күзләренә карады.— Шуңа кайтыгыз. Тырышып карагыз! Үзегезгә каттый рәвештә: берни дә булмады, диегез. Булмады. Булмады,— дип сеңдерергә тырышып кабатлады ул.

Аннан ул йорт почмагыннан борылды да кинәт күздән югалды. Хатын тәмам тетрәнеп басып калды, бу минутта ул еш-еш кага башлаган йөрәген генә тойды. Автобустан төшкән экскурсантлардан берәү аннан нидер сорады, ул машиналь рәвештә җавап бирде. Тагын нидер сорадылар, ләкин ул инде сорауны аңлар хәлдә түгел иде, сүз катучының җирән битеннән тәгәрәгән тамчыга аптырап карап торды. Ләкин йөз а н ы к ы түгел, түгел иде!— һәм ул куркынып музей каршында җыелган төркемне этә-этә читкә омтылды. Аны хәзер бердәнбер теләк — тизрәк бу бөҗрадан чыгу һәм әле генә ул кереп югалган, күзенә соңгы тапкыр ак күлмәге чалынып калган почмакка барып җитү теләге биләп алды. Артыннан ишетелгән ризасыз тавышларны, тиргәү сүзләрен ул ишетмәде.

Ир кеше юкка чыкты. Ул инде урамда юк иде. Бәлки әнә теге төркемдәдер? Бәлки текә борылыштан үтеп баручы таксига утыргандыр? Гомумән бар идеме соң ул? Бәлки бу өндәге төш кенәдер? Берничә секунд кына үтте бит? Кеше ул арада юкка чыга аламы? Бәлки бу гүзәл һәм куркыныч төш кенәдер?

Шунда аның кулыннан асфальтка җыйнак кына көмеш зажигалка төште...

## III

Ул шактый вакыт урамда йөрде. Шәһәрне аркылы диярлек чыгып бер чатка туктады. Һәм үзенең кайда икәнен аңларга тырышып басып торды. Шунда гына экренләп үз йортына килеп чыгып, үз тәрәзәсенә карап торуын искәрде. Йорт үзе дә, тәрәзәләре дә аңа ничектер ят булып тоелды. Аны монда нидер алып кайткан, менә ул подъездга кереп, баскычтан югары күтәрелде, ишекне ачты. Беренче

күргән кешесе улы булды. Малай әнисенең җиңел аяк тавышын, күлмәге кыштырдавын ишетеп каршы чыкты.

— Әнием! Син бүтән беркая да бармыйсың бит? — диде зарыккан малай.

— Минме? Юк, юк, улым,— диде ул кинәт уянып киткәндәй,— беркая да бармыйм. Менә чыгып кына керәм дә... Чыгып керергә кирәк әле, улым.

— Әйдә, алайса, бергәләп уйныйк! — малайның күзләре шатлыктан балкыды.

Әнисе килеп аны кочагына алды, күкрәгенә кысты, йомшак чәчләрен сыйпады. Һәм шул мизгелне аңа бүгенге хәлләрнең барысын, барысын да улы беләдер сыман тоелды. Ул барысын да күргән һәм ишетеп торган. Гафу итәрме соң аны бала? Кайчан да булса аңлармы? Ул кинәт баланың күзләренә элеккечә тутырып карый алмавын сизде. Моңа хәтле портретын гына белеп, бүген инде юлында очраган бу кешегә булган мәхәббәте бала белән ике арага килеп керде... Утрауны су баса башлады?..

— Әйдә уйныйбыз! Нишләп болай үлгән шикелле торасың?

Малайның тавышын ишетсә дә, ул берни аңламады.

— Шакмак уйныйк! Өй төзик, әйдә!

— Әйе, кадерлем... Шакмак...

Бу минутта ул төсле шакмаклардан икәүләшеп төзегән өй белән соңгы тапкыр саубуллашырга кайтканын төшенде. Бу мизгелдә ул малае белән саубуллашуын аңлады. Моңа хәтле күңеле ятмый гына яшәлгән булса да, гомере шушында үткән йорты белән саубуллаша иде ул бу минутта. Утрауны баскан су инде күкрәккә җитеп, йөрәк белән тигезләшкән һәм торган саен югарырак күтәрелә бара иде. Һәм бу суның элекке тормышны бөтенләй күмеп китәсен ул белә иде...

Ул җиңел адымнар белән бала бүлмәсенең кояшлы идәнендә йөренде, аннан, үз ягына чыгып, көзге каршына утырды, куллары аңсыз рәвештә инде кирәге беткән косметика әйберләренә кагылгалап алды. Әйе, боларның инде кирәге юк иде. Ләкин нишләргә? Ул унбиш яшьлек кыз чагында ук портретын күреп гашыйк булган кешесен очратты. Хәтта сөйләшеп тә торды... Димәк, үзен портрет белән нинди дер тыгыз бәйләнештә сизү һәм кайчан да булса бу кешене очратуына ышанып яшәү юкка гына булмаган икән. Бу чыннан да тормышка ашты. Аның уйлары, әллә кайлардан урап кайтсалар да, котылу юлын таба алмады. Котылу юлы, әлбәттә, бар, әмма ул упкынга тарта...

Ак майка белән трусик кигән улы ачык тәрәзә төбенә күкрәге белән ятып урамга кәгазь самолет очырды. Аннан канәгатьләнеп әнисенә таба борылды да шаркылдап көлеп җибәрде, ләкин көлү тавышы шундук киселеп калды.

— Син нигә елыйсың? — дип сорады малай.

Әнисе күзләрен сөртте, ә күз яше һаман туктамады.

— Чүп кергәндер, улым,— диде әнисе.

— Ә син күзеңне ю! Кульяулык белән сөрт! — дип бала кульяулык китермәкче булды.

— Кечкенәм минем!.. Сабыем!..

Ул тез чүгеп малайны кочаклады, шашынып үпте, нигәдер гафу үтенде. Ә малай берни аңламыйча шырык-шырык көлде генә, чөнки аны әнисенең иреннәре, чәчләре кытыклый иде.

— Мин бит мондый булганга гаепле түгел, шулаймы, улым? Әллә барыбер гаеплеме? — дип сорады ул малайдан яшь аралаш.

Әйе, котылу юлы бар, ләкин ул упкынга, кеше ышанмаслык, кире кайтып булмаслык тирәнлеккә тарта. Моны яхшы аңласа да, ул инде

күңелендә көндез аяк баскан бөҗрадан ычкынырлык көч тапмады. Һәм бу бөҗрадан ул котылырга да теләмәде. Портретның күп еллар элек аны буйсындырган көче артып, җиңеп булмаслык дәрәҗәгә җитте. Бу көч хәзер аның алдына тере кеше сыйфатында килеп баскан иде. Ул аны ни дә булса кылырга мәҗбүр итә иде.

«Бәлки минем акылдан яздырырдай көчле хисләрем аны портрет әсирлегеннән азат иткәндер»,— дип уйлады ул.

Язмышы күптән хәл ителгән булса да, ахырынача менә бүген ачыкланды. Ничек кенә карышмасын, ул инде еллар буе саклаган илаһи мәхәббәтен җиңә алмаячак!.. Җиңә алмаячак...

Ул үксеп елый башлады, чөнки бу минутта якыннарына кайгы китерәсен дә, өйдән чыгып китәсен дә яхшы аңлый иде. Һәм шуның өстенә ирен, улын ташлап күп газаплар күрәсен, төрмыштагы бердәнбер ышанычын, таяныр кешесен югалтасын һәм үзенә урын табалмый интегәсен дә белә иде. Ләкин аның гомер-гомергә хыялланып яшәгән кешесе бар лабаса. Бу дөньяда ул да яши икән бит!.. Шулай булгач, ул инде һичшиксез аның белән булырга тиеш... Хәзер ул бары тик бер нәрсәне — аның белән бергә булырга тиешлеген генә белә иде...

Өстәлне зур бүлмәдә әзерләделәр.

Ир тиешле кеше хатынының борчылганын күреп торды. Аның читкә төбәлгән күзләрендә нindидер хәвефле уй тыпырчына, кул хәрәкәтләре дә сәер иде. Әле тоз савытын ала, кулында әйләндергәли дә урынына куя, аннан салфеткага үрелә һәм анысын да онытып читкә этәрә иде. Аның куллары уйланмаган хәрәкәтләр ясый, күзләре берни күрмәгәндәй каядыр әчкә, күңел түренә төбәлгән иде.

— Сине урамда күргәннәр. Бер танышым машинадан күреп калган... Кем артыннан йөгерә идең?

— Танышың? Нинди танышың? Белмим, нәрсә турында сөйли торгансыңдыр.

Ул теленә ни килсә, шуны әйтеп салды һәм ялганның болай шома чыгуына үзе дә гаҗәпләнеп куйды. Дөресен дә әйтеп булыр иде, чөнки курку хисе тоймады, ләкин болай итеп соңгы сызыкны чыгуны беразга кичектерергә теләде.

— Нәрсә дивана шикелле утырасың, ачуым килмәгәе? — диде ир кеше.

— Карале, сәгать дүртенче киткән бит? Син бүген эшкә бармыйсың мәллә?

— Нинди эш тагын? Кайттым дип әйтеп торам бит! — диде ире хатынының нindидер сер яшеренгән куркыныч күзләренә карап.

Стена. Араларында стена үсеп чыкты. Ул ничектер бөгәрләнеп һәркайсын үз эченә алды. Бу ике дөньяны хәзер берни дә тоташтырмый иде. Стеналар, кая карама стеналар, ә чыгу юлы бер генә...

— Син миңа кияүгә яратмыйча чыктың! Мин һәрвакыт моны сизеп яшәдем! Минем белән бергә булганда да, кемгәдер хыянәт итәм дип, син мине күрәлмадың!

Тавыш каяндыр еpermanентан килгән шикелле тоелды.

— Күрәлмадым? Нигә алай дисең? Мин сиңа турылыклы хатын булдым. Мин бәлки шулай булып калыр да идем... Син мине аңларга тиеш! Мин бүген а н ы очраттым. Әйе, үзен! Теге портреттагы кешене... Дон-Жуанны...

— Тилердеңме әллә! Хыял белән күпме яшәргә мөмкин, моның чиге булырга тиештер бит инде! Сиңа дәваланырга кирәк!

— Нигә сез барыгыз да мине авыруга санайсыз? Син мине яки башка берәүне яратсаң, аңлар идең. Без дошманнар түгел бит? Син минем ирем идең. Юк, минеке түгел, син миндә күрергә теләгән

хатынның ире... Син тотма мине. Җибәр. Мин хәзер бөтенләй башка кеше.

— Бу ни дигән сүз тагын? Күпме гомер яшәп?! Сиңа... дөресен генә әйткәндә, больницага ятарга кирәк. Ятарга да тынычланырга. Әйткәннәрең адәм көлкесе бит. Барысы да җайланыр. Ну, тынычлан, тынычлан! Синең башта нәрсәдер бар, ахры.

— Әллә мине акылдан шашкан дип уйлыйсыңмы? Тилергән дип ышандырмакчымы? Ләкин мин бит күптәннән шулай. Син өйләнгәндә үк мин шундый идем. Һәм шул килеш калдым да.

Тормышның китеклеге бөтен кискенлеге белән калкып чыкты.

Кая карама стена. Менә стенада ишек пәйда булды. Ишек — упкынга алып чыга. Анда һәлакәт һәм бер үк вакытта котылу. Әйе, котылу... һәм шулай дөрес булачак.

Ләкин бик кыйммәткә төшә түгелме?! Баласы һәм аңа булган мәхәббәте аркылы атлапмы? Бу мәхәббәтнең балага ни дәрәҗәдә кирәклеген белгән килешме?

Ул инде үз ихтыяры белән яшәми иде. Ниндидер гали, үзеннән өстен торган ихтыяр көче аны буйсындыра, барысын да өзәргә, ташларга мәҗбүр итә.

...Хатын үз күңеленә ут салган бу кешене шәһәр кунакханәләреннән эзләгәндә Никольский ерак иде инде.

Теге көнне университетның фәнни конференциясендә докладын укып, ул кабат музейга килде. Конференциядә куелган проблемалар аны инде кызыксындырмый иде. Галерея тын һәм буш. Берәмсәрәм генә кешеләр күренгәли, аның артында тукталып, зур тәрәзә каршындагы стенага эленгән иске портретка күз ташлыйлар һәм алга узалар, ә ул төстәшенә төбәлгән килеш һаман басып тора да тора.

Казанга килү аның тормышында гадәти бер эпизод кына булганга, биредә ул мондый хәлләр ачылыр дип башына да китермәгән иде. Үзе сурәтләнгән портретны күрермен дип тә, үзенә гашыйк булган хатынны очрату ихтималын да уйламады. Чынбарлык көтмәгәндә сөер һәм серле төс алды, анда аңлап булмаслык мәгънәләр яшеренгән сыман тоелды. Акылга сыймаслык бу охшашлык та, серле мәхәббәт тә бер табышмак иде.

Ул гомере буе икегә бүленеп яшәде. Бер яктан һәр яңа хискә тулысынча бирелеп, аннан ләззәт табып яшәсә, икенче яктан — күңелендә ниндидер кыймшанмас бер нокта булып, үзенә дә, дөньяга да нәкъ шул ноктадан карый иде. Соңгы очрашуда беренче кеше тәмам тетрәнде, ул инде биредә калырга да риза иде. Аны чын тормыш ымсындырды, үзенә тартты. Әмма икенчесенә исә киләчәк кенә иксез-чиксез булып күренә, ул гына һәрвакыт каядыр дәшә, каядыр чакыра, ул гына яңарта иде. Киләчәктә бөек момент бар иде шул, анда даими эзләнергә кирәк иде һәм чын яшәүне ул әлеге эзләнү белән генә бәйли иде. Икенче кеше тагын җиңеп чыкты.

Никольский шул ук көнне Казаннан китеп барды. Ә хатын аны һаман эзләде. Ул хәзер өенә дә кайтмый иде. Сәгатьләр буе урамнарда йөри, кунакханә яннарында басып тора, аннан дежурга барган шикелле музейга килә... Бераз вакыт үткәч хатын да күздән югалды.

## IV

Бу ике кешенең моннан соң ниләр кичергәнен сөйләп тормыйм. Һәр язмыш үзенә күрә бер сер ул һәм күп очракта сер булып калыр-

га да тиеш. Чит кул кагылып аның гармониясен бозуы, табигый агышын үзгәртүе мөмкин. Әгәр бу хәлләр уйлап чыгарылган булса, ул чакта әле бер хәер, геройларым мин дигәнчә генә йөреп, бернинди кыенсыну кебек хис кичермәс тә идем; ул чакта, автор буларак, вакыйгаларга ябышып ятмыйча, аларга өстән карап үземне иркен һәм ирекле хис итәр идем. Ләкин мин — булган хәлләрне теркәп баручы хронограф кына, очраклы гына килеп чыгып гаҗәпкә калган шаһит. Барысын да сөйләп бирә алмыйм һәм ул кадәресе миңа билгеле дә түгел.

Дөресен генә әйткәндә, мин бу фаҗигале тарихның азагын гына күрдем. Сөйләгәннәрем исә бары тик вак кыйпылчыклардан бөтен бер картина төзергә тырышу. Аяк терәп вакыйгалар нәкъ менә мин сөйләгәнчә булды дип тә әйтә алмыйм. Әйе, сөйләгәннәремдә дөреслек зур, әмма аерым детальләр, штрихлар нәкъ шулай булды дип әйтә аламмы? Юк, алай дияргә кыюлыгым җитми.

....Тетрәндергеч очрашу сәгатьләре үтеп китте һәм аерылышу мизгеле килде; күпме генә зарыктыргыч елларны, хисапсыз көннәрне һәм төннәрне сыйдырмады ул мизгел? Хәзер аның тормышы шушы мизгелдән гыйбарәт иде; яңадан очрашу турында хыяллану, өметсезлеккә төшү, бертуктамый эзләү, белешү һәм ялгызлык — болар барысы да шул мизгелгә сыйды. Никольский үзе дә аның шикелле яшәде: шул ук өмет һәм өметсезлек, эзләнү һәм ялгызлык гомер буе юлдаш булды.

Ул көнне алар нәрсәнедер аңламый калдылар. Нидер аңланылмый калды. Әйе, йөзгә-йөз торып бер-береңне күреп булмый икән, тик соңгы чиктә генә кушылыр өчен дөньяга килгән бу ике кешенең фаҗигасе ачыкланды.

Җитмеш дүртенче-җитмеш бишенче елларда мин Мәскәүдә укыдым. Язучыларның Кузнецкий мосттагы китап кибетендә булсын, Арбатның букинистлар магазинында яисә башка шуның ише китап сата торган җирләрдә булсын, күземә һаман саен бер кеше чалына иде. Җәй җитте, көз дә үтте, тагын кыш килде. Шундый очрак туры килеп без аның белән танышып киттек, аннан дуслашып та алдык.

Профессор Никольский ялгызы гына яши иде. Атнага бер тапкыр янына олы яшьтәге нindидер хатын килә, квартирын рәткә сала, керен юа, атналык азык-төлек хәстәрләп куя. Ул аны искечә: «Минем экономкам» дип атый. Бу аскет һәм фанатикның гаять зур квартирасында кая карама китап иде. Шәхси китапханәләр арасында моннан да баерагын минем әле беркайчан да күргәнем юк. Шул кадәр бай китапханә иде ул.

Никольский таңга калырлык, хәтта нindидер фантастик шәхес иде. Еш кына аның өендә мин хатын-кызларны да күргәләдем. Шулай да мине шаккатырганы хатын-кызлар түгел иде. Хатын-кыз логикасы беренче карашка сәер тоелса да, аның да, мөгаен, үз дәлилләре бардыр. Мине бөтенләй икенче мәсьәлә кызыксындыра, хәтта таң калдыра иде. Китаплар белән тулган зур гына кухняда кайчакны без чәйләп яки кофе эчә-эчә сәнгать, фәлсәфә, фән турында гәпләшеп төн үткәрә идек; һәм шул чакны гүя каршыңда нindидер чиксез зур әйберләргә каршы баручы фикри образ калка. Бу фикер бөтен галәмне кочагына алган проблемалар белән изалана, галәм тарихын, аның мәгънәсен, гармония белән дисгармониянең асылын аңларга тели иде. Гап-гади мохит — тәрәзәсе нindидер стенага караган иркен кухня, тәмәке төпчеге өелгән көл савыты, сөрем сарган чәйнек һәм стеналарның теге ягында йокыга талган зур шәһәр — барысы да

кинәт үтә күренмәлегә әверелә һәм аның аша космик коллизияләрне күрә башлыйсың.

Нигә болай бөтенесен белергә, ачыкларга, хәл итәргә ашкынгандыр ул? Анда ниндидер гармониягә ирешү фаҗигасе яши иде. Галәмдә һәм кешенең үзендә. Бөтен нәрсәдә. Бу борынгыдан килә торган фикер газабы, уянып китеп тышкы дөньяны да үзенә буйсындырырга теләгән фикернең өзгәләнүе иде... Соңрак мин Никольскийның галимнәр арасында да шактый үзенчәлекле даны таралуын белдем. Ул анда да үз кеше булып китә алмаган. Бәйсез холык-фигыле һәм гадәттән тыш бай интеллекты белән галим-голәмә арасына сыймаган булып чыкты.

Бераз югалып торып, Никольский янына соңгы тапкыр килүемдә ул минә нинди иде һәм мин үзем дә аның турында нәкъ шундый фикердә идем.

Бик тә аптыраган кыяфәттә язу өстәле янында утыра иде ул. Каршысында ниндидер сәер киемле, кулына кылыч тоттырып ясалган портрет репродукциясе — җентекләбрәк карасам үз портреты булып чыкты... Портрет классик манерада язылган. Өстәлдә конверт, кеч-кенә генә көмеш зажигалка һәм ниндидер вак-төяк ята...

— Үлде минем... экономкам. Мин аны танымаганмын,— диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә.— Моннан егерме алты ел элек беренче күрүемдә дә танымаган идем... Бу хәл сезнең шәһәрдә булды... Таныган булсам, ул минем сеңлем, дустым, хатыным, сөяркәм дә була алыр иде бит... Каршымда басып торды, ләкин мин аны танымадым... Берничә ел элек ул тагын килде, анда да танымадым. Бу өйдә ул минем ярдәмчем иде, анам, тәрбиячем шикелле кадерләп тотты, ләкин мин аны танымадым! Мин аны гомер буе таный алмадым. Гомерем буе эзләдем, көттем, тагын эзләдем... Кайчандыр мин аңа: «Бер үк нәрсәне эзләсәк тә, без төрлене эзлибез бит...» дигән идем. Ялгышканмын! Нинди сукырлык! Фаҗигале сукырлык! Мәңгелек сукырлык!

Ул төнне без таң аткач кына аерылыштык.

**Русчадан Солтан ШӘМСИ тәрҗемәсе.**

Валентин Оскоцкий

# БЕР СӘЯХӘТ ТУРЫНДА

ЮЛ ЯЗМАЛАРЫ

Узган елның җәендә Татарстанда уздырылган совет әдәбияты атналыгында миңа да катнашырга туры килде. Элеккеге Шөгер, хәзерге Лениногорск районының Иске Куак авылын яңадан күрергә мөмкинлек бирүе белән атналык минем өчен аеруча истәлекле булып калды. Куен дәфтәремә теркәлгән бу язмаларымда әлеге авылга ни өчен баруым, анда кемнәрне очратуым һәм нәрсәләр күрүем турында сөйләргә телим...

Шулай итеп, мин Иске Куакка юл тотам...

Бала чак тәэсирләре күңелдән беркайчан да җуелмый. Алар рухи өлгергәнлекнең нигезендә яталар. Лев Толстойның һәм Максим Горькийның автобиографик трилогияләре, С. Аксаков, Н. Гарин-Михайловский повестьлары һәм башка бик күп язучыларның бала чак истәлекләренә нигезләнеп иҗат ителгән әсәрләр әнә шуны раслый. Бу әсәрләр арасында Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повесте да лаеклы урын алып тора. Моннан берничә ел элек бу повесть турында язып та чыккан идем. Яшермим, ул вакытта мин язучыга ияреп, аның бала чактагы бихисап күп сукмаклары буйлап атлаганда, Гомәр Бәшировның туган авылын гына түгел, үзебезнең Иске Куакны да, хәтеремә ничек кереп калган булса, шулай итеп күз алдыма китердем.

Менә монда инде халыкның рухи хәзинәсендә гасырлар буена тупланып һәм сакланып килгән, беркайчан да искерми торган матур традицияләр, гореф-гадәт һәм йолалар турында авторның уйлануларын тагын бер тапкыр исеңә төшерми булдыра алмыйсың. Әлеге бай хәзинә акыллы, үткен һәм зирәк сүз, йомшак аһәңле җыр һәм дәртле бию көйләре, халыкның беркайчан да искермәс олы йолалары, гореф-гадәтләре аша буыннан-буынга тапшырыламы, үзенең билгеле бер эзен калдырамы — бу сорауга иң дөрес, кирә кагылмаслык җавапны Бөек Ватан сугышы бирде. Барлык кешеләр өчен дә бер үк, шуның белән беррәттән һәркемнең үз сугышы иде ул. Минем өчен бу сугыш — камалышта калган Ленинградның 1941—1942 нче елгы тын алгысыз салкын кышы, Ладога аша сузылган атаклы тормыш юлы, Вологда, Пермь, Свердловск, Чиләбе, Уфа аша әйләнгеч юллар белән Иске Куакка килеп җиткәнгә кадәр шыксыз, караңгы, ягылмаган товар вагоннарында атна-айлар буена иза чигүләр...

Татарстанда булып узган совет әдәбияты атналыгында йөреп кайтканнан соң мин Николай Тихоновның «Бәхет кошы» исемле автобиографик повестен укып чыктым. Оятыма каршы, дип әйтимме, аңарчы әле минем еракта калган бала чак истәлекләренә нигезләнеп язылган бу әсәрне укыганым юк иде. Ул китапны миңа Иске Куакта бүләк иттеләр.

«Безнең Иске Куак авылы, — дип яза автор, — Оренбург тракты буйлап, олы юлдан читтә урнашкан... Куаклыларның җир-сулары җитәрлек булган. Риваятьләргә

караганда, алар бирегә илнең көнбатыш якларыннан күчеп килгәннәр. Монда әле хәзер дә Мальковский, Лесомский, Войцеховский, Полянский, Любецкий кебек фамилияләрнең еш очравы да шуны раслый. Элеккерәк заманнарда алар изүе нечкә бау белән бәйләнеп куела торган киндер күлмәк киеп йөргәннәр, җирле сөйләшләре мәскәүлеләр телен хәтерләткән... Якын-тирәдәге авылларда күп санлы татарлар, чувашлар, марилар яшәгән...

Иске Куак авылының иген басулары, урман-болыннары егермешәр чакрымга сузылган. Ул үзе Куак һәм Чишмә елгалары бергә килеп кушылган урынга салынган.

Чишмә елгасына бер-берләреннән әллә ни ерак булмаган мул сулы инешләр койган. Авылдан өч чакрым ераклыктагы зур урман куеныннан агып чыккан ул инешләрне, гади генә итеп, Беренче, Икенче, Өченче һәм Дүртенче инеш дип атаганнар. Чишмә ярлары буйлап авыл тирәли тезелеп киткән таулар бер-берсен сәламләп утырганнар. Ул таулар бу якларда булган Пугачев һәм аның иптәшләре хөрмәтенә Пугачиха, Щепачиха, Бияниха... дигән исемнәр белән аталып йөртелгәннәр...»

Егерменче гасыр башларында Иске Куак авылы әнә шундый булган. Бөек Октябрь революциясе давылын, гражданнар сугышы һәм күмәкләшү чорларын башыннан кичергән авылның йөзе Бөек Ватан сугышы елларында бик нык үзгәрә. Йортлар саны дүрт йөзгә җиткән Иске Куакта инде бөтенләй башка фамилиядәге кешеләр — Денисовлар, Жаковлар, Мироновлар, Абражеевлар яши. Тирә-юньдәге тауларның исемнәре акрынлап онытыла, аларның элекке атамалары картлар телендә генә сакланып кала. Чишмә елгасына коя торган инешләр саекканнан-саега, алар язгы ташу вакытларында гына бер дулап-җәелеп алалар да яңадан үз ярларына чигенәләр. Якын-тирәдәге авыллардан Иске Куакка караганда җитенкерәк тормышлы Сарабиккол дигән татар авылы күңелемә кереп калган. Аның зур-зур йортлары, чиста итеп себерелгән урам-тыкрыклары һәм ишегаллары әле дә булса күз алдымнан китми.

Биеккә, тау башына менеп карасаң, туган авылым Иске Куак үзенең канатларын чиксез киңлеккә җәеп салган һәм томшыгын елганың текә борылышына юнәлдергән ниндидер бер кошны хәтерләтә. Ул борылышта кайчандыр күпер һәм су тегермәне бар иде. Хәзер инде тегермән юк, ә элекке күперне җәяүлеләр чыгып йөрер өчен салынган яңа, асылмалы күпер алыштырган. Авылның урта бер җирендә олы гөмбәзле чиркәү, аның янәшәсендә һәр якшәмбедә халык мыжлап торган базар мәйданы, шунда ук кызыл кирпечтән җиткерелгән һәм авылда бердәнбер таш йорт исәпләнгән сәүдәгәр йорты булганлыгын ачык хәтерлим. Алардан арырак тоташтан салам түбәле өйләр, үрмә һәм утыртма читән белән әйләндереп алынган каралтылар һәм бәрәңге бакчалары тезелеп китә. Корылмалар арасында сирәк-мирәк кенә алты почмаклы йортлар да очраштыргалый. Без шуларның берсенә килеп урнаштык.

Тормышның астын-өскә китергән сугыш еллары турында уйланганда, әгәр мин, ул вакытта һәр тормышта тынычлык һәм татулык хөкем сөрде, дисәм, дөреслеккә хилафлык кылган булыр идем. Көндәлек эшләр һәм мәшәкатьләр арасында һәртөрле ыгы-зыгы, әрләш-тиргәш, үзара тынышмаучанлыклар әледән-әле булгалап торды. Ләкин юк-бар сәбәп аркасында килеп чыккан андый вак-төяк нәрсәләрне халыкның әйтеп бетергесез олы кайгысы һәм уртак язмышы бөтенләй оныттырды. Мөгаен, шуңа күрәдер, өлкән яшьтәгеләр, бигрәк тә эвакуацияләнеп килүчеләр бер-берләренә көннән-көн ныграк тартылдылар. Кичләрен укытучылар бүлмәсендә җемелдәгән утка карап мәктәпкә, я булмаса җыйналып клубка килү аларның гадәтенә керде. Ара-тирә үзләре дә авылда калган ике-өч бөртек егет катнашында концерт һәм спектакльләр куйгаладылар. Бервакыт авылга «Алар Ватан өчен сугыштылар» дигән кинофильм алып килделәр, ә икенче тапкыр Казан һәвәскәрләре концерт куеп киттеләр. Татарстанда беренчеләрдән булып Советлар Союзы Герое исемен алган авылдашыбыз, очучы Василий Иванович Яницкий белән очрашуга багышланган кичәгә халык аеруча күп җыелды. Күптән түгел аның рәсемен мин Иске Куакта туып-үскән икенче бер Советлар Союзы Герое, шулай ук очучы Иван Александрович Заварикин рәсеме белән бергә Ленинград паркында Дан аллеясында күрдем. Аларның соңгысы сугыштан әйләнеп кайтмады, 1945 елда һәлак булды.

Авыл кешеләре фронттагы туганнарыннан һәм якыннарыннан хатлар көтеп яшәде. Инде көтеп-көтеп тә бер төрле дә хәбәр булмагач, түземлекләрен җуеп, билгеле бер сәгатьтә үзләре почтага юл тоттылар.

Район үзәгеннән килгән һәм шыплап тутырылган капчыкларны бушатканда аларның барьер кырында тын алырга да куркып басып торулары әле дә булса күз алдымда. Берничәшәр тапкыр кычкырып укып чыкканнан соң хатларны кадерле истәлек итеп саклар өчен иплән кенә почмактагы иконалар артына җыеп куялар иде. Ул хатларга җавапларны да бергәләшеп яздылар. Хат алган кеше әйтеп торган сүзләрне кәгазь битенә арадан кем дә булса берсе түкми-чәчми терки барды: ул вакытта өлкән яшь-тәгеләр арасында ныклап укый-яза белүчеләр бик аз иде. Фронтовиклардан сирәк-мирәк кенә кыска гына вакытка кайтып китүчеләр булгалады. Бу исә һәркем өчен зур бәйрәмгә әверелде. Андый чакларда бөтен авыл халкы кунакка кайткан сугышчы йортына ябырылды. Ул үзе авылдагы һәр өйгә диярлек сугылып чыкты.

Кышкы озын, караңгы төннәрдә тәрәзәләр аша йортларда сүнәр-сүнмәс янган «тычкан утлары»ның тонык шәүләсен генә чамаларга мөмкин иде. Керосин лампалары бик сирәк кабызылды: кешеләр үзләре ясаган сукыр лампаларын яки чыра яндырып, бергәләп кич утыру һәм башка бәйрәмнәр өчен кирәк булачак керосинны янга калдырырга тырыштылар. Шырпы шулай ук кадерле нәрсәгә әйләнде, аны бик сак тоттылар. Көлгә күмеп учакта ут асралмаган көннәрдә, өсте ябулы савытка салып, көйрәгән кисәү алып чыгу өчен күршедән-күршегә йөрү гадәткә керде.

Авыл Советы стенасына бердәнбер репродуктор тәлинкәсе эленеп куелган иде. Ул карлыккан тавыш белән Совет Информбюросы сводкаларын хәбәр итеп торды. Немецлар Сталинград янына килеп җиткәч, авылда: «Имеш, Шөгер өстендә дә дошманның разведка самолетлары күренгән икән», — дигән сүзләр таралды. Эвакуацияләнеп килгән кайбер гаиләләр, төргәкләрен төйнәп, яңадан юлга — Уралга һәм аннан да арырак китәргә җыена башладылар. Винница яки Бароновичидан килгән күп балалы аналарны шелтәләргә безнең һичбер хакыбыз юк. «Оккупация» дигән коточкыч сүз аларның йөрәген бөтеннәрнекенә караганда алданрак яралады. Ленинградлылар үзләрен тынычрак тоттылар — блокада аларны түземлеккә, сабырлыкка өйрәткән иде. Ә бит алар кичергән авырлыкларны хәтта күз алдына китерергә дә куркыныч...

Эвакуацияләнүчеләр килү белән укытучылар һәм укучыларның саны бермә-бер артты. Укыту икешәр, хәтта өчәр сменада алып барылды. Дәрестә балалар пальто һәм баш киемнәрен киеп утырдылар. Дәфтәр урынына газета һәм иске китап битләренә корымнан ясалган кара белән яздылар.

Без, унике-унөч яшьлек малайлар, үз өлешебезгә тигән авыр йөкне әле ныгып та җитмәгән иңнәребезгә сыкранмыйча күтәрдек. Шуның белән бергә һаман тиктормас, йөремсәк, ә кайвакытларда тыңлаусыз һәм кеше сүзен бар дип тә белмәгән яшүсмерләр булып калуыбызда дәвам иттек. Җәнҗал чыгарган, тәпәләшеп алган чакларыбыз да булмады түгел. Шау-шулы уеннарны ярата идек. Әмма «сугышлы» уйнаган чагыбызны хәтерләмим. Андый уеннарны уйнау оят тоела, чөнки кыр почтасы штемпеле сугылган өчпочмаклы хатлары һәм кара пичәтле кайгы кәгазьләре белән һәр адымда үзен искә төшереп, җирдә чын сугыш бара иде...

Алдан ук бернәрсәне искәртеп куюны кирәк саныйм: мин үзем бүгенге яшьләр турында, алар кебек чагында без мондый түгел идек, хәзергеләр кайгы-хәсрәтнең, ачлык-ялангачлыкның ни икәнен дә белмичә, кәеф-сафа кылып җиңел тормышта яшәргә яраталар дип мыгырданучы кешеләр белән килешмим. Һәр чорның үз җыры бар, яңа җырларны искеләре астында күмеп, томалап калдырырга тырышу мәгънәсез бер эш булыр иде. Ләкин шул ук вакытта миңа үземнең тормыш тәҗрибәм дә бик кадерле. Кайчакта мине ата-аналары тапканны эгоистларча әрәм-шәрәм итеп яшәүче тәти егетләр һәм кызлар тайчандыра. Әгәр алар арасында безнең өчен иң изге нәрсәне — сугыш еллары истәлекләрен санга сукмаучыларны, алай гына да түгел, аяк астына салып таптаучыларны күрсәм, йөрәгем җәрәхәтләнә, җаным әрни. Һәм Даниил Гранинның «Блокада китабы»нда документлар нигезендә расланган фактларның берсе мине менә ни өчен аеруча көчле тетрәтә: «Көнгә кеше паекка бирелгән 125 грамм блокада икмәге белән тукланып торган икән, моның ул кадәр шаккатырлык нәрсәсе бар, — дип фикер йөртә анда Ленинград техникумнарының берсендә укучы, үз-үзенә чамадан тыш ышанган кыбырсык кыз. — Телим икән, мин атна буе ипи ашамыйча тора алам һәм үземне барыбер бик әйбәт хис итәчәкмен»...

Күңелне рәнҗетә торган мондый сүзләрне тыңлавы ук авыр һәм оят. Менә шуңа күрә дә, әсәрнең авторлары белән бергә, алар «мораль дистрофия» дип атаган авы-

руның симптомнары нинди зарарлы икәнлеге турында борчылып, кат-кат уйланмыйча булдыра алмыйсың. Әйе, кешеләрнең бүгенге буынына, бигрәк тә яшьләргә, сугыш истәлекләрен күңелләрендә саклау бик кирәк.

Сугыш еллары хатирәләрен, ул чорда баштан кичкәннәрне хәтеремдә кабат яңарту — мине нәкъ әнә шул теләк юлга чакырды да инде.

Иске Куак авылы... Кулларымнан җитәкләп, алда күп нәрсәләр вәгъдә иткән тормыш юлыннан атлатып алып киткәне өчен мин аңа гомергә бурычлы. Менә шуңа күрә дә бала чак эзләрем калган җылы, йомшак туфрагына тезләнеп, бүген аның олы җанлы кешеләре алдында зур хөрмәт белән баш иясем килә. Игенче хезмәтенә, җирне маңгай тире белән сугарып ул үстергән ипекәйгә бәләкәй чагымнан ук ихтирамым чиксез зур минем. Уларын һәм ирләрен, абыйларын һәм вәгъдәләшкән егетләрен яу кырына озаткач, тыныч чорда алар гына башкарып чыга алырдай авыр эшләрне, замана йөген үз иңнәрендә күтәргән аналарның һәм тол хатыннарның, малайларның һәм яшь кызларның җил ашаган кырыс йөзләре әле дә булса күз алдымнан китми. Еллар узганнан соң мин хәзер бернәрсәне ачык аңладым: кешеләр өчен тормыш һәм сулыш алу кебек үк кирәк булган интернациональлек хисе безнең йөрәкләребезгә әнә шул чакта ук бернинди патетик сүзләрсез генә килеп кергән. Сугыш елларындагы Иске Куак тирә-яктагы авыллардан халкының күп булуы белән генә түгел, күп милләтле булуы, төрле телләрдә сөйләшүе белән дә аерылып тора иде. Анда руслар, татарлар, мордвалар, чувашлар яшәде, аннары украиннар һәм белоруслар күчеп килде. Илебезнең барлык халыклары телләрендә җыр булып кабатланган «тату гаилә тойгысы» күңелләрдә үзеннән-үзе бөреләнде һәм халыктан безгә күчкән иң матур сыйфатларның берсе булып каныбызга сеңде.

Бөгелмәдән Иске Куакка алып бара торган юлның озынлыгы 100 чакрым чамасы. Моннан 35 ел элек шул араны җигүле атта узу өчен безгә ике көн вакыт кирәк булган иде. Ә бу юлы без аны машина белән ике сәгать эчендә үттек. Мин, дулкынлануымны юлдашыма сиздермәскә тырышып, үткәннәрне бер-бер артлы искә төшереп, эчтән генә уйланып барам... Янәшәмдә «Советская Татария» газетасының үз хәбәрчесе Николай Андреевич Егоров утыра. Иске Куакта аның туганнары һәм якыннан күреп белгән кешеләре бар икән. Аларның кайберләре минем дә күптәнге танышларым булып чыкты.

Элек район үзәге булган Шөгерне дә узып киттек. Иске Куакка егерме чакрымлап кына калды. Күп тә үтмәде: «Менә болар Иске Куак басулары була инде», — дип куйды юлдашым. Әйе, бу җирләр миңа да бик таныш. Элек монда бәрәңге утырталар иде. Хәзер, әнә, ул урыннарда куе һәм тигез булып тишелгән уҗымнар күтәрелеп килә. Кырлар шул ук та, шул ук та түгел кебек. Кайчандыр кара капкач булып алабута, билчән, сарут каплап киткән басуларда бүген чүп үләненең әсәрен дә күрмәссең. Болын һәм көтүлекләр, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчалары ясалма яңгыр ярдәмендә сугарыла. Торбалардан сиптерелгән су, билгеле бер биеклектә тоташ агынтыга әверелә һәм кояш нурлары белән өретелеп салават күпере хасил итә. Ерактан карaганда бу күренеш кырлар өстеннән йөзеп баручы төрле-төрле төстәге үтә күренмәле җилкәнне хәтерләтә. Дөньямны онытып, шул матур күренешкә сокланып барганда, Николай Андреевичның сынаулы карашы миңа текәлгәнлеген тоям һәм үз-үземне кулга алырга, сабырлыгымны җуймаска тырышам. Әмма авыл кырындагы борылышта үземә күптәннән таныш агачларны, шул агачлар арасыннан күзгә чалынып киткән больницаны күргәч, кычкырып җибәрмичә булдыра алмадым:

— Нишләп соң МТС бинасы күренми? — дидем мин, элекке машина-трактор станциясенең больница артында тезелеп киткән корылмаларын күз алдыма китереп.

— Хәзер монда җитен заводы,— дип җавап кайтарды юлдашым. — Бөтен нәрсә ер-яңадан үзгәртеп корылды.

— Ә ерганаклы чокыр кая?

— Чокыр үз урынында. Инеше дә әүвәлгечә агып ята. Ләкин ул бездән уңдарак иске юл буенда калды. Без яңа юлдан кайтабыз.

Ике көннән соң, Әлмәт шәһәрендә «Татнефть» берләшмәсе җитәкчеләре белән очрашу вакытында, мин бер сан ишеттем: бу берләшмә төзелгән 1950 елдан башлап республикада 40 мең чакрым яңа юл салынган. Ишеттем... һәм Иске Куакка әллә кай-

чангы, тузып, җимерелеп беткән юлдан кайтмавыбызны башыма да китерә алмаслык беркатлы булуымны уйлап, юлдашыма сиздермичә генә елмаеп куйдым.

Иске Куакны тануым да, танымавым да әнә шундый «әчке монолог»тан башланды. Чиркәүнең гөмбәзе юкка чыкса да, каркасы әле хәзерге көнгәчә сакланып калган һәм ул, бер-ике елдан Культура йорты булып әверелер өчен, төрле яктан янкормалар белән әйләндереп алынган. Аның янәшәсендәге зур кирпеч йортка да капиталь ремонт уздырыла. Анда колхоз идарәсе күчәчәк. Мәктәп яңа, ә искесенә интернат урнашкан. Авыл бәләкәйләнеп калгандай күренә, чөнки аның ике якка сузылган оч-канатлары кыскара төшкән, урамнары һәм тыкрыклары һаман да шул ук. Ләкин ике яклап бөтенләй бүтән йортлар тезелеп киткән. Болары элеккеләренә караганда күп тапкыр зуррак, иркенрәк һәм матуррак. Салам түбәле өйләр монда әйтерсең лә беркайчан да булмаган. Ә шулай да авылны карап йөргәндә миңа салам түбәле ике өйне күрергә туры килде. Соңыннан белдем: аларны хәзерге яшьләр кешеләрнең әле моннан берничә дистә ел элек кенә нинди шартларда яшәгәнлекләрен белеп торсыннар өчен махсус калдырганнар икән.

Унбиш ел бер дә алышынмыйча «Ленинский путь» колхозын җитәкләгән Вениамин Георгиевич Арютин белән танышам. Хезмәттәге тырышлыгы һәм фидакарьлеге өчен ул Ленин, Октябрь Революциясе һәм «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнгән. Аның белән сөйләшкәндә фикерләремне бер тирәгә тупларга телим. Ләкин юкка гына. Хәтер йомгагым сүтелеп, уйларым үткән вакыйгаларга бәйләнешле рәвештә күңелгә онытылмаслык булып кереп калган авылның мөхтәрәм кешеләренә барып тоташа. Йортында кайчандыр безнең гаиләбез яшәгән Василий Денисов күптән инде дөнья куйган. Хуҗалык итә белүче, киң күңелле, төпле һәм акыллы карт иде. Ә аның улы, әтиемнең полкташы Илья Васильевич Денисов кайда икән хәзер? Ярдәмгә авылның өлкән яшьтәге агайларын чакырам. Аларның җаваплары әзер:

— Әйе, бар иде Илья Денисов. Сугыштан исән-сау әйләнеп кайтты. Ләкин авылда торып калмады, Лениногорскига күчеп китте. Әтисе исән чагында бик еш кайтып йөри иде, соңгы араларда күренгәне юк.

Бүгенге көндә нинди эш белән шөгыльләнә дисезме?.. Пенсиядә булса кирәк. Өлкән улы Василий — танылган кеше. Ул Лениногорскида яши, нефть промышленностенда эшли.

— Ә Василий Иванович Яницкий?

— Хәтерегездәдер, ул бит бер кулын өздереп кайткан иде. Аны Борисоглебскидагы очучылар әзерли торган училищега җибәрделәр һәм ул шунда төпләнеп калды.

Мин Василий Ивановичның туганнан туган энесе, сабакташ дустым Шурка Абражеев турында сорашам һәм: «Ул да абыйсы юлыннан китте, очучы булды», — дигән җавапны алам. Хәзер ул Ростов-Донда яши икән... Аннан соң тагын бер Денисовлар гаиләсен хәтерлим. Алар без яшәгән Денисовларның кардәшләре иде, күп балалы гаилә иде ул. Әтиләре Егор Денисов сугышка кадәр Иске Куакта авыл Советы председателе булып эшләгән. Фронтта һәлак булган. Олы уллары Иванны армиягә без монда чакта алдылар. Ул китте, ә өйдә берсеннән-берсе кечкенә сабыйлар утырып калды. Бик авырлык белән яшәде ул гаилә...

— Иван Егорович Денисов? — дип кабатлады колхоз председателе Вениамин Георгиевич Арютин һәм Николай Андреевич Егоров беравыздан. — Соң ул Денисовлар турында район газетасының бүгенге санында да язганнар. Менә, рәхим итегез...

Лениногорскида чыга торган «Заветы Ильича» газетасын кулга алам һәм анда басылган «Денисовлар династиясе» дигән очерк юлларына текәләм: «Әтиләре һәлак булды. 1943 ел башында Иванны да сугышка алдылар... Ул, пулемет взводы командиры булып, Берлинга барып җитте. Аны штурмлауда катнашты һәм җирне гүя аягүрә торып басарга мәҗбүр иткән мәхшәр эченнән исән-сау чыкты». Шөкер, исән, димәк, Ваня. Очеркны укыйм һәм Иванның катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарга капиталь ремонт ясау, яшьтәшем Александрның бораулау эшләре идарәләре начальникларының урынбасарлары, Михаил һәм Владимирның баш инженерлар булып эшләүләрен беләм. Очеркта әйтелгәнчә, барысы да нефтьче һөнәрен сайлаганнар, барысы да тормышта үз урыннарын тапканнар. Бераз олыгая төшкән Анна Григорьевна ял көннәрендә гадәттәгечә бөтен гаиләләре белән бергәләп әнилә-

ре яши торган туганнары Николай йортына җыелган балаларына карап-сокланып туя алмый. Йорт эче оныкларының күңелле, җанга рәхәтлек бирә торган шау-шуы белән күмелә. Әйбәт итеп мунча ягыла, аннары традицион табын әзерләнә.

Сүз агышында тагын бер исем — укытучы Валентина Афанасьевна исеме телгә алынды. Валентина Афанасьевна Болотова шушында, авылда яши. Ләкин хәзер инде ул укытмый, күптәннән пенсиядә. Без аның янына юнәләбез. Мин аңа үземнең исемемне, сугыш вакытында Иске Куакта яшәвемне әйтәм. Юк, хәтерләми. Танымавы өчен гафу үтенә. Әйе, күпме еллар үткән, бу вакыт эчендә ул күпме балаларны укытып чыгарган. Авылныкыларны истә калдыру җиңелрәк, ә эвакуацияләнгәннәрне ничек итеп хәтерләп бетермәк кирәк: килгәннәр дә киткәннәр...

Колхоз идарәсендә утырганда ук Вениамин Георгиевичтан мин үзе җитәкләгән хуҗалык турында сөйләвен үтенгән идем. Басынкы, тыныч холыклы председатель сүзгә саран. Ул бары тик бер генә тапкыр, мин авыл халкының сугыштан соңгы елларда ничек яшәве турында сорау биргәч кенә, гадәттәге сабырлыгын югалтты. Авыр шартларда яши ул чордагы Иске Куак, ярлы һәм ачлы-туклы яши. Кешеләр, аеруча яшьләр, авылны ташлап китәләр. Ә барып төпләнер урын юк, дип зарланырлык түгел. Ул чактагы геолог-тикшеренүчеләрне кем генә хәтерләми икән?! Шөгер нефть ятмалары инде 1943 елда ук ачылган була. Һәм халык нефть промыселларына агыла башлый. Ни әйтсәң дә анда хезмәт хакы да тотрыклы, яшәү урыны һәм культура да шәһәрнекенә охшыйрак төшә. Өстәвенә укырга, белемеңне күтәрергә, күңелеңә якын һөнәргә ия булырга да мөмкинчелек бар...

Тора-бара нефть индустриясе авыл хуҗалыгын да үз артыннан ияртә. Илленче еллар азагыннан башлап Иске Куакның да хәле акрынлап яхшыра башлый. Авыл яңадан үсә һәм яшәрә. Халыкның стабильләшүе аркасында колхоз тагын 53 нче яңа йорт төзүгә ирешә. Колхозчыларның уртача айлык хезмәт хакы 145 сумнан арта. Соңгы өч ел эчендә хуҗалык бер миллион сум саф табыш алган. Тугызынчы бишьеллыкны ул сөт буенча өч ел ярымда үтәгән. Колхозның терлекчелек профиленә туры китереп, монда 1152 баш сыерга исәпләнгән һәм тулысынча механикалаштырылган яңа комплекс төзелгән.

Әнә шулай яши бүгенге Иске Куак. Кыш көннәрендә суны Чишмә елгасыннан ташырга мәҗбүр булган авыл урамнарына су торбалары сузылган. Бүлмәләрне яктырткан электр утлары, газ баллоннары, мотоцикл һәм телевизор кебек әйберләр — монда да гадәти бер нәрсәләр. Йортларның гына түгел, кешеләрнең дә йөз-кыяфәтләре, характерлары бик нык үзгәргән.

Чишмә елгасына төшәбез. Суга сикерер алдыннан дәртсенеп кайчандыр без басып торган шул ук текә яр. Ә менә елга үзе бик нык үзгәргән, аның теге чактагы саф, чиста суы соңгы елларда шактый пычранган, болганган. Умарта оялары хәтерләтеп, яр буенча тезелеп киткән кечкенә мунчалар юкка чыккан. Язларын елганың аръягында шау чәчәккә күмелеп утырган шомырт агачлары да сагынып сөйләргә генә калган. Аларның киселеп бетү сәбәбен миңа кыска гына итеп болай аңлаттылар:

— Агачларны кисеп, ул урыннарда культуралы көтүлекләр ясалмаган булса, җәмәгать терлекчелеге хәзерге дәрәҗәгә ирешер идемени?!

— Аулак өйләр, җыелышып кич утырулар да беттеме? — Алдагысына бернинди дә бәйләнеше булмаган әнә шундый яңа сорау ычкынды телемнән. Хәер, бу сорауны мин аңлы рәвештә бирдем. Моның шулай булуын Вениамин Георгиевич та сизенде, ахры, көтмәгәндә бөтенләй икенче нәрсәгә кучүем аны һич тә гаҗәпләндермәде.

— Аулак өйләр турында нинди сүз булуы мөмкин, — диде ул көлемсерәп, — хәзер бит кешеләр бер-берләре белән телевизор аша танышалар, телевизор аша күрешәләр...

Монда мин әдәби тәнкыйть цехындагы кайбер коллегаларымның иске авыл тормышындагы башлангыч чорны сагынып көрсенүләре турындагы сүзләре белән бәхәскә кермичә булдыра алмыйм. Бер караганда, аларны аңлап та була: кеше буларак үзенең башлангыч чорына ваемсыз карауучыларның җанын, мөгаен, прагматизм микроблары кимерәдер. Әмма узган заманга табыну, аңа соклану ничек кенә көчле булмасын, бары тик шул хис иркенә генә буйсынып, бүгенге сулышын тоймыйча яшәүне мин һич тә акыллылык димәс идем. Ул юл белән киткәндә, авызымнан җил алсын, чыра яки чабата заманнарына кире әйләнеп кайтырга мөмкин. Иске Куакта һәм якын-

тирәдәге башка авылларда чабатаны бик оста үрәләр иде. Ә хәзер аның хәтта исемен дә онытып баралар. Яшермим, малай чагымда чиксез сокландырган һәм тоташтан берничә чакрымга сузылып киткән шомыртлы әрәмәләрнең юкка чыгуын күреп мин дә бик әрнедем. Ләкин сугарулы болыннарның да үз матурлыклары бар. Үз куллары белән тудырылганлыктан, ул матурлыкны бүгенге яшь буын безгә караганда да тирәнрәк тоядыр. Әйе, матур бер истәлек булып күңелемә кереп калган кич утыруларның бетүе дә кызганыч. Әлбәттә, телевизор кешегә күбрәк рухи азык бирә. Тик монда, әгәр дөрес куллана, дөрес файдалана белсәң, дип өстәргә кирәк...

Кич якынлашып килә. Бәгелмәдә мине иптәшләрем көтә. Иртәгә иртүк Әлмәткә китәргә тиешбез. Безнең язучылар бригадасының тынгысыз житәкчесе — «командор»ы Юрий Суровцев алдан ук кат-кат кисәтеп куйды: «Төнлә булса да билгеләнгән жиргә жыелып бетәргә!»

Кабат Лениногорскига кайтабыз.

— Нәрсә, Денисовларга сугылып чыгабызмы әллә? — ди кинәт Николай Андреевич.

— Сез аларны беләсезмени?

— Кем генә белми икән аларны?!

Кышын яшьнәгән яшен кебек көтмәгәндә Иван Егоровичка килеп керәбез. Ишегалдындагы һәм шунда ук Александрга шалтыраталар. Менә ул да килеп житте, ә вакытыбыз санаулы. Капка төбендә машина көтә. Бәгелмәдә «командор»ыбыз үз-үзен кая куярга белми булыр. Ашык-пошык кына фотоальбомнар караштыргандай итәбез. Андагы рәсемнәрнең берсендә мин элек үзем яшәгән өйне һәм күп санлы туган-тумачалары уратып алган Василий Денисовны күрәм. Әле «син»гә, әле «сез»гә күчәбез, бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә сөйлибез. Менә хәзер, ул очрашуны искә төшергәндә, бер нәрсәгә үкенеп бетә алмыйм: тегесен сорашмаганмын, монысын белешмәгәнмен...

Өстәл янына утырышабыз. Иван безне куна калырга кыстый. Мин аңа яңадан иркенләп килергә сүз бирәм. Ә хәзергә, истәлек итеп карар өчен, өлкән Денисовның фоторәсемен алам. Аның артына: «Бу рәсем сезгә авыр сугыш елларында Иске Куакта бергә-бергә яшәгән чагыбызны хәтерләтсен»,— дип язылган.

— Я, ничек барып кайттың? — дип сорый миннән Бәгелмәдә «командор».

— Беләсеңме, бәхетле кеше мин. — һәм үз-үземә сөйләнгәндәй итеп өстәп куям. — Еракта гы үткәнемне эзләп киткән идем, бүгенге көнемне табып кайтып киләм. Үзем белән очрашкан, танышкан кешеләрдән күпме яңа, дулкынландыргыч хатирәләр алып кайттым Шөгер, Лениногорск якларыннан. Алар бит минем өчен сугыш чоры хатирәләре кебек үк кадерле һәм онытылмас хатирәләр.

Кабат очрашканга кадәр, якташ дуслар!

**Рәшит ГӘРӘЙ тәрҗемәсе.**

**Сатимҗан Санбаев,**
казакъ язучысы

# ЙӨРӘГЕМӘ КАДЕРЛЕ ЯКЛАР

*Татарстанда уздырылган Совет әдәбияты көннәре турында язмалар*

1

Вакыт торган саен тыгызлана. Без фәнни-техник революция заманында яшибез. Дөнья кичәгегә караганда һаман катлаулырак була бара. Информация белән тулы кызыксынуларның, рухи омтылышларның офыклары киңәя. Һәм әле кайчан гына теге яки бу культураның рухи дөнья өчен әһәмияте әллә ни тоелмаган формалары язучының дөнья белән бәйләнешендә, әдәбиятларның үзара элемтәсендә шул кадәр тыгыз контактка керә, алар бу очракта мөһим бер факторга әверелә. Вакыт безгә үзе әйтеп тора. Шул ук вакытта, зур әдәбият шул кадәр күптән барлыкка килгән, ул безгә, хәтта төрле баскычларда булса да, һәрвакыт булгандыр шикелле. Ләкин без төрле милләт әдәбиятларының төрле чорда иҗат ителгән һәм гомумкешелек культурасының алтын фондын тәшкил иткән бик күп мисалларны күрсәтә алабыз. Әгәр дә игътибар беләнрәк карасак, аларның дөньяга гади соклану яки дөньяны образлы күзаллау гына булмавын, бәлки кеше рухының күтәрелеш моментларын, җирдәге туганлык һәм гуманизм идеалларын раслау өчен көрәш икәнен дә күрербез.

Мәрхәмәтле кешелек шундыйлар исәбендә бөек татар шагыйрьләре Габдулла Тукай һәм Муса Җәлилне дә атый.

**Сөй гомерне, сөй халыкны,**
**Сөй халыкның дөньясын.**

Яңа буыннарга мөрәҗәгать итеп, Тукай кайчандыр шулай дип язган иде.

Тукай яшәгән һәм иҗат иткән чорда, аннан мең чакрымнар ераклыкта казакъ халкының бөек улы Абай Кунанбаев милли шагыйрьнең үзенә ирешүнең, үз җиреннән гомумкешелеккә илтә торган юлның озын һәм авыр икәнлеген исбат итте. Габдулла Тукай да, Абай Кунанбаев та язучының халыкта булган иң яхшыны ышандырырлык һәм дөрес образлр аша тасвирларга, аны башка халыкларга үз халкының бүләге итеп тәкъдим итәргә тиеш булуын күз алдында тотканнар. Һәм, әлбәттә, ике шагыйрь дә әлеге олы миссияне һәр әдипнең булдыра алмасын да яхшы белгәннәр. Әдәбиятка да, башка тере организмнарга хас булган кебек үк, илһам очышының шатлыклары белән беррәттән, уңышсызлыклар да хас.

Татар язучылары да күпмилләтле әдәбиятыбызга үзләренең лаеклы өлешләрен керттеләр. Татарстанда уздырылган Совет әдәбияты көннәре нәкъ шуның бер дәлиле. Ул—татар әдипләренең югары сәнгать осталыгын югары бәяләү, аларның изге бурычларын намус белән үтәүләрен хөрмәт итү. Шуның белән бергә, Совет әдә-

бияты, совет әдипләре алдында торган, бергәләп хәл итәсе яңа бурычларны барлау, бүгенге замандашларыбызның катлаулы һәм бай дөньясын күрсәтеп бирү, җәмгыятебезнең, үз халкының, кешелекнең өзлексез үсеп, алга баруы турында кайгырту һәм чын рухи батырлык хас булган совет кешесенең образын тасвирлаган яңа китаплар язу.

Тормыш әдәбиятны барлыкка китерә торган бик күп яңа компонентлар алып килде. Техника, элемтә чаралары үскән бер чорда элек, гомумән, ФТР гел булмагандыр да дигән уй килеп туа: әйтик, кеше таштан беренче корал ясаганда да, җирнең түгәрәк икәнен белгәндә дә, кеше үзенең галәмнең бер кисәкчәсе икәнен аңлаганда да, галәмнең үзенә үтеп кергәндә дә... Баксаң, матур тел белән, образлы итеп язу гына җитми икән бүген. Китап камилме? Язучы конфликтларны заманча итеп чишә алганмы? Башкача әйткәндә, язучы заманчамы? Язучы кайда гына яшәсә дә — Ашхабад янындагы авылдамы, Алма-Атадамы, борынгы Казанның үзәгендәме, я булмаса күп миллионлы башкалабыз Мәскәүдәме,— берәүгә дә күптән инде бернинди дә ташлама юк. Чын әдәбиятның законнары иҗат итүчеләрнең барысына да бер үк.

Әдәби геройларда рухи батырлык та, намуслылык та, горурлык та булырга тиеш. Димәк, кешеләр язмышын бирә белү сәләте генә җитми, ә үзеңә дә, социаль-актив шәхес буларак, шул ук категорияләр белән яшәргә, үз иленнең, үз халкының ихтыяҗлары белән, димәк, гомумкешелек проблемалары белән дә янып яшәргә кирәк. Бу процесс, әлбәттә, бик озын һәм бер дә җиңел түгел. Биредә уңышка ирешүнең бердәнбер юлы—язучының тормыш белән аңлы бәйләнеше. Без бу кагыйдәне яхшы үзләштердек, һәм шуңа күрә дә борынгы Татарстан җирендә яңа тормыш төзү тәҗрибәсенә мөрәҗәгать иттек, мөмкин кадәр ныграк үзләштерергә тырыштык. Чөнки һәр укучыга мәгълүм: язучының әсәре кеше акылына ныграк тәэсир итсен өчен, ул профессиональ дәрәҗәдә язылган булырга һәм тормыш дөреслегенә нигезләнгән булырга тиеш.

Без Татарстанның бик күп почмакларында булдык: уннарча коллективларга бардык, республиканың промышленносте, авыл хуҗалыгы һәм культурасы белән таныштык. Совет әдәбияты көннәрендә катнашучылар Татарстан тормышы турында шактый гына хәбәрдар булсалар да, үз күзләребез белән күргәч, республика үсеше безне таңга калдырды. Әйе, Татарстан—совет иленең һәрьяклап үскән, чәчәк атучы республикаларының берсе. Монда булган һәркем үзе белән бары тик якты тәэсирләр генә алып китә. Без Бөгелмә нефтьчеләре, КамАЗ машина төзүчеләре алдында чыгыш ясадык, «Дуслык» нефтүткәргечнең башланган урынында булдык, Ленин комсомолы исемендәге Миңлебай газ эшкәртү заводын карадык. Җәлил шәһәренең яшел агачларга күмелеп утырган урамнары буйлап йөрдек, «Красный ключ» кошчылык фабрикасы эшчеләре белән сөйләштек. Кыскасы, коммунизм төзелешенең алгы сызыгында көрәшүче меңләгән хезмәтчәннәрнең киеренке һәм илһамлы хезмәтенең шаһитлары булдык. Алар бай тарихи һәм зур культура мирасын саклаучы борынгы җирдә яшиләр һәм эшлиләр.

Очрашулар вакытында кызыклы сөйләшүләр, әңгәмәләр туды, без аларның озын дәвамлы булуын, ныклы дуслык урнаштыручы әңгәмәләр булуын телədeк. Заводлардагы, колхоз кырларындагы реаль геройлар безнең булачак китапларыбызда ничек урын алыр, инженер функциясен үтәүче монтажник, галимнәр белән бәхәс алып бара алырлык төзүче, кышкы салкында да, көчле җилдә дә туктаусыз хезмәт батырлыгы кабатлаучы эшче безнең әсәрләрдә ни рәвешле гәүдәләнеш табар? Без ул чакта шул хакта уйладык.

Үзенең тормышы белән кешелекне танып-белүнең яңа импульсларын тудырган совет кешесенең рухи көчен ниләр белән үлчәргә? Аның башлангычы һәм чиге кайда? Биредә, күрәсең, тормышыбыздагы бик күп өлкәләрнең яңа үзгәрешләре турында сөйләргә туры киләдер.

Эшчеләр дөньясы гади генә түгел. Без моны Яр Чаллыда ачык күрдек. Хәтта КамАЗ нинди генә яшь завод булмасын, биредә дә үзенең традицияләре, шуның белән бергә, тиз генә күреп булмый торган тирән агымнары да бар икән. Монда инде кыскача гына танышу түгел, ә җентекле анализ, тикшерену кирәк, даими игътибар, художникның үткен күзе кирәк. Һәм без Совет әдәбияты көннәрендә катна-

шучылар, шушындый очрашуларның—тугандаш әдәбиятлар вәкилләренең Татарстан хезмәт ияләре белән очрашуларының киләчәктә традициягә әйләнеп китүен теләдек. Без Татарстан эшчеләренең хезмәтенә бөтен кешелеклелек сыйфатлары, һәм иң элек, яңага омтылу хас булуын күрдек. Әлеге сыйфат аларның эшен бүгенге колхозчыларның, интеллигентларның тормыш максатлары-омтылышлары белән тәңгәлләштерә. Димәк, безнең әдәбият тасвирлаган бүгенге хезмәт кешесенең образы, күрәсең, дөньяның бөтен калган яклары белән—тәнкыйтьчеләрнең яраткан сүзләре белән әйтсәк, җәмгыятьнең иҗтимагый, политик, экономик һәм рухи структурасы белән бәйләнештә бирелергә тиештер.

Татар язучысы Г. Ахуновның иң яхшы китапларында без җәмгыятьнең гармоник үсеше сәгать саен, көн саен иҗат итүче, яңа тормыш төзүче совет кешесенә бик тә аңлаешлы һәм якын булуы, бу хиснең аның өчен табигый булуын күрсәткән фикернең уңышлы гәүдәләнешен күрәбез. Язучы күп кенә язучылар өчен типик күренешкә әйләнгән хаталардан кача алды. Аның әсәрләрендә җентекләп тасвирланган техник, фәнни һәм производство проблемалары да, иҗтимагый хезмәтне шәхси тормыш белән махсус рәвештә чуалтып бетерүләр дә юк. Ә бит безнең китапларда барысы да була, ләкин без аларда чын мәгънәсендә тулы канлы бүгенге заман героен сирәк очратабыз. Ә Г. Ахунов үзенең героен бары тик хезмәткә хокуклы булуын гына күрсәтми, ә аның бөтен якларын да ачып бирә һәм аның гражданлык активлыгын беренче урынга куя.

Гомумән, татар язучыларының соңгы ун-унбиш ел эчендә язылган иң яхшы китаплары бүгенге тормышның төбенә үтеп иҗат ителгәннәр. КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Л. И. Брежнев сүзләрен искә төшерик: «Художник совет халкының күпкырлы бөтен тормышы белән никадәр тыгызрак элемтәдә торса, иҗат казанышларына һәм уңышларына ирешү юлы да шулкадәр турырак була».

Һәм иҗат кешесенә программа булырлык әлеге сүзләрне татар язучылары бөтен җитдилеге белән үзләренә корал итеп кабул итәләр.

## 2

Тормышны реалистик тасвирлауда татар әдәбиятының традицияләре күптәннән килә. Тукайның һәм Ибраһимовның, Такташның һәм Җәлилнең иҗат мирасы бөтен культура дөньясына билгеле. Шунысы куанычлы, күренекле әдипләрнең шушы традицияләре Татарстанның бүгенге язучылары тарафыннан иҗади рәвештә үстерелә. Бүгенге көндә бөтенсоюз укучылары арасында популярлык казанган татар язучыларының фамилияләрен генә санап чыксаң да, бер биткә генә сыймас иде. Татар әдәбиятының Көнбатыш Европа, Латин Америкасы, Африка әдәбиятлары белән дә элемтәсе көннән-көн ныгый. Ә бит бу традиция шулай ук күптәннән килә. Егерме җиде яшь кенә яшәп калган Тукай шул кыска гына гомерендә йөзләрчә классик шигырьләр, поэмалар гына язмаган, ә Гете, Һейне, Шиллер... әсәрләрен дә татар теленә искиткеч итеп тәрҗемә иткән. Безнең уртак хәзинәбез булган әдәбиятка чын мәхәббәт кенә Бөгелмәдәге Ярослав Гашек музеен тудыра алгандыр. Минем моңа иманым камил. Культура үзәге булып йөргән теләсә кайсы зур шәһәрләр дә шушындый кызыклы музей белән мактана алмыйлардыр, мөгаен. Бөгелмә, гомумән, үзенчәлекле шәһәр. Ул Ватаныбызга кешелекне фашизм коллыгыннан азат итү өчен барган изге көрәштә батырларча көрәшкән сигез Советлар Союзы Герое биргән шәһәр. Әлеге геройларның барысы да Бөек җиңүгә кадәр яши дә алмаганнар. Бу очракта икенче бер Советлар Союзы Герое, антифашистлар подпольесының җитәкчесе Муса Җәлилнең үлем алдыннан Моабит төрмәсендә язган шигырь юллары искә төшә:

**Җыр өйрәтте мине хөр-яшәргә**
**Һәм үләргә кыю ир булып.**
**Гомерем минем моңлы бер җыр иде, —**
**Үлемем дә яңрар җыр булып.**

Бөгелмәдән ерак түгел генә нефтьчеләр белән төзүчеләрнең зур булмаган шәһәре балкып тора. Аның иseме — Җәлил. Ул бик пөхтә, чиста. Биредә әдәбиятны яраталар, андый җирләр язучыларның йөрәгенә, әлбәттә, кадерле. Без Җәлилдә бары бер генә көн булдык, әмма ул бер сәгать кебек кенә узып китте. Совет әдәбияты көннәрендә катнашучылар җәлиллеләр белән озаклап хушлаштылар. Минем каләмдәшләр батыр совет шагыйре һәм гражданины Муса Җәлил исеме белән бәйләнешле бу шәһәргә бер тапкыр гына әйләнеп килмәсләр әле.

Без әр-яңа автобуста барабыз. Алда безне Чаллы көтә. Шагыйрьләр, язучылар исемен йөртүче илебездәге шәһәрләрне искә төшерәбез. Баксаң, андый шәһәрләр аз түгел икән: Пушкино, Горький, Джамбул, Шевченко, Мирзо Турсун-Задә... Без М. Җәлилнең фронттан әнинә җибәргән бер хатыннан шундый юлларны хәтерләдек. «Үлемнән соң да яшәү бар бит әле... халык күңелендә, халык аңында яши торган тормыш бар».

Ул көнне без барыбыз да Муса Җәлилнең рус теленә тәрҗемә ителгән шигырьләр китабын алып киттек. «Шагыйрьнең китабын һәр язучының әеннән табарга була,— диде безгә Татарстан өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин,—ләкин Муса Җәлил исемен йөрткән шәһәрдә тапшырылган Җәлил китабы сезнең өчен кадерле, изге реликвия булачак». Китапның титул битендә: «Татарстанда Совет әдәбияты көннәре истәлегенә», — дип язылган иде.

Ә каршыбызга әр-яңа буяулары елкылдап торган зур йөк ташучы машиналар агыла. Аларның алларында инде күзләр ияләшеп беткән «КамАЗ» эмблемасы балкый.

### 3

Без Яр Чаллыга Кама батыры 100000 нче «КамАЗ» эшләп чыгарган көнне килеп төштек. Бу хезмәт батырлыгына рекордлы кыска срокларда ирешелде, вакытлы матбугат татар машина төзүчеләренең әлеге җиңүе турында күп язды. Һәм без аларның батырлыгын, вакытка—аларның иң беренче, иң үзсүзле көндәшенә тормыш мәгънәсе бирә алуларының бәясен яхшы аңлыйбыз.

Заводта уздырылган митингта юбилей машинасының ачкычын казакъ Кормангожа Толепбергенович Самархановка тапшырдылар. Казагыстан ССРның атказанган транспорт работнигы, «Почет билгесе» ордены кавалеры, VIII, IX һәм X бишьеллыклар ударнигы К. Самарханов ике прицеплы гүзәл «КамАЗ-5320» машинасында элек тә йөргән икән. Аннары шунысы да миңа символик булып тоелды: Самарханов әлеге машинаны алырга Уральск шәһәреннән—шагыйрь Габдулла Тукай үзенең ярты гомерен уздырган шәһәрдән килгән.

Без Самархановның машинаны ничек итеп дулкынланып кабул итүен күзәттек. Мин ул чакта «менә хәзер Самарханов бу машина белән Казагыстанга таба юл алачак һәм безнең җирләрне тоташтырачак, аның юлы, аның рухи омтылышы безнең казакъ һәм татар халыкларының электән үк кадерләп сакланган бөек дуслыгына бер штрих булып өстәләчәк» дип уйладым. Кайчандыр бик күптән, әгәр төгәлрәк әйтсәк, 1909 елда, шул ук дала юлыннан казакъ далаларына таба акрын гына арба тәгәрәгән. Әлеге арба таулар арасындагы үзәнлеккә урнашкан ерак авылга Абай шигырьләренең версткасын алып кайткан. Казакъ әдәбиятының классигы Абай Кунанбаевның беренче китабы Казанда басылып чыга. Ул вакытта шагыйрь үзе исән булмый инде, кызганычка каршы, китабын күрә алмый. Аның, гомумән, үзе исән чакта бер китабы да басылмый. Әмма без, Абайның варислары, татар халкының казакъ культурасына туганнарча ярдәмен күңелләрдә саклыйбыз.

Унарлаган милләт вәкилләре яшәгән һәм эшләгән Чаллыда совет кешеләренең тормыш проблемаларының уртаклыгын, халыклар язмышының аерылгысызлыгын ничектер аеруча ныграк тоясың. «Мөгаен, шушы хәл төрле республика һәм өлкә язучыларының иҗади эзләнүләрендә уртак юнәлешләр тудырадыр». Бу фикерне Совет әдәбияты көннәрен йомгаклаучы теоретик семинарда СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, күренекле тәнкыйтьче Ю. И. Суровцев әйткән иде. Шуны да өстәргә кирәк,

милли характерны тасвирлаганда, әгәр дә язучы туган халкының милли үзенчәлеген, культурасының колоритын югалта икән, ул һәрчак гомумкешелек культурасының зур югалтуы булып исәпләнде һәм исәпләнә. Ә бит Чаллы шәһәр комитеты урнашкан йортның фойесына Тукайның нәкъ менә үзеннән соң килгән буынга мөрәҗәгать итеп әйткән сүзләре уеп язылган:

**Сөй гомерне, сөй халыкны,**
**Сөй халыкның дөньясын.**

Завод һәм фабрикаларда, нефть промыселларында һәм институтларда, колхоз һәм совхозларда узган очрашулардан соң, Татарстаннан алып киткән рухи байлыкны берничә сүз белән генә әйтеп бирүе авыр, билгеле.

Һәр коллектив — үзе бер дөнья, катлаулы дөнья. Хәзергечә итеп әйтсәк, тере социаль-психологик организм. Аның, әлбәттә, үзенең уңышлары һәм уңышсызлыклары, үзенең гимннары, маршлары һәм үзенең генә җырлары була. Коллективны белмәгән килеш, аның тормышын өйрәнми торып, аның проблемаларын, мәшәкатьләрен күрмичә коллектив тормышын белем диючеләр, һичшиксез, ялгышалар. Совет Татарстанында хезмәт ияләренең ничек яшәвен, аларның кызыклы, катлаулы тормышын, аның эченә кермичә торып, белү өчен, күрәзә, алдан күрүче булырга кирәк. Ләкин, алдан күрүчеләр, билгеле булганча, тулы канлы чын әдәбиятны тудыра алмыйлар. Коллективны берничә көн эчендә өйрәндем, диючеләр дә бик нык ялгышалар. Алар, мөгаен, Почет тактасындагы я булмаса, отчетларда язылган маршларны беләләрдер дә, әмма күңелләргә яшерелгән җырларны һәркемгә дә ачып салмыйлар. Кешенең табигате шундый. Ул җырны кычкырып җырламасалар да, аны ишетә белергә кирәк. Һәм ул җырны ишеткән язучы, бәлки, моңа кадәр үзенең дә җанында яткан җырны ишеткәндер. Әгәр дә шундый уртаклык, шундый җан берлеге туа икән, уртак җыр туа икән, китап та булачак дигән сүз.

Нәкъ шундый китап язасы килә!

Үземнең каләмдәшләремә — күптәнге дусларыма да, Татарстанда тапкан яңа дусларыма да иҗат уңышлары телим. Ул дусларны мин шушы татар җирендә — кешеләрнең шатлыклы да, моңлы да җырлары белән яктыртылган юлларында, сукмакларында таптым.

Йөрәгемә кадерле җирләр бу!

**Харис Зәйнуллин,**
*КПССның Арча райкомының беренче секретаре*

**Заһид Шәфигуллин,**
*Татарстанның атказанган культура работнигы*

# КҮҢЕЛЛӘРДӘ ТУКАЙ МОҢНАРЫ

Халкыбыз мул тормышта яши, дибез. Муллык! Гаять киң аның мәгънәсе. Авыл кешесе өчен өенең зур, иркен, матур булуын да, каралты-кураның ныклыгын да, кием-салымның әйбәтлеген дә, абзар тутырып терлек, кош-корт асрауны да, баз тулы бәрәңге, әсәк тулы ашлыгы булуын да, айдан-айга акчалата эш хакы килеп торуын да аңлата ул. Болары — муллыкның материаль ягы.

Ләкин материаль байлык — муллыкның яртысы гына бит. Материаль байлыгы зур булып та, рухи яктан ярлы кеше — гарип кеше ул.

Кешенең күңел үсеше туганнан алып, соңгы көненәчә бара. Ул эш нигездә кешенең рухи байлыклар белән танышу, аларга мәхәббәт саклау, матурлыкның кадерен белү, белем алу аша бара.

Моның өчен вакыт, дәресрәге, кешенең буш вакыты булуы мөһим. Хәзерге шартларда хезмәтне механикалаштыру һәм автоматлаштыру киң колач алган чорда, авыл кешесенең буш вакыты даими арта. Халыкны рухи баету чаралары һәм алымнары җирле шартларга һәм традицияләргә, мөмкинлекләргә карап сайлана.

Әйтик, менә Арча ягы өчен нинди үзенчәлекләр, нинди традицияләр хас соң? Ул, беренче чиратта, Тукай ягы, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәкимнәрне биргән як. Тагын да гомумиләштеребрәк әйткәндә, әдипләр ягы. Тәрбия эшендә нигә бу факторны файдаланмаска!

Нигә Арча районы хезмәт ияләрендә якташ шагыйрьләренә һәм язучыларга булган мәхәббәт хисен бөтен әдәбиятны ярату хисе дәрәҗәсенә үстермәскә! Тукай яки С. Хәким поэзиясен яраткан укучы Пушкинны һәм Лермонтовны да, Рәсүл Гамзатовны һәм Мостай Кәримне дә яратачак иң.

Бала әдәбият белән «Туган тел» һ. б. шундый кечкенә-кечкенә шигырьләр аша таныша башласа, тора-бара, ягъни үсә төшкәч, аның үзен сокландырырлык әсәрләр язган авторлар белән дә очрашасы, «тере» язучыны күреп сөйләшәсе дә килер. Бу очрашу аның гомерендә мәңгелек эз, якты истәлек калдыра, аңарда әдәбиятка сүнмәс мәхәббәт кабызуга ярдәм итәр.

Арча районы партия оешмасы халыкны эстетик тәрбияләү чараларын оештыруда әнә шушы фикердән чыгып эш итә. Әдәбият, сәнгать работникларының район хезмәт ияләре белән очрашуын теләп оештыра. Бу очрашуга игенчеләрнең, терлекчеләрнең күбрәк катнашуын тәэмин итә.

Шушы яктан караганда, 1979 елның июль башындагы очрашу аерата истәлекле булды. Эссе, кояшлы матур көн иде. Як-якларына яшь урман полосасы сузылган асфальт юлдан Тукай-Кырлайга районның төрле авылларыннан терлекчеләр, игенчеләр утырган автобуслар агылды. Күңелләрдәге хисләр ташкыны булып, шат җырлар яңгырый иде.

Бу көнне меңнән артык кешенең Кырлайга җыелуына нинди вакыйга сәбәп булды соң?

«Татарстанда совет әдәбияты көннәренә катнашу өчен илебезнең төрле почмакларыннан килгән төрле милләт әдипләре белән очрашуга җыелдылар алар», — дип язды ул көннәрдә газеталар.

Әлеге әдипләр: Украинадан Ю. Бедзик, Таҗикстаннан М. Хакимова, Мәскәүдән М. Львов, М. Колосов, Ленинградтан А. Шевелев, Башкортстаннан Р. Сафин, Удмуртиядән В. Ившин, Үзбәкстаннан Н. Нарзуллаев, Төрекмәнстаннан Я. Перкулиев, Татарстаннан С. Хәким, Ш. Галиев, И. Юзиев, Т. Миңнуллин, Ф. Мусин һәм башкалар халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай белән исәнләшергә, аның җырларында макталган шүрәле урманнары белән танышырга бирегә килгәннәр иде.

Һәм биредә — Тукай җырларына мул «азык» биргән шушы авылда — шагыйрь якташларының Тукайлар, Пушкиннар эшен дәвам иттерүче әдипләр белән очрашуы олы бәйрәмгә әверелде. Биредә һәр ике як — кунаклар да, хуҗалар да — бер-бер-

сенә бурычлы булып калмады. Хуҗалар — район хезмәт ияләре — кунакларны, рус совет шагыйре Михаил Львов сүзләре белән әйткәндә, «Тукай туып үскән туфракта аның якташларының хәләл көче белән үстерелгән икмәк» белән сыйласалар, әдипләр Яңа Кырлай культура йорты янындагы мәйданда район игенчеләрен һәм терлекчеләрен үз әсәрләре белән таныштырдылар. Күп кенә әсәрләрне нәфис сүз остасы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Айрат Арсланов уку шигырьләрнең аһәңен, тыңлаучыга тәэсирен тагын да арттырды.

Язучы һәм шагыйрьләрнең ерак җирләрдән нәкъ менә Кырлайга килүенең үзенә күрә сере бар. Тукай мемориалы, Тукай музее шушында үсеп чыкты. «Үсеп чыкты» диюебез дә юкка гына түгел.

Без илебездә А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой, М. Горький, Ш. Камал һәм башка күренекле әдипләрнең музейларын беләбез. Алар халыкның ихтыяры белән әлеге әдипләр яшәгән яки эшләгән, күпмедер дәрәҗәдә аларның эзе сакланган биналарда ачылганнар. Шуңа күрә, бу музейларны ачу өчен мәгълүм дәрәҗәдә нигез булган диясе килә. Ә Г. Тукай музеен ачу өчен аның туган авылында да, торган авылында да нигез булырлык биналар күптән искереп, юкка чыккан иде. Тукай истәлеге бары тик халык күңелендә генә яши иде. Аны киләчәк буыннар да сокланырлык итеп матдиләштерү теләге бөтен республика хезмәт ияләренең, бигрәк тә Тукай якташларының күңелен биләп торды.

Бу игелекле эштә күренекле скульптор, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Бакый Урманченың энтузиазмы хакында әйтми мөмкин түгел. Ул проектлаштырды бу мемориалны.

Аннары әлеге комплексны коруда, Тукай исеме белән бәйле тарихи истәлекләрне реставрацияләүдә автомобиль юллары идарәсе, республика Урман хуҗалыгы министрлыгының Арча подразделениеләре, Карадуган мебель фабрикасы, ТАССР Культура министрлыгының реставрация мастерское, төзү материаллары комбинаты, Арча һәм Әтнә төзү-монтаж идарәләре, ремонт-монтаж идарәләре, ремонт-төзү идарәсе, «Тукай-Кырлай» һәм К. Маркс исемендәге колхозлар, «Ватан» совхозы, ремонт-эксплуатация службасы, Арчадагы 17 нче механикалаштырылган күчмә колонна, Казандагы компрессорлар заводы, Зеленодольск фанера-мебель комбинаты эшчеләре көчләрен кызганмый эшләделәр. Аларның бу эшне күңел биреп, намус белән башкаруының нигезендә бөек Тукайга булган олы мәхәббәтләре ята иде.

Әлбәттә, Тукай музеен хәзерге заман әдәби музей дәрәҗәсендә төзү бер гасырга якын тарихы һәм тәҗрибәсе булган ТАССР Дәүләт музее ярдәменнән башка мөмкин түгел иде. Тукай яшәгән йортлар сакланмаган кебек, экспозициягә куярга ул файдаланган әйберләр дә юк дәрәҗәдә иде. Татарстан Дәүләт музееның әдәбият бүлеге (мөдире Д. Баһаутдинова) аларны эзләү һәм табу өчен Уральскига, Казанга һәм Татарстанның төрле урыннарына экспедицияләр оештыруы, шагыйрь тормышына һәм иҗатына бәйле материаллар җыю буенча армый-талмый эшләве олы хөрмәткә лаек. Тукай музее экспозициясендә шагыйрьнең Кырлайдагы тормышы белән беррәттән, Уральскидагы һәм Казандагы тормышы һәм эшчәнлеге дә шактый киң урын алуы — шуның нәтиҗәсе. Хәзер музейда Мотыйгия мәдрәсәсендә Тукай һәм башка шәкертләр укыган китапларның төп нөсхәсен күрәсең. Заманында Тукай эшләгән типография, Казанда ул яшәгән «Болгар» номерларының 40 нчы бүлмәсе күренешләре дә Дәүләт музее хезмәткәрләре тырышлыгы белән тергезелде.

Иң мөһиме — Тукай үзе яшәгән авыл пейзажына, урманга гашыйк иде. Музейда авыл һәм урман сулышы сизелергә тиеш дигән фикерне үзәккә кую яшь художник А. П. Лиюхинга экспозиция проектын эшләүдә дөрес чишелешләр табарга ярдәм итте.

Йөрәк кушуы буенча эшләнгән эшләрнең нәтиҗәсе дә күркәм. Киләчәк буыннарга лаеклы мирас булырлык музей-мемориал үсеп чыкты. Тукай мемориалына XIX йөз ахырында Тукайны асрамага алган крестьян Сәгъди абзый йорты, музей, китапханә, культура йорты, җәйге эстрада, өч катлы урта мәктәп, парк, икешәр катлы административ һәм сәүдә үзәкләре керә.

Музей бинасы үзәктә тора. Якында гына урманнан эзләп табып кайтарылган агач сыннар скульптор кулы тию белән «чын шүрәлегә» әверелгәннәр, алар «кети-кети уйнарга» дип каршыга киләләр сыман. Берсенең кулы Быелтыр егет бүрәнәсе ярыгына кысылып калган. Музей янындагы ясалма күлдә каз-үрдәкләр йөзеп йөри...

Игътибарны әйрәта нарат исе аңкып торган сап-сары бүрәнәләрдән корылган мәһабәт музей бинасы җәлеп итә. Өч залда: Г. Тукайның бала чагына, Уральскидагы тормышына, Казан чорына багышланган экспозицияләр куелган. Тагын бер зал «Г. Тукай безнең көннәрдә» дип атала. Өске каттагы «Тукай сынлы сәнгатьтә» дигән бүлектә исә илебез художниклары һәм скульпторларының әсәрләре тупланган. Алар арасында Хаҗиморат Казаковның Тукайның бала чагын сурәтләгән, Ленинград рәссамы Фәйзрахман Әминевнең Тукай геройларын тасвирлаган картиналары бар.

(Яшерен-батырын түгел, авыл районнарында әлегә тәрбия үзәге булырдай музейлар сирәк. Ә халыкта мондый учреждениегә ихтыяҗ зур. Хәзер Кырлайга районның барлык мәктәпләреннән экскурсиягә киләләр. Биектау, Саба, Балык Бистәсе, Кукмара районнарыннан килүчеләрнең исәбе юк).

Килгән кунакларга музейның фәнни хезмәткәрләре Алсу Галиева, Зәйтүнә Гарипова, музей мөдире Борис Антонов аларга Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлын, ул чор белән совет чорын чагыштырып, хәзерге үзгәрешләрне кешеләр күңелендә калырлык итеп аңлаталар. Гому-

мән, музейлар — яшь буынны эстетик һәм политик тәрбияләүгә лаеклы өлеш кертә. Ә Тукай музее эшче һәм колхозчыны гына түгел, яңадан-яңа буын шагыйрь һәм әдипләрне дә үзенә тарта торган үзәк булып тора.

Табигый ки, спектакль күрсәтү өчен клуб яки культура йорты, халыкны әдәбият белән тәэмин итү өчен китапханә һәм китап магазины кирәк булган кебек, хезмәт ияләре белән әдипләрне һәм сәнгать работникларын очраштыра торган урын булдыруның әһәмияте зур. Һәм Кырлайда шундый урын — Тукайга музей-мемориал булдыру белән халыкны эстетик тәрбияләү өлкәсендә район бик нык отты.

Очрашуларның берсендә Михаил Львов: «Мөселманнар хаҗ кылу өчен Мәккәгә агылган кебек, әдипләр дә Тукайга баш ию, аңа олы хөрмәтен белдерү өчен Кырлайга килә» дип бик дөрес әйтте. Әйе, бирегә Татарстан шагыйрьләре һәм язучылары бик еш була. Бигрәк тә Тукай туган көнне һәр яз саен Кырлайда поэзия бәйрәме уздыру традициягә әверелде. Һәр яз саен бирегә шигырь бәйрәме уздырылуның сере Сибгат Хәкимнең түбәндәге шигъри юлларында ачык әйтелгән:

> Язлар килгәч, Кырлай урманында
> Көязләнеп үсә яшь каен.
> Яшел ботакларын түбән иеп,
> Ул сагына җырчы Тукаен.
> Сагына аны озын нәратлары,
> Мәңге яшел торган чыршысы.
> Сагына Кырлай, сагына бөтен илем
> Сөекле улын — халык җырчысын.

Тукайны сагынып килү — аны үзеңнең остазың итеп кабул итү, күңелләрнең аның белән сөйләшүе, аның традицияләрен дәвам иттерү ниятләренең күркәм чагылышы ул.

Традицион поэзия бәйрәменнән тыш, яшь язучылар һәм шагыйрьләр семинары да Арча районында уздырылган иде. Татарстан Язучылар союзы һәм ВЛКСМ өлкә комитеты тарафыннан үткәрелгән бу чара Балтач, Саба, Биектау һәм Арча районнары яшь язучыларының зона конференциясе дип аталды. Ул КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карары куйган таләпләр яктылыгында барды.

Залда утыручылар әдәбиятыбызның танылган әдипләре, якташларыбыз Сибгат Хәким һәм Гомәр Бәшировның чыгышын зур дикъкать, кызыксыну белән тыңладылар. Арча яклары элек-электән зур шәхесләргә бай булган. Аларның татар культурасына, илебез халыклары мәдәниятына керткән өлешләре зур. Сибгат һәм Гомәр ага әнә шул турыда сөйләделәр. Күңелләрдә ул традицияләргә тугрылык хисе туды.

Җыеп әйткәндә, Тукай рухын яшьләргә бирү юнәлешендә районда күп төрле эшләр башкарыла. Шул исәптән колхозларга, культура йортларына, мәктәпләргә, китапханәләргә Тукай исеме бирелүен дә әйтергә кирәк. Районның Арча, Олы Әтнә, Яңа Кенәр һәм башка торак пунктларында 48 урам Тукай исеме белән атала. Аларның исеме үк Тукайга ихтирам, аның әсәрләре аша туган якка, аның табигатенә мәхәббәт тәрбияли.

Гомумән, якташыбыз Г. Тукайның туган көннәрендә шигырь бәйрәме тесендә барлык культура учакларында әдәби-музыкаль кичәләр, китап укучылар конференцияләре, викториналар, китап күргәзмәләре оештырыла, плакатлар эшләнә, әңгәмәләр уздырыла.

Һәр ел саен культура учреждениеләрендә, мәктәпләр белән берлектә, Г. Тукай әсәрләре буенча рәсем күргәзмәләре оештырыла. Районның барлык китапханәләрендә һәр ел саен шагыйрьнең туган көне уңае белән аның әсәрләрен пропагандалау айлыклары уздырыла. Наласа, Казанбаш, Гөберчәк, Күлтәс, Югары Пошалым, Олы Мәңгәр авыл китапханәләрендә «Тукай — татар поэзиясенең һәйкәле», «Г. Тукай — халыклар дуслыгы җырчысы» дигән әдәби кичәләр, Тукай-Кырлай, Олы Әтнә һәм Яңа Кенәр зона балалар китапханәләре, районның балалар китапханәсе Г. Тукай шигырьләрен укуга конкурслар оештыралар.

Әйе, районда Тукай иҗаты, Тукай образы, Тукай традицияләре халык массаларын эстетик тәрбияләүдә гаять киң файдаланыла. Бу исә тәрбия эшендә халык күңеленә үтеп керергә ярдәм итә.

*
* *

Бирегә сүз Г. Тукайга бәйле тәрбия эшләре хакында барды. Инде әйткәнебезчә, Арча ягы — башка күренекле шагыйрь һәм язучыларны да үстергән як. Алар Арча районы өчен үз кешеләр. Андый әдипләр районга шигырь бәйрәменә генә түгел, туган-үскән җирләрен сагынып та кайталар. Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр ага Бәширов Арчада гына түгел, туган авылы Яңасалада да ел саен диярлек була. ТАССРның Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Сибгат Хәким дә туган авылы Күлле Кимедә әледән-әле кунак. Мөхәммәт Мәһдиевне ел саен туган авылы Гөберчәктә очратасың. Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты язучы Гариф Ахунов та туган ягы Арчага кайтып килергә һәрчак вакыт таба. Рафаэль Төхфәтуллин, мәрхүм Мостафа Ногман, Мәрзия Фәйзуллина, Гасим Лотфи, Госман Бакиров, Нәҗип Мадьяров, Самат Шакир кебек язучы һәм шагыйрьләрне дә район халкы үз якташы итеп хөрмәт белән кабул итте һәм итә.

Үзенең шигырьләрендә әйткәнчә, Сибгат Хәким игенче уйлары, игенче хисләре белән яшәүче шагыйрь буларак, авыл хуҗалыгы өчен табигать шартларының ничек килүенә дә битараф карый алмый: «Иген уңса — җыр да тиз языла», дип искә ала ул.

Мондый шагыйрьгә колхозчылар йөрәк серләрен ачалар, киңәшләр алалар.

Кичләрен культура йортларында шагыйрьнең Арча ягында алган тәэсирләрен-

нән туган җырлары яңгырый. Аның иҗатына багышлап мәктәпләрдә, культура йортларында кичәләр оештырыла. Кайберләрендә ул үзе катнаша, чыгыш ясый. Катнашу мөмкинлеге булмаганда да кичә күңелсез үтми. Мәсәлән, Олы Әтнә, Күлле Киме, Куәм, Чиканас культура йортларында аның шигырьләрен укуга багышланган конкурслар күңелдә бик җылы тәэсир калдыра. Аның туган якның матурлыгы турындагы патриотик җырларын, шигырьләрен һәвәскәр җырчылар, нәфис сүз осталары искиткеч тәэсирле итеп башкарганлыктан, тамашачылар кичәдән, шагыйрьнең үзе белән сөйләшкәндәй булып, рухланып таралалар. Кичә үзенә бер бәйрәмгә әверелә.

Г. Бәширов — Арча ягы күренешләрен һәм кешеләрен нәфис итеп тасвирлау нигезендә күп романнар иҗат иткән язучы. Аның «Намус» романы геройлары үрнәгендә инде утыз еллап район хезмәт ияләре тәрбияләнә. Колхозчылар, мәктәп укучылары аны укып, китапханә оештырган конференцияләрдә фикерләрен уртаклашалар, ә инде язучының үзе белән очрашкач, тагын да зуррак кызыксыну белән әлеге әсәрләр, геройлар турында сүз башлыйлар, уйларын-фикерләрен әйтәләр, гәпләшәләр, язучының әсәре үзләренең уйларына-планнарына нинди үзгәрешләр кертүе хакында сөйлиләр. «Туган ягым — яшел бишек» әсәре буенча районның барлык китапханәләрендә конференцияләр, Яңасала, Каенсар авылларында язучы белән очрашу үткәрелде. Язучының «Җидегән чишмә» әсәре буенча да Югары Курса, Казанбаш, Яңасала, Ташкичү, Наласа авыл китапханәләрендә кызыклы сөйләшүләр булды.

Г. Ахуновның «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» романнары буенча фикер алышу, китап укучылар конференциясе Арча педагогия училищесында һәм районның барлык авыл китапханәләрендә үтте. Язучының иҗатына багышлап китап күргәзмәләре, стендлар, беседалар, әдәби кичәләр, фикер алышулар уздырыла.

«Без бит Арча яклары» исемле китабы исә районның конкрет кешеләре белән, колхоз председательләре, механизаторлары, партия работниклары белән очраштыра. Китап аша аларның эчке дөньясына үтеп керәбез. Әсәрдә авылның бүгенге проблемалары да күтәрелә. Автор үз геройларын тормышның текә борылышлары аша үткәрә.

Бу әсәр буенча да китапханәләрдә китап укучылар конференцияләре, фикер алышулар уздырылды.

Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрендә дә Арча ягы совет авылы кешеләренең тормышы калку чагыла. Күп кенә кешеләр «Без кырык беренче ел балалары», «Фронтовиклар» һәм башка әсәрләрендәге геройлар йөзендә үзләрен һәм иптәшләрен таныйлар. Шуңа күрә аның әсәрләре буенча автор катнашында да, аңардан башка да кызыклы сөйләшүләр, бәхәсләр була. Аның «Каз канатлары», «Кеше китә — җыры кала» әсәрләрен дә Арча ягында җылы каршыладылар.

Мондый очрашу-әңгәмәләрне без тәрбия эшендә хезмәт ияләренең эстетик карашларын киңәйтүгә ярдәм итә торган үтемле алым итеп саныйбыз.

Соңгы елларда якташ әдипләребезнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә игътибар район мәктәпләрендә дә артты. Бу өлкәдә район мәктәпләрендә байтак эш башкарыла.

Укучыларда якташ әдипләр аша бөтен әдәбиятка, туган якка мәхәббәт тәрбияләнә. Алар якташ әдипләребезнең тормышын һәм иҗатын өйрәнеп кенә калмыйлар, үзләре дә каләмнәрен сынап карыйлар һәм иҗат җимешләрен бирәләр. Яшь каләмнәргә ярдәмгә барлык сигезьеллык һәм урта мәктәпләрдә әдәбият түгәрәкләре эшли. Аларның кайберләре «Яшь иҗатчылар», «Яшь каләмнәр» исемнәрен йөртәләр. Әдәбият түгәрәгендә катнашучылар үзләренең әсәрләре белән район һәм республика матбугатында басылалар.

*
* *

Әйе, халыкны рухи, әхлакый тәрбияләүдә әдәбият һәм сәнгатьнең роле гаять зур, тик аларны файдалана белергә генә кирәк. Бу эшне без нигездә китапханәләр, культура йортлары, клублар һәм район газетасы аша тормышка ашырабыз.

Яшь каләмнәрне тәрбияләүдә һәм үстерүдә, хезмәт ияләрен эстетик тәрбияләүдә «Коммунизмга» исемле район газетасы да зур роль уйный. Ул партия оешмаларының оештыру, политик тәрбия эшен, колхоз һәм совхозлардагы хуҗалык эшләрен киң яктырту белән бергә, райондагы әдәби көчләргә туплану урыны булып тора. Редакция каршындагы «Тукай якташы» исемле әдәби түгәрәктә егермегә якын яшь автор каләмен чарлый.

Әдәбият түгәрәгенә йөрүчеләр — төрле һөнәр кешеләре. Арча педагогия училищесы укытучысы (татар теле һәм әдәбияты) Дәмир Галимов хәзер гражданнар сугышы герое Азинның безнең Арча якларында булуы турында әдәби-документаль повесть өстендә эшли.

Түгәрәкнең актив члены, Күңгәр урта мәктәбе хуҗалык мөдире Галиәхмәт Шаһиәхмәтов лирик шигырьләр яза. Аның шигырьләре әледән-әле район газетасында дөнья күрә. Галиәхмәт Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә читтән торып укырга керде.

Гөлчирә Кәримуллина — Наласа авылы кызы, колхоз бухгалтериясендә эшли. Туган авылына, аның табигатенә гашыйк. Хезмәт кешесенең рухи матурлыгын тоя белә һәм шундый рух белән сугарылган шигырьләр иҗат итә.

Нәфыйк Нәсыйхов — «Северный» совхозы йөкчесе. Кыска парчалар, кыска, үткен сюжетлы сатирик һәм лирик шигырьләр иҗат итә.

«Сельхозтехника»ның район берләшмәсенең Яңа Кенәр бүлекчәсе инженеры Марат Абдуллин район газетасында үзенең беренче проза әсәрләре белән чыгыш

ясады. Аның кыска хикәяләрен, юморескаларын укучылар җылы кабул итте.

Арча педагогия училищесы студенткалары Сания Шәрәфиева, Миләүшә Бәдретдинова, «Тукай-Кырлай» колхозыннан Тәслинур Гыйззәтуллина, Арча крахмал заводы эшчесе Әнвәр Вәлиев, Арча хәзерләүләр конторасы директоры урынбасары Зөфәр Рамазанов, Дусым авылыннан колхозчы Таһир Мөхәммәтшин редакциягә әледәнәле шигырьләр җибәреп торалар.

Әдәби берләшмә белән Радик Фәизов җитәкчелек итә. Ул кыска хикәяләр яза, инде алты җыентыгы дөнья күрде.

«Коммунизмга» район газетасында системалы басылып килә торган «Тукай якташы» әдәби сәхифәләрендә башлап язучы райондашларның хикәя, шигырь һәм парчаларына зур урын бирелә. Укучылар яшь көчләрнең беренче әсәрләре белән нәкъ менә район газетасы аша танышa, аларны укып рухлана. Хәер, анда башлап язучылар гына түгел, танылган язучы һәм әдипләрнең мәкаләләре, хикәяләр, шигырьләре һәм рецензияләре дә басыла. Бу газетада андыйлардан М. Мәһдиев, Н. Мадьяров актив катнаша.

Газетада сатира почмагы бар. Ул, Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасыннан файдаланып, «Шүрәле бүрәнәсе» дип атала. Анда җәмгыятебезнең әхлак кагыйдәләрен бозучыларның, хуҗасызлыкка һәм башка шундый кимчелекләргә юл куючыларның «бармаклары» «Шүрәле бүрәнәсе» ярыгына кыстырыла.

*
* *

Хезмәт ияләрен язучыларның әсәрләре белән таныштырып баруда китапханәләргә җитди бурыч йөкләнгән. Аны тормышка ашыруны тагын да яхшырту максатында районда үзәкләштерелгән китапханә системасы оештырылды. Ул авыллардагы 78 китапханәне берләштерә. Алар арасында Арчадагы, Олы Әтнә һәм Яңа Кенәрдәгеләре шактый зур булулары белән аерылып торалар. Мәсәлән, Әтнәдәге Пушкин исемендәге китапханәдә 28 мең китап бар, шуның 15 меңе татар телендә. Алардан 2 меңгә якын китап укучы файдалана. Аның карамагында унбиш күчмә китапханә бар. Алар укучыларга эш һәм яшәү урыннарында китаплар тәкъдим итәләр.

Әтнәдәге зона балалар китапханәсендә, кайчан гына килсәң дә, укучыларның күп булуын күрәсең. Китапханәдәге заман таләпләренә туры китереп эшләнгән стендларга карап сокланасың. Яшь буынны өлкән буынга лаеклы алмаш итеп тәрбияләү өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Телисең икән, яңалыклар белән таныш, укыйсы килгән китабыңны алып укы. Китапханә хезмәткәрләре балаларны һәрвакыт ачык йөз белән көтеп алалар.

Китапханәдә абонемент бүлегенә Татарстанның атказанган культура работнигы Җәүһәрия Мәрданова мөдирлек итә. Ул китапларны саклап тотуга, укучыларда матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләүдә күп көч куя, системалы рәвештә әңгәмәләр үткәрә.

Казанбаш авылы китапханәсе (мөдире М. Мифтахова), Олы Мәңгәр (мөдире Л. Сабитова), Күлле Киме авыл китапханәсе дә (мөдире Ф. Сәгыйдуллина) әдәбиятны халыкка җиткерүдә күп төрле алымнар куллануыры белән аерылып торалар.

Хезмәт ияләрен рухи баетуда партиябез культура учреждениеләренә гаять зур бурычлар йөкли. Бу бурычлар КПСС Үзәк Комитетының «Үзешчән художество иҗатын тагын да үстерү чаралары турында»гы, шулай ук «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарларында бәян ителгән. Әлеге карарларның беренчесендә: «...барлык клуб учреждениеләрендә, предприятиеләрдә, колхоз һәм совхозларда, уку йортларында художество иҗаты белән шөгыльләнү өчен кирәкле шартлар тудыру, үзешчән коллективларга эшчеләрне, колхозчыларны, хезмәткәрләрне, студентларны, укучыларны һәм сугышчыларны киңрәк тарту, халык театрларын һәм һәвәскәр музыкаль, хореография, хор коллективларын, сынлы сәнгать, кино һәм фото сәнгате студияләрен тагын да үстерү чараларын эшләргә һәм тормышка ашырырга» кушылган.

Партиянең шушы күрсәтмәләрен гамәлгә ашыру максатында районда байтак кына эшләр эшләнде. Яңа клуб һәм культура йортлары төзү белән берргә, булган культура учреждениеләрен җиһазлау һәм аларда үзешчән художество иҗатын үстерүгә игътибарны көчәйттек.

Хәзер районда 160 клуб һәм культура йорты, 120 киноустановка халыкка культура хезмәте күрсәтә. Культура учреждениеләрендә 1700 һәвәскәр төрле түгәрәкләрдә шөгыльләнә. Әтнә культура йорты каршында халык театры эшли. Узган ел Әтнә халык театры үзенең 60 еллыгын билгеләп үтте. Бу театр коллективы татар драматурглары әсәрләрен генә түгел, башка халык язучылары иҗат иткән әсәрләрне дә сәхнәләштерә. Ленин премиясе лауреаты Ч. Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» дигән әсәрен оста сәхнәләштереп, Казан, Уфа һәм Мәскәүнең Пушкин исемендәге театры сәхнәләрендә чыгыш ясады, РСФСР һәм СССР күләмендәге үзешчән сәнгать смотрлары лауреаты дипломнарына лаек булды. Халык театрының һәвәскәр артистлары соңгы 12 ел эчендә 40 тан артык әсәрне сәхнәдә 500 тапкыр куеп, 100 меңгә якын тамашачыга культура хезмәте күрсәтте.

Биредә Г. Тукайның «халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә бу күренештә йөри» дигән сүзләре искә төшә. Чыннан да халыкта талантлар аз түгел. Дөрес, һәркайсы артист та, рәссам да, шагыйрь дә булып бетә алмаса да, һәркемгә мәгълүм дәрәҗәдә үз талантын, осталыгын күрсәтү, иҗат белән шөгыльләнү өчен бездә шартлар җитәрлек. Бу фикерне раслау өчен әлеге халык театры артистларына күз салыйк. Әнә Рәфкать Хәкимов — Тукай исемендәге колхоз тимерчесе, Таһир Гыйләҗев — шу-

лай ук колхозчы, Ринат Нәҗмиев — хуҗалык мөдире, Гөлнур Хәкимова — автоклуб мөдире, Нажия Вәлиуллина — китапханә мөдире, Сергей Котельников һәм Фоат Фазлыев — урта мәктәп укытучылары...

Һәвәскәрләрнең байтагы инде үз гомерендә 30—40 һәм аннан да артык роль башкарды. Коллективның 4 члены — Г. Сибгатуллина, Г. Мәрдәнов, Җ. Хәйруллина һәм Р. Мохтаров — ТАССРның атказанган культура работниклары.

Олы Әтнә культура йорты каршындагы җыр һәм бию ансамбле дә үзенең сокландыргыч чыгышлары белән күп тапкырлар тамашачыларның ихтирамын казанды.

Арча ягы үзешчәннәре беренче Бөтенсоюз үзешчән сәнгать иҗаты фестивалендә дә актив катнаштылар. Анда тугыз коллектив һәм аның башкаручылары республика фестивале лауреаты булды, унөч коллектив һәм аларның башкаручылары республика оештыру комитетының дипломнары һәм грамоталары белән бүләкләнде. Алар арасында Наласа культура йорты халык инструментлары оркестры, Олы Әтнә, Күлле Киме, Шурабаш бию коллективлары, Арча район культура йорты хоры, ике вокаль ансамбль, Сәрдәбаш гөсләчеләр ансамбле бар.

Районда культура эшен тагын да яхшырту өчен күрәштә Арча район культура йортына зур бурыч йөкләнә. Ул барлык авылларның культура йортлары һәм клублар өчен методик үзәк булып та хезмәт итә. Аңа иң ерак авыллардан өйрәнергә, тәҗрибә алырга киләләр. Шуңа күрә бирәдә эш үрнәк булырлык итеп оештырылырга тиеш.

Арчада «Октябрь» кинотеатры төзелү культура йортын мәгълүм дәрәҗәдә кино күрсәтүдән азат итте һәм массовый культура чаралары өчен мөмкинлекләрен арттырды.

Арча культура йорты (директоры Розалина Әминова) көндезен дә, кичен дә гөрләп тора. Биредә 428 урынлы тамаша залыннан тыш, лекцияләр һәм башка шундый чаралар өчен 100 урынлы кече зал, төрле секцияләр, түгәрәкләр өчен махсус җиһазланган бүлмәләр, бал биюләре өйрәнү, гомумән, бию кичәләре үткәрү өчен зал булуы культура йортының берьюлы купьяклы эш алып баруы өчен уңай шартлар тудырды. Биредә уңышлы эшләүче драмтүгәрәк белән беррәттән (җитәкчесе Н. Галәвиева) башка коллективлар да республикада танылды.

Культура йорты яшьләргә генә түгел, өлкән яшьтәгеләргә дә культура хезмәте күрсәтүне үз өстенә алды. Биредә ветераннарның җыр ансамбле һәм балаларның 35 кешелек халык инструментлары ансамбле эшли. Егетләр һәм кызлар өчен дә 45 кешелек халык инструментлары оркестры оештырылган. Теләгән кеше тынлы оркестрга, теләгәннәре эстрада оркестрына йөри. Хор ансамбле хатын-кызлардан 40, ир-атлардан 20 кешене берләштерә. Бию ансамбле чыгышларын карап ләззәтләнми мөмкин түгел. Чөнки милли стильдә тегелгән костюмнар аларның башкару осталыгына ямь өсти, чыгышларның гүзәллеген арттыра. Шуңа күрә үзешчәннәрнең чыгышлары еш кына профессиональ артистларныкыннан бик аз аерыла.

Ансамбльләрнең концерт программалары шактый уйланып төзелә, аларга якташ шагыйрьләрнең әсәрләре нигезендә эшләнгән җырлар һәм биюләр кертелә. Менә егетләр хоры программасында шундый җырлар бар: «Безгә тынычлык кирәк», «Тәрәзә юа кызлар», «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Туган тел», «Тәфтиләү» һ. б. Кыскасы, биредә Г. Тукай һәм С. Хәким сүзләренә язылган җырлар шактый урын алган.

Биредә эстетик тәрбиянең кайбер яклары гына, бигрәк тә Арча районы өчен үзенчәлеклерәк булганнарын гына яктыртуны кирәк таптык. Билгеле, районда башка формалар да, ягъни республиканың барлык районнарына хас һәм уртак булган форма һәм алымнар да аз түгел. Мәсәлән, кино хезмәте аша массаларга эстетик тәрбия бирүне алыйк. Ул да бик йогынтылы чара. Районда кинофильмнарны барлык концерт-спектакльләргә караганда күбрәк карыйлар. Күп кенә клубларда һәм культура йортларында атна саен 4—5 сеанс кинофильм күрсәтелә. (Ә бит авылда шул кадәр концерт-спектакль әзерләп өлгерү мөмкин түгел). Районда бер елда күрсәтелгән фильмнар саны 23 меңгә җитә. Аларны 870 меңнән артык тамашачы карый. Бу — шул кадәр кеше фильм карагандә үзендә мәхәббәт хисләрен яңарта, явызлыкка, мәкергә нәфрәтләнә, гаделлекнең җиңүенә теләктәшлек белдерә, гүзәллекне күрә, яхшыны яманнан аерырга өйрәнә дигән сүз. Кино хезмәте халкыбызны югары культуралы, киң карашлы, үз Ватанын сөюче кешеләр итеп тәрбияләргә ярдәм итә.

Район хезмәт ияләренең вакытлы матбугатны күп укуы да аларның политик һәм эстетик карашлары киңәюгә булыша. Газета-журнал алдыручылар елдан-ел арта. 1979 елда районга 76988 газета-журнал килгән булса, 1980 елга аларның саны 79 меңнән артып китте, ягъни 1000 кешегә 1113 данәгә җитте. Бу — һәр гаиләгә 4—5 газета-журнал дигән сүз. Политик газета-журналлардан тыш, әдәби басмалар белән дә бик кызыксыналар. «Казан утлары »журналы гына да районга 1431 данә килә. «Огонек», «Новый мир», «Волга» журналларын, «Роман-газета»ны, «Азат хатын», «Чаян», «Крокодил» кебек басмаларны алдыручылар да меңнәрчә.

Вакытлы матбугатның киң таратуның әһәмияте шунда, газета-журналлар аша (алар нинди генә мәсьәләләр яктыртмыйлар!) кешеләр үзләрен үзләре тәрбиялиләр, экономик-политик өлкәдә, әдәбият-сәнгать, культура өлкәсендә хәл ителә торган мәсьәләләр турында хәбәрдар булалар, үзләренең игътибары, эшчәнлеге нәрсәгә юнәлдерелергә тиешлеген мөстәкыйль хәл итә алалар. Кешеләрнең үзләрен үзләре тәрбияли алу дәрәҗәсенә күтәрелүе — җәмгыятебезнең югары үсеш дәрәҗәсен чагылдыра.

## Геннадий Волков

# ТАТАРСТАННЫҢ ҮЗ УЛЫ

«Мине туган җирем Татарстанның бай поэзиясе куандыра һәм сокландыра».

**П. Хузангай.**

Үзе исән чагында ук зур хөрмәт казанган Педер Хузангай Татарстанда туа, беренче шигырьләрен шунда яза башлый. Татарларның башкаласы Казанны (чувашча — Хузан) ул үзенә әдәби псевдоним итеп ала.

Хузангайның «Яшьтәш дустыма» дигән беренче шигыре 1923 елда туган авылы Сиктәрмәдә (хәзерге Әлки районына керүче авылда), ә «Безгә авыр булса булсын» исемле программа характерындагы шигыре шул ук елны Казанда язылган. Аның иҗаты шул әсәрләрдән башлана.

Казанны Хузангай үзенең бишеге дип атый. Аның яшьлегенең иң матур еллары шунда үтә. 1923 елда ул биредәге чуваш педтехникумына укырга керә, 1927—1930 елларда исә Казан Көнчыгыш педагогия институтында укый. «Вопросы литературы» журналының 1964 елгы беренче санында басылган автобиографиясендә Хузангай Казан турында болай дип яза: «Минем өчен ул тоташ яңалык: университет, китапханәләр, Татар культура йорты, чуваш язучылар союзының «Канаш» дип аталган «Казан ячейкасы»... Татар яшьләренең сөйгән әдипләре Гадел Кутуй һәм Һади Такташны тыңлаганда, гүя тамырларым тоташып калган туган авылымны искә төшерәм»...

Халыклар дуслыгын җырлаучы шагыйрьнең сугышчан интернационализмы нәкъ менә биредә — төрле милләтләр гомер кичергән җирлектә туа. Казанга килгәнче ул татар телен, ә Казанда рус телен ныклап үзләштерә. «Минем өч туган халкым, өч туган телем бар», — ди Хузангай. Шовинизм тарафдарларын фаш итеп, ул «татар» дигән сүзгә тарихи якын килмәүләре өчен әрни. Бу — татарларны дус һәм туган иткән кешенең, Татарстанның үз улының әрнүе иде.

Менә шагыйрьнең 1974 елда «Современник» нәшриятында басылып чыккан «Язмышлар» исемле соңгы китабы. Аның беренче һәм өченче бүлекләрендә туган җир, авылдашлар, балачак һәм яшьлек турындагы шигырьләре тупланган. Дүртенче бүлектәге «Инча» шигырен укыганда, шагыйрьнең балачагы белән ахыргача бәйле инешне күрәбез. Ә сигезенче бүлектәге шигырьләр әдипнең йөрәгенә иң якын образларны күз алдына китереп бастыра. Бу бүлеккә «Тукай каеннары», «Муса Җәлилгә» һәм башка шигырьләр урнаштырылган.

Хузангай, туган җиренең игелекле улы буларак, үзен үстергән халыкка, яшьлек идеалларына һәрвакыт тугрылыклы калды. «Аптраман ыруы» исемле шигъри романындагы лирик герой үзенең улын менә ничек тирбәтә:

**Руслар якын дустың булсын,**
**Татар — юлдашың.**
**Туганнар без... Йокла, минем**
**Нәни чувашым.**

...Хузангайның Казандагы татар дуслары Шәрәф Мөдәррис, Афзал Шамов һәм Зәки Нури белән әңгәмә алып барган чакларына туры килгәнем бар минем. Хәл-әхвәл сорашканнан соң аларның сүзләре һәрвакыт поэзия турында, Чувашстан һәм Татарстан турында сөйләүгә күчә иде. Шагыйрьнең шул чакларда язылган «Россиям минем» дигән поэмасы хәтергә килә. Хузангай аны чувашча да, русча да укый, кирәк икән, аерым юлларын татарча да кабатлый.

**Туган халкым минем яңа чорда**
**Үзенең иреген, бәхетен тапканда, —**
**Сүз бирдем мин җырда, тормышымда**
**Туган җирнең рухын сакларга.**
**Безнең телдә «Казан» — «Хузан» булгач,**
**Хузангай дип исемем атадым.**
**Синең алда булган бурычым түләп**
**Бетерә алсам иде, Ватаным!**

Хузангайның искиткеч яхшы хәтерле булуын басым ясап әйтәсе килә. Ул Пушкинның һәм Маяковскийның барлык әсәрләрен диярлек яттан белә иде. «Владимир Маяковский» поэмасында ул Маяковский, Кутуй һәм Такташ турында зур рухлану белән язды. Бу исемнәрне шагыйрь бервакытта да теленнән төшермәде. 1928 елда ук инде ул Казанда үзенең Маяковский белән очрашуы турында очерк язды һәм анда татар әдәбиятындагы казанышларны да читләтеп үтмәде.

Шагыйрь ул еллардагы кадерле күренешләрнең беренче карашка бик вак булып тоелган детальләренә кадәр онытмый:

**Машинкада, китап, журналда**
**Салкын күренә бер сүз: «Яңалиф».**
**Ул зәңгәр дә була, ул ал да —**
**Кемнәр әйтмәс уттай яна дип.**

Монда бер нәрсәне искә төшереп үтәргә кирәк. «Яңалиф» Хузангайның поэтик язмышында зур роль уйнады. 1928 елда «Яңалиф» журналы битләрендә, башка телдә беренче тапкыр буларак, Хузангайның иҗат үрнәкләре басылып чыга. Бу вакытта аңа әле егерме яшь кенә була. Шагыйрьнең татар теленә тәрҗемә ителгән «Әнигә хат» шигыре, мәсәлән, җылы лиризмы белән үзенә җәлеп итә. Шуның белән бергә аны авторның туган ягына багышланган шигырь дип тә санарга мөмкин. Чөнки аның әнисе соңгы көннәренә кадәр диярлек Татарстанда яши.

Яраткан шагыйре һәм якын дусты Гадел Кутуй — Хузангай өчен иң кадерле образларның берсе:

**Мәскәүдә ЛЕФ, монда — «Сул фронт»,**
**Кыскача: «Сулф». Барыбер шул фронт!**
**Кутуй йөри яныл-ашыгып,**
**Сулф кушканны эшкә ашырып.**

Хузангайның бөтен иҗатына хас үзенчәлек — тормыш дөреслегенә тугрылыклы булу. Ул тарихи дөреслекне очраклы вакыйга-күренешләрдән аера белә. Моны бигрәк тә аның «Туган як шигырьләре» дип аталган поэтик циклына карата әйтергә кирәк.

Шагыйрьнең басылып чыккан илледән артык китабын күздән кичерсәң, аларның һәркайсында Татарстан турында язылган шигырьләрне күпләп очратасың. Аның публицистик мәкаләләрендә дә Татарстан һәм Казан әледән-әле телгә алына. 1958 елда Чабаксарда басылган «Сайланмалар»ының беренче томы «Мин Россиядә яшим», «Сиктәрмә» һәм «Якташлар» дигән циклардан тора. Шагыйрьнең якташлары — аның авылдашлары, ягъни Сиктәрмә кешеләре. «Сиктәрмә» ул татарча «бишек» дигән сүз. Җыеп кына әйткәндә, болар — туган җир, туган йорт турындагы җырлар.

— Туган халкымның рухын, тарихи язмышын мин беренче тапкыр Казанда аңладым, — дип Хузангай үзе үк ачыктан-ачык әйтә.

Миңа Казанда Хузангай белән күп тапкырлар очрашырга, Татарстан буйлап күп тапкырлар бергә йөрергә туры килде. 1951 елның июнендә Татарстан башкаласында чыга торган «Херле ялав» («Кызыл байрак») газетасы редакциясендә чуваш студентлары һәм аспирантлары белән очрашуыбыз әле дә исемдә. Әлеге очрашу алдыннан гына Хузангайга чуваш халык шагыйре дигән мактаулы исем бирелгән иде. Татар-

станда үткәрелгән чуваш әдәбияты һәм музыкасы атналыгында да без бергә булдык. Шунда алган тәэсирләр үзе бер тема. Ә менә редакциядә уздырылган очрашу турында бер-ике сүз әйтеп узмыйча булмый.

Хузангай анда миннән диссертациямнең темасы турында сорады. Мин аңа Татарстанда совет мәктәбенең туу тарихын өйрәнүемне әйттем.

— Син Казанда татар темасы белән шөгыльләнәсең, ә Мәскәүдә профессор Горский чуваш теле турында яза,— диде ул. Аннары, минем ни дип җавап бирергә белми торуымны күреп, сүзен дәвам итте:

— Беренче чуваш әлифбасы, чуваш телендә чыккан газетаның беренче саны Казанда басылды, беренче чуваш театры Казанда оештырылды... Ихтимал, син әле Чувашстан турындагы хезмәтләрең өчен татарлар тормышыннан бик күп материал туплый алырсың.

Хузангай Татарстан язучылары һәм галимнәре, аларның патриотизмы, интернационализмы һәм милли горурлыклары турында дәртләнеп сөйли торган иде. Мәктәпләрдә уку-укыту эшенең куелышында татарларны үрнәк итеп куюы хәтеремдә калган. Чуваш шагыйренең татар халкының эш сөючәнлеге, сәләте каршында зур ихтирам белән баш июе дистәләрчә шигырьләрендә чагыла. Шулай да туган җире һәм яшьлек бишеге булган Татарстанга багышлап иҗат иткән шигырьләре арасында «Туган Татарстаныма» дигән шигыре иң уңышлысыдыр. Бу шигырь Хәсән Туфан һәм Шәрәф Мөдәррис тәрҗемәсендә татарча да берничә тапкыр басылды.

**Туган илем, Татарстан,**
**Синдә үскән чуваш идем.**
**Кабатланмас якты еллар**
**Искә төшә һаман минем.**

Хузангай күңеле белән һәрвакыт Казанга тартылды. 1964 елның 24 декабрендә «Уфа—Казан» поездыннан җибәргән хатында ул Казан университетына, үзенең иҗат кичәсенә ашыгуы, әмма авырып торуы турында яза да: «Барып җитәргә иде, барып җитәргә иде...» — дип өсти. Шагыйрьнең Казанга ни өчен ашыкканлыгын аңлавы кыен түгел:

**Кайда безнең өчәр телдә**
**Шигырь укып йөргән еллар! —**
**Һади Такташ, Гадел Кутуй**
**Миңа киңәш биргән чорлар!!**

Хузангайны Татарстан белән бәйләгән рухи-әхлакый җепләрнең ныклыгы аның татар шагыйрьләренә мөнәсәбәтендә аеруча ачык күренә. Әдипнең Бөек Октябрь революциясенең ун еллыгы уңае белән язылган шигыре «Татар шагыйрьләренә» дип атала. Революция төрле милләт улларын һәм кызларын үзара якынайта — шагыйрь өчен иң әһәмиятлесе әнә шул. «Минем йортым — сезнең йорт, мин сездә кунак», — ди ул ихлас күңелдән.

Соңга табарак Хузангай татар шагыйрьләренә җибәргән шигырьләрендә, хатларында, котлауларында буыннарны тарихи барлау темасына, халыклар дуслыгы темасына кат-кат әйләнеп кайта. Алар төрле стильдә һәм төрле уңай белән язылганнар. Кайберләре реквием шикелле кайгылы, әмма көчле рухлы. Муса Җәлилгә багышланган шигырьләрнең беренчесе, мәсәлән, реквиемне хәтерләтә, ә икенчесе — ода, гимн.

«Һади Такташка» шигырен Хузангай 1931 елда, күренекле шагыйрьнең үлүе турында ТАСС хәбәрен ишеткәч, Тбилисидә яза. Бу шигырьдә автобиографик юллар да байтак.

Хузангай шагыйрьнең мәңге яшь булып калачагына, халкы аның үлемсез исемен онытмаячагына, кешеләрнең аны көннән-көн ныграк аңлаячакларына, үз ытәчәкләренә ышана.

«Муса Җәлилгә» шигыре шуның белән кызыклы, анда Хузангай Җәлилгә украин шагыйре Тычина турында сөйли. Телләрнең бер-берләрен ихтирам итүләрен конкрет күрсәтү өчен шагыйрь «Ватан» һәм «батькивщина» сүзләрен куллана.

Шуны да әйтергә кирәк, Хузангай шигырьләрендә татар сүзләре еш очрый, шагыйрь алардан ике халык арасындагы рухи бердәмлеккә генә түгел, ә бәлки телләр

якынлыгына, уртаклыгына басым ясау өчен дә файдалана. Хәсән Туфанга ул: «Хөрмәтле Туфан, әссәламегаләйкүм!» дип мөрәҗәгать итә.

Муса Җәлилгә багышланган бер шигырендә Хузангай Мәскәүдә бергә эшләгән еллары турында сөйли. Ул аны Җәлилнең алтмыш еллыгын уздыру кичәсенә баргач, Оренбургта яза. Хузангай миңа аннан ике хат салды. Икесендә дә, авырып ятуы сәбәпле, Мусаның туган авылы Мостафага бара алмавы турында ачынып язды. Бу— аны арабыздан алып киткән авыруының башлануы иде. Башка шигырьләрендә дә Хузангай Җәлил образына, аның тиңдәшсез батырлыгына күп мәртәбәләр мөрәҗәгать итте.

«Мин кешелекнең акылына ышанам» дигән шигырендә Хузангай Кубага Җәлил белән бергә оча һәм аның «Гомерем минем моңлы бер җыр иде» дигән сүзләрен кабатлый. «Җырларым» шигыре Хузангайның күңеленә бик якын: бу шигырьне чуваш теленә ул тәрҗемә итте. Миңа Хузангайның китапларында телгә алынган кайбер татар язучылары: Каюм Насыйри, Галиәсгар Камал, Зариф Бәшири, Галимҗан Ибраһимов, Кави Нәҗми, Кәрим Тинчурин, Һади Такташ, Гадел Кутуй, Муса Җәлил, Афзал Шамов, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Шәрәф Мөдәррис, Салих Баттал, Әхмәт Исхак, Зәки Нури, Гали Хуҗиев, Фатих Хөсни һәм, әлбәттә, Тукай, Тукай, Тукай... Тукайның исемен ул, әгәр шулай әйтергә ярса, адым саен кабатлый. Күп кенә очракларда аны дөньяның бөек шагыйрьләре рәтеннән санап уза. Тукай Хузангайга Шекспир, Руставели, Низами, Пушкин, Шевченко кебек үк кадерле. «Рухлары буенча яшьтәшләр һәм дуслар» дигән мәкаләсендә бу хакта ул үзе үк басым ясап әйтә. Тукай һәм Иванов идеяләренең уртаклыгы Хузангайның һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Тукай иҗатында ул ике фронтта — милләтчелеккә һәм милли нигилизмга каршы көрәш алып бару өчен таяныч таба. Үзенең бу мәкаләсен Хузангай менә мондый сүзләр белән тәмамлый: «Без Тукайның якты чакыру авазын зур шатлык белән тыңлыйбыз: «Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!..»

Педер Хузангай — татар әдәбияты турындагы бик күп хезмәтләр һәм докладлар авторы. Аның «Татар поэзиясе антологиясе»нә язган рецензиясе чын мәгънәсендә уникаль хезмәт. «Дуслык исеме белән» дигән мәкаләсендә ул Хәсән Туфан иҗаты турында искиткеч зур җылылык белән сөйли.

— Татар, украин язучылары белән безнең элек-электән килә торган иҗат дуслыгыбыз ныгыганнан-ныгый, — диде Хузангай СССР язучыларының өченче съездында зур горурлык белән. Бу дуслыкны ныгытуда аның үзенең дә хезмәте зур булды.

Хузангай Татарстан турында күп һәм яратып язды. Чувашлар әти-әниләренең йортын «алтын бишек» дип атыйлар. Хузангай өчен Татарстан да нәкъ әнә шундый кадерле урын иде. Ул татар халкының уңышларын күреп ихлас күңелдән куанды. Әгәр аның Татарстан һәм татарлар турында әйткән һәм матбугатта басылып чыккан сүзләрен бергә җыйсаң, үзе бер калын китап булыр иде. Татарстандагы каләмдәш дусларының иҗаты аны һәрвакыт дулкынландырды, алар турында ул һәрвакыт дәртләнеп сөйли иде. Мин, мәсәлән, Белоруссия партизаны, шагыйрь Зәки Нуриның тормышы һәм иҗаты хакында, «Известия» газетасында Николай Хохловның очеркы басылып чыкканчы ук, Хузангайдан ишетеп белдем.

Безнең җырларыбыз, гореф-гадәтләребез, сүзләребез бер-берләре белән туганлаша, дип язды Хузангай. Шуның белән бергә милләтчелек һәм шовинизмның теләсә нинди чагылышы аңарда чиксез нәфрәт тудырды. Сталинград фронтының рядовой солдаты, принципиаль коммунист патриотизм һәм интернационализм идеяләрен алга сөрде. Владимир Фирсовның «Хәтер» дигән шигыренә карата ул: «Ханнар һәм патшалар турында сөйләгәндә халыклар турында да онытмаска кирәк», — дип язды. Светлана Евсееваның «Иля» шигыре хакында исә РСФСР Язучылар союзының сигезенче Пленумында да сөйләде, «Дуслык китабы»нда да язып чыкты. Андый авторларга ул чиксез зур интернациональ яңгырашлы шигырь белән җавап бирде. Һәм монда да үзенең якын туганнары булган татарларны онытмады.

Хузангай зур шагыйрь иде, аны үз халкының һәм башка тугандаш халыкларның, шул җөмләдән, татар халкының да тарихыннан аерып карау мөмкин түгел

**Ибраһим Гази**

# КӨНДӘЛЕКТӘН БЕР БИТ

## 1943

Февраль ахырында самолет белән Ростовка килеп төштем. Кар бетеп бара. Шәһәр өсте күгелҗем томанмы-төтенме белән капланган. Менә самолетның тәгәрмәчләре җиргә тиделәр. Моторлар, гөрелдәп, самолетны аэродром янына тарталар.

Шәһәрнең тетелгән булуы өстән үк күренгән иде. Хәзер бөтен детальләре белән күз алдында: менә аэродром янында ук боеприпас төягән берничә немец вагоны өстенә бомба килеп төшкән. Вагоннарның кайсы кырын яткан, кайсы чәрдәкләнгән, авиабомбалар атылышып җиргә сибелгән, ләкин ни өчендер ярылмаганнар. Кырыкка бөгелеп, бөтерелеп беткән тимер-томыр тавы өелеп калган. Шартлау дулкыны якындагы өйләрне ишеп ташлаган.

Без тыкрык белән шәһәргә чыгабыз. Аяк астында телефон чыбыклары чуала, патроннар, снарядлар, гранаталар аунап ята. Янган, кырыкка бөгелеп куркыныч төскә кергән танклар, автомашиналар: кайбере үләксә шикелле сузылып ята, кайберләре үлем алдыннан, үлем газабы белән газапланган кебек, арт «аяклары»на басып, бөтен гәүдәсе белән алга ыргылып торалар.

Без, тимерчыбыкларга абына-сөртенә, шәһәрнең җимереклегенә таң калып барабыз.

Без барасы җир биредән 12 километр чамасы ераклыкта. Бирედә гомумән кызык: берәүләр әйтә, 8 километр, ди, берәүләр—12; кайвакытны барасың, барасың—һаман 8 километр кала, барасың, барасың — һаман 8...

Боз өсләп Дон аркылы чыкканда, патруль туктатып, безгә шикләнеп карады: сез, ди, чолганыштан кайтып килмисезме ди, бик өс-башларыгыз тетелгән, ди. Ә без, чынлап та, окружениедә яткан кешеләрдән бер дә ким түгел: аякта киез итек, ботинкасы барның ботинкасы котың чыгарлык.

Үткәрде. Киттек. Бик озак эзләп йөри-йөри, ниһаять, таптык.

Ике-өч көннән соң Батайскидан без яңадан Ростовка күчтек. Без узган юлы Ростовның үзәген күрмәгәнбез икән әле. Ләкин үзәкнең исеме генә калган—үзе юк инде. Бер генә исән йорт калмаган: кара тәрәзәләр (дөресрәге, тәрәзә урыннары), саламдай тимер балкалар, ишелеп төшкән түшәмнәр, челпәрәмә килгән пыяла... тау-тау кирпеч—менә шул бөтен калган әйбер.

Халык гадәтләнгән. Янган йортларга берәү дә күтәрелеп карамый. Тик без генә аһ-уһ дип барабыз. Памятниклар ватылган, бакчалар киселгән, тапталган, магазиннар яндырылган, бөтен җирдә: тимер дә кирпеч, тимер дә кирпеч. Әнә кызлар көлешә-көлешә таган атыналар... Берәүләр мәктәптән кайтып килә.

Ростовта әлегә водопровод эшләми, электр, мунча юк, трамвай юк.

Кичә политотделның кадрлар бүлегенә—Ростовтан 35—40 километр җиргә (һәм аннан ары—хуҗалык бүлегенә) бардык..., Баштанаяк пычракка манчылдым. Машинада утыра-утыра тәмам каттым.

Бүген ике сәгатьләр чистартынгач, ниһаять, пальтоларым, чалбарлар, бүрек, ботинкаларым бераз адәм рәтенә керде,

4/III—43. Ростовта тора башлаганга да байтак вакыт үтте. Өч номер газета, бер-ике листовка чыгардык. Ләкин соңгы көннәрдә күңелне ниндидер бер корт өзлексез кимереп тора. Һичбер күренеп торган сәбәбе юк, ә эч поша да поша. Кичәле-бүгенле бу «кортның» сәбәбен таптым. Туган-үскән җирне сагынам икән! Шул пычрак, ач Казанның кай төшендер сагынам бит шуның. Бүген сугышлар бетеп шунда кайтсам, мостовой ташларына хәтле үбәр идем мин аның.

Бирედә дә безнең җир, үз шәһәребез, үз кешеләребез, үз табигатебез, ләкин Гурий Николаевич[1] бакчасындагы топольләр, Мирәтәк урамындагы[2] сазлык, пычрак, ындыр артындагы грива, Казан белән Мирәтәк арасындагы озын юл миңа чиксез якын. Чөнки мин шунда яшәгән, шунда ми-

нем хатыным, балам, бөтен тормышым минс шунда калган. Мин хәзер ничектер ике тормыш белән яшим: үзем биредә, күңелем анда. Алар бүген анда нишлиләр, Валерик нәрсәләр сөйли, ниләр эшли — гел шул турыда уйлыйм. «йорт» һаман кимереп тора, эшләргә, яшәргә ирек бирми. Юкка гына: «иле ямьсез, суы тәмсез, иләмә кайтасым килә», дип җырламаганнар. Халык җырларының мәгънәсен менә шушындый вакытларда тирәнрәк аңлый башлыйсың, дөресрәге — алардагы тирәнлекне, адәм баласының аларга чумырылган хисен, моңын-зарын яхшырак аңлый башлыйсың.

Хәзер үз илеңдә, үзең теләгән эш белән мәшгуль булсаң икән!

Биредә инде яз! Ләкин бу яз да түгел, кыш та түгел—недоразумение! Бездәге аяк астында шыгыр-шыгыр килә торган кар биредә юк. Яз көне бездә кар йомшак, боламыкка әйләнеп китә дә, суга әйләнеп, җәелеп ята, яисә гөрләп ага башлый, ә биредә әллә нәрсә шунда—үз илең түгел диген дә бетер инде. Өйдән хат сирәк килә.

20/III—43. Кичә—якшәмбе көнне—көн бик матур иде. Без, йөреп керергә дип, урамга чыктык. Ростовның иң тетелгән, ләкин кайчандыр иң матур урамнарыннан йөреп арыгач, кайтып ашадык та, мин газета алып ятып кына торган идем, тагын башланды. Башта карарга гына дип йөгереп чыктык: шундый матур булып тезелеп киләләр, ә зениткаsucceeded тотене, ак чәчәк шикелле, тазралмыйча бик озак тора. Гөрс-гөрс шартлый, сызгыра,—безне төрткәләп подвалга төшерделәр. Бомбежканың нәрсә икәнен бераз аңлый башладым. Безнекеләрдән берәү юк инде. Әле бүген дә урамда ятучылар бар—җыеп бетермәгәннәр.

...Бүген тагын килделәр. Әле миңа—бомба астында булмаган кешегә—кызык. Ләкин шулай да подвалда яхшырак. Бер партия үткәндә мин подвалда идем, икенче, өченче волналарны өйдә кичердем. Сипте—борчак урынына. Гел тирә-күрше урамнарга эләкте, бу юлы безгә эләкмәде. Барып карадым—атларның эчләрен актарып ташлаган. Кешеләр ята. Өйләрнең тәрәзәләрен, ишекләрен, түбәләрен туздырып ташлаган. Бөтен урам чүп-чар белән тулган.

Кызык күренеш. Ике бомбежка арасында урамда шаулашып балалар уйный, таган атыналар; бомба тавышын ишетүгә—җил очыртып ташлаган кебек, юкка чыгалар. Бераз тынгач—тагын: көлгән, уйнаган тавышлар.

Кичә, бүген сыерчык сайраганны тыңладым. Аларның да, бичараларның, ояларын өфертеп төшергән. —25/III—43.

ИСКӘРМӘЛӘР:

[1] Гурий Николаевич — Сердинский Г. Н. — И. Гази хатынының атасы.

[2] Мирәтәк — Лаеш районындагы авыл. И. Газиның хатыны А. Г. Сердинская сугыш вакытында Мирәтәктә укытучы булып эшли.

## Самат Шакир

# МӘРМӘРГӘ УЕЛГАН ИСЕМ

Украинаның Волынский өлкәсе, Горохово район үзәгендә зур каберлек— Дан биеклеге бар. Анда Бөек Ватан сугышында һәлак булган батырлар— совет солдаты һәм офицеры күмелгән.

Ул изге урынга сукмак өзелми. Бөек Ватан сугышы ветераннары, яшьләр, мәктәп балалары килә. Аналар йөрәге кебек талпынучы Мәңгелек ут кайгылы көннәрне искә төшерә. Дәһшәтле сугышларны, изге Ватаныбыз бәйсезлеге өчен соңгы тамчы канга кадәр көрәшеп һәлак булган фидаиләрне...

Мәрмәргә уелган исемнәр арасында татар халкының батыр улы, язучы, гвардия лейтенанты Хәмит Кавиев та бар. Бу исем безгә яхшы таныш, без аны хөрмәт белән искә алабыз. К. Кавиевның исеме алтын хәрефләр белән язылган шушындый ук мәрмәр такта Казанда — Матбугат йортында да тора.

Хәмит Кави татар әдәбиятында үзенчәлекле урын алып тора. Ул фәнни-популяр, фәнни-фантастик жанрда иҗат итте. Кече яшеннән Тукай шигырьләрен ярата, аларны күңелдән өйрәнә. Бала чагыннан ук әдәбиятка, китапка гашыйк булган Хәмит үзе дә әкиятләр, шигырьләр, җырлар яза башлый. Мәктәптә укыган елларда аның иншалары кызыклы эчтәлеге һәм матур теле белән аерылып торган.

Хәмит 1906 елның 22 декабрендә Чувашстанның Козловка районы, Әлмән авылында укытучы гаиләсендә туган. Сәлим абзый улын үзе шикелле авыл укытучысы итәргә тырыша. Үсә төшкәч, Хәмит әтисе киңәше белән, күбрәк педагогик китаплар укыса да, бөтен күңелен матур әдәбиятка багышлый. Рус һәм чуваш авылларына якын булганга, Әлмән кешеләре руслар һәм чувашлар белән аралашып яшиләр. Шуңа күрә Хәмит бала чагыннан ук рус һәм чуваш телләрен белә башлый, соңга таба рус телендәге китапларны судай эчә. Күренекле чуваш шагыйре Константин Ивановның «Нарспи» әсәрен яратып укый, рус телендәге фәнни-фантастик һәм маҗаралы китапларны кулыннан төшерми. Туганнарының сөйләвенә караганда, ул авылның топографик картасын төзегән, балалар белән уйнаганда сәяхәтче булып, Американы ачкан Христофор Колумб булып уйнаган. Ул үзенең сабакташларына һәм туганнарына: «Үсеп кенә җитим, Магеллан кебек дөнья әйләнә сәяхәткә чыгам, яңа утраулар ачам», — ди торган булган. Хәмитнең дөньяга карашы, таланты бик тиз ачыла. Ул мәктәпне Мактау кәгазе белән тәмамлый. 14 яшендә Хәмит Казанга килә һәм педагогия техникумына укырга керә. Әнә шул елларда ул очерклар, мәкаләләр язып газета-журналларда актив катнаша башлый. Беренче китабын бастырып чыгарганда Хәмит Кавига әле егерме яшь тә тулмаган була.

Техникумда укыган елларында яшь егет язучылар белән аралаша, әдәби түгәрәккә йөри, очрашуларда катнаша. Әмма аны күбрәк фәнни-фантастик темалар, географик ачышлар кызыксындыра. 1926 елда педагогия техникумын бик уңышлы тәмамлап Хәмит укытучы булып эшли башлый, Көнчыгыш педагогия институтында читтән торып укый, яңа әсәрләр яза, редакцияләр белән тыгыз элемтәдә тора. Соңга таба Хәмит Кави техникумда биология һәм география укытучысы булып эшли башлый, ел саен



илебезнең төрле якларына сәяхәтләр ясый, анда күргәннәрен көндәлекләренә язып бара. Соңыннан әлеге материаллар нигезендә очерклар һәм повесть иҗат итә.

Хәмит бик яшьтән тарихи урыннар белән кызыксына, Советлар Союзының казылма байлыклар чыга торган төбәкләрендә була, Татарстанда Пугачёв гаскәре үткән авылларга һәм шәһәрләргә бара, күп кенә кыйммәтле материаллар җыйный. Ул 1937 елда ерак Арктикага да сәяхәт ясый. Бу җаваплы, куркыныч сәфәр вакытында Хәмит Кави махсус хәбәрче буларак хәбәрләр һәм очерклар язып тора. Менә шул хәбәрләрнең берсе:

«Быел, Арктика тарихында беренче тапкыр буларак, махсус пароходта Арктикага туристларның сәяхәте оештырылды. Сәяхәттә катнашучы 100 дән артык турист 18 августта Мәскәүдән Ленинградка чыгып киттеләр. Туристлар Ленинградтан поезд белән Мурманскига барып, аннан диңгез пароходы белән Яңа Җиргә китәчәкләр. Аннан соң Баренц диңгезе, Рус гаване, Надежда борыны, Маточкин Шар, Кармакул, Амзерма, Карский диңгезе һәм Ак Диңгез аркылы Архангельскига кайтачаклар. Туристларның бу кызыклы сәяхәтенә күренекле белгечләр җитәкчелек итәчәк».

Хәмит Кавиның китаплары һәр елны диярлек басылып тора. Ул барлыгы 15 ләп китап чыгара. Аларның барысында да шул заман сулышы, бишьеллык планны үтәү буенча көрәш, эшчеләрнең һәм крестьяннарның тырыш хезмәтләре ачык чагыла. 1930 елда Х. Кавиның «Кавказ таулары аркылы җәяү» дигән китабы басылып чыга. Язучы безне Кавказ табигате, упкыннар, кар белән капланган биек таулар, сөнге кебек кыялар, текә таулардан агып төшкән шарламалар, серле елгалар, кайнар чишмәләр белән таныштыра. 1932 елда басылган «Боз диңгезенә таба» дигән китабында исә Мурманск тимер юлы һәм шәһәре, ак төлкегә бай булган Кильдин утравы, балык тотучылар, болан асраучылар, җәнлек аулаучылар турында кызыклы итеп яза. Бик салкын һәм томанлы көннәрдә дә совет кешеләре кырыс табигатькә каршы торалар, хезмәттә зур уңышларга ирешәләр, яңа рекордлар яулыйлар. Бу батырлыкны язучы дәлилле һәм оста итеп, укучы яратып укырлык итеп тасвирлый. Китап мавыгы хикәя укыган кебек җиңел укыла. Язучының «Идел буенда йөрү» (1931 ел), «Балалар күмер өчен көрәшәләр» (1932 ел), «Кузбасска сәяхәт» (1934 ел) һәм башка китаплары хезмәткә дан җырлыйлар. Хәмит Кави бик эшчән, тынгысыз язучы-педагогларның берсе була. Хатыны Мәрьям апаның әйтүенә караганда, ул Татарстан, Башкортстан, Чувашия һәм Мари республикаларында йөреп, андагы табигать, халыкның көнкүреше, этнографиясе турында дистәләрчә мәкаләләр язган, халык авыз иҗаты үрнәкләре җыйган. Бу елларда төрле газета-журналларда Х. Кавиның мәкаләләрен һәм очеркларын да еш очратабыз. Ул материалны тормышның үзеннән ала, шул чор вакыйгаларының эчендә кайный. Хәтта чаңгы походлары оештыра, үзе шунда катнаша һәм бу турыда язып та чыга. «Казаннан Мәскәүгә кадәр чаңгы белән», «Чаңгыда йөрүнең файдасы» кебек мәкаләләре шуңа мисал булып торалар.

Мех техникумы укучыларының чаңгы белән Мәскәүгә кадәр походта катнашуларын берничә тапкыр Хәмит Кави оештыра. Шушы походта катнашуы һәм уңышларга ирешкәне өчен ул Почет грамотасы белән бүләкләнә. Бу поход турында 1936 елда «Кызыл Татарстан» газетасында «Мех техникумы чаңгычылары Мәскәүдә» дигән хәбәр басылган. Походта катнашучыларны Мәскәү халкы зур алкышлар белән каршылаган. Мәскәү газеталарының берсендә Хәмит Кавиның рәсеме дә басылган.

Хәмит Кави балаларны илебездәге бөек төзелешләр белән таныштырып бара. Аның «Ак диңгез — Балтик каналы», «Зур Фәрганә каналы», «Икенче Баку»га экскурсия» һ. б. очерклары зур әһәмияткә ия. Язучы-педагог Хәмит Кави республикабыз һәм

Казан шәһәренең тарихи урыннары турында кызыклы язмалар әзерли. Шундый фәнни-популяр хезмәтләреннән «Кабан күле», «Казанка елгасы буйлап», «Татарстанда карст», «Казан дәүләт университеты» аеруча киң колачлы.

Х. Кави тәрҗемә өлкәсендә дә тырышып эшли. Ул үзе турында 1935 елда болай дип яза: «Мин 1925 елдан бирле төрле газета-журналларда мәкаләләр, очерклар язып киләм. Унлап китабым чыкты. Быел яза башлавыма ун ел тулды.

Минем бөтен язган әйберләрем басылмаган. Басылмаганнары басылганнарына караганда күбрәк... Хәзер зур китап язу өстендә эшлим.»

Х. Кави шагыйрь Фатих Кәрим, тәнкыйтьче Гомәр Гали белән аерата дус була, үзенең әсәрләрен алар белән киңәшеп яза. Фатих Кәрим һәм Гомәр Гали аның китапларын редакцияләп чыгарганнар.

Бөек Ватан сугышына кадәр язучыны, аркасына юл капчыгы аскан хәлдә, Татарстанның һәм Советлар Союзының әле бер, әле икенче ягында еш күрергә мөмкин була. Шул сәяхәтләреннән соң Х. Кави «Унбер республика буйлап» дигән китап яза. Аның өзекләре «Пионер каләме» журналында басылалар. Ләкин китап дөньяга чыкмый кала, немец-фашист илбасарларына каршы сугыш башлана.

Язучы һәм педагог буларак, Хәмит Кавины хөрмәт иткәннәр, аның тырышлыкларына зур бәя биргәннәр. Җәмәгать эшләрендә актив катнашканы, Казан мех техникумында яхшы эшләгәне, яшь буынга коммунистик тәрбия бирүгә зур өлеш керткәне өчен 1936 елда аңа Мәскәүдә Тышкы сәүдә халык комиссары имзасы белән исеме язылган сәгать бирелгән. Шулай ук ул «Бишьеллык ударнигы» дигән исемгә лаек булган.

Мех техникумында Хәмит Кави язучы Г. Кашшаф һәм балалар язучысы А. Әхмәт белән бергә эшләгән. А. Әхмәт аның эшчәнлегенә сокланып болай дип яза: «Х. Кави бик тырыш язучы иде. Аның өлгерлегенә без соклана идек. Ул укытучы-педагог та, фәнни-популяр темага китаплар язучы да. Аның өстенә техникумда һәртөрле җәмәгать эшләре дә алып бара. Һәр көнне диярлек вакытлы матбугатта мәкаләләре, очерклары чыга, барысына да өлгерә, бик актив эшли иде».

1941 елның сентябрендә Хәмит Кави Кызыл Армия сафына китә. Ул Мәскәү янындагы каты бәрелешләрдә катнаша. Беренче җиңүләребез турында Х. Кави үзенең гаиләсенә шатланып хатлар яза. Ул хатлар батырлыкка омтылу, җиңүгә ышаныч хисе белән сугарылган: «Фашист басып алучыларның көннәре санаулы. Без аларны эссе табада биетәбез. Газиз аналар, мөгътәбәр картлар һәм карчыклар, тол хатыннар һәм ятим балалар үчен алу өчен без дошманны кыйныйбыз, ул ерткычлардан үч алабыз! Без изге Ватаныбызны немец-фашист этләреннән чистартабыз, халыкларга ирек һәм бәхет китерәбез!» — дип яза ул.

Гвардия дивизиясе составында Х. Кави, дошманны куа-куа, Украинага килеп керә. Идел ярларыннан килгән егет Днепрга ашкына, бөек шагыйрь Тарас Шевченконың туган җирен азат итү өчен канлы бәрелешләрдә катнаша.

Сугыш кырларында чыныккан гвардияче командирны танк училищесына җибәрәләр. Ул анда кыска сроклы курста укып, танкист була, каты бәрелешләрдә катнаша. Яу кырында күрсәткән батырлыклары өчен Хәмит Кави медальләр белән бүләкләнә. Аның турында фронт газетасында язып чыгалар. Фронт штабыннан Мәрьям ханымга язылган хатларында да Х. Кавиның туган илебез өчен үз-үзен аямыйча сугышуы, иң куркыныч минутларда да танкистларны рухландырып дошманга каршы баруы һәм җиңеп чыгуы әйтелә. Укытучы һәм язучы алгы сызыкта батыр солдатка әйләнә, танк белән җиңүгә юл яра.

Х. Кави сугыш кырында да үзенең иҗат эшен дәвам итә, очерклар, хикәяләр яза, «Туп һәм китап» дигән повесть өчен материаллар туплый, «Хаккый батыр турында» дигән зур күләмле китап яза. Әмма ул үзенең хыялларын тормышка ашыра алмый кала, 1944 елның 15 июлендә һәлак була. Аны полкташ дуслары зур хөрмәт белән җирлиләр.

Сугыштан соң Хәмит Кавиның әсәрләре «Алар сафта» дигән китапта басылып чыкты. Ләкин әлегә әсәрләренең азмы-күпме тулырак басмасы юк. Язучының басылган һәм басылмаган әсәрләре шактый күп, аларны дөньяга матур китап итеп чыгару безнең изге бурычыбыз булып кала.

# ТӘҖРИБӘЛЕ ЖУРНАЛИСТ, ТАНЫЛГАН ШАГЫЙРЬ ИДЕ УЛ

Аннан бирле бик күп вакыт үтте, күп су акты. Әмма яшь чактагы хатирәләр онытылмаслык булып күңелгә сеңеп калалар бит. Бу кечкенә язмада мин шундый хатирәләрнең берсенә тукталмакчымын.

Укытучылык хезмәте белән саубуллашып, Мамадыш район газеталары редакциясендә ярты ел чамасы гына эшләгәннән соң, туган районыма — Чаллыга әйләнеп кайттым.

Ул замандагы Чаллы, Кама елгасы буенда утырганын исәпкә алмаганда, бер ягы белән дә хәзергесенә охшамаган иде. Җилле көннәрдә күз ачкысыз ком бураны эченнән чак-чак кына күренә торган авыл өйләре таралып урнашкан кечерәк кенә бер шәһәр, район үзәге иде. Ул чакта Чаллыда дан тоткан һәм күрше тирәдәге районнарга хезмәт күрсәтә торган берданбер зур корылма — пароход белән Кама буйлап югарыга күтәрелгәндә Алабугадан кузгалып киту белән диярлек күренә башлаган ашлык элеваторы иде. Калганнары вак-төяк предприятиеләр: тегермән, такта яру заводы...

Комсомол члены булганлыктан, башта мин ВЛКСМның Чаллы райкомына кереп сөйләштем, киңәштем. Анда миңа берничә төрле эш тәкъдим иттеләр. Газетада эшләү стажым бик кечкенә булуга да карамастан, журналист профессиясе ошап өлгерде булса кирәк, мин район газеталары редакциясенә җибәрүләрен үтендем. Иртәгесен, кабат килгәч, партия райкомы белән сөйләшеп, редактор урынбасары вазифаларын үтәү өчен редакциягә барырга әйттеләр, һәм мин шунда юл тоттым.

Ул вакытта Чаллыда рус һәм татар телләрендә «Трактор» исемле газеталар чыгып килә иде. Редакция Үзәк урамдагы ике катлы агач йортның өске катындагы ике бүлмәдә урнашкан, ә типография элеккеге чиркәү бинасында иде. Мин килеп кергәндә эчкәрге бүлмәдә, тәрәзә буендагы зур өстәл артында чәчен артка җибәргән, мөлаем йөзле, бик матур күзлек кигән егерме биш — утыз яшьлек бер кеше эшләп утыра иде. Ул хезмәтенә шул чаклы нык, җаны-тәне белән бирелгән, хәтта минем кергәнемне дә абайламады. Шуңа күрә, исәнләшкәнемне ишеткәч, сискәнеп китте.

Таныштык. Әлеге чибәр кешенең редактор Нур Баян икәнен белдем. Тәрҗемәи хәлемне сорашып, шул ук районның Түбән Суыксу авылында ярлы крестьян гаиләсендә туганымны, Алабуга педтехникумын тәмамлаганнан соң, ел ярым укытучы һәм аннары газета редакциясендә эшләвемне, журналистлык хезмәтен дәвам иттерү нияте белән килүемне белгәч, аның болай да мөлаем йөзе тагын да яктырып китте, хәтта елмаеп та куйды.

Әле беренче мәртәбә генә очрашуыбызга да карамастан, шагыйрь Нур Баян мине күптәннән көтеп алган кунагы шикелле каршылады, үз итеп сөйләште. Редакция аппаратында кеше җитмәгәнлектән, чамасыз күп эшләргә туры килүен, алай да өлгерә алмавын, иҗади эш белән шөгыльләнергә бер дә вакыты калмавын әйтеп, бераз зарланып та алды. Һәм, бүген үк булмаса да, иртәгәдән дә калмыйча эшли башлавымны үтенде.

Иртәгесен мин редакциягә килдем һәм аның белән бергә эшләргә керештек. Аппаратта тагын ике иптәш — рус газетасы секретаре А. Даричев һәм татар газетасы секретаре М. Садыков бар иде. Өч кеше алып барган вазифаны дүрткә бүлгәч, эш беркадәр җиңеләйде, җанланып китте. Шулай да шактый авыр һәм катлаулы вакыт — 1932 елның җәе иде ул. Авыл хуҗалыгын күтәрү, колхоз һәм совхозларны оешу-хуҗалык ягыннан ныгыту өлкәсендә партия куйган зур бурычларны тормышка ашыруга советка каршы элементлар каты каршылык күрсәтәләр, корткычлык эшлиләр, техниканы бозалар, колхоз милкен урлыйлар, хезмәт дисциплинасын какшатырга, ашлык әзерләүне өзәргә тырышалар, партия эшенә чын күңелдән бирелгән активистларны, шул җөмләдән авыл хәбәрчеләрен, сагалап торып әзәрлеклиләр, теш-тырнаклары белән колхозларны эчтән таркатырга маташалар иде. Мондый шартларда партия аппаратының дәвамы булган газета работникларыннан да зур уяулык, вакыт һәм сәламәтлек белән хисаплашып тормыйча, бөтен көчне куеп, җиң сызганып эшләү таләп ителә иде. Без, кулыбыздан килгәнчә, шул таләпләр югарылыгында булырга тырыштык та.

Урак өсте, ашлык хәзерләү вакыты иде ул. Газеталарның ике-өч санын бергәләп чыгардык. Шуннан соң Нур Баян, сәламәтлеге какшау сәбәпле, врачлар кушуы белән, кыска вакытлы ялга чыкты һәм үз районыбызның Иштерәк авылына кымызга китеп барды. Әмма ул анда да ялын эш белән аралаштырды. Типографиядән үзе белән беркадәр хәреф, бәләкәй басу машинасы һәм кәгазь алып барып, Иштерәк тирәсендәге колхозларда урып-җыю һәм дәүләткә ашлык тапшыруның барышын яктырткан берничә сан кечкенә газета — нәни «Трактор» бастырды. Ә район газеталарын чыгаруны безгә ышанып тапшырды. Бу исә, бигрәк тә минем өчен, куанычлы яңалык, шундый җаваплы эштә чиркәнчек алу булды, чөнки газеталарның ул саннары, редактор урынбасары буларак, минем имза белән басылды.

Сентябрь ахырларында Нур Баян Чаллыга кайтты һәм без айдан артык яңадан бергә эшләдек. Шул кыска гына арада мин аның көчен кызганмыйча, төпкә җи-

гелеп эшләүче, тугры, аралашучан, шәфкатьле, үтә ярдәмчел һәм шул ук вакытта бик тыйнак иптәш, кыскасы, егет кеше икәнен күрдем. Журналистлык өлкәсенә әле аяк баскан гына чагымда ул минем якын кешем, тәүге остазым булды.

Төп эштән бушаган чакларында Нур Баян иҗади хезмәткә чума, шигырьләр яза иде. Мин исә аның шул чакта иҗат иткән шигырь һәм поэмаларының беренче тыңлаучысы, укучысы идем. Аның авыл тормышын тирәнтен өйрәнеп, зур тырышлык, дәрт, күтәренке рух белән язылган һәм Сирай, Булат, Суфия һәм башкалар кебек җанлы образлар аша авылдагы сыйнфый көрәшне, колхозларны оешу-хуҗалык ягыннан ныгыту һәм икмәк өчен көрәшне оста чагылдырган «Яңгырлы төн» поэмасы нәкъ шул елларда иҗат ителде. Киң планда язылган бу әсәрне укучы бик җылы каршы алды, җәмәгатьчелек аңа югары бәя бирде.

Кичләрен, редакциядә эшне түгәрәкләгәч, Нур Галимович үзенең әлеге поэмасын укый, ә мин рәхәтләнеп тыңлый торган идем. Аның шул әсәрендәге элек тыңлаган мондый юллар әле дә булса хәтеремдә саклана:

**Без һәр көнне**
**һаман**
**Алга табан**
**Зур адымнар белән барабыз,**
**Җиңүчеләр булып**
**Кемнәр чыкты,**
**Сез тарихка борылып карагыз.**

Шундый кичләрнең берсендә мине чак кына «теге дөньяга» җибәрмәгән бер вакыйга булды. Икебез дә зур өстәл өстендә янәшә утырабыз. «Яңгырлы төн»нең дәвамын укыйдык. Шуннан соң Нур Баян браунингын кобурасыннан чыгарды да чистартырга кереште. (Ул чакта, заманына күрә, чыгарма рәвешендә, җаваплы работникларга корал йөртергә рөхсәт ителә иде.) Чистартып бетерүгә, обоймасын куйганчы, браунингының курогын тартып җибәрде. Бер дә көтмәгәндә көчле шартлау тавышы яңгырады. Баян аптырап китте, агарынды, күгәренде, ни әйтергә дә белмичә, тәмам каушап, югалып калды. Минем дә хәлем шундыйрак иде. Бераз һушыбызга килгәч, карасак, пуля миңа орынып кына диярлек узып, стена сәгате астына барып кергән булып чыкты. Обойманы алганда бер патронның браунинг көпшәсендә утырып калганлыгы ачыкланды. Бу инде корал белән эш итә белмәү янсә саксызлык бәласе иде.

Моның өчен ул миннән шул чакта да, аннан соң очрашкан чакларыбызда да күп мәртәбәләр гафу үтенде.

Нур Баян хакында тагын шуны әйтәсем килә: ул үзенә карата да, башкаларга карата да бик таләпчән һәм эшне җиренә җиткереп, пөхтә итеп башкарырга ярата иде. Шундый була торып та инде кимчелек яки хата китә калса, ул аның өчен үкенеп бетә алмый, җаны әрни, күңелендә ярасы шактый озак вакытлар саклана иде. Шул елның июль ахырларында татар телендә чыга торган газетада Казаннан килгән бер мәкаләдә хата киткән була. Анда, ялгыз хуҗалыкчы ашлыкны гектардан күрше колхоз тапшырганнан ким тапшырмаска тиеш, диясе урынга, артык тапшырмаска тиеш, дип басылган, һәм нәтиҗәдә ялгыз хуҗалыкчыларга өстенлек бирелә кебек килеп чыккан. Бу хатасын ул бик авыр кичерде һәм газетада эшләүнең үзенчәлекләре хакында сөйләшеп утырган вакытларыбызда ул миңа, васыять итеп әйткәндәй:

— Менә сабак ал. Ялгыш җибәрмәү өчен, матбугат кешесенә минер шикелле үк игътибарлы, сак булырга кирәк,— диде.

1932 елның ноябрь башында Нур Баян, Чаллы белән саубуллашып, гаиләсе белән Казанга китеп барды. Аның киңрәк мәйданга чыгу, иҗат эшен ныклап дәвам иттерү турындагы хыялы гамәлгә ашты. Мин редакциядә аның урынына калдым. Атнаун көн узуга Татроста хәбәрчесе итеп билгеләнүем хакында Казаннан карар һәм таныклык килеп төште. Моны Нур Галимович оештырганлыгын белдем.

Безнең ара моның белән генә өзелмәде. 1934—1941 елларда, мин Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә һәм аннан соң Казанда эшләгәндә Нур Баян белән без күп мәртәбәләр очраштык. Мин дә һаман матбугат тирәсендә кайнашканга күрә, безнең уртак темаларыбыз күп була, сүз арасында Чаллыда эшләгән чакны да искә алып куя торган идек. Мин аны тәҗрибәле журналист, күренекле шагыйрь һәм киң күңелле иптәш буларак якын күрә, ихтирам итә идем.

Исән булса, Нур Галимович Баянга быел 75 яшь тулар иде. Әммә, кызганычка каршы, аңа бу көнне күрергә насыйп булмады. Бөек Ватан сугышы бетәргә унунбиш көннәр генә кала ул, сугышчан бурычны үтәгәндә каты яраланып, Австрия кырларында үлеп калды...

Мин аның якты образын бүген дә зур ихтирам белән искә алам.

**ГЫЙМАДИ КАМАЛИЕВ,**
**РСФСРның атказанган культура работнигы.**

Флера Сафиуллина

# ТАТАР ПРОЗАСЫНДА ХИКӘЯЛӘҮ

*Тарихи-стилистик анализ*

Татар прозасы XIX йөз ахыры, XX йөз башында әдәби жанр буларак формалашу чорын кичерә. М. Акъегет, З. Бигиев, З. Һади, Ш. Мөхәммәдов традицияләрен Ш. Камал, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Ибраһимовлар тагын да югарырак баскычка күтәреп дәвам иттерәләр, татар прозасының классик үрнәкләрен бирәләр. Ш. Усманов, К. Нәҗми, И. Гази, Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Ә. Еники исемнәре белән күренекле икенче дулкын прозабыз үсешенә үзеннән зур өлеш кертә. Аннан соң тагын бер дулкын— Р. Төхфәтуллин, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Ә. Баянов, М. Мәһдиев, Ш. Бикчурин, М. Хәбибуллин, В. Нуруллиннар килеп керә. Алар артыннан әдәби талантлары, тормыш тәҗрибәләре төрлечә булган яңа көчләр килә... Һәрбер язучы дөньяны үзенчә күрә, үзенчә сурәтли, үзенчә бәяли. Һәр язучының үзенә генә хас язу алымнары, стиль чаралары, хикәяләү осталыгы бар.

Әдәби әсәр бездә, гадәттә, ике фәннең өйрәнү объекты булып тора. Әсәрне әдәбиятчылар өйрәнә: идея эчтәлеген, сюжетын, композициясен, геройларның бирелешен һ. б. мәсьәләләрне тикшерә. Юл уңаенда гына тел мәсьәләләренә дә тукталып үтә. Әсәрне телчеләр тикшергәндә, шулай ук берьяклылык килеп чыга. Лингвист әдәби әсәрдә нинди синонимнар, антонимнар, күпмәгънәле сүзләр, диалектизмнар һ. б. куллануны теркәп күрсәтә; иң шәп очракта аларны язучының осталыгына, персонажларның характеристикасына бәйләп карый. Әдәбиятчының өлешенә кермәскә тырыша. Һәм, дөресен әйтик, керә дә алмый. Х. Курбатов, Х. Сарьян кебек әдәби-эстетик анализны тел үзенчәлекләренә бәйләп алып бару бөтен кешенең дә кулыннан килми. Менә шуңадыр да әдәбият һәм тел арасында булып, бер-берсенә гаять тыгыз бәйләнгән күренешләр бездә өйрәнелмичә кала бирә. Мондыйлар рәтеннән татар прозасында хикәяләү үзенчәлекләренә караган проблеманы атарга мөмкин булыр иде.

Хикәяләү—авторның (әсәрдәге сөйләүченең) вакыйгаларны бәян итүе. Әсәрнең композицион, идея-эстетик бөтенлеге хикәяләү белән тыгыз бәйләнгән. Хикәяләү 3 нче затта автор исеменнән, лирик герой исеменнән, вакыйгаларга катнашкан 1 нче зат исеменнән алып барылырга мөмкин.

Татар прозасының үсешендә хикәяләү дә шактый үзгәрешләр кичергән. З. Һади, З. Бигиев әсәрләрен, мәсәлән, И. Гази, Ә. Еники, А. Гыйләҗев әсәрләре белән янәшә куйсак, хикәяләүдә зур аерма күрербез. Беренчеләренә хас булган салмаклык, хәтта әкренлек, монотонлылык, күпмедер битарафлык, авторның үзе сурәтли торган хәлләрдән читтә торуы исемнәре аталган безнең чор язучыларына ят әйбер. Хикәяләүдә динамизм, гаять зур эмоциональлек, бай сурәтләү чаралары, лиризм, авторның үз геройларына ачык әйтелмәгән, әмма тоелырлык актив мөнәсәбәте, ягъни автор концепциясе—болар хәзерге татар прозасында әйдәп баручы сыйфат. Мәкаләбездә куелган максат татар прозасының үсеш дәвамында күзәтелгән хикәяләү үзенчәлекләрен билгеләүдән гыйбарәт. Шуны да искәртеп китик: теманы ачу процессында без барлык язучыларга да бер үк күләмдә игътибар итүне мөмкин булмас дип исәплибез.

Татар филологиясендә турыдан-туры бу темага карамаган хезмәтләр юк дәрәҗәсендә аз. Тегеяки бу язучының телен, стилен тикшергәндә, аңа бераз кагылып китәләр. Прозабызның тарихын тикшергән бер мәкаләсендә[1] Ф. Мусин чәчмә хикәя-

[1] Ф. Мусин. Олы юлга чыкканда (татар прозасында роман һәм повесть тарихыннан). — Татар теле һәм әдәбияты. Бишенче китап. Казан, 1976, 231—251 б.

ләү барлыкка килүнең сәбәпләренә тукталып, хикәяләү алымнарының поэтик әдәбият һәм фольклорга мөнәсәбәтен һәм алар белән тыгыз бәйләнешен тикшерә. И. Бәшированың «Татар прозасында хикәяләү стиленең үстерелеше»[1] дигән мәкаләсе турыдан-туры без тикшерә торган мәсьәләгә карап, автор хикәяләү стиленең үсешендә өч этап күрсәтә. Беренче этап XIV гасырдан алып К. Насыйри әсәрләренә хәтле чорны үз эченә ала. Бу чорда автор битараф, төрле чыганаклардан ишеткән вакыйгаларны гына бәян итә, сүзләр үзләренең номинатив мәгънәләрендә генә кулланылалар. Икенче этап, И. Бәширова фикеренчә, М. Акъегет, З. Бигиев, Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими, Ш. Мөхәммәдов, З. Һади исемнәре белән бәйле булып (XIX йөз ахыры—XX йөз башы), вакыйгаларга автор мөнәсәбәте, сүзләрнең бәяләү, эмоциональ-экспрессив төсмере, сюжет линиясенең ачыла төшүе белән характерлана. И. Бәширова өченче этапны Ш. Камал, Ф. Әмирхан исемнәре белән башлый һәм безнең көннәргәчә дәвам итә дип күрсәтә. Бу—чынбарлыкны сөйләп түгел, ә тасвирлап бирү, сүзнең сурәткә әверелү баскычы. Күрсәтелгән мәкаләдә 1 нче чор бик төгәл сурәтләнгән, шуңа күрә без сүзебезне проза жанры формалашып килгән чордан башларбыз.

З. Һади, М. Акъегет, З. Бигиев һ. б. иҗатлары белән характерлы бу чорда автор хикәяләве төп үзенчәлек булып тора. Автор өченче заттан сөйли. Хикәяләү салмак, бик тыныч, әкрен, бертөрле. Авторлар моны үзләре дә сизәләр, күрәсең, һәм укучыга мөмкин хәтле якынрак булырга тырышу турыдан-туры аңа мөрәҗәгать итүгә китерә. Автор укучыны битараф калдырасы килми, «гыйззәтле укучы», «хөрмәтле әфәнделәр», «хөрмәтле укучыларымыз» кебек эндәшләр белән укучыларны үз хикәяләвенә ияртеп алып китәргә тели. Бу үзенчәлек татар халык әкиятләренә барып тоташа кебек. Анда да әкият сөйләүче үзенең барлыгын сиздереп куя. Әкият барышында да, әкиятнең ахырында да тыңлаучылар белән мөнәсәбәт сизелә: «Ярар, тегеләр өйләренә кайта торсыннар, без Таңбатыр янында калыйк» («Таңбатыр»). «Егет әле дә яхшы гына гомер итәдер иде, әле бу көннәрдә барганым юк, хәлен белмим, ничегрәк яши торгандыр» («Тылсымлы чыбык») һ. б.

Прозаның беренче үрнәкләрендә әкиятләрдән килгән башламнарның характерлы булуын да әйтеп үтик. Әкиятләрдәгечә башламнарны («Борын-борын заманда булган икән, ди, бер карт аучы»—«Аучы егет»; «Алпамша ярлы гаиләдән чыккан бер малай була»—«Алпамша») «Нәһҗ-әлфәрадис»тагы башламнар дәвам итә кебек: «Бер шәех бар иде». «Әбү Мәсрид ингән бик юмарт кәрим ирде». «Зөннун Мисрыйны зинданга каттылар». «Вакыт эчендә бер падишаһ бар иде» һ. б. Бу әсәрдәге башламнар герой турында аның холкы, берәр сыйфаты турында беренчел һәм кыска гына мәгълүмат бирәләр, я геройны эш-хәрәкәттә күрсәтәләр. Алар кыска, нәкъ әкиятләрдәгечә. XIX—XX йөз башы прозасында, күрәсең, мондый башламнар таралган булганнар.

Мондый гади башламнар белән бергәтән XIX—XX йөз башы татар әдәбиятында «саллы» башламнар зур урын алып торалар. М. Акъегет, З. Һади, З. Бигиев әсәрләренең башламнарын искә төшерик. Алар хикәяләүнең үзе кебек салмак, озын һәм... бераз ялыктыргыч та. Ш. Камал, Г. Ибраһимовка хас кыска динамик башламнарга килеп җиткәнче, шактый вакыт, тәҗрибә, осталык традициясен үстерергә кирәк була.

XIX йөз азагы XX йөз башы проза әсәрләрендә хикәяләүнең монотонлы булуы аеруча күзгә ташлана. Мондый интонацияне барлыкка китерүдә татар теленең грамматик закончалыкларыннан берсе—җөмләдә хәбәрнең иң ахырдан урнашуы—хәлиткеч роль уйный. Проза әсәрләрендә генә түгел, поэзия әсәрләрендә дә хәбәрнең юл ахырларына туры килүе көйләп уку өчен бөтен шартларны тудырган. XIX йөз ахыры—XX йөз башы проза әсәрләрендә хәбәрнең җөмлә башына чыгарылуы юк дәрәҗәсендә аз күрсәтелә. Автор хикәяләвендәге «Салисән, номер эченнән **табылган** бер мәктүб» (З. Бигиев, «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә», 409 б.), **«Нәүбәт җитте** Габденнәсыйр әфәндегә» (З. Бигиев, «Өлүф...», 431 б.)[2] кебек инверсиягә мисалларны бу чор язучыларда юк дәрәҗәсендә сирәк очратасың. М. Акъегетнең «Хисаметдин мелла» әсәрендә хәбәрнең җөмлә ахырында килүе 91 процент, З. Бигиевның «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә 94,7 процент тәшкил итә. Бу үз чиратында хикәяләүдә бертөрлелеккә китерми калмый.

Монотонлылык хәбәр формаларының охшашлыгы исәбенә дә арта. Хәбәрнең категорик үткән заман формасы **—ды—де—ты—те,** төрек формасы **—мыш—меш,** хәзерге заман мәгънәсендәге **—ыр—ер—р** формалары, мәсәлән, М. Акъегетнең «Хисаметдин мелла»сында 75 проценттан артыгракны тәшкил итәләр. «Габденнәсыр әфәнде, Казаннан туй мәсарифы өчен акча сорап, мәктүп **язмыш.** Мәктүпне хадим сыщик Ивановка виреп, Казанга Габдуллинга **күндермеш.** Мәктүп бу тарыйка **язылмыш иде»** (З. Бигиев, «Өлүф...», 446 б.).

З. Һадиның «Яңа әсхабе кәһаф»ында хәбәр формалары төрләнә башлый, шулай да **—ды—де** белән **—а иде** формалары өстенлек итә. Ш. Мөхәммәдовта **—дыр—дер** кушымчасы алган хәбәр барлык төрләрдән дә күбрәк кулланыла: барадыр, әйтәдер.

Хикәяләүдәге монотонлылык тагын бер сәбәп аркасында барлыкка килгән. 90 про-

[1] И. Бәширова. Татар прозасында хикәяләү стиленең үстерелеше. — Татар теле һәм әдәбияты. Алтынчы китап. Казан, 1977.

[2] Текстлар М. Гайнуллинның «Татар әдәбияты. XIX йөз». Тулыландырылган икенче басма (Казан, 1968) һәм М. Х. Гайнуллин һәм Ж. Вәзиеваның «Татар әдәбияты, XX йөз». I кисәк, Югары уку йортлары өчен. Төзәтелгән икенче басма, (Казан, 1964) китаплары буенча китерелә.

центка якын җөмләләр — хикәя җөмләләр. Алар тыныч тонда, салмак әйтеләләр: интонациянең кискен күтәрелүе яисә төшүе бу төр җөмләләрдә күзәтелми. Бик сирәк очракларда гына автор хикәяләвенә тойгылы, сорау җөмләләр килеп керә. Мәсәлән. «Гаҗәп!!! Господин прокурор бер дә зан кылмаган сөальне Габдуллиннан сөаль кылды» (З. Бигиев, «Өлүф...», 433 б.). «...Мәхәббәтнең нә идегене аңламасларыннан мокатдәм бонлар бер-беренә мәхәббәт итмешләр иде. **Әмма никадәр** дә саф вә халис мәхәббәт иде!..» (Р. Фәхретдинов, «Әсма», 654 б.). Хикәяләү агышына интонация төрлелеге бирә торган һәм хәзерге әдәбиятта гаять күп очрый торган өтау җөмләләр бу чорда шулай ук күзәтелмиләр диярлек.

Монотонлылык—хикәяләү уңаенда авторның исенә төшкән, әмма төп җөмләдәге ясcылыкка сыеп бетмичә, башкачарак интонация белән аерылып торган сүзләр өстәлү исәбенә дә югала бара. Әмма бу төзелеш үзенең яралгы хәлен генә кичерә әле: «Габбас аганың кадыны Шәмси абыстай (асылда аты Шәмсекамәр иде, ләкин атыны бозып Шәмси дирләр иде) күптән менланың килмәкене өмет итәр иде (М. Акъегет, «Хисаметдин менла», 364 б.). «Габбас мелла мәктәп ачып балалар укытыгында Хикмәт хаҗиның хөсете шул мәртәбәдә иде ки, әгәр дә мөмкин улса, мәктәбене ваттырып, урынында улан тупракны суга салдырыр иде (боның баш сәбәбе кыз мәсьәләсе идеке мәгълүмдер)» («Р. Фәхретдинов, «Әсма», 637 б.).

Автор вакыйгаларны бик җентекләп, эзлекле итеп хикәят кылу өстенә, үзенең яшертен мөнәсәбәтен белдерергә дә омтылыш ясый башлый. Бу мөнәсәбәт аерым сүзләрдә, җөмләләрдә, контекстта сиземләнә. Автор хикәяләвенә подтекст, ирония, героена карата өстәнрәк карау төсмерләре дә килеп керә. Ш. Мөхәммәдов хикәяләрендә бу ирония гротеск характерын ала. Автор булган вакыйгаларны хикәя итә кебек кенә. Ләкин һәр җөмлә ул сурәтләгән персонажларның рухи, мораль йөзен ачуга өлеш кертә, автор алардан үтергеч итеп көлә һәм укучыны да битараф калдырмый.

Бу чорда автор хикәяләве белән янәшә персонаж сөйләме дә шактый актив кулланыла башлый. Чит сөйләм автор сөйләменнән сизелерлек дәрәҗәдә аерылып тора һәм, нигездә, сорау җөмләләр һәм аларга җаваплар рәвешендә оеша. «Нәһҗ-әлфәрадис»тагы кебек үк булмаса да, XIX йөз ахыры прозасында да автор сүзләренең туры сөйләм белән гаять тыгыз бәйләнеше күзәтелә. Репликаларның автор сүзләренә структур-грамматик яктан тыгыз бәреккән булуы җөмләләрне озын итә, ә бу—үз чиратында тагын монотонлылык тууга сәбәп була: «Нәчә кеше?» — дәю сөаль кылдыгыма, «Ирле-хатынлы икәү, бер кызлары да вар, барчасы өчәү»,—дәю хадим җавап вирде» (З. Бигиев. «Өлүф...», 418 б.) Репликаларның автор сүзләре белән тыгызлыгы бигрәк тә З. Бигиевта күзәтелә. Аңарда М. Акъегеттәге шикелле юл башыннан мөстәкыйль итеп бирелгән диалоглар юк. һәр ике реплика бик тыгыз, бер җөмләгә оешып бәйләнгән.

Күрәсең, югарыда искә алынган диалогик берәмлекләрнең авырлыгын сизеп, хикәяләүне җанландыру теләге беләндер, Р. Фәхретдинов хәтта драматургиядәге «саф» диалогка охшашларын да куллана. Мондый диалогны соңрак «Яфрак асты яки мәкерҗә ярминкәсе» дигән әсәрендә Ш. Мөхәммәдов та төрле персонажларга нисбәтән куллана. Автор сүзләрендәге бертөрлелек (әйтте, диде, сорады һ. б.) язучыны туйдыра булса кирәк. Әңгәмәнең, вакыйгаларның, фикерләрнең киеренкелеген күрсәтергә теләгәндә, бу сүзләр хикәяләүне әкренәйтәләр кебек. Хәзерге әдәбиятта— А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, Ш. Бикчурин, Ә. Гаффар хикәяләвендә бу алым яңача чагыла.

Элекке дәвер хикәяләвендә диалогның урыны зур түгел. Нигездә, автор хикәяли һәм, булган тәкъдирдә, диалогтагы репликаларның күләме гаять зур. Җанлы сөйләм репликаларына хас кыскалык, динамизм аз чагыла. Персонаж сөйләме белән автор сөйләме мөстәкыйль җөмләләр буларак аерылып торсалар да, сыйфаты, җөмләләрнең структур-грамматик үзенчәлекләре ягыннан бик охшашлар. Күләм ягыннан да алар автор җөмләсе кебек үк зур һәм авыр кыяфәтлеләр. Аерым очракларда гына персонажның сөйләменә бераз үзенчәлек, индивидуаль билге өстәлә. Мәсәлән, З. һадиның «Бәхетсез кыз»ында ике егетнең, Хәнифә белән Хәдичәнең сөйләшүендә шул якның җирле сөйләм үзенчәлекләрен сиземләп була.

Г. Ибраһимовның да беренче иҗат тәҗрибәләрендә персонаж сөйләме юк дәрәҗәсендә аз. Хәтта персонажларны сөйләтәсе урында да автор үзе сөйли, персонаж сөйләмен күбесенчә кыек сөйләм рәвешендә формалаштыра: «Мәдрәсәгә килүе илә укымышлыларыны тәнкыйть итәргә дә, бу дәресләрне ташлап, заманага муафыйк рәвештә итеп голүме диния вә фәнун укырга кирәклекне сөйләргә башлады» («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»). Персонажларның сөйләме бер-берсеннән аерылмый диярлек. Автор ничек хикәяләсә, персонаж да шулайрак сөйли.

Хикәяләү темпын билгеләүдә җөмлә күләменең үсешен күзәтү кызыклы булыр. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә уртача һәр биткә 19,5 җөмлә туры килеп, һәр җөмләдәге сүзләр саны 12,6 га җитә. Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» әсәрендә—бер биткә 15,4 җөмлә һәм һәр җөмләдә 20,4 сүз; К. Нәҗминең «Язгы җилләр»ендә—24 һәм 10,2; Ш. Маннурның «Агымсуларга карап» әсәрендә—27,8 һәм 9,8; А. Гыйләҗевнең «Мең чакрым юл»ында — 30,7 һәм 7,4; Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим»ендә—36,6 һәм 6,2; М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар»ында 37,1 һәм 6. Бу саннар татар прозасындагы хикәяләүдә сыйфат үзгәрешләре булуын бик ачык күрсәтәләр булса кирәк.

Өлгергән прозага хас үзенчәлек—табигать күренешләрен сурәтләү беренче проза

әсәрләрендә шулай ук күзәтелми. Сирәк кенә теге яки бу авылның урнашуына бәйле аерым җөмләләр булса да, табигатьнең матурлыгы, аның кеше күңеленә, хисләренә бәйләнеше, табигатьне поэтизацияләү бу әсәрләрдә урын алмаган. Г. Ибраһимовта гына бу сыйфатлар хикәяләү үзенчәлеге булу дәрәҗәсенә күтәрелә.

XX гасыр башы әдәбиятында хикәяләү алымнары шактый төрләнә. Һаман авторны гына, янсә һаман персонажларны гына сөйләтеп тору, күрәсең, язучыларны канәгатьләндерми башлый. Хисләр, тойгылар ташкынын, аларның тиз-тиз алышынуын, эмоциональ хикәяләүне тәэмин итә торган чаралар кирәк була. Күрәсең, шуңа җавап рәвешендә (күпмедер күләмдә, көнбатыш һәм рус әдәбияты тәэсирендәдер), татар әдәбиятында хикәяләүнең уртак сөйләм дип аталган үзенчәлекле бер төре формалаша.

Бу алымның барлыкка килү сәбәпләре, шартлары нинди соң? Рус филологиясендә аны болай аңлаталар. XIX йөзнең башында хикәяләү стилендә реформа барлыкка килә. Матур әдәбиятка интенсив рәвештә җанлы сөйләм теле элементлары үтеп керә башлый. Геройларның эчке дөньясына тагын да тирәнрәк үтеп керү теләге дә башка төрле хикәяләү алымнарын эзләүгә этәрә. Уртак сөйләмне хикәяләү алымы буларак рус әдәбиятына прозада реформа ясаган А. С. Пушкин алып керә дип саныйлар. Татар прозасында уртак сөйләм XX йөз башында, ягъни рус әдәбияты белән чагыштырганда бер гасыр соң кулланыла башлый. Бу алымның яши башлавы өчен барлык яктан да өлгергән проза кирәк, ә татар прозасы жанр буларак нәкъ шушы чорда формалашып җитә. Татар әдипләре рус әдәбияты, дөнья әдәбиятының казанышлары белән дә таныша баралар. Моңа хәтле классик канунннарга китап һәм язу традицияләренә буйсынып яшәгән татар прозасы тел. ягыннан шактый зур үзгәрешләр кичерә. Хикәяләүдә яңа алымнар, яңа интонация, яңа чаралар барлыкка килә. Шулардан иң характерлысы — уртак сөйләм. Татар әдәбиятында уртак сөйләм турында беренче башлап фикерләр әйтүче Х. Р. Курбатов була (Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре. К., 1956).

Уртак сөйләмнең хикәяләүдә барлыкка килүе, беренче чиратта, әдәбиятның үсеше һәм язучының әдәби осталыгы белән бәйләнгән. Галимнәр аны иң катлаулы алымнарның берсе дип бәялиләр һәм аны бары тик тирән психологик һәм әдәби талантка ия булган язучылар гына куллана ала[1] дип исәплиләр. Уртак сөйләм — проза үсешендә зур казаныш. Аның барлыкка килүе рус әдәбиятында А. С. Пушкин исеме, камилләшүе — М. Ю. Лермонтов, Н. В. Гоголь, И. С. Тургенев, А. П. Чехов, Л. Н. Толстой исемнәре белән бәйле булса, татар әдәбиятында да аның беренче чаткылары прозаның өлгергән чорына карый.

Уртак сөйләм — туры сөйләмнең механик рәвештә автор сөйләменә күчүе генә түгел. Бу — бөтенләй яңа күренеш, монда автор белән персонажның карашлары туры килә, автор персонаж булып уйлый, фикер йөртә башлый. Уртак сөйләмнең татар әдәбиятына үтеп керә башлавы беренче проза әсәрләрендә үк күзәтелә. Ләкин бу бик аз, аның чикләрен билгеләү дә бик кыен. Мәсәлән, З. Бигиевның «Гөнаһы кәбаир» романында автор Җиһангир белән бергә борчылырга җөрьәт итә:

«Җиһангир әфәнде тугры хатыны Маһруйның бүлмәсенә керде — **буш! Хатыны юк!..** Икенче бүлмәгә кергәч, кызы Фәридәне күрде...» Р. Фәхретдиновның «Әсма» сында да уртак сөйләмгә тартым күчеш сизелеп куя: «Кесәләргә кул тәкрар кереп чыкты исә дә, һәр дәфгасендә буш чыкты!.. **Ак!.. Акча юк!.. Алмышлар!.. Акча җирендә җилләр исеп торыр!..** Муса акчасыны аннан карады, боннан эзләде, сорады, ялынды, аглады, юк, табылмады».

Ш. Мөхәммәдовның «Япон сугышы яхут доброволец Батыргали агай» повесте татар прозасы үсешендә үзенчәлекле урын алып тора. Дидактик прозадан сәнгатьчән прозага күчүне бу әсәрдә шактый ачык сизмәләргә була. Повестьта инде авторның ирониясен, героена мөнәсәбәтен белдерә торган, шул ук вакытта персонаж белән бер аваздан әйтелгән сөйләм кисәкләре күренә башлый. Уртак сөйләм Ш. Камал, Ф. Әмирхан әсәрләрендә хикәяләүдә махсус алым буларак өлгереп җитеп, персонажларның уй-хисләрен, кичерешләрен сурәтләүдә гаять оста һәм матур кулланыла башлый. «Городовойның китмәвенә Муса борчыла башлады. **Ни өчен городовой утыра, ни өчен китми! Каравылчы китте, бу һаман утыра... Юкса ул Мусаны җинаятьче дип белеп тә юри шаярып кына белмәгән төсле кыланамы әллә!** Муса мөмкин кадәр аның белән күзгә күз караудан кача иде, гүя Муса аның күзенә караса, ул кинәт көлеп җибәрә һәм Мусаның күзенә карап: «Ничек хатыныңны изә алдың? Егет! Афәрин!» дип мыскыллаячак иде...

**Ни өчен ул еш-еш сәгатенә карый, кемне көтә икән! Яхшыга түгел бу... Тышта кемнәр булса да булырга кирәк.**

Шул арада тышта шаулап яңгыр ява башлады» (Ш. Камал, «Уяну»).

Ш. Камал әсәрләре өчен хикәяләүнең 3 нче заттан алып барылуы хас, ә мондый хикәяләүдә автор һәм персонаж сөйләме шактый кискен аерылып тора һәм уртак сөйләмне куллануның мөмкинлекләре арта. Ш. Камал бу алымны хикәяләү үзенчәлеге дәрәҗәсенә күтәрергә омтылыш ясый («Акчарлаклар», «Таң атканда», «Матур туганда»).

Ф. Әмирханда уртак сөйләм тирән психологик анализ алымы буларак кулланыла. Аеруча «Хәят» повестенда әдип үзенең героинясы белән бергә борчыла, газаплана, шатлана, шикләнә, соклана... Ф. Әмирханның Хәяткә симпатиясе шул хисләр аша сиземләнә: «Бер секунд эчендә уй яңадан эшкә керešте: **чынлап та, Михаилга ни дип җавап бирергә кирәк инде!.. Михаил матур бит. Михаил сөйкемле бит... Ул, ул, ул бик сөйкемле, бик чибәр бит. Аның калынрак кына кашлары, матур гына итеп карый торган коңгырт күзләре... тагын ал-**

**лә кайсы төшләре бик килешле бит»** («Хәят»).

Г. Ибраһимов әсәрләрендә уртак сөйләм еш кына эчке монологка күчеп китә, аның белән тыгыз үрелеп бара. Шулай да Г. Ибраһимовта хикәяләү алымы буларак уртак сөйләм зур үсеш алып китә алмый. Моның бер сәбәбе — байтак әсәрләренең I нче зат исеменнән язылуы булса, икенче сәбәбе Г. Ибраһимовның хикәяләүдә эпиклыкка, салмаклыкка омтылуы белән аңлатыла.

30—40 еллар әдәбиятында уртак сөйләм сизелерлек үсеп китә алмаса да, язучылар вакыт-вакыт аңа мөрәҗәгать итәләр, «күңел хәрәкәте», эчке кичерешләрне укучылар дулкынланырлык итеп сурәтләүгә омтылалар. Ә инде 50 еллар әдәбиятында уртак сөйләм хикәяләүдә күпләп кулланыла башлый. И. Гази, К. Нәҗми, М. Әмир, Г. Бәширов әсәрләре уртак сөйләмгә шактый бай. Күбесенчә ул уңай геройларның характер бөтенлеген, матур хисләрен, уйларын, борчуларын ачарга ярдәм итә: «Нәфисә, толым очларын бер сүтеп, бер үрә-үрә, зур коңгырт күзләре белән апачык һәм тыныч кына итеп әнисенә карап тора...

**Юк, Нәфисә үзендә һичбер гаеп сизми. Аның вөҗданы пакь, аның Газиз исәлегенә янсә үз намусына тузан кадәр дә күләгә төшергәне юк! Һич!** (Г. Бәширов. «Намус»).

Хикәяләүдә төп алымнарның берсе булып, уртак сөйләм 60—70 еллар прозасының характерлы үзенчәлегенә әйләнә. Уртак сөйләм геройның эчке дөньясын сөйләп кенә калмый, бер персонажны икенче персонаж аша тасвирлау, үзхарактеристика бирү, табигать күренешләрен герой аңы аша чагылдыру, геройларның иҗтимагый, рухи, әхлакый йөзен ачу кебек функцияләрне тагын да киңрәк үти башлый.

Соңгы вакытта хәзерге татар әдәбиятындагы психологик анализ турында күп языла. Әмма галимнәр шушы психологизмны тәэмин итүче чаралар рәтеннән ни өчендер уртак сөйләмгә игътибар итмиләр. Уртак сөйләмне хикәяләү алымы буларак кулланган әдипләр арасында иң башлап Ә. Еникине күрсәтергә кирәк. Әдип катлаулы чынбарлыкны кеше аңында бөтен тулылыгы, каршылыклы булуы, төгәллеге белән күрсәтә. Кеше күңеленең иң тирән почмакларына кереп, аның эчке дөньясындагы каршылыклы уйлар, хисләр көрәшен сурәтли. Аерым әсәрләрендә уртак сөйләм тоташ бер агым булып бара. «Рәхмәт, иптәшләр», «Рәшә», «Әйтелмәгән васыять» әсәрләрендә бу үзенчәлек аеруча күзгә ташлана. «Рәшә» повестенда автор хикәяләүне шушы юл белән алып бара диярлек. Түбән җанлы, бөтен тормышын исәпкә корган, нинди генә шартларда да тормышка җайлашып яши торган мещанны автор үзеннән-үзе кыйната. Әгәр Ә. Еники үзе сөйләсә, автор исеменнән «ул болай», «ул тегеләй» дип күрсәтә-күрсәтә хикәяләүгә күчсә, «Рәшә»нең эчке ирониясеннән нәрсә калыр иде икән? «Бер дә гаҗәп түгел, чөнки Зөфәр болай **өстән караганда**, әйбәт кеше иде, аннары, **кирәксә**, гомумән ул үзен иң уңай яктан күрсәтә дә белә иде. Рәхим ит, ул игътибарлы да, ачык йөзле дә, йомшак телле дә, тыйнак, сабыр да, кыскасы — милый человек!» Менә шушы «милый человек»ның бөтен акылын, җанын биләп алган рухи ярлылыгын Ә. Еники аның үз авызыннан диярлек үк фаш иттерә. Уртак сөйләмгә корылган бу хикәяләүдә я автор фикерләре, я Зөфәр фикерләре өстенрәк тора, әмма интуитив рәвештә әсәрнең буеннан-буена шушы уртак сөйләм эченнән авторның үз героена мөнәсәбәтен сизеп торасың: яратмый ул аны, өнәми, вакыты белән күрә алмый... Авторның бәясе, мөнәсәбәте күзгә бәрелеп тормый, гадәттә иң кечкенә бер сурәтне барлыкка китерә торган сүзнең мәгънәсенә өстәп бирелә бара. Кызык хәл, уртак сөйләм бары тик Зөфәр — автор сөйләменнән генә оеша; Рәшидә — автор, Таибә абыстай — автор, карт — автор һ. б. уртак сөйләмне табу мөмкин түгел. Ә башка язучыларда күп планлы хикәяләү белән бергә һәр персонаж янында автор бар, алар бергә сөйлиләр. «Рәшә»дәге уртак сөйләмнең мондый үзенчәлеген искә алып бетермәү кайбер аңлашылмаучылык, төрлечә фикерләр туура сәбәп булды, күрәсең. Бу Ә. Еникинең хикәяләү үзенчәлеген билгели торган күренештер, чөнки «Әйтелмәгән васыять», «Рәхмәт, иптәшләр!» әсәрләрендә дә шундый хәл өстенлек итә.

Хәзерге проза әсәрләрендә кагыйдә буларак күп геройлар катнаша. Бу хәл прозаның үз чиратында күп тавышлы булуын китереп чыгара. Һәрберсенең үз интонациясе, үз авазы, үз теле бар. Шуларда характер үзенчәлекләре дә чагыла. Шулар янында автор да күзәтеп тора. Герой һәм авторның бер-берсенә бик якынлашуы Ф. Хөсни хикәяләвендәге уртак сөйләм аша аеруча калку күренә. Уртак сөйләм хикәяләүгә лирик җылылык, самими юмор алып керә. Ф. Хөсни үзенә генә хас җорлык белән героеның йомшак ягын табып, дусларча «кытыклап» ала, вакыты белән шактый каты бәрелеп, бөтенләй юкка чыгарып ташлый. Автор белән геройның үзара шулай якынлыгы укучыларда дусларча ышану атмосферасы тудыра, хикәяләүнең табигыйлеген арттыра.

Кайбер язучылар һәр герой янында булырга тырышалар. Хикәяләү бер персонаждан икенче персонажга күчә икән, автор да шуның янына күчеп, аның белән бергә уйлый, фикер йөртә башлый. М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар»ын алыйк. Дөрес, авторның иң яратып сурәтләгән, үзенең иң әһәмиятле фикерләрен тапшырган герое — Рушад. Автор күбрәк шуның янында. Ләкин Нәркискә күчсә — аның белән, директор хатыны Гөлчирәгә күчсә — аның белән, Ләйләгөлгә килсә — аның белән бергә сөйли. Кыскасы, авторның һәр герое янына ашыгып-ашыгып күчүе хикәяләүне ышандырырлык дәрәҗәдә самими, табигый итә. Автор Рушад белән сөйли: «Рушад нишләргә дә белмәде. Моңарчы бу кызның язмышы, хисләре белән үз күңелендә җи-

ңелчә генә шаярып йөрүе аңа җинаять булып тоелды. **Юк, бу кыз иң бөек мәхәббәткә лаек! Шекспирлар, Тургеневлар язган туры, пакь, бөек хисләргә генә лаек бу! Ә син үзеңнең тупас ботинкаларың белән басып кереп, аның хисләре белән исәпләшмичә, шәхесен рәнҗеткәнсең. Янәсе, син авыл егете, син гади матрос, ә бу — профессор кызы. Янәсе, син дөньяда барын да күргән кеше, ә бу кызыйның ал да гөл».**

Автор Нәркис сүзләренә, уйларына телəктәш булып сөйли: «Бу драма әле өенче көн генә узды...

**Еларга, еларга иде хәзер, күз яшьләрең дәрья булып бөтен хәсрәтеңне алып киткән иде. Шул дәрьяда үзең дә йөзеп китнең, тыныч, кешесез яр буена чыгыең. Юк, анда бер генә кеше булсын иде — ул сиңа елмаеп кулын бирәп торсын иде. Мәсәлән, кем! Рушад! Әйе, әйе, шул булсын иде!..**

Нәркис капка баганасына сөялде. Башы әйләнеп китте. Урамнан Рушад килә иде».

Уртак сөйләмдә персонажның индивидуаль сөйләм үзенчәлекләре, иҗтимагый йөзе чагылыш таба: **«Кызлар, күзләрен елтыратып, әбиләренә карап тора башладылар. Шушы икән инде ул папаларына мама тиешле әби-карчык! Үзе кечкенә, үзе арык, өстенә киң җиңле әкәмәт кенә күлмәк кигән, башына вак чәчәкле сары яулык бәйләгән, в общем, типичная башкирка икән!»** (Ә. Еники. «Әйтелмәгән васыять»).

Уртак сөйләм хикәяләүдә фальшька урын калдырмый. Бу алым белән язган әдип үз героен ахыргача белергә, андагы күңел тибрәнешләренең иң нечкәсен дә тоярга, фикерләренең каршылыклы бөтенлеген бирә белергә тиеш була. Ә болай язу җиңел түгел. И. Газиның «Онытылмас еллар», «Тургай картаямы икән?», Ә. Еникинең «Тәнге тамчылар», «Туган туфрак», «Әйтелмәгән васыять», Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым», М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар», Х. Хәйруллинның «Картлык... кемгә шатлык» һ. б. әсәрләрдә хикәяләү уртак сөйләмгә корылган диярлек. Мондый хикәяләүдә ихлас күңеллелек өстенлек итә. Укучы шушы күңел тибрәнешләренә ышанырмы? Күңелендәгене әйтеп бетереп булырмы? Саф грамматик яктан әйтеп бетермәгән, тәмамланмаган җөмләләр күп очраса да, уртак сөйләм тулган күңелләрне бушатырдай алым икән. И. Газиның «Тургай картаямы икән?» исемле гаҗәеп матур, самими хикәясендә Шәйхаттар бабай белән бергә автор да сөйли, әмма өстенлек бабайга бирелгән. Бабай белән бергә автор яшьлеген юксына, сөйгәнен сагына, кавыша алмавына үкенә: «Бүген Шәйхаттарның күңеле нишләптер гел егет чагына кайтып төшә дә тора. Кояш та бүтән иде дип әйтерләр ди картлар. **Юк, кояш шушы ук иде, тургайлар да шушылар ук, сандугачлар да... Гөлҗиһан белән булды, һай булды... Әнә тегә йөгереп үтеп баручы кызчык та картаермы икән! Аны да сөячәкләр бит инде, аны да кочакка кысачаклар. Кояш күрмәс, бәлки, ә ай күреп торыр. Ай дигәнең Гөлҗиһан белән Шәйхаттарны да гел күреп торды... Ай белән тургай картаймый, алар гел булачак, ә менә Шәйхаттар юк инде, Гөлҗиһан да юк, бик күптән юк... Тегә, йортлары мәктәп катындагы Гөлҗиһан карчык дисеңме! Сүз ул бетешкән карчык хакында түгел. Юк, бөтенләй башка Гөлҗиһан...».**

Уртак сөйләм автор хикәяләве белән чиратлашып барырга да мөмкин. Бу чылбыр шундый катлаулы, хәтта кайда бетеп, кайда башлануын да билгеләп өлгереп булмый:

«Килсә, винтовкасына таянып, часовой, шакаеп басып тора. **Чыктың, пычагым, болай булгач!** Чигенеп, тимер мичкәләр артына сеңде. **Ни заман туктамыйча килгән пароход тикмәгә генә туктамагандыр, бушатасы я төясе нәрсәсе бардыр. Менә шул вакыт кешеләргә буталып чыгып китеп булмасмы!**

Аркаларына ящиклар күтәргән грузчиклар, пароходка кереп, йөкләрен идәнгә ларк-лорк иттереп салдылар» (И. Гази. «Онытылмас еллар»).

Уртак сөйләмне ничек аерырга соң? Х. Курбатов күрсәтүенчә, уртак сөйләмдә персонаж сөйләме күбрәк өенче зат формасындагы зат алмашлыклары, затланышлы фигыльләр ярдәмендә бирелә. Өндәү һәм сораулар күп кулланыла, ымлыклар, эмоциональ сүзләр, күрсәтү алмашлыклары, кереш сүзләр хикәяләүдә уртак сөйләмгә күчү турында сигнал бирәләр [1]. Болардан тыш та уртак сөйләм башлануын хәбәр итүче тел чаралары бар. Шуларның иң характерлыларына тукталып үтик.

Уртак сөйләмгә күчү атау җөмләләр, күзаллаулы баш килешле әйләнмәләр, тойгылы, сорау җөмләләрдән башлана. «Сәләмә малайның якынаюын күргәч, матур күзле апай әйберләрен үзенә табарак тартып куйды. Ботинеке төсле матур, сөйкемле күзләре, куркынып, Хәлимгә төбәлде.

**И, буржуй дисәң буржуй, малы өчен калтырана** (И. Гази. «Онытылмас еллар»).

«Ә Гөлзифаның йолдызы һаман яктырыпяктырып җемелди, каядыр өнди, каядыр чакыра. **Кая өнди, кая чакыра икән ул! Нәрсәләр вәгъдә итә икән! Белсәң иде...»** (Р. Төхфәтуллин. «Йолдызым»).

Автор хикәяләве тәмамланып, уртак сөйләм башлануны кереш сүзләр, **әйе, юк**, кебек модаль сүзләр, **әнә, менә** кебек ишарә сүзләре хәбәр итәләр: «Уйлана торгач, бу гаделсезлекнең дә очы кайда яшеренеп ятканын тапкан кебек булды: **кара әле, нишләп соң хатын-кызга имана җирә бирмиләр икән! Хатын-кыз да ике аяклы, ике куллы лабаса!** (Ф. Хөсни. «Гыйльмениса»)

«Карана торгач, таныды бит Гаяз. **Әнә кайчандыр үзе укып йөргән мәктәп иске урынында тора. Түбә калайлары тутыккан, тәрәзәләрендә фанера...** (И. Гази. «Алмагачлар чәчәк ата»).

Персонажның каршылыклы уй-фикерләрен белдергән очракта уртак сөйләм каршы куючы теркәгечләр кергән тойгылы өн-

---

[1] Х. Курбатов. Күрсәтелгән хезмәт. 156 бит.

дәү һәм сорау җөмләләр белән башланып китә: «Әгәр бүгеннән ферманы ташласа, мәсьәлә тирәнгә китәчәк, каш ясыйм дип күз чыгаруың бар.

**Ләкин... хурлык бит, хурлык! Бар да сине сүксеннәр, бар да сине гаепләсеннәр! Бар да хаклы, тик син бер үзең гаепле! Ничек бу болай!..** (Ә. Еники. «Рәхмәт, иптәшләр!»)

Уртак сөйләмнең хикәяләүгә килеп керүе фигыльләрдә зат, заман, наклонение һәм юнәлеш формаларының кинәт үзгәреп китү юлы белән дә булырга мөмкин: «Күзләре караңгыга ияләшкәч, Хәлим зур-зур корылмаларны аера башлады. **Өйләр дисәң, тәрәзәләре юк, амбарлар дисәң, шундый коточкыч озын амбарлар була микәнни! Малик козгын әнә нинди бай да, аның амбары болар янында чебеш кенә.** (И. Гази. «Онытылмас еллар».)

Уртак сөйләмгә күчеш инверсия белән төзелгән җөмләләрдән башланырга яисә керешмәләр рәвешендә дә килеп керергә мөмкин: «Тарихта Рушадка «Боз өсте сугышы» эләкте — анысын чатлатып сөйләде, тик каушаудан «ухо» сүзен күплек санда «ухи», «принес» сүзенә — «принесел» дип **[янәсе, хатын-кыз булса, принесла бит!]** әйтеп кенә имтихан алучының көлүенә сәбәп булды» (М. Мәһдиев. «Фронтовиклар»).

Хикәяләүдә уртак сөйләмнең күләме төрлечә булырга мөмкин. Уртак сөйләм аерым бер сүздән дә, сүзтезмәләрдән дә, бер җөмләдән дә, бер абзацтан да, берничә абзацтан да тора ала.

Уртак сөйләмдә автор хикәяли, ләкин персонаж исеменнән хикәяли. Менә шуңа күрә дә персонажның бар хисләре, уе, шиге, борчуы, шатлык-газапларын бирү өчен уртак сөйләм гаять кулай булып чыга. Бу хисләр гаммасы телдә тойгылы, сорау һәм гомумән эмоциональ җөмләләр белән тәгъбир ителә. Менә шуңа күрә дә уртак сөйләм составында сорау һәм тойгылы җөмләләрнең саны, роле гаять зур. Автор хикәяләве гадәттә эпик интонация белән бара. Менә шушы салмак, әкрен генә барган уңайга бөтен хисләр тулылыгы, дулкынландыргыч интонация белән уртак сөйләм килеп керә. Бу ритмик-интонацион каршы куелыш шактый күләмле җөмләләрдән гыйбарәт булган автор хикәяләвеннән соң кулланылган кыска, тыгыз, тойгыга бай җөмләләр белән чиратлашудан да барлыкка килә: «Асылның иңенә җылы тунын салып, кукрайган әтәч кебек басып торуы гына яңартты бу истәлекләрне.

**Шул контр, шул иблис синнән көлсен әле, синнән генә түгел, эшләгән эшеңнән көлсен... Ни ди бит, «Киндерби» ди бит, ә! Ул куана, рәхәтләнеп көлә инде моннан. Юк, көлми тор әле!** Тамак ялгарга кайтканда да Хәсән карт һаман Асылны сүкте, аның белән бәхәсләште (Х. Хәйруллин. «Картлык.. кемгә шатлык»).

Хәзерге вакытта психологлар, физиологлар һәм телчеләр тарафыннан өйрәнелә торган эчке сөйләм XX гасыр прозасында аеруча зур урын алып тора. Язучылар укучыны геройның эчке дөньясы ташкынына кертеп җибәреп, ниндидер комментарийлар бирүдән баш тарталар. Татар филологиясендә эчке монологлар турында аерым фикерләр бар. Иң беренче чиратта аны Г. Ибраһимов әсәрләренә [1] бәйле рәвештә тикшерәләр.

Эчке монологны уртак сөйләм белән тәңгәлләштерү дә, аерым карау да очрый. Һәр икесе геройның эчке дөньясын сурәтләү чарасы буларак кулланылса да, алар арасында тәзелеше һәм контекстуаль чараларның янәшәлеге ягыннан шактый аерма күрергә мөмкин.

Эчке монолог — ул саф персонаж сөйләме, туры сөйләм. Авторның ул сөйләмгә карата мөнәсәбәте аерым комментарийларда гына белдерелә ала. Ә уртак сөйләмдә бер үк вакытта персонаж да, автор да сөйли. Уртак сөйләм персонаж сөйләменә карата авторның үз мөнәсәбәтен дә белдерергә мөмкинлек бирә. Эчке монологта зат алмашлыклары, фигыль-хәбәрләр — беренче затта, ә уртак сөйләмдә— күбесенчә, өченче затта була. Эчке монолог гаять зур эмоциональлеккә ия, кинәт һәм тиз әйтелгән фикерләрдән тора. Уртак сөйләм үзенең табигате белән эчке монологка караганда салмаграк, тынычрак. Эчке монолог, күбесенчә, төбәп әйтүне, эндәшүне күз алдында тотканга, эндәш сүзләр күп кулланыла. Уртак сөйләмдә алар очрамый.

Эчке монолог, гадәттә, уңай геройлар авызыннан әйттерелә. Аеруча авыр хәлдә калган, җитди сынаулар алдында торган геройлар эчке монологка мөрәҗәгать итәләр. Эчке монологта аларның рухи сыйфатлары ачыла. Шунысы кызык, авторның симпатиясе булмаган геройларның эчке монологы очрамый. Кире геройларны рухи тормыштан мәхрүм итүендә үк инде авторның бу геройга кире мөнәсәбәте күренә.

Эчке монолог хәзерге прозада психологик анализ алымы буларак, хикәяләүдә еш файдаланыла. I нче зат исеменнән язылган әсәрләрдә эчке монолог ташкын булып, бер агым булып бара. 3 нче зат исеменнән язылган әсәрләрдә аның роле, уртак сөйләм һәм диалоглар зур урын алу сәбәпле, сизелерлек дәрәҗәдә кими.

Җыеп әйткәндә, уртак сөйләм ярдәмендә персонажның эчке кичерешләре, уйтойгылары бирелә, психологик анализ ясала; персонажның характеры, дөньяга карашы ачыла; ул авторның персонажга карата мөнәсәбәтен ироник, юмористик, симпатик һәм антипатик тоннарда, яшеренрәк төстә белдерергә мөмкинлек бирә; аңарда персонажның иҗтимагый, әхлакый, рухи йөзе һәм индивидуаль сөйләм үзенчәлекләре чагыла; хикәяләү стиленә эмоциональлек, интонацион төрлелек биреп, аны монотонлыктан коткара.

Уртак сөйләмнең табигатенә килгәндә, аны хикәяләүдәге үзенчәлекле алым дип бәяләү дөресрәк булыр. Башка синтаксик берәмлекләрдән аермалы буларак, уртак сөйләмнең модельләрен билгеләү кыен,

[1] М. Х. Хәсәнов. Галимҗан Ибраһимов. Казан, 1964.

ул — әсәрнең эчтәлегеннән, хикәяләүдән, контексттан чыгып билгеләнә. Уртак сөйләмнең төп билгесен хикәяләүнең ике планлы булуы, ягъни автор һәм персонаж сөйләмнәренең берләшүе тәшкил итә. Хәзерге проза текстының тел ягыннан оешуында актуаль тип буларак уртак сөйләм хикәяләүдә һаман да зуррак урын били бара. Хәзерге дөнья әдәбиятына хас «аң ташкыны» («поток сознания»), уртак сөйләм һәм эчке монологка нигезләнгән хәлдә, татар әдәбиятына да киң күләмдә үтеп керә. Бу бигрәк тә Ә. Еники, И. Гази, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев һ. б. хикәяләрендә ачык чагыла.

Еш кына хәзерге проза әсәренең стилистикасында төрле характердагы катламнар ачылып, алар үзара керәшәләр. Аерым әсәрләрдә авторның 3 нче заттан хикәяләве өстенлек итеп, персонажларның диалоглар ярдәмендә бер-берсенең характерын, вакыйгаларны ачыклавы икенче урында тора. Уртак сөйләмгә чагыштырмача аз урын бирелә. Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, Г. Ахунов, Ш. Маннур, А. Расих, Н. Фәттахлар өчен хас алым бу. Кайчак әдәби әсәр буеннан буена диярлек уртак сөйләмгә корылып, бәйләүче звенолар кебек кенә автор хикәяләве килеп керә. Мондый стилистика Ә. Еникинең күп кенә әсәрләрендә күзәтелә. Ә кайбер әсәрләрдә авторның 3 нче заттан, яисә I нче заттан хикәяләве бәйләүче звено булып, әсәрдәге вакыйгалар һәм характерлар үстерелешен диалоглар алып бара. Мондый хикәяләүне А. Гыйләҗев яратып куллана кебек. Ә кайчак автор хикәяләвендә үз персонажларына гаять якын торган, аларның һәрберсен үзенчә яратып елмая торган лирик герой да чагылып китә. Монысы — М. Мәһдиев хикәяләвенә тартым күренеш.

Хәзерге әдәбияттагы хикәяләү бөтенләй яңа төрле фразаны — спонтан, табигый фразаны китереп чыгарды. Фикер — туган хәлендә теркәлә. Грамматик һәм логик яктан гаять камил, әдәби яктан эшкәртелгән, образлы, нәфис фразалар белән беррәттән, фикер формалашкан чагында теркәлгән фразалар зур урын алып торалар. Ә алар, күбесенчә, уртак сөйләмгә күчкән чакта сизелерлек күп кулланылалар. Берничә мисал китерик: «Диванда елап утырган әнисен күргәч, Хәбир аптырап калды. Ник елый ул? Ә баш шаулый. Ох, шаулый! Нәкъ поезд баргандагы кебек. Поезд. Новосибирск поезды... Ә ул поездда Мәдинә. Ире янына бара. Әхмәт исемле лейтенант. Аһ, Мәдинә! Тереләй утка салдың бит син... Суйдың, үтердең... (Ш. Хөсәенов. «Мәхәббәт сагышы».)

«... без тып-тын урман аланыннан атлап киттек. Тукталгач, кыз башын иде дә... таш сын шикелле, даһи художник әсәре шикелле тып-тын калды. Әллә елый... Болай күпме торырга мөмкин? Мин аны кызганып башыннан сыйпаган идем, ул күкрәгемә сыенды да — әллә бәхет, әллә оят белән җанымны көйдереп — әллә чәчләре ут идеме?! — һушымны айкап ташлады. һәм... мин аны кочакларга мәҗбүр булдым. Юк, ялганламыйм, мәҗбүр түгел, кочаклау бәхетенә лаек... Ә ул, шуны гына көткәндәй, бөтен зиһенемне кочакларына бөтереп, июль көне кебек эссе иреннәре белән кагылды. Бу иреннәр, бу кайнар иреннәр, бу кайнар үбү — миңа таныш... Мин аны кабул иттем. Әйе, әйе, бу — Наташа үбүе! Бу — Наташа!» (Ә. Баянов. «Дүрт монолог».)

«Ерагайды торналар, тавышлары ишетелми. Мин утырам да утырам... Ничәү булдылар икән?.. Тик аларны санарга ярамый... Санасаң торналар юлларында адашалар... Һәр язда Югары авылга кайтып, бала үстереп китүче үз ягыбыз торналарын без бик яратабыз. Адашмасыннар алар!..» (А. Гыйләҗев. «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят».)

Хәзерге татар прозасында I заттан хикәяләү шактый күп күзәтелә башлады. Г. Ибраһимовның «Яз башы», «Табигать балалары», «Алмачуар», «Кызыл чәчәкләр»еннән килә торган бу алым 60—70 еллар прозасында яңа көч белән тагын кабатлана. Г. Ахуновның «Чиклəвек төше», Н. Фәттахның «Мөдир Сәҗидә», Гөлшаһидәнең «Минем кала алуым», А. Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», Р. Төхфәтуллинның «Җиләкле аланнар», Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим», «Дүрт монолог», В. Нуруллинның «Аккан су юлын табар» повестьлары, олы әдипләребез Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек», Ш. Маннурның «Агымсуларга карап», М. Әмирнең «Малайлыкта кунакта» кебек автобиографик повестьлары, яшьләрдән М. Галиевнең «Карлы абагалар» һ. б. әсәрләрдә хикәяләү I нче заттан алып барыла. Автор-хикәяләүче үзе катнашкан вакыйгаларның эчтәлеген сөйләп кенә калмый, ул шулар эчендә кайнап, үзенең һәм башка геройларның холкы, тормышка мөнәсәбәте, табигате, уйхисләренә аңлатма бирә, аларга билгеле бер әхлакый позицияләрдә торып, үз бәясен белдерә. Мондый хикәяләүдә интонациянең ышандыргыч булуы, үз-үзеңә ирония, үзеңне-үзең укучы алдында ачып салу авторның ихлас булуында шик калдырмый, вакыйгаларның, персонажларның тормышчан, психологик дөрес булуларын китереп чыгара.

Әдәби әсәрләрдә автор — гади хикәяләүче генә түгел. Кайчандыр гаять объектив булган хикәяләүгә авторның тормыш фәлсәфәсе, бик нечкә күзәтүләргә ия гомумиләштерү, шушы авторга гына хас лирик чигенешләр килеп керә. Татар прозасында бу алым бигрәк тә соңгы елларда язылган әсәрләргә карый. Бер яктан, бу— шартлылык, метафорик сурәтләүләр белән бәйле. Җеп очы Г. Ибраһимовка барып тоташа торган бу алым Ә. Баяновның «Ут һәм су», «Төлке тоту кыен түгел», «Тавыш— табигать бүләге», Ә. Гаффарның «Гозер», «Кашан җыры» кебек әсәрләрендә үзәккә куела. Икенче яктан, тормыш фәлсәфәсе теге яки бу вакыйгага, геройларның рухи хәленә бәйле рәвештә хикәяләүгә килеп керә. А. Гыйләҗевның «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары»,

«Фронтовиклар», Ф. Хөснинең «Авыл өстендә йолдызлар» повесте һәм хикәяләре авторның хикәяләүче буларак кына түгел, ә шул вакыйгаларны читтән карап, бәя биреп торучы буларак та актив катнашуы турында сөйлиләр. «Мәхәббәт һәм нәфрәт» турында хикәят»нең башламында ук автор ни өчен бу әсәрне язу сәбәпләрен сөйли. М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар»ында ике автор бар кебек. Аның берсе — хикәяләүче, вакыйгаларны бөтен дереслеге белән тасвирлаучы. Аның белән янәшә икенче автор — гаять тә нечкә лирик, юморист, сизгер, аңгәмәдәш, үз геройларын бераз гына өстән карап мыек астыннан гына елмаеп тора. Әйдә әле, нишләрсең икән? ди кебек.

Хәзерге әдәбиятның хикәяләү үзенчәлекләреннән тагын берсе — аның диологик характеры. Өченче заттан хикәяләүдә дә, беренче заттан хикәяләүдә дә диалогның роле һәм күләме гаять зур. Геройларның рухи, мораль йөзен ачуда, карашлар, фикерләр бәрелешен күрсәтүдә, персонажларның сөйләм үзенчәлеген бирүдә, әсәрнең сюжетын һәм композициясен төзүдә диалогның дәрәҗәсе хәзерге прозада һаман арта бара. Диалог җанлы сөйләмдәге кебек табигый, ул кыска-кыска репликалардан гыйбарәт. Менә А. Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар» хикәясеннән Әдилә һәм Ибраһим диалогы үзләре кебек үк самими:

— Әллә оныттыңмы? — дип сорады ул кинәт.

— Нәрсәне, Әдилә?

— Оныткан, икмәктер, оныткан!

— Әйт инде!

— Минем чәчне тартып китүеңне! Яңагыңа чалтыратуым хәтереңдәме?.. Әллә син башка кызларның да чәчен тарта идеңме?

— Онытмадым, Әдилә! Башкаларныкын тарткан булмады, кояштыр!

— Сөям диган ымың түгел идемени ул, Ибраһим!

— Ай-һай, каты чәпегән идең яңакка!

— Онытырлык булмасын дидем, Ибраһим... Егетләрнең хәтер кыска була бит аларның...»

Дөрес, диалогны хикәяләү алымы буларак куллану төрле язучыларда төрле дәрәҗәдә. Кайбер язучыларда авторның өченче заттан хикәяләве күләм ягыннан өстенлек итә. Диалоглар, автор сүзләре арасына килеп кереп, салмак, эпик хикәяләүгә әлләни зыян китермиләр. Г. Бәширов, К. Нәҗми, Г. Минский, Г. Ахунов, А. Расих һ. б. әсәрләрендә шундый хикәяләү сизелә. Аерым язучылар диалогны хикәяләүдә төп алым буларак кулланалар. А. Гыйләҗевның «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим», М. Хәбибуллинның «Чоңгыллар», Н. Фәттахның «Мөдир Саҗидә» һ. б. шундый алым күзәтелә.

Җитлеккән әдәбият формалар, стильләр, алымнар төрлелеген күпсенми. Шулай булырга тиеш тә. Әдәбият һаман бер төрле генә язучылардан торса, аның ни кызыгы булыр иде икән?! Язучының хикәяләү үзенчәлеге аның талантына, осталыгына, әдәби-эстетик зәвыкларына, эрудициясенә дә бәйле. Заман үзгәрә, татар укучысы да дөнья әдәбияты белән таныш, рус әдәбиятының да иң матур, талантлы үрнәкләрен оригиналда укый. Мондый укучы татар язучыларының да шундый югарылыкта язылган әсәрләренә мохтаҗ. Аның да **заманча** теманы **заманча** югарылыкта, **заманча** формалар белән сурәтләгән әсәрләрне укыйсы килә. Хәзерге укучы **заманча** хикәяләүне дә көтә, билгеле. Г. Ибраһимов, Ш. Камаллардан килгән эпик, салмак, традицион хикәяләүне һич тә кире какмыйча, аның белән янәшә хәзерге проза әсәрләренең күбесенчә хас булган динамизм, кыскалык, экспрессивлык, фәлсәфи башлангычның артуын күрми калу яисә күрмәскә тырышу беркатлылык булыр иде.

Гомумән, хәзерге татар әдәбиятында хикәяләү сыйфат ягыннан үсте, яңа үзенчәлекләр белән баетылды: прозада лаконизм көчәеп китте, 3 нче заттан хикәяләү белән бер үк дәрәҗәдә 1 нче заттан хикәяләү зур урын алды (ә бу, үз чиратында, сөйләм әйләнмәләрен күбрәк куллануны, димәк, интонация үзгәрешен китереп чыгарды), уртак сөйләм, чит сөйләмнең бер төре булудан бигрәк, хикәяләү алымы буларак кулланыла башлады. Әсәрләрнең подтекст катламы сизелерлек көчәйде, автор фәлсәфәсе ныклы урын алды. Җанлы сөйләм теленнән күпләп кергән әйләнмәләр, автор хикәяләвендә дә еш кулланылып, хикәяләүнең динамик, тыгыз эмоциональ характерын билгеләделәр. Хәзерге әдәбиятка хас бу гомуми сыйфатлар һәр язучы әсәрендә үзенчә чагылыш таба, һәм әдәбиятыбызда хикәяләү алымнарының төрлелеге һәм заманчалыгы нәкъ менә шулар белән билгеләнә.

# ОЛЫ ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ҖИТДИ ХЕЗМӘТ

Китапның тышлыгында ике исем: Рафаэль Мостафин һәм Сибгат Хәким. Әдәбиятта, гомумән рухи тормышыбыз елъязмасында яхшы мәгълүм исемнәр. Галим-язучы (журналист-язучы дисәк тә дөреслеккә туры килә) Рафаэль Мостафин шагыйрь Сибгат ага Хәким турында, аның тормышы һәм иҗат юлы турында китап язды һәм аны Мәскәүдә, «Советская Россия» нәшриятында «Совет Россиясе язучылары» сериясендә бастырып чыгарды.

Сибгат Хәким — телдә күп тибрәнгән, язуга күп төшкән исем. Сугыштан соңгы 30—35 ел эчендә аның иҗатын гел уңай яктан гына диярлек бәяләгән күп дистә мәкаләләр чыкты. Без бу хәлгә — уңай бәяләргә күнектек тә шикелле инде. 1971 елны шундый мәкалә-чыгышларны берләштергән, «Сибгат Хәким» дигән библиографик характердагы бер китап Казанда да басылып чыккан иде. Аның авторлар саны шактый ишле һәм төрле булып, китапның рухы үзгә һәм стиле дә төрлечәрәк иде. Ә бусының авторы бер, язылу вакыты да шактый ук конкрет. Тагын шунысы бар: үз Казаныңда татарча чыккан китапны үз өендәчәрәк, үзең телгән таныш укучыларың белән бергәрәк торып һәм гомум уртак югарылыктан чыгыбрак укыйсың, хөкем итәсең. Ә инде бүтән телдә, бу очракта рус телендә чыккан хезмәт, аның таралу сферасын һәм укучылар контингентын истә тотып булса кирәк, бераз бүтәнчәрәк язылган. Ирексездән чагыштырасың, башка әдәбиятлардагы хәлләр белән аналогия үткәрәсең һәм... әйтергә кирәк, үз әдәбиятыңдагы теге яки бу күренешне объективрак бәяли башлыйсың.

«Йөзгә йөз торганда чын йөзне күрмәссең» дигәнрәк бер тәгъбир бар. Р. Мостафинның бу китабы белән танышкач, шул әйтем искә төште. Чыннан да, үземне Сибгат аганы, аның тормыш юлын, иҗатын шактый ук яхшы (заманында аның турында матбугатта мәкаләләр белән дә чыккан булды) беләм дип йөри идем. Юк, алай түгел икән! Ул — катлаулырак, тирәнрәк, бүтәнрәк икән! Китап биргән беренче тойгы әнә шул булды. Бу әле бергә-бергә иҗат иткән, бер Казанда бергә-бергә дөнья көткән каләмдәше алган тойгы. Ә русның һәм бүтән халыкларның киң катлау укучыларының байтагы өчен, Сибгат Хәким дигән шагыйрь бөтенләй үзгә булып, хәтта өр-яңа булып ачылуы да мөмкин бит. Димәк, әлеге тойгының тагын да зуррак һәм тәэсирлерәк булуы бар.

Рафаэль Мостафин — журналист каләмле язучы. Укучының күңелен яхшы тоеп эш итүгә, фикерне ачык һәм җиңел формаларда җиткерә алуга ирешкән язучы. Ул — төпле тәнкыйть мәкаләләре белән беррәттән, документаль нигездә язылган әсәрләр авторы да. Муса Җәлил турында чыккан популяр китаплары, «Экваторлар аша» дигән повесте һ. б. моңа ныклы дәлил. Р. Мостафин — өйрәнеп-белеп яза торган һәм алынган материалына чын мәгънәсендә мөкиббән китеп иҗат итә торган автор. Аның бу сыйфаты «Сибгат Хәким» дигән әлеге монографик китабында да ачык күренә. Автор, хәле җиткән кадәр (әлбәттә, кеше күңеленең бөтен нечкәлекләрен белеп бетерү мөмкин түгел!), шагыйрьне баштан-аяк, әнәсеннән җебенә хәтле өйрәнергә тырышкан. Шагыйрь шәхесенә аның ихтирамы зур, шагыйрь язганның күбесе аның күңеленә хуш һәм якын. Бу хөрмәт хисе һәр абзацта, һәр биттә сизелеп тора. Китап кече күңеллелек белән, зур такт саклап язылган. Автор, шагыйрьнең кайбер әсәрләрен беркадәр тәнкыйть иткән очракта да, йомшак тон сайлап, теге яки бу негативрак күренешнең асылын ачканда, аны, шул заманның рухи атмосферасына бәйләп аңлатырга тырыша.

Китап — кечерәк-кечерәк егерме бер бүлектән тора. Аның һәрберсе аерым уйлану-эссе рәвешендә. Теләсә кайсы бүлекне аерым алып укыганда да билгеле бер төп мәгънә — фикер ачык аңлашыла, өзеклек сизелми. Һәр бүлек — шагыйрь тормышының бер этабын яки иҗатының бер спектраль кырын ачуга багышланган. Автор шагыйрь турындагы төп фикерләрен әнә шулай «төйнәп-төйнәп» бер төзек хикәяләр мәрҗәне тезгән.

Һәр иҗатчының, һәр язучының хакыйки бәясе — аның халык рухына тәэсир итү дәрәҗәсе белән билгеләнә. Халыкта матурлык тойгысын арттыру, фикерләү-үзаңын көчәйтү, көч-дәрманын кешелек куйган идеалларга хезмәт иттерергә юнәлтү... Әлбәттә, мондый миссияне башкарыр өчен әдипкә, талантка ия булу белән бергә, халык-ил тормышының иң үзәгендә тору шарт. Үзенә тигән дәвернең чын мәгънәсендәге замандашы, аваздашы, фикердәше

һәм көрәштәше булу шарт. Хәтта, алай гына түгел, син үз заманыңнан ярты күкрәккә генә булса да, алда да барырга тиешсең әле. Юкса, сиңа иярмәячәкләр. Ә әйдәүче булыр өчен ышанулары кирәк. Ә ышанычны ничек яулыйлар соң? Халык белән булып, аның тормышы белән яшәп, шатлык-кайгысын бергә бүлешеп. Сибгат Хәким исә үз халкының язмышында «эрегән» әдип. Р. Мостафин шагыйрь биографиясенең һәм иҗатының халык тормышыннан аерылгысыз икәнлеген һәм шушы аерылгысызлык, бердәмлек аның яшәү һәм илһам чыганагы икәнлеген бу китабында тагын бер кат раслап күрсәтә.

Сибгат Хәким биографиясе — ул безнең халык вәкиленең, хезмәт иясе баласының соңгы 50—60 ел дәвамындагы биографиясе. Крестьян улы, балачагы һәм яшьлеге авыл табигатендә, киеренке хезмәт атмосферасында үткән, аннан — рабфак, педагогия институты, Ватан сугышы... «Заман белән сөйләшеп яшәргә омтылганмын, — дип язды Сибгат Хәким соңрак үз иҗаты турында, — сөйләшү өчен урын бар: сүз арасына үзенең фаҗигаләре белән сугыш килеп кергән, югалтулар ачысы, түзелеш мәйданнары, яңа буын кешеләре, туган илнең табигате, бәхәсләре, шатлык һәм әрнүләре... Минем өчен иң кирәге — халык рухы. Минем өчен иң авыр, ирешүе иң читен нәрсә — һаман шул тирәдә яткан уйлар... Шуңа кайчан да булса бер ирешергә омтылу хисе яздырта шагыйрьне...»

Кайчан да булса бер ирешү... Халык рухын аңларлык, аңларлык кына түгел, аның җырчысы булырлык шагыйрь дәрәҗәсенә кем, кайчан ирешә! Тукайлар, Такташлар, Җәлилләр бу югарылыкка үсмер чакта ук ирешсәләр, икенче берәүләр, әйтик, Нури Арсланов кебекләр, чәчләре тәмам чаларып беткәч кенә күтәрелә алалар. Бу процессны шәхси теләк яки тырышлык белән генә аңлатып булмый, хикмәт художество талантының үзенчәлегендә. Сибгат Хәкимне дә зур поэзиягә иртә килде дип әйтеп булмый. Беренче юка китапларын утыз яшенә кадәр чыгарса да, чын мәгънәсендәге җитлеккән камил шигырьләр шактый озак еллар үткәч кенә языла башлый. Шуңа күрә дә, шагыйрьнең 1976 елны Казанда чыккан сайланма шигырьләренең бер томлыгында башлангыч 10—15 елдагы иҗаты бик аз күләм тәшкил итә. Кемнәрдер Сибгат Хәкимнең олы шагыйрь булуын «Пар ат»тан саный, кемнәрдер «Суд залыннан» исәпли... Р. Мостафин да Сибгат Хәкимнең иҗат эволюциясенә шактый киң туктала, чагыштырмача озак өлгерүнең сәбәбен ачыкларга тырыша. Китабының бер урынында телдә йөргән мәгълүм караш-теорияне дә искә төшереп үтә: «...иҗатчы өч стадия үтә. Башта ул чынбарлыкны танып белә, күрә, кичерә; аннан ул аларны «оныта», соңыннан — күңеле аша яңадан искә төшерә». Иҗади өлгерүне — беренче күргән, тойган тәэсирләрне яңадан искә төшерү аралыгы белән билгели. Ихтимал, бу карашта да дөреслек бардыр, әмма бүтән төрле сәбәпләрнең булуы да мөмкин. Талантның ачылу хикмәтләрен, судагы балыкның, һавадагы кошның юлын белеп булмаган кебек, аңлатуы авыр нәрсә. Сибгат Хәким иҗатының башлангыч елларында сүлпәнрәк эшләсә, соңгы 20—25 ел эчендә ат кебек эшләде. Бу хакта сүз куерту, зур әдипнең үзеннән бигрәк, бүгенге әдәби хәрәкәттәге яшьрәк кешеләргә карый. Яшьтән ныгытыбрак эшләп калу хәерлерәк бугай. Иртә торсаң — ит пешә, соңлап торсаң — бит пешә, ди халык. Сер түгел бит: дөньяда һәрвакыт ярыш бара. Системалар арасында, илләр-халыклар арасында. Ә инде иҗатта, сәнгатьтә, әдәбиятта, эстетик казанышлар сферасындагы ярыш ул — иң гуман ярыш, кешелекле ярыш. Дөнья — алдан юл ярып баручыларны, «беренче эшелондагы»ларны таный иң әүвәл, аларга соклана, аларны күтәрә. Сибгат Хәкимнең «дөньяда Пушкин бар, Пушкин бар!..» дигән юллары бар. Әйе, дөньяның тагын Лермонтовлары, Петефилары, Тукайлары бар... Шагыйрьнең тагын мондый юллары да бар бит әле: «беренчеләр мине сагындыра, беренчеләр минем истә гел». Кыскасы, әдәбиятка мөмкин кадәр иртәрәк килсәң, заманың өчен күбрәк кирәгең булуы мөмкин.

Китап рус телендә язылып, шул телдә укучылар өчен адресланган булгач, табигый, шагыйрь иҗатының үрнәкләре дә, өзекләр һәм цитаталар рәвешендә, тәрҗемәдә бирелгәннәр. Авторның шагыйрь иҗаты турында әйтергә теләгән күп фикерләре дә әлеге шул тәрҗемә мисаллар белән беркетелеп барыла. Шулай булгач, тәрҗемәнең нинди дәрәҗәдә булуы, бу очракта, ифрат зур роль уйный. Шуңа күрә, китапта Сибгат Хәкимнең тәрҗемә китаплары һәм тәрҗемәчеләре турында аерым бер бүлек булуы бик урынлы. Милли әдәбиятларның үсешен һәм язмышын хәзер тәрҗемә эшеннән башка күз алдына китерү кыен. Тәрҗемә эше — дәүләткүләм әһәмиятле эш. Һәр эшнең асылы сыйфат белән билгеләнә. Тәрҗемәдә дә шулай. Бүтән милләт укучылары күңеленә бәйрәм китерә алырлык байтак поэтик ачышлар, тәрҗемә начар булу сәбәпле, югалып кала. Кагыйдә буларак, тәрҗемә оригиналдан кайтышрак чыга. Бу җәһәттән Сибгат Хәким мисалы шактый гыйбрәтле. Аның тәрҗемә китаплары мисалында бездәге поэзия тәрҗемәсе эшенең гомум торышын, уңай һәм кимчелекле якларын чамаларга була. Беренчедән, С. Хәкимнең бу уңайдан эше бик яхшы бара кебек. Ул, Хәсән Туфан яки Нури Арсланнар кебек, бу эшне үз агымына куйган кеше түгел, тәрҗемәгә нык игътибар биреп русча күп китаплар чыгарган шагыйрь. Русчада чыгару ягыннан аны безнең поэзиядә Тукай, Җәлил, Ерикәйләрнең китаплары саны белән генә чагыштырып була. Исән татар шагыйрьләреннән рус телендә иң күп басылган бердәнбер кеше. 1947—1977 еллар эчендә аның русча егерме китабы чыккан. Шуның сигезе Казанда (Бу урында шуны да искәртеп узасы килә: безнеңчә, тәрҗемә китапларын үзәк нәшриятларда чыгару хәерлерәк. Беренчедән, җирле нәшрияттагы кагазь мөмкинлекләрен ана телендә чыгары-

лырга тиеш китаплар өчен сарыф итү дөрес булса, икенчедән, үзәк нәшриятларда тираж һәм таралу сферасы ягыннан өстенлеге зуррак). Аларның гомуми тиражы — 308 мең чамасы. Шигъри әсәрләр өчен шактый гына саллы сан бу. Ихтимал, тиешле дәрт, җегәр һәм хуплау булганда, мондый «багаж» белән, ил поэзиясе орбитасына гына түгел, ә Рәсүлләр, Кайсыннар, Эдуардаслар, Мостайлар кебек, Европа, дөнья әдәбияты аренасына да чыгу мөмкин булыр иде... Алда әйткәнебезчә, киңрәк даирәгә чыгуда тәрҗемәчеләрнең роле зур. Әлбәттә, авторның үз роле дә бәләкәй түгел: ул тәрҗемәләргә талымсыз карарга, поэзияне кыерсыту хисабына компромиссларга бармаска тиеш. Рафаэль Мостафин үз китабында бу мәсьәләгә тәфсилләп туктала. Шагыйрь иҗатын рус телендә яңгыраткан М. Львов, Н. Сидоренко, Р. Моран, Н. Беляев, Р. Кутуй һәм башка тәрҗемәчеләрнең иҗади концепцияләрен һәм эш стильләрен анализлап, бүгенге тәрҗемә эшенең торышы, спецификасы, үсү перспективалары турында кызыклы гына теоретик фикерләр әйтә һәм кайбер практик киңәшләр белән уртаклаша.

Сибгат Хәким — җырчы шагыйрь. Аның сүзләренә язылган йөзләрчә җырлар халык күңелендә ныклы урын алган. Сибгат Хәким — Тукайчы шагыйрь. Бөек Тукай рухына һәм эшенә тугрылыгын раслап, аның турында поэмалар циклы иҗат иткән шагыйрь. Сибгат Хәким — Ленин Татарстаны шагыйре. Ул — «Ленин фәрманы белән», «Язгыгыз, җир уллары», «Дәверләр капкасы» кебек поэмалар, «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Бер горурлык хисе яна миндә» кебек шигырьләр авторы. Сибгат Хәким — фронтовик шагыйрь. «Дуга», «Үрләр аша» поэмалары, «Уналты йорт безнең тыкрыкта», «Белгәннәр тик тора», «Торыгыз, Мусалар!» кебек шигырьләр аның кулы белән язылган. Сибгат Хәким — публицист шагыйрь. Ул — йөзләгән чыгышлар, мәкаләләр, рецензияләр авторы (әле 1979 ел ахырында гына аның әдәби-публицистик мәкаләләрен берләштергән калын бер томлыгы дөнья күрде). Сибгат Хәким — яшь язучыларның (бер язучыларның гынамы әле!) якын дусты һәм киңәшчесе. Сугыштан соңгы еллардан башлап дистәләгән язучылар турыдан-туры аның ярдәме белән әдәбиятка аяк бастылар, иҗади үрләр яуладылар... һәм, ниһаять, Сибгат Хәким — мәшһүр Казан артының илгә игелек күрсәткән данлы бер улы... Кеше һәм иҗатчы буларак, әдипнең күпкырлы эшчәнлеге Рафаэль Мостафин монографиясендә шактый тулы күрсәтелгән. Тәнкыйтьче Сибгат Хәким иҗатын татар әдәбиятының бер казанышы итеп кенә карамый, ә күпмилләтле совет әдәбиятының органик бер өлеше итеп күрсәтә. Дөресе дә шул: шагыйрь иҗаты — милли бизәкле, интернациональ эчтәлекле бай иҗат.

Рафаэль Мостафин бу китабында шагыйрьнең иҗат лабораториясе серләрен дә беркадәр ачып күрсәтергә тырышкан. «Шигырьләр ничек туа?» дигән бүлектә шагыйрьнең укучыларга киң мәгълүм шигырьләреннән «Тәрәзә рамнары», «Фәрхинур», «Рамазан» шигырьләренең язылу тарихын бәян итә. һәр шигырь артында конкрет кешеләр, конкрет язмышлар тора икән бит! Кайберләренең исемнәре дә шул көе үзгәртелмичә шигырь тукымасына кереп киткән. Гомумән, Р. Мостафин шагыйрь иҗатының төп этапларын билгели торган байтак әсәрләргә җентекле анализ ясый. Шулай да, шагыйрь иҗатында әһәмиятле урын тоткан кайбер әсәрләр автор игътибарыннан беркадәр читтә калганнар. Әйтик, «Бакчачылар», «Дала җыры» кебек башлангыч чор әсәрләренә шактый урын бирелеп тә, атаклы «Кырыгынчы бүлмә» турында бер сүз дә диярлек әйтелмәве аңлашылып бетми. Ихтимал, кайбер әсәрләрне шагыйрь замандашларының (мәсәлән, Ф. Кәрим, М. Җәлил, Х. Туфан, Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис h. б.) шул ук темага яки шуңа якынрак темага язылган әсәрләре белән чагыштыру нисбәтендә анализлап караганда да кызыксыз булмас иде. Гомум әдәби процесс фонында шагыйрьнең уңышлы һәм кимчелекле яклары ачыграк күренер иде. Шулай ук, кайбер шигырьләргә аңлатма биргәндә урыны-урыны белән нечкә поэтик тоемның да җитенкерәп бетмәве сизелгәли... Әлбәттә, үзең эшләүгә караганда, кеше хезмәтен бәяләү җиңелрәк. Хезмәт белән танышкач тагын бүтән фикерләр дә уянмады түгел. Алары китапны тагын да яхшырак күрү теләгеннән иде. Ә без хәзергә булганын тәкъдир итә белик. Мәскәүдә беренче тапкыр исән татар язучысы турында төпле монография чыкты. Бу — шатлыклы вакыйга.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН.**

## Роберт Миңнуллин

### Йолдызлар

Бардык та кичә балыкка,
Елгада таң аттырдык.
Тик без балык каптырмадык,
Без йолдызлар каптырдык.

Йолдызлары шундый эре!
Кимендә менә мондый.
Күрсәгез, күрер идегез —
Чуртан да андый булмый.

Без тоткан йолдызлар белән
Зу-ур чиләк тулган иде,
Чиләгебез йолдыз белән
Чүмәкәй булган иде.

Тик йолдызлар иртә белән
Качканнар да беткәннәр.
Хәйләкәрләр — качар өчен
Таңны гына көткәннәр.

Алар бер дә юкка гына
Качкан ла күгебезгә.
Без җибәргән була идек
Аларны үзебез дә!

### Саныйлар

Җыелганнар утыргычка
Гөлнарлар, Саниялар.
Мактаныша-мактаныша
Нәрсәдер саный алар.

— Синең ничәү?
— Минем бишәү!
— Дүртәү генә минеке.
— Ә минем авызда — ике,
Ә кесәмдә — унике.

— Ә мин кичә энем белән
Егермене ашадым.
— Ә мин бүген берүземә
Унынчыны башладым...

Баксаң, кызлар көн дә шулай
Бәйрәм ясыйлар икән:
Алар шулай саный-саный
Кәнфит ашыйлар икән.

Бер ел үскән.
Утыргычта —
Гөлнарлар, Саниялар.
Әле булса, мактанышып
Нәрсәдер саный алар.

— Минем әле унөч калды,
Кызыкмыйм артыгына.
— Ә минеке унбер әле,
Тик берсе ярты гына.

— Ә минеке берәү дә юк,
Нишлим инде, жәл дә соң,
Жәл булса да, жәлли-жәлли
Суырдылар һәммәсен...

Баксаң, мактана-мактана,
Калдырып бар эшләрен,
Кызлар шулай саный икән
Исән калган тешләрен.

## Боек үгез

Утарда яши үгез,
Беркемгә дәшми үгез.

Ул дөньяга ачулы,
Кетә капка ачуны,
Тизрәк чыгып качуны.

Басып тора ул оеп,
Ул — күңелсез, ул — боек.

Мөгезләргә эш тә юк,
Эш булмагач, көч тә юк.

Үгезгә мәзәк түгел —
Мондый тормыш үгезгә
Бөтенләй хаҗәт түгел.

Болай ул беркемгә дә
Күрсәтә алмый көчен —
Боек ул
Шуның өчен!

## Алмаш-тилмәш

Күрегез Алмазны! —
Мактанып, шатланып
Ве-ло-си-пе-ды-на
Бара ул атланып.

Тормый ул вакланып,
Утырмый сакланып...

Ай... руле шул мәлне
Аз гына борылды,
Алдагы коймага
Барып та орылды.

Чәчрәде очкыннар
Алмазның күзеннән,
Ә велосипедның
Чылбыры өзелгән.

Ә тәгәрмәчләре
Кыйшайган, тишелгән.
Алмазның аягы
Калайга киселгән...

Әй, юлчы иптәшләр!
Йөрегез сакланып,
Тормагыз таптанып,
Тормагыз! Югыйсә,
Калырсыз тапталып —
Ве-ло-си-пед килә
Алмазга атланып.

## Белә икән

Олымы ул, кечеме ул,
Сөйләшсә дә кем белән,
Бөтен белгәне Айратның:
«Мин беләм дә мин беләм».

Малайлар бергә җыелып
Сөйләшсәләр берәрни,
Тыңламый да, әйтә Айрат:
— Беләм инде, беләм, — ди. —

Миңа акыл өйрәтмәгез,
Тыңларга да теләмим,
Сез күргәнне, сез белгәнне
Әллә кайчан беләм мин!

— Ни беләсең, Айрат? — дибез.
— Барысын да беләм, — ди.
— Берни белмисең бит, — дибез,
— Анысын да беләм, — ди.

## Арыган

Хәлим бүген өйләренә
Кайтып керде кичкә генә.
Кайтып керде аякларын
Сөйри-сөйри көчкә генә.

Керегезче, күрегезче:
Ул бөтенләй хәлдән тайган.
Арыганын, алҗыганын
Белеп була әллә кайдан.

Әйтерсең лә, көне буе
Күмер чапкан ул шахтада.
Әйтерсең лә, көне буе
Басып торган ул вахтада.

Әйтерсең лә, көне буе
Су ташыган чишмәдән ул.
Әйтерсең лә, утын ярган,
Әллә ниләр эшләгән ул...

Эшләмәсә, егет кеше
Шушы кадәр арыймы соң?
Кечкенә килеш шул кадәр
Эш эшләргә ярыймы соң?

Арымас иде дә Хәлим,
Яман эшкә тарыган ул:
Эшләгәнгә арымаган,
Эшсезлектән арыган ул!

# КОЯШЛЫ ГӨРЛӘВЕКЛӘР

*Мәгъсүм Хуҗинга 50 яшь*



Аңа кешеләрнең сукмагы өзелми. Бигрәк тә яшьләр күп килә. Яшьләрнең чын дусты, фикердәше ул. Аның белән теләсә нинди темага рәхәтләнеп сөйләшергә мөмкин. Дөнья, ил, республика хәбәрләре кирәкме сиңа, фән-техника, спорт, әдәбият-сәнгать яңалыкларымы — ул барысыннан да хәбәрдар, барысын да энәсеннән җебенә кадәр белә.

Тормыш юлы — катлаулы сугыш елларының бөтен кыенлыгын үз җилкәсендә татып, авылда үтә. Университет тәмамлагач, Казанда, аннары Казагыстанда яшьләр газеталарында эшли. Менә инде ун елга якын «Чаян» журналы редакциясендә җаваплы секретарь. Журналы шаян булса да, хезмәте җитди.

Беренче хикәяләре илленче еллар ахырында «Идел» альманахында басыла. Дүрт-биш хикәя китабы авторы. Хикәя жанрының авырлыгын тоеп, төмен белеп иҗат итә.

Иҗатка җан ятмаган, кул бармаган көннәрендә аны еш кына шахмат клубында очратасың. Кыш уртасында җәһәннәм артындагы урман-кырларны гизеп йөрергә яисә Идел бозы өстендә балыкчы романтикасына бирелеп утырырга ярата ул, табигать белән бер үзе күзгә-күз калырга ярата. Әтисе Хәмит абый җирне яшелләндерүгә күп көч куйган хөрмәтле кеше — бөтен тирә-юньгә танылган бакчачы. Улының табигатьне авыл малайларыча эчтән генә сызып яратуы, бәлки, шуннан киләдер. Табигать турында уйланулары, сөенүләре, борчылулары аның хикәяләренә дә кояшлы гөрләвек булып агып керә.

Мәгъсүм Хуҗин геройлары табигатькә, җиргә, игенче хезмәтенә, авыл мохитенә җаны-тәне белән гашыйк кешеләр.

Аның геройлары аз сүзле, ләкин алар җылы, ягымлы сүзләрен дөньядагы тереклек ияләренең һәркайсына җиткерергә, табигать иркәләренең һәрберсенә тигез итеп өләшергә тырышалар. Алар үзләренә кыенлык килгән чакларда да шәхси ихтыяҗлардан, шәхси борчулардан өстен була беләләр.

Мәгъсүм Хуҗин хикәяләрен укыганда без гадел, самими, эчкерсез кешеләр белән очрашабыз, аларның уй-фикерләрен, кылган эшләрен хуплыйбыз, үзебез дә сизмәстән, аларның тынгысыз матур тормышы белән яши башлыйбыз.

Ул — хикәя жанрына иң турылыклы язучыларыбызның берсе. Аның хикәяләре елдан-ел җыйнаклана, камилләшә, рухи-психологик яктан тирәнәя бара. Бу сыйфатлар

исә аның геройларын, әдәби образ буларак, тагын да җанландыралар, тагын да калкурак итеп күрсәтәләр. Геройларын гына түгел, көмеш тояклары белән җир клавишларына басып матур көй чыгаручы ак колыннарны, йөнтәс маэмайларны, кешеләргә мәңгелек дуслык теләгәндәй, җитәкләшеп үскән талларны, моңсу иген кырларын, уйга чумган тауларны, җыр матурлыгына дан җырлап челтерәгән төнге суларны да җанлы, самими итеп якты төсләр белән сурәтли белә автор.

Кайчагында таң алдыннан кешене авылның әллә кайсы очында гына ишетелеп киткән гармун моңы сискәндереп уята. Елыйсыңны да китерә ул моң, шатландыра да. Син аның якынайганын көтәсең. Ләкин ул якынаймый, таң җилләренә ияреп еракларга китә. Тик синең күңелеңдә гармун моңы кузгаткан дулкын югалмый, күтәрелә, үсә. Ул дулкын, гармун моңын еракларга алып киткән таң җиле кебек, сине татлы хатирәләргә, яшьлеккә алып китә.

Мәгъсүм Хуҗин хикәяләрен укыганда да күңелдә нәкъ әнә шундый дулкын кузгала, таң җилләренең йомшак сулышын тоеп, яшьлек урамнарында йөргәндәй буласың.

**Фаил ШӘФИГУЛЛИН.**



*Балалар язучысы Резеда Вәлиевага май аенда 50 яшь тулды. Ул Башкортстанның Кыйгы районы Дүшәнбикә авылында туып үсә, шунда урта мәктәп тәмамлый.*

*Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, Татарстан китап нәшриятында яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә эшли башлый. Бүген дә ул анда шигырь һәм проза китаплары редакцияли, тәрҗемә эше белән шөгыльләнә.*

*Резеда Вәлиева нәниләргә һәм яшүсмерләргә атап күп санлы шигырь, поэма китаплары бастырып чыгарды: «Минем дусларым» (1960), «Нәниләргә бүләк» (1965), «Якты йолдызым» (1968), «Зәңгәр алан әкияте» (1971), «Батырлык турында җыр» (1974), «Әниемә бүләгем» (1978) һ. б.*

*Бу санда укучыларыбызга аның яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

# Резеда Вәлиева

## Ленин туган көн

Зәңгәр-зәңгәр су өстеннән
Көмеш бозлар аккан чакта,
Ерак-ерак юллар гизеп
Кошлар илгә кайткан чакта,
Куе кара болытларны
Ярсу җилләр таратканда,

Төн карасын ярып җирдә
Якты-аяз таң аткандай,
Килде ул көн. Балкып килде,
Кояш көлде, дөнья көлде.
Шаян җилләр ашыга-ашыга
Тупылларга чуклар элде.
Умырзая чәчәкләре
Елмаешып уяндылар.
Яшь бөреләр, бәбкәләрдәй,
Талпынышып куандылар.
Җырчы кошлар, горур сайрап,
Шатлык хәбәр итте илгә.
Ул көн —
Мәңге сүнмәс Кояш —
Даһи Ленин килде җиргә!..

## Бишек җыры

Кояш ятты бишегенә,
Күзләрен йомды.
Кошлар да сайрамый инде.
Чишмәләр тынды.
Яфраклар да серләшмиләр,
Йоклады каен.
... Без дә йоклыйк,
Бәү-бәү итик,
Улым, улкаем...

Песиең дә арыды әнә,
Боегып калды.
Башын салып тәпиенә,
Йокыга талды.
Аюыңа борынын төртеп
Йоклый аткаең...
Без дә йоклыйк,
Бәү-бәү итик,
Улым, улкаем...

Зәңгәр болытлар артыннан
Ай карый көлеп.
Малайларым нишли анда,
Йоклыймы? — диеп.
Әкрен басып йокы бабай
Йөри өй саен...
Әйдә йоклыйк,
Бәү-бәү итик,
Улым, улкаем...

# МОҢ ЧИШМӘЛӘРЕН ЭЗЛӘГӘНДӘ

*Мәхмүт Нигъмәтҗановка 50 яшь*



Бөек Тукай «халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер» дип атаган җыр-көй мирасы мәдәниятыбыз үсешендә аерым урын биләп тора. Милли музыка сәнгатебез тамырлары белән әнә шул нигезгә тоташа. Шуңа күрә халык музыкасы үрнәкләрен җыю, аның бай традицияләрен өйрәнү бүгенге профессиональ сәнгатьнең һәм профессиональ башкару осталыгының да яңа баскычка күтәрелүенә ярдәм итә. Без татар музыка фольклористикасына зур өлеш керткән М. Мозаффаров һәм Җ. Фәйзине аерым бер хөрмәт белән искә алабыз. Бу өлкәдә яңадан-яңа кызыклы сәхифәләр ачылуы талантлы музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов исеме белән дә бәйләнгән.

М. Нигъмәтҗанов—милли музыка фольклористикасындагы аерым нәтиҗәләрне гомумиләштерүгә һәм әлегәчә билгеле булмаган халык моңнарын җыю-өйрәнүгә багышланган киң колачлы фәнни-иҗади эшчәнлеге белән ил күләмендә генә түгел, чит илләрдә дә танылган галим. Аның «Советский композитор» нәшриятында басылып чыккан «Татар халык җырлары» китабы (1970 ел), мәсәлән, «халыкара этномузыкологиягә гаять зур өлеш кертү» дип бәяләнде (ЮНЕСКОның «Studia Musicologica» журналы, № 14, 1972, 455 нче бит).

Мәхмүт Нигъмәтҗановның тормыш һәм иҗат юлын күздән кичергәндә, теләсә нинди кыенлыкларга, очраклылыкларга да карамастан, олы максатына бару юлыннан чигенмәгән кеше язмышы белән очрашасың. Ул Саба районының Олы Арташ авылында туган. Ләкин тормышның беренче сынаулары аны Татарстаннан еракта — әтисе Нигъмәтҗан абзый 16 яшеннән шахтер булып эшли башлаган Донбасс якларында көтеп тора. Бөек Ватан сугышы башлангач, абыйсы белән апасы фронтка китә, озаклямый әниләре дә вафат була. Ялгызы гына калган 12 яшьлек Мәхмүт, фронт сызыгын кичеп, фашистлар вакытлыча басып алган җирләрдән Мәскәүгә кайта. Җиңүне якынайту өчен кулыннан килгәнне башкара: хәрби заводта балта остасы булып эшли, бомба-снарядлар өчен әрҗәләр ясый. Аннан соң яшүсмер егетнең уку, һөнәргә өйрәнү еллары башлана: Донбасста һөнәр училищесын тәмамлый, Юдинодагы тимер юлчылар училищесында машинист ярдәмчесе белгечлеге ала. Сәләтен-зирәклеген күреп һәм киләчәгенә зур өметләр баглап, Мәхмүтне тимер юлчылар техникумына укырга җибәрәләр. Техникумны тәмамлагач, ул Юдинода үзе укыган училищеда яшьләрне паровозчы һөнәренә өйрәтә. Бер үк вакытта белемен-әзерлеген тагын да камилләштерү нияте белән Казан дәүләт университетының математика факультетына читтән то-

рып укырга керә. Намуслы хезмәте белән мастер Нигъмәтҗанов тиз арада хөрмәт казана, шул елларда үзәк журналларның берсендә аның фоторәсеме дә басылып чыга.

Егет кешенең күңелендә йөгәне-ияре белән ат ятар диләр. Скрипка кылларыдай тартылган рельсларга карап уйланганда, поезд тәгәрмәчләренең тынгысыз җырына колак салганда да булачак музыка белгече үзенең алдагы тормыш борылмаларын һәм иҗат үрләрен күз алдына китергәндер төсле.

Биш-алты яшендә үк әтисенең гармунында күзләрдән яшь килерлек итеп моң чыгара алган малай бер генә мизгелгә дә үзен музыкасыз-җырсыз күз алдына китерә алмый. Хәрби госпитальләрдә аккордеоны белән концерт куеп йөргәндә, Казанда һәм Мәскәүдә үзешчән коллективлар белән җитәкчелек итәргә туры килгәндә ул төрле уен коралларында уйнарга өйрәнә, башкару осталыгын арттыра бара, үзе дә вальс, марш, җырлар иҗат итә. Ниһаять, 1953 елда хәлиткеч адым ясала — М. Нигъмәтҗанов Казан дәүләт консерваториясенә укырга кабул ителә. Ул инде студент чагында ук музыка училищесында дәресләр бирә, ә консерваториядә укуын тәмамлагач, профессор Г. И. Литинскийның полифония буенча ассистенты булып кала. Бернич ел Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә художество җитәкчесе булып эшләгәндә дә М. Нигъмәтҗановның фәнни иҗат ялкыны сүрелмәде. Бүгенге көндә ул Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре булып эшли. М. Нигъмәтҗанов 1968 елда ук инде РСФСР Композиторлар союзының идарә әгъзасы, музыка белеме һәм фольклор комиссиясе председателе урынбасары итеп сайланган иде.

Мәхмүт Нигъмәтҗанов — төрле нәшриятларда басылган биш китап һәм күп санлы мәкаләләр авторы. Татарлар яшәгән бик күп төбәкләрдән үзе язып алган материаллар (дүрт меңгә якын җыр-көй үрнәкләре) нигезендә ул халык җыр сәнгатенең жанр һәм стиль үзенчәлекләрен ачты. М. Нигъмәтҗановның эшчәнлегенә күренекле музыка белгечләре Г. И. Литинский, Ю. В. Виноградов һәм Е. В. Гиппиус һәрвакыт игътибарлы булдылар һәм бик югары бәя бирделәр.

Тулаем алганда, М. Нигъмәтҗанов хезмәтләрен халык моңнары энциклопедиясе дип атарга мөмкин булыр иде. Аларда музыкаль мираска киң һәм тирән мәгълүматлы караш белән очрашасың. Ул еш кына иҗатның актуаль проблемаларын беренче булып күтәрә һәм аларны чишү юлларын күрсәтә. Галим халкыбыз тарихын, көнкүрешен, гореф-гадәтләрен тирәнтен белә, фәннең башка өлкәләре һәм башка халыклар сәнгате белән бәйләнеш традицияләренә, бүгенге музыка белеме казанышларына таянып эшли.

М. Нигъмәтҗановның матбугатта чыккан хезмәтләре, халыкара киңәшмәләрдә, РСФСР Композиторлар союзы съездларында һәм пленумнарында ясаган чыгышлары музыкаль җәмәгатьчелектә һәрвакыт җитди кызыксыну уята, милли музыка сәнгатебезнең үсешенә тәэсир ясый. Иҗат эшенә бөтен ихласы белән бирелгән, халкыбызның моң чишмәләрен эзләүдә ару-талуны белмәүче галимнең юлы уң булсын!

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ.**

Ислам Әхмәтҗанов

# ЯШЬЛЕК ҺӘМ ШИГЪРИЯТ ЮЛДАШЫ

*«Татарстан яшьләре» газетасының 60 еллыгына*

Халык җырларында һәм әкиятләрендә шундый бер матур шигъри деталь бар: ерак-ераклардан очкан кошларның канатында кешеләргә шатлыклы хәбәр килә. Күңелләр белән күңелләр сөйләшә, өзелгән җепләр ялгана...

Кешеләрнең күктәге хыялы күптәннән инде җиргә төште. Аккошларның ак канатларына түгел, ә ак кәгазьгә язылган хәбәрләр көн саен безгә «очып килә» һәм күңелебезне күтәрә, рухыбызга байлык өсти, яшәешебезне ямьли, җир шарының барлык төбәкләре белән бәйләнешкә кертә. Ул «ак канатлар»ның берсе—күптән түгел үзенең алтмыш еллык бәйрәмен билгеләп үткән «Татарстан яшьләре» газетасы.

Вакытлар җиленең сары төсе иңгән сәхифәләр безне ерак елларга, онытылмас көннәргә—1920 елның 22 январена илтә. Ул көнне Казан шәһәрендә татар коммунистик яшьләренең «Кызыл яшьләр» исемендәге беренче газетасы дөнья күрә. Редакцион мәкаләдә без мондый юллар укыйбыз: «... бу газетабыз яшьләр өчен, яшь көчләрнең сүзен сөйли. Яшьләрчә уйлый торган, яшь буын файдасын гына күзәтүче буларак...» Шунда ук мондый сүзләргә дә тап булабыз: «Газетабыз бәлки кимчелекле булыр. Бәлки аны алып бару да башта бик авыр күренер. Ләкин без инде башлаган эшебезне дәвам иттерергә тәвәккәлләдек».

«Татарстан яшьләре» — республикабыз комсомолының данлы елъязмасындагы бер кызыл юл, берничә буын яшьләренең тормышында якты эз калдырган газета ул.

Якты идеаллар өчен барган канлы көрәшләрдә, беренче зур төзелеш мәйданнарында, яңа гына оешкан колхоз кырларында — һәр җирдә газета яшьләрнең якын дустына, көрәштәшенә әйләнә. Беренче хәбәрчеләр дә — яңа тормыш төзүче яшьләр. Алар үзләрен борчыган сорауларга җавап эзләп хәбәрләр, үтенечләр, җырлар, шигырьләр язганнар. Газета беренче еллардан ук әдәбият ярдәмендә яңа кеше тәрбияләү мәсьәләсен үзәккә куя һәм бу традицияне әле дә уңышлы дәвам иттерә.

Матбугат һәм әдәбият. «Татарстан яшьләре» газетасы үткән юлга гына күз салсак та, әлеге ике төшенчәнең бер-берсе белән өзелмәс бәйләнештә яшәвен күрербез. Матбугат — каләм осталары өчен киң мәйдан гына түгел, ә аларны халык күңеленә якынайта торган рухи күпер дә. Әдәбиятның матбугаттан башка үсүен күзаллавы читен. Алай гына да түгел, матбугатның хасияте шунда ки, ул әдәбият-сәнгатьнең үсешенә турыдан-туры йогынты ясый.

1924—1925 елларда «Кызыл яшьләр»нең җаваплы секретаре булып эшләгән шагыйрә Зәйнәп Бәширова үзенең истәлекләрендә газетаның шул чордагы иҗади тормышын болай сурәтли: «...Яшь хәбәрчеләр арасыннан туып килә торган әдәби көчләрнең үсүенә «Кызыл яшьләр» газеты киң юл ачты. Октябрь дулкыннары белән, татар кызлары арасыннан күтәрелеп чыгып шигырьләр яза башлаганда (1920 елларны) мин үзем дә партиянең, комсомолның, «Кызыл яшьләр» редакциясенең кайгыртучанлыгын сиздем. Эшче, крестьян яшьләреннән яңа яза башлаган каләм көчләренә газетта күбрәк урын бирү өчен 1925 елны «Кызыл яшьләр» газетасында әдәбият сәхифәсе оештырылды. Толымбай, Шәһәретдинов һәм Нур Баян кебек язучыларның беренче әсәрләре шушында басылды». Шагыйрә бу әдәбият сәхифәсендә үз иҗатлары белән катнашкан 15 яшьлек егет, ә хәзер танылган галим, профессор Хатип Госманны, «Кызыл яшьләр» газетасында хәбәрче буларак та, балалар язу-

чысы буларак та эшләп йөргән Муса Җәлилне зурлап искә төшерә.

1926—1927 елларда «Кызыл яшьләр» газетасының хәбәрчеләре 600 кешегә җитә. Шул хәбәрчеләр арасыннан әдәбиятыбызның яңа буынын тәшкил иткән дистәләрчә каләм осталары—язучылар, шагыйрьләр, драматурглар, тәнкыйтьчеләр үсеп чыга. Күбесенең иҗат биографияләре турыдан-туры «Кызыл яшьләр» газетасыннан башлана.

Бу уңайдан герой-шагыйрь Муса Җәлилнең батыр көрәштәше, күренекле балалар язучысы Абдулла Алишны горурлык белән искә алып китми мөмкин түгел. Аның исеме газета битләрендә 1929—30 нчы елларда күренә башлый. Казан төзүчеләр техникумы студенты Абдулла Алиш газетаның иң якын дусты була. Хәбәрләр, мәкаләләр, очерклар, шигырьләр, хикәяләр яза. Шунда чыныгу ала, комсомол язучысы булып җитлегә, шул чорда оештырылган «әдәби походларда» актив катнаша. «Кызыл яшьләр»нең 1930 елгы 8 нче февраль санында аның «Яңа илгә яңа җырлар кирәк» дигән ялкынлы мәкаләсе басыла. Социализм төзүче яшьләргә яңа җырлар кирәклеген бик вакытлы күтәргән бу чакыруны хуплап, редакциягә йөзләрчә хатлар, тәкъдимнәр килә. Аларны яшьләр үзләре яза. Бу хатлар газета битләрендә басыла. Алиш чакыруын кайнар хуплаучылар арасында яшь композитор Җәүдәт Фәйзи дә була. Ул «Яңа җырлар турында миңа да сүз бирегез» дигән мәкаләсендә: «Алиш иптәш кузгаткан фикер, әлбәттә, бик урынлы. Без матур әдәбият белән эшче-крестьянның аңын социализм төзүгә юнәлдерсәк, халык җырлары белән дә шул ук халыкны тәрбияләргә омтылырга тиешбез»,—дип яза («Кызыл яшьләр», 4 март, 1930 ел), һәм яшь композитор газетаның 10 еллык юбилеена «Кызыл яшьләр маршы»н иҗат итә. Алишның чакыруы нәтиҗәле була. Газетада яңа җырлар басыла башлый. Алиш башлап җибәргән бу традиция бүген дә дәвам итә.

Абдулла Алишның соңгы язмасы «Татарстан яшьләре»нең 1941 ел, 22 июнь санында басыла. Без кайнар йөрәкле хәбәрчебез рухын изге итеп саклыйбыз.

1926 елларда егерме яшьлек Габдрахман Минский газетаның үз хезмәткәре буларак та, әдәби иҗаты белән дә газетаның үсүенә, көч туплавына матур өлеш кертә. Журналист хезмәте аңа иҗатының киңлеген арттырырга, заманча яңгырашын көчәйтергә ярдәм итә. Шул чордагы күп кенә яшь язучыларның тырышлыгы белән «Кызыл яшьләр» газетасы «чор көзгесе»нә әйләнә.

Бу елларда «Кызыл яшьләр» газетасындагы материалларның төп темасы — авыр индустрияне аякка бастыру, бик кишәрлекләргә бүленгән җирләрне эре күмәк хуҗалыкларга берләштерү, Кызыл Армияне ныгытуга яшьләрне тарту. Ул индустрияләшү файдасына кызыл өмәләр үткәрү, яңа төзелешләр фондына акча җыеп тапшыруны пропагандалый. 1930 елның 28 сентябрь санында газетада менә шундый хәбәр басылып чыга: «Правда» исемендәге һава корабы файдасына 6 сум кертеп, яшь язучылардан түбәндәге иптәшләрне ярышка чакырабыз: Мирсәй Әмир, Түрәй, Әсфәндияров, Сафа Әюп, Ф. Кәрим, Ф. Мөсәгыйть, Т. Теләш, Х. Туфан, Т. Госманов, Мостафин, Җәүдәт Фәйзи, Демьян Фәтхи, Нигъмәш Булат.

И. Гази+Н. Баян».

Озак та үтми, Ф. Кәримнең шигырь белән язылган «Дирижабльгә» исемле җавабы күренә:

**«Чакыруыгызга җавап итеп**
**5 сум кертәм, Баян һәм Гази,**
**Тиңләшергә чакырам:**
**Әсма Мөслимова,**
**Земтехникум—Хөсәен Гыймади,**
**Ләбиб Гыйльми, Н. Абдраин,**
**ВПИдән иптәш Г. Кәлим,**
**«Кызыл яшьләр» аша җавап бирегез,**
**Сездән җавап көтеп:**
**Ф.Кәрим».**

«Кызыл яшьләр» газетасының чыга башлавына 10 ел тулуны республика җәмәгатьчелеге киң билгеләп үтә. Юбилей көннәрендә газета укучылар белән әдәби очрашулар һәм конференцияләр оештырыла. Нур Баян газета юбилеена үзенең «Сәлам!» дигән шигырен багышлый.

**...Җырлыйсы күп,**
**Җырлыйм**
**һәм җырлармын,**
**Җыр постында һаман каламын,—**

дип яза ул газетага мөрәҗәгать итеп.

«Әдәбият сәхифәсе»ндә шул чордагы яшь язучылардан Ибраһим Гази, Фатих Кәрим, Әсгать Айдар, Әмирхан Еники, Гадел Кутуй, Фатих Хөсни, Мирсәй Әмир һәм башкаларның беренче әсәрләре басылып чыга. Алар иҗатының беренче авазлары халыкка «Кызыл яшьләр» аша барып ирешә. Әдәбиятыбызның алтын фондына кергән иҗатларның чишмә башы әнә кайдан башланган.

Бу елларда тарихта күрелмәгән эшләр башкарыла. Интервентлар һәм акгвардиячеләр белән канлы сугышларда җиңеп чыккан халкыбыз социалистик төзелеш алып бара: культура революциясе зур казанышлар яулый, авылны күмәк хуҗалык нигезенә күчерү тәгәлләнә, индустрияләштерү киң колач ала.

Әле егерменче елларның башында ук Алексей Толстой:

«Герой! Безгә безнең заманның герое кирәк»,— дип күтәреп чыга. Яңа җәмгыятьнең иҗат итү чынбарлыгы тормышның һәр өлкәсендә яңа геройлар тудыра. Яшьләр матбугаты ул геройларны таба, күтәреп ала.

Язучылар — хәбәрчеләр дә, комсомол работниклары да булалар. Яңа җәмгыятьнең яңа тип журналистлары үсә. Нәкъ менә алар совет әдәбияты алдына куелган үзәк бурычны — яңа совет кешесе образын иҗат итүне төп эшләре итеп саныйлар. Аларның тормышка разведкасы ВЛКСМ өлкә комитеты фәрманы белән яшьләр матбугаты аша оештырыла. Очерклардан, мәкаләләр-

дән, агитацион шигырьләрдән башлаган авторлар бу елларда ук татар совет әдәбиятының өметле каләмнәренә, соңрак төп көчләренә әвереләләр. «Татарстан яшьләре» яшь язучыларның социалистик реализм методын үзләштереп иҗат итүенә ирешүдә зур тәрбия эше башкара. Әдәбият тарихын тикшеренүчеләр өчен «Яшьләр матбугаты һәм татар совет әдәбиятының формалашуы» дигән — әле ачыласы зур бер сәхифә ул.

Әдәбият сәхифәләре дәвам итә. Буыннан-буынга күчкән бу дәвамлылык бик күп язучы, шагыйрьләрнең иҗатларын иңләп, аларны укучы күңеленә түкми-чәчми тапшырып килгән. Бөек Ватан сугышыннан соң «Яшь сталинчы» исеме белән яңадан чыга башлаган газетаның редакторы булып күкрәгенә орден-медальләр тагып яу кырыннан кайткан шагыйрь Гали Хуҗиев эшли. Киемнәреннән дары исе дә бетеп өлгермәгән, Белоруссия партизаннары сафында авыр походларны батырларча узган шагыйрь Зәки Нури, илебез киңлекләрен япон самурайларыннан саклауда үзен батыр комсомолец-солдат итеп таныткан Әдип Маликов һ. б. лар газетаның яңадан ныклап аякка басуы өчен фронттагы кебек көрәшәләр.

Шәрәф Мөдәррис, Гамир Насрый, Газиз Мөхәммәтшин, Рәшит Гәрәй, Шамил Рәкыйпов, Барлас Камалов кебек язучылар һәм шагыйрьләрнең яшьләр газетасында эшләүләре, аның иҗади һәм рухи көчен арттыру өстендә күп көч куюлары нәтиҗәсендә сугыш елларында тукталып торган газета яңадан туды, үсте, сугышчанлыкка иреште. Газета белән бергә югарыда телгә алынган һәм язышып торган башка яшь каләм ияләренең үз иҗатлары да тамыр җәйде. Шагыйрь Әдип Маликов редакциядә эшләгән елларны искә алып болай дип язды:

«...Комсомол газетасында эшләгән еллар иҗатым өчен бай материал бирде. Үземне мин, армиядәге сыман, һаман разведкада, тормышның алгы сызыгында итеп сизә идем».

Бу сүзләре белән Әдип Маликов шул чорда ныклап иҗат итә башлаган каләмдәшләренең уртак фикерен әйтә.

**Үз гомереңдә күпме бөркетләрне**
**Өйрәткәнсең ерак очарга...**
**Тугры юлдаш, сердәш, рухи азык**
**Булгансыңдыр күпме дусларга!**
**Иптәш итеп сине тыйнак Муса**
**Ишегеңне шакып кергәндер.**
**Яшен булып янган Муса җырын**
**Газинурлар ятлап йөргәндер,**

— дип язган иде шагыйрь Рәшит Гәрәй «Татарстан яшьләре» газетасына багышланган шигырендә.

«Әдәбият-сәнгать» сәхифәләре бүген дә газетада даими урын били. Элеккеге күркәм традицияләр яңа эчтәлек белән баеый. Хәзер дә яшь язучыларның беренче әсәрләренә «Татарстан яшьләре» газетасы фатиха бирә, алар биредә беренче китапларына тәнкыйть һәм киңәш сүзе ишетәләр. Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, Равил Фәйзуллин, Шамил Маннапов, Мөдәррис Әгъләмов, Фәннур Сафин, Роберт Миңнуллин кебек инде укучыларга яхшы таныш шагыйрьләр, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев, прозаик Әхәт Гаффар һәм башкаларның иҗаты даими рәвештә яшьләр газетасы битләрендә күренә барып, әдәбият сөючеләрнең игътибарын җәлеп итте.

Остазлар—яшьләргә терәк. Бу «Татарстан яшьләре» битләрендә бигрәк тә ачык чагыла. Танылган каләм осталарының яшьләр иҗаты турында кайгыртып язган мәкаләләре, киңәшләре әледән-әле газетада басылып тора. Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Гомәр Бәширов һәм башка остазларның сүзен яшьләр өчен җәй башында яуган шифалы яңгыр белән чагыштырасы килә. «Хәзер әдәбиятка яшьләр бик кирәк. Чөнки һәр чорның үз язучылары, үз авторлары була. Мәсәлән, безнең буын язучысы гражданнар сугышы, колхозлашу, Бөек Ватан сугышы, сугыштан соңгы чор турында язды. Ул инде бүгенге көн турында яза алмаска да мөмкин. Бүгенге тормышның матурлыгын яшьтән күреп, аңлап, тоеп үскән яшь кеше каләме кирәк монда. Мин мәйданга әнә шундый яшьләр чыгуын көтәм»,—дип язды Гомәр ага Бәширов яшьләргә мөрәҗәгать итеп. Бик күп яшь авторлар моны тирәнтен аңлап иҗат итteләр.

Яшьләр үз казаннарында гына кайнамыйча, илебезнең күпмилләтле әдәбиятындагы иң яхшы әсәрләрне туган телебезгә тәрҗемә итүдә дә актив эшлиләр. Ул тәрҗемәләрнең иң уңышлылары «Нинди иркен минем туган илем» дигән рубрика белән газетабыз битләрендә басыла килә.

«Татарстан яшьләре»нә 60 яшь.

Моннан алтмыш ел элек чыга башлаган әдәбият сәхифәләренең лаеклы варисы булып, бүген редакция каршында «Яшьлек» әдәби берләшмәсе эшләп килә. Берләшмә эшендә инде беренче китапларын бастырып чыгарган яшьләр белән бергә, кулларына яңа гына каләм алган яшь иҗатчылар—студентлар, эшчеләр, хезмәткәрләр һәм башка бик күп һөнәр ияләре катнаша. Аларның иң уңышлы иҗат җимешләре безнең әдәби сәхифәләрдә дөнья күрә. Газета Зиннур Мансуров, Рашат Низамиев, Харрас Әюпов, Мөдәррис Вәлиев, Ркаил Зәйдуллин һәм бүтән яшьләрнең иҗатлары тирәнрәк, саллырак булуына ярдәм итә. «Яшьлек» әдәби берләшмәсе утырышларына күренекле каләм осталары килеп, үзләренең бай иҗат тәҗрибәләре белән уртаклашалар, яшьләргә киңәш бирәләр. Шагыйрьләр Нури ага Арсланов һәм Әхсән Баянов белән әнә шундый иҗади очрашулар аеруча хәтердә калды.

Республикабыз районнарында эшләп килүче әдәби берләшмәләр белән иҗади элемтәдә тору шулай ук газетаның матур традициясенә әйләнде. Әдәби берләшмәләр эшчәнлеген газета битләрендә яктырту, алар белән иҗади дуслыкта яшәү үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә, яшь иҗат көчләре безнең даими авторларыбызга әйләнәләр, әдәбият мәйданына юл алалар.

«Яшьлек» әдәби берләшмәсе—утлы елларда туган әдәбият сәхифәләренең лаеклы дәвамчысы, 60 яшьлек «Татарстан яшьләре»нең бүгенге яшьлеге ул.

### ФӘННИ-ТЕОРЕТИК КОНФЕРЕНЦИЯ

КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында В. И. Ленинның тууына 110 ел тулуга багышлап республиканың фәнни-теоретик конференциясе уздырылды.

Конференцияне КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ачты.

В. И. Ленин тормышының һәм эшчәнлегенең Казан чорына, аның тарих, политик-экономия, философия өлкәсендәге фәнни хезмәтләренә багышланган докладлар белән фән докторлары, профессорлар Р. И. Нәфиков, И. М. Ионенко, К. Ф. Фасеев, фән кандидатлары С. М. Михайлова, А. Г. Гузняев һәм В. Н. Комаров чыктылар.

### «ЗУР ИДЕЛ-80»

Казанда Татарстан Художниклар союзының яңа төзелгән Күргәзмә залында «Зур Идел» зона күргәзмәсе ачылды. Бу күргәзмәгә әзерлек биш ел дәвамында барды. Мари, Татарстан, Удмуртия, Чувашия автономияле республикалары, Астрахань, Волгоград, Горький, Куйбышев, Саратов, Ульяновск өлкәләре сынлы сәнгать осталары анда күрсәтү өчен иң уңышлы әсәрләрен тәкъдим иттеләр. Бу әсәрләрдә алар совет кешеләренең революцион традицияләргә бай үткәнен, сугышта күрсәткән батырлыкларын һәм бүгенге көндәге фидакарь хезмәтен, илебез халыкларының бер семьядай тату, дус яшәвен төрле жанрларда чагылдырдылар. Күргәзмә В. И. Ленинның тууына 110 ел тулу алдыннан ачылуын истә тотып, күренекле художникларыбыз бөек юлбашчының образын мәңгеләштерү юнәлешендә дә күп көч куйдылар.

Зона күргәзмә комитеты барлыгы 584 художникның 1300 әсәрен сайлап алды. Авторлар арасында күпләгән зур күргәзмәләрдә катнашкан тәҗрибәле осталар да, мондый күргәзмәдә беренче генә тапкыр катнашучы яшь рәссамнар да бар. Бу шатлыклы тантананы кереш сүз белән КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ачты.

Республикада гына түгел, ә илебез тормышында иҗтимагый-политик әһәмияткә ия булган бу күргәзмәне ачу алдыннан РСФСР культура министрының беренче урынбасары Е. В. Зайцев, РСФСР Художниклар союзы идарәсе председателе С. П. Ткачев, «Зур Идел» зона күргәзмәсе комитеты председателе Х. А. Якупов һәм күргәзмә залы бинасын төзүчеләр исеменнән 10 нчы төзү-монтаж идарәсе начальнигы И. П. Парамонов чыгыш ясады.

Экспозицияне КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Р. М. Мусин ачты.

Зона күргәзмәсен ачу тантанасында партия өлкә комитеты бюросы членнары, КПСС Үзәк Комитетының культура һәм пропаганда бүлекләре работниклары, Идел буе автономияле республикалары һәм өлкәләре иҗат союзлары вәкилләре, сынлы сәнгать осталары, культура эшлеклеләре, сәнгать сөючеләр катнашты.

Бишенче «Зур Идел» күргәзмәсе 12 майга хәтле эшләячәк.

### ИДЕЛ БУЕ ХУДОЖНИКЛАРЫ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

13 мартта Актерлар йортында V «Зур Идел» зона художество күргәзмәсен ачуда катнашкан Идел буе сынлы сәнгать осталарының иҗат конференциясе булды. Анда күргәзмәгә тәкъдим ителгән әсәрләргә бәя бирелде, зона художниклары алдында торган әһәмиятле бурычлар тикшерелде.

Конференцияне кереш сүз белән РСФСР Художниклар союзы идарәсе председателе, СССР Художество академиясенең действительный члены, РСФСРның халык художнигы С. П. Ткачев ачты.

Экспозициягә куелган сынлы сәнгать, скульптура һәм көнкүреш сәнгате, графика әсәрләре турында «Творчество» журналы баш редакторы Ю. И. Нехорошев, сәнгать фәннәре докторы Н. В. Воронов, Мари АССР Художниклар союзы идарәсе председателе А. С. Бокулевский сөйләделәр.

Конференциядә «Зур Идел» зона күргәзмәсе комитеты председателе, СССР Художество академиясе член-корреспонденты, РСФСРның халык художнигы Х. А. Якупов, РСФСР культура министрының беренче урынбасары Е. В. Зайцев, РСФСР Художниклар союзы идарәсе секретаре, РСФСРның атказанган художнигы И. Л. Бруни, РСФСР Художниклар союзының Куйбышев бүлеге председателе В. М. Пашкевич, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов, художник Б. И. Давыдов (Саратов), сәнгать белгече А. Г. Григорьев (Чувашия) һ. б. чыгыш ясадылар.

Иҗат конференциясендә «Зур Идел» күргәзмәсен оештыру комитеты председателе, КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев катнашты һәм чыгыш ясады.

Конференция эшендә КПСС Үзәк Комитеты инструкторы М. М. Лабузова катнашты.

### КАЛӘМ ОСТАЛАРЫ КИҢӘШӘ

1980 ел илебез тарихында гаять истәлекле булуы белән хәтердә калачак. Быел Ватаныбыз В. И. Ленинның тууына 110 ел, фашистик Германияне җиңүебезгә 35 ел тулуны билгеләп узачак. Татарстан хезмәт ияләре исә туган республиканың 60 еллыгын да бәйрәм итәчәкләр.

Республикабыз Язучылар союзы бу күренекле даталарга хәзерлекне күптән башлады һәм киң план нигезендә алып бара.

Каләм осталары иҗади активлыкларын арттырдылар. Алда — яңа эшләр, яңа чаралар. Юбилейларга багышланган яңа китаплар чыгачак. Күргәзмәләр оештырылачак. Әдәби берләшмә җитәкчеләренең икенче семинары булачак. Актаныште яшь язучыларның зона конференциясе узачак. Әдипләребез «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Татарстан — туган ягым» дигән тематик очрашулар уздырачаклар, «Казан язы» дигән әдәби кичәләр үтәчәк. Фронтовик язучыларның радио һәм телевидение аша чыгышлары булачак. Очерклар һәм публицистика секциясендә хәрби-патриотик темаларга иҗат ителгән әсәрләр тикшереләчәк...

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председатель урынбасары тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин иҗат союзы партоешмасының ачык җыелышында ясаган докладында әнә шулар хакында сөйләде.

Фикер алышуларда язучылардан Б. Камалов, К. Тимбикова, Г. Шәрәфетдинов, «Яшь ленинчы» газетасының җаваплы секретаре С. Ибраһимова, «Ялкын» журналының баш редакторы Р. Хафизова, «Азат хатын» журналының баш редакторы В. Ихсанова катнаштылар.

### ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫ

1980 елның 28 февралендә РСФСР Верховный Советына, ТАССР Верховный Советына, халык депутатларының җирле Советларына сайлаулар булып узды. Халык депутатлары арасында әдәбият һәм сәнгать әһелләре дә бар. Мәсәлән, СССРның халык артисты Нәҗип Җиһанов, Татарстанның халык артисткасы Ирина Хәкимова ТАССР Верховный Советына, драматург Туфан Миңнуллин, ТДАТның баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов, Композиторлар союзы идарәсе председателе Мирсәет Яруллин, Художниклар союзы идарәсе председателе Әнәс Тумашев Казан шәһәр Советына, шагыйрь Роберт Миңнуллин Казан шәһәренең Бауман район Советына, Әлмәт язучылар оешмасы җитәкчесе Әдип Маликов Әлмәт шәһәр Советына депутат итеп сайландылар.

### ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Татарстан Язучылар союзы каршындагы шагыйрьләр секциясенең чираттагы утырышы булды. Анда яшь шагыйрь Нияз Акмалов шигырьләре тикшерелде. Яшь тәнкыйтьче Равил Кукушкин докладыннан соң, фикер алышуларда Хәсән Туфан, Әхмәт Исхак, Илдар Юзеев, Рәдиф Гатауллин, Мөдәррис Әгъләмов, Шамил Маннапов, Әхмәт Рәшитов, Мансур Вәлиев һәм башка иптәшләр катнашты. Алар яшь шагыйрь иҗатына төпле анализ ясадылар, андагы уңай һәм кимчелекле якларны күрсәттеләр.

* * *

Проза һәм очеркистлар секциясенең берләштерелгән утырышында гомумиләштерелгән очерк турында сөйләшү булды. Филология фәннәре кандидаты Ф. Әгъзәмов күпкырлы очерк жанры турында рус һәм татар матбугатына таянып кызыклы доклад ясады.

Фикер алышуларда А. Расих, М. Зарипов, М. Миншин, Ф. Миңнуллин һ. б. катнаштылар.

* * *

Татарстан Язучылар союзы каршындагы тәрҗемәчеләр секциясенең чираттагы утырышы булды. Анда яшь шагыйрь һәм тәрҗемәче Вячеслав Башировның соңгы елларда иҗат ителгән тәрҗемәләре тикшерелде. Утырышта К. Миңлебаев, Т. Журавлев, М. Зарецкий, С. Шәмсетдинов, Э. Блинова катнаштылар. Тәрҗемәләргә анализ ясалды, файдалы киңәшләр бирелде.

* * *

«Казан утлары» журналы каршындагы яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәгенең чираттагы утырышы булды. Утырыш яшь тәнкыйтьчеләр иҗатын тикшерүгә багышланды. Х. Янов, З. Хөснетдинов, Ф. Зөлкарнәев, Х. Хәкимуллина рецензияләренең уңышлы һәм кимчелекле яклары анализланды, әлеге мәкаләләр, төзәтелгәннән һәм тулыландырганнан соң, журналда басарга тәкъдим ителде.

Утырышта тәнкыйтьче, «Идел» альманахы редакторы Мансур Вәлиев һәм редакция хезмәткәрләре катнашты.

### КамАЗДА ТЕАТР КӨННӘРЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының бер төркем артистлары автомобиль төзүчеләр каласы — Чаллыда, «Театрның иҗат яшьләре — КамАЗга» дигән девиз астында, театр көннәре үткәрделәр. Өч көнлек театр бәйрәме вакытында драматург Риза Ишморатның «Тормыш дулкыннары» әсәре буенча куелган яңа спектакль күрсәтелде, шулай ук завод цехларында, төзелеш мәйданнарында, клубларда һәм тулай торакларда очрашулар үткәрелде.

Театр көннәрендә «Тормыш дулкыннары» әсәренең авторы — өлкән драматург Риза Ишморат һәм язучы Рәисә Ишморатова да катнашты.

## ИҖАДИ ДУСЛЫК

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры белән Х. Ямашев исемендәге мех берләшмәсе культура сараеның үзешчән сәнгать коллективы арасындагы иҗади дуслык ныгыганнан-ныгый бара. Профессиональ артистлар белән үзешчәннәр очрашуы һәр ике як өчен дә файдалы уза. Бу юлы да шулай булды. Мехчылар культура сарае каршында эшләүче халык театры коллективы чираттагы очрашуга СССРның халык артисты, РСФСРның К. Станиславский исемендәге, ТАССРның Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Ш. Биктимеровны, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы В. Минкинаны, ТАССРның атказанган артистлары И. Баһманов белән Н. Дунаевны һ. б. артистларны чакырды. Кунаклар театр коллективының шулай ук үзләренең шәхси иҗат планнары турында сөйләделәр, сәхнә осталыгына кагылышлы мәсьәләләр турында үз фикерләре белән уртаклаштылар. Ә соңыннан алар театр сәхнәсендә куелган аерым спектакльләрдән өзекләр уйнап күрсәттеләр.

## ИҖАДИ ПӘНҖЕШӘМБЕЛӘР

Татарстан Композиторлар союзында һәр атнаның дүртенче көнендә иҗади киңәшмәләр һәм очрашулар уздырыла. Мондый иҗади пәнҗешәмбеләрдә, композиторларның иҗатын тагын да активлаштыру максаты белән, күп төрле мәсьәләләр тикшерелә, яңа әсәрләр буенча фикер алышу үткәрелә.

Чираттагы иҗади пәнҗешәмбедә композитор Рәшит Гобәйдуллинның шагыйрь Ренат Харис либреттасына язылган «Ватанана уллары» исемле яңа ораториясе тыңланды. Патриотик рух белән сугарылган бу әсәрне тыңлаучылар яратып кабул иттеләр, ораторияне тагын да камилләштерү теләге белән кайбер киңәшләрен дә белдерделәр.

Бу көнне композитор Бату Мулюковның да ике яңа романсы башкарылды.

Шушы ук пәнҗешәмбедә ТАССРның халык артисткасы, үз иҗаты белән музыкаль җәмәгатьчелектә зур мәхәббәт казанган композитор Сара Садыйкова СССР Композиторлар союзына член итеп алынды.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Мәскәүдә СССР Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау Бөтенсоюз бюросы советының XII пленумы булды. Анда КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карары актылыгында матур әдәбиятны пропагандалау өлкәсендәге бурычлары, В. И. Ленинның тууына 110 ел тулуга һәм Бөек Ватан сугышында җиңүнең 35 еллыгына әзерлек мәсьәләләре тикшерелде. Пленумда Татарстан Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы мөдире Хәкимҗан Халиков, бюро советы председателе Равил Фәйзуллин катнашты.

* * *

7 мартта язучыларның Тукай исемендәге клубында хатын-кыз язучылар белән очрашу кичәсе булды. Кичәдә язучылардан Ләбибә Ихсанова, Рәисә Ишморатова, Лена Шакирҗанова үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Очрашуда катнашкан сәнгать әһелләреннән Сара Садыйкова, Зилә Сөнгатуллина, Хәйдәр Бегичев, Галина Казанцева, Мөнирә Хәбибуллина, Алик Садыйковлар үз һөнәрләрен күрсәттеләр.

Хатын-кызларны котларга кичәгә шагыйрьләр Нәби Дәүли һәм Мөхәммәт Садри да килгән иде.

Кичәне язучы Кояш Тимбикова алып барды.

* * *

Шагыйрьләрдән Рәшит Гәрәй һәм Фәннур Сафин, җырчылар Риф Гатауллин, Клара Хәйретдинова, баянчы Хәйдәр Сафин Балык Бистәсе районы колхозларында һәм мәктәпләрендә әдәби-музыкаль кичәләр уздырдылар. Бу кичәләр В. И. Ленинның тууына 110, Татарстан АССРның төзелүенә 60 ел тулуга багышланган иде.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Оешма утырышында яшь автор Марат Ганиевнең кечкенә күләмле 25 хикәясен эченә алган кулъязмасы тикшерелде. Автор Миңлебай газ эшкәртү заводында слесарь булып эшли. Хикәяләре эшчеләр тормышын чагылдырган вакыйгаларга, детальләргә шактый бай.

Чыгып сөйләүчеләрдән Г. Афзал, Р. Тәхфәтуллин, Ә. Маликов, Азат Ганиев, Фәрит Гыйлметдинов, Роберт Рәкыйпов, Әхтәм Фәтхетдинов һ. б. авторның уңышларын күрсәтү белән бергә, тел өстендә бик нык эшләргә кирәклеген әйтеп үттеләр.

«Әлмәт» әдәбият берләшмәсенең чираттагы утырышында әдәби активлык мәсьәләсе тикшерелде. Язучылар оешмасының җаваплы секретаре Ә. Маликов «Язучының актив тормыш позициясе һәм заманчалык» дигән темага чыгыш ясады. СССР һәм РСФСР Язучылар союзлары пленумында алган тәэсирләре белән уртаклашты. Фикер алышулардан соң яшь авторларның әсәрләре тикшерелде.

Ленин комсомолы исемендәге Миңлебай газ эшкәртү заводы клубында Ленин юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Шагыйрьләрдән Ә. Маликов, Дм. Матвеев, И. Винокуров партиябезгә, республикабызга багышланган яңа шигырьләрен укыдылар. Түбән Мактама китапханәсе мөдире Римма Ильясова чыгышыннан соң, Әлмәт музыка училищесы коллективы көче белән куелган концерт тыңланды.

# БИЛГЕСЕЗ СОЛДАТ

**МӘСГУТ ИМАШЕВ**
музыкасы

**МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ**
шигыре


Без киләбез сиңа җәйләрдә, язларда,
Киләбез сиңа тынлыкны саклап.
Син безнең абый,
Син безнең әти,
Син безнең бабай, билгесез солдат.

Кушымта:

Үлгәннәр далада гөл булып үсәләр,
Үлгәннәр далада җил булып исәләр.
Гөлләрне һәрвакыт сезгә дип җыярбыз.
Җилләрне һәрвакыт сез диеп тоярбыз.

Без киләбез сиңа кышларда, көзләрдә,
Бөек нәселнең дәвамын раслап.
Гөл булып үстең,
Җил булып истең,
Син безгә көчтең, билгесез солдат.

Кушымта.




и сә-ләр Гөл-ләр-не һәр ва-кыт
сез-гә дип җы-яр-быз
Җил-ләр-не һәр ва-кыт
сез ди-еп
Җил-ләр-не һәр ва-кыт сез ди-еп
һәр ва-кыт
Кабатлау өчен
сез-гә дип җы- яр- быз.
Тәмамлау өчен
быз. Сез-гә дип җы- яр-
быз.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

Журналның киләсе айда чыгачак 6 нчы саны тулаем Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасы төзелүнең 60 еллыгына багышлана. Татарстан Министрлар Советы Председателе Гомәр Усмановның беренче битләргә урнаштырылган мәкаләсе укучыны Совет Татарстанының илебез күләмендә тоткан урыны, алтмыш ел эчендә ирешкән уңышлары һәм перспективасы белән таныштыра.

Сез бу айда язучы Гариф Ахуновның яңа әсәрен укый башладыгыз. 6 нчы санда исә «Йолдызлар калка» повестеның дәвамы биреләчәк.

Проза әсәрләреннән тагын язучы Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» исемле повесте басыла башлый. Әсәр укучыны кеше гомеренең мәгънәсе, ата-ана һәм балалар мөнәсәбәте турындагы фәлсәфи уйларга тартыр, мөгаен.

Юбилей санына өлкән буын әдипләребез Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан һәм Фатих Хөсни дә яңа әсәрләре белән катнашалар.

Әдәби тәнкыйть бүлегенә урнаштырылган «Ай үсәсен көн үсеп» исемле мәкаләсендә М. Хәсәнов әдәбиятыбызның үткән юлын, үсеш баскычларын тасвирлый. Бу бүлектә тагын бер кызыклы язма бар: редакция, юбилей уңаеннан, кайбер язучыларыбызга берничә сорау белән мөрәҗәгать иткән иде, әдәбиятыбызның үткәненә һәм бүгенгесенә, үсеш принципларына кагылышлы кыйммәтле фикергә бай җаваплар укучыны да мавыктырыр, мөгаен.

Очерклар һәм публицистика бүлегендә Я. Абдуллинның «Рухи асылыбыз» исемле язмасы, 80 нче елгы Мәскәү Олимпиадасына караган мәкаләләр бар.

«һәр шагыйрьдән бер шигырь», «Бәйрәмгә — дуслар букеты», «Безнең календарь», «Китап күзәтү» рубрикаларына да тирән эчтәлекле, бай фикерле әсәрләр кергән.

Журналның соңгы битләренә, гадәттәгечә, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары теркәлгән.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210